# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Факил САФИН. Гөл җаны. Мәхәббәтнамә. *Сонетлар бәйләме.* ........3

Айдар ХӘЛИМ. Әти-әни, миңа ничә йөз яшь?.. *Балачак хатирәләреннән.* ........7

Мөхәммәт МИРЗА. Адәм баласы. *Бишьюллыклар.* ........81

Равилә ШӘЙДУЛЛИНА-МУРАТ. Тау башында бүре бар. *Роман.* ........86

Оксана ИЛЬЮП. Җан ялганыр төнгә... *Шигырьләр.* ........139

Гөлүсә БАТТАЛОВА. Чыра. *Хикәя.* ........144

ЯҢА ИСЕМНӘР

Гөлара ШӘРИПОВА. Могҗизалар барга ышанам... *Шигырьләр.* *(Рәдиф ГАТАШның кереш сүзе белән).* ........152

Азалия САБИТОВА. 1:1. *Хикәя.* ........156

ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘЛӘРДӘ

Рәмзис ИСМӘГЫЙЛЕВ, Әзһәр ЗӘЙНИ, Нур СИБАГАТУЛЛИН, Айзат СОЛТАНОВ, Зәлидә ЗАРИПОВА, Зөлфия СИРАЕВА, Сирина ҖИҺАНШИНА, Гүзәлия ГАЛЛӘМОВА, Рафаил ӘХМӘДИЕВ, Гөлсинә САВГАНОВА, Гүзәлия ШӘРИПОВА, Роберт САФИН, Рамазан РӘХИМҖАНОВ, Рөстәм КӘРИМОВ *шигырьләре.* *(Минзифа ӘХМӘТШИНАның кереш сүзе белән).* ........161

ФӘН

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. «Мин – үз урынымда...» ........165

СӘНГАТЬ

Гали АРСЛАНОВ. Күпкырлы бай иҗат иясе. *(Хөсәен Уразиковның тууына – 130 ел).* ........169

ЮБИЛЕЙЛАР

Гөлназ НУРИЕВА. Безнең остаз ул! *(Факил Сафинга 70 яшь).* ........173

«Казан утлары» архивыннан. ........176

*Хатлар яздым утырып:* Иштван Даби, Разил Вәлиев, Клара Булатова, Флёра Сафиуллинаның Марсель Галиевка язган хатлары. ........178

*Газиз тавышлар:* Күпме җырлар җырланмыйча калган *(Фәрит Яруллинның тууына – 110 ел).* ...183

Ул үз чорын төптән аңлап язды (*Әхәт Гаффарның тууына – 75 ел).* *Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ........184

*Шаян сәхифә:* Уены-чыны бергә. ........185

Сканворд. Рәис ГАБДУЛЛА төзеде. ........189

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 1 (1215) 2024*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---


★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Татарстан Республикасы, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.12.2023, график буенча 29.12.2023, басылып чыгу вакыты 11.01.2024
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-3512. Тираж 3040.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+
© «Казан утлары», 2024 ел



Факил
Сафин

# ГӨЛ ҖАНЫ. МӘХӘББӘТНАМӘ

СОНЕТЛАР БӘЙЛӘМЕ

**Үзәк сонет**

Гөлләрнең дә бар җаны, гөлләр дә көнгә карый.
Җырга әйләнә бары – моң гына гөлнең таҗы.

Күпләр тоймыйдыр аны, гөлнең чыкта янганын.
Сузылмасын кулларың, күрдем яше тамганын...

Сөюгә юк чик-чама, балкый әнә нурланып,
Җил иркәли юлларың. Син кил генә, туктама,
Бер тыңлачы җырларын, гөл җанында ни барын.

**1**

Гөлләрнең дә бар җаны, хисләр беткән буталып.
Чык нурыннан ут алып, яктырталар дөньяны.

Көткән чакта кил яме, меңнәрдән алам танып,
Тузгый хисләрем янып, көл итмә син көн ямен.

Сүзгә саран мәхәббәт,читкә алмам күзләрем,
Агардылар бүзләрем, синең барлыкка рәхмәт.
Дәшми генә кил, яме, бакча тулы гөлләрем...

**2**

Гөлләр дә көнгә карый. Искә алмый, дисеңме,
Хис адашып йөрсенме? – Хатларым сиңа бармый.

Факил САФИН (1954) – *шагыйрь, прозаик; Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Г.Исхакый, А.Алиш исемендәге әдәби премияләр иясе. «Саташып аткан таң» роман-трилогиясе, «Биек тауның башларында», «Галәм күзе» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

Гөл таҗын җилләр тарый. Иң кадерле исемне
Җуймас өчен бит инде күңелдән тоташ барлыйм.

Турыгыздан үткәндә ай шәүләсе сының да.
Куенга томан тула. Гөлне кояш үпкәндә.
Торырмын да сиенып, югалырмын тын гына...

**3**

Җырга әйләнә бары... Гүзәллек – изге дога.
Чәчләргә мамык йога, тупыл уйната буран.

Җәйнең сәер көне бар, сөю шикелле бугай,
Әйтерсең кышкы тугай, бөтерелеп ява кар.

Хисләр канатын җәеп, мине ташлап китмәкче,
Ялгызлык иш итмәсен. Сагыштан тора җәем,
Ул юк, диләр, көтмә син... Гөлләрең ишетмәсен...

**4**

Моң гына гөлнең таҗы. Чын сөюгә юлыккан,
Гөл керфеген йолыкмас – юрауларга мохтаҗмы?

Күл өстендә кыр казы, күтәрелгәндер Ыктан.
Инде канат ныгыткан, җил уйный – сагыш сазын.

Дулкыннар ярсуланып, ярларга бәрә-бәрә,
Тагын хәбәр җибәрә. Таң туа алсуланып...
Сүзем әйтеп өлгерәм, хатым укы, бергәнәм.

**5**

Күпләр тоймыйдыр аны. Тынлык ишегең шакыйм,
Үтә алмамын бакый кул сузымы араны.

Тынлык – сөю араны. Дөньяның серен ачыйм,
Айда сурәтең ясыйм, кысып тотып ярамны.

Ераклык үлчәм түгел, йолдыз карый үрелеп,
Җан чигенә сүрелеп. Сулкылдап яна күңел.
Мин яралы бүре бит, читлегем син – тере бик.

**6**

Гөлнең чыкта янганын күреп, сүзсез калган бар.
Һәр сөюдә ялган бар, мин моны соң аңладым.

Далаларның кылганын өзеп, кулга алган бар.
Дулкыннарга салган бар сөюнең ялкыннарын.

Бер караштан кабынып, иләсләнеп йөргән бар.
Күк түренә менгән бар. Бер карашка абынып...
Елаган бар, көлгән бар. Өшеп-туңып сүнгән бар...

**7**

Сузылмасын кулларың учактагы күмергә.
Яра калыр гомергә, борма сөю юллары.

Бардыр ялгыз кунганың сыенып кара җиргә.
Ут сүнгән, җилләр өргән, юк җылытыр юрганың.

Сөю эзләп йөргәндә адашкан күпме юлчы.
Мосафир, сабыр булчы. Син суратка тезләнмә.
Күңеле ачык булсын, тормышка гашыйк булсын.

**8**

Күрдем яше тамганын... Шундый ямьле көн иде,
Җанда якты көй иде. Суда йөзә талларым.

Син янымда яр, ярым. Балкып торган гөл идең,
Сагышланма, көл инде, оныт борчу моң-зарың.

Яшь тәгәри күзеңнән. Йөрәк кылы «зең» килде,
Яшерәсең йөзеңне. Син шул сердән өзелгән.
Яфрак күмә эзеңне, ишетмисең сүземне...

**9**

Сөюгә юк чик-чама, төн кабынган, төн яна,
Изге хисләр өр-яңа, йолдызлардан чык тама.

Куллар кулда, юк ара, иң беренче дөньяда,
Сөю туган, шуңа да җаннар җанга юл яра.

Җир югалды, күк югалды. Акыл бетә, хис кала,
Яңа галәм ярала. Мәңгелек юлын алды:
Таңда томан тарала, уҗым өсте парлана...

**10**

Балкый әнә нурланып, сөю кабынган чаклар.
Яшьлек яккан учаклар дөрли, ул бетми янып.

Утырам ялгыз калып. Җилләр керә кочакка,
Үзебездән качсак та, яшьлек кайта юл ярып.

Бәхетсез түгел идек, сөйдек асыл ярларны.
Безне сөйгәннәр бардыр... Мәхәббәткә баш идек.
Очратсам яшь парны, уйлыйм – тиңнәр болармы?..

**11**

Җил иркәли юлларың. Кыңгырау чыңы истә.
Антлар итешкән кичтә, чирттек күңел кылларын.

Кем бире, кемнәр ары, уйга килмәде һич тә,
Соңгы күрешү дип тә... Чәчтә – гомер карлары.

Еллар үткәч очраштык, җыелышып торабыз,
Уй-ниятләр корабыз. Карашлардан аңлаштык,
Хушлашуга барабыз... Ниләр булыр? Карарбыз...

**12**

Син кил генә, туктама. Мин каршыңа йөгерәм.
Соңгы поезд... Өлгерәм! Маңгаемнан тир тама.

Карап күзләрем тала, йөзләремә җил бәрә,
Язмыш безне җилгәрә, бүзләргә мана-мана...

Перрон артка шуыша, бусы соңгы талпыну,
Сына-сына юксыну. Өметләрнең ялкыны,
Тезген салган елкыдай, җилләр белән куыша.

**13**

Бер тыңлачы җырларын, күкне иңли моң-сагыш.
Кагыла күрмә ялгыш, чуалтырсың кылларын.

Белә идем җыр барын, гөлдә дә безнең язмыш.
Көнгә көн ялгап барыш, хыянәтләргә тарып.

Моң – сөюдән яралган, моңсыз калу куркыныч,
Кешелек булсын тыныч: Галәм буйлап таралган
Җыр көче – сынмас корыч! Бездән җыр – түгел кылыч!

**14**

Гөл җанында ни барын, и күңелем, аңла син! –
Җанга гөнаһ алма син, яманнарга эз салып.

Төрле хәлләргә тарып, пыскып кына янма син.
Җиргә яман калмасын, барыйк таңга юл ярып.

Адашканга терәк бул, дөресләргә таяныч.
Беркем булмау – аяныч. Туган җирдә кирәк бул!
Биеклекне кыеп оч, мәхәббәтле җанда көч!



Айдар
Хәлим

# ӘТИ-ӘНИ, МИҢА НИЧӘ ЙӨЗ ЯШЬ?..

БАЛАЧАК ХАТИРӘЛӘРЕННӘН

**Кәркәлетауның чык бөртекләре**

Истәлек – ул иң дөрес жанр. Истәлекләр язу дигән теләк тугач та, алдыма нидән-нәрсәдән башларга дигән сөаль килеп басты. Беренче булып, туган йортым каршындагы Кәркәлетау артыннан тәгәрәп килеп чыккан кояш, меңләгән нурларда чагылган хәтфә каз бәбкәсе үләне, инәм ягыннан картатамның төш кебек кенә хәтеремдә сакланган йорт-ихатасы күз алдыма килде. Бу минем язмышым әлифбасы иде. Кечкенә бакча, шундагы куаклыклардан «сикереп чыккан» иске кара мунча, чылбырлы чиләге белән дөбер-дөбер, аска-өскә йөри торган чыгырлы кое... Талап алынган малларыннан соң әлегә исән сакланган баганаларын пушка көбәге кебек аптырап, күккә төбәгән буш абзар хәрабәләре... Шунда ук салкын авызы белән урам якка чыккан таш подвал, таш келәт... Һәм алъяпкычын артка төйнәп бәйләгән картинәй... Ул аны шулай оста итеп чияләндермичә «чалып» бәйли һәм үзе генә чишә белә. Ничек? Чияләндермичә чишәр өчен уңайлы итеп бәйләү – бу минем сабый чагымнан күңелемә сеңдергән беренче серем. Менә картинәй мине кул чеметеме белән һавадан каз мамыгыдай йолкып ала да җилтерәтеп, боз салкыныдай суык таш келәткә алып керә һәм ниндидер иске байлык – буш мичкәләр арасына яшереп, кулыма катыклы касә тоттыра да боера:

– Мә, тиз генә чөмер! Карттаң күрмәсен!..

Тукта, дим мин үземә, минем әллә күпме сугышлардан исән кайткан ак сакаллы карттамның көне шушы бер көрәгә катыкка калганмы? Ул аны оныгыннан кызганганмы? Юк, мәсьәлә монда, мотлак, катыкка кытлыкта түгел, ә тормыш  кушкан табигый, хәләл вазгыять, ягъни олылар күзенә

Айдар ХӘЛИМ (1942) – *шагыйрь, прозаик, публицист; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты. «Өч аяклы ат», «Татар моңы», «Хунвейбин» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

чалындырмыйча, караш ташлатмыйча, юк кына нәрсәне дә башкалардан яшергән, күрсәтмәгән булып, яшь буынны өлкән буын алдында сабыр, тыйнак итеп тәрбияләү ихтыяҗында...

Юк, ялгышасың, диде икенче тавыш, бу күренешләр күпкә соңрак булырга тиеш. Истәлекләрең күпкә алданрак булган бит. Истәлек булган вакыйга турында гына языла. Барлык гомерне истәлек, ядкарь итеп булмый. Истәлек сайланырга бурычлы. Мин куркып калам: кулымнан килерме? Сайлануым акланырмы? Сүзең бары тик үзең хәтерләгән хәл-әхвәлләрдән башланырга тиеш. Һәм мин кирегә беткән таз малай сыман истәлекле вакыйгаларның башлам башын эзләп, баш миемне актара, ботарлый башлыйм. Уйланам, уйланам да, тагын шуларга килеп чыгам: Кәркәлетаудан тәгәрәп чыккан кояш, меңләгән нурларда уйнаклаган хәтфә үлән, карттам абзарының пушка сыман күккә төбәлгән баганалары... Юк, ди теге тавыш тагын да – синең болардан күпкә иртәрәк искә алырлык хатирәләрең дә бар! Сайланырга кирәк!

Кайчандыр ерак 1981 елның кичендә мин «Туган йорт тупсасында» дигән шигыремдә:

Алсу иртә.
Кояш Кәркәлетауга
Алтын баржа булып туктаган.
Сезгә куш уч алтын алып бирәм
Үрелеп кенә туган тупсадан,

– дип язган булганмын.

Язмышыма рәхмәтлемен, бу «баржа» үз йөгеннән миңа гомерем буена кушучлап алтын бүләк итә торды. Укучым да минем белән килешәдер, шәт. Аллаһы Тәгалә үз кодрәте белән бу алтынны миңа бүген дә бүләк итә кебек. Әйе, икенче караганда, Кәркәлетау артыннан алтын паровоз кебек гүләп килеп чыккан кояш та нәкъ шуның җимеше түгелмени? Бу китабымда мине һәм укучымны гел генә әнә шушы кояш озатып йөрсә иде, амин.

Хатирәләремне өстәмә материаллардан чыгып түгел, ә бәлки бары тик хәтеремнән чыгып язам. Болар чынлап та «хәтерле хатирәләр». Саф хәтер белән генә эш итү – бу, бәлки, яхшырактыр да. Хикәятемә керешердән алда укучыма бер үтенечем дә бар. Безнең якта «әтәй-инәй» дип сөйләшәләр. Аның мәгънәсе «әти-әни»гә тиң булса да, тегесенең сулышы минем өчен ничектер «җирлерәк һәм табигыйрәк» кебек. Аннан, бу әсәрнең бүлекләре төрле елларда, төрле чорларда язылды. Берсендә «әти-әни» дигән булсам, икенчесендә эчтәлек «әтәй-инәй» дип телемә килгән. Телемә кайчан, нинди калыпта килсә, шул калыпта алдым.

Әнием, ягъни инәм турындагы истәлекләр – мин белеп өлгергәннәрдән. «Белеп өлгергәннәрдән» дип әйтергә мәҗбүрмен, чөнки адәм баласы үзен кеше, гражданин буларак, бу да әле әгәр барлык шартлары да килеп җиткән очракта, егерме биш-утыз яшьләрдә генә таный, бәяли башлый. Ә мин әниемнән егерме яшьтә үк ятим калдым. Дөресрәге, дүртенче сыйныфтан унынчы сыйныфны тәмамлаганчы, карлардан тырпаеп чыккан маяклы юллардан кайтып та кермичә, бит алмаларын һәм аякларымны туңдырып, өшетеп, «әниле килеш тә әнисез» үсәргә мәҗбүр булдым.

Сугыш гаепле. Ихластан да, мин әниемнән күп, бик күп нәрсәләрне, гомумән алганда, «тормышның үзен сорашырга» өлгерә алмый калдым. Әтиемнең гомерен фронт ядрәсе киссә, әниемнең гомерен шул ук фронтның «тыныч тормыштагы» газаплары кисте. Мин аңардан хәтта үз туганнарым, нәселебезнең күз алдыбызда яшәп яткан тармакларын, «кемнең дус, кемнең дошман» икәнлеген белешергә дә өлгермәдем.

Әйе, мин, сабыйлыгым белән, һушыма килеп өлгермәстән, хәтта газиз картатам Шиһабетдиннең хәләл җефете – газиз картинәмнең исемен сораша да алмый калганмын. Хәерниса дигән мәгълүмат бар барлыкка, әмма ул документлар расламасы түгел. Бу бит хәтерсез калу белән бер! Анаңның анасының исемен белми калу – гөнаһ. Мине сугыш ятимлеге шундый хәбәр-хәтерсез иткән иде. Кем иде теге кардәшемнең, ничек иде икән бу кардәшемнең исеме? Кычкырып, җир тырнап үтенсәм дә, җавап юк, зират туганнарым каберләре белән тулган, әмма ул миңа иң кирәк исемнәрне атый алмый, ул өнсез. Шуңа күрә мин мәңге онытмас өчен Шиһабетдин картатамның хәтеремдә сакланган балаларын, ягъни өлкән туганнарын берәмтекләп санап китәм: алар унтугызынчы гасырның азагында дөньяга килгән Габдрахман бабам, аңардан кечерәк Габдулла бабам, аңардан кечерәк Зөлхия әбием, аңардан кечерәк Заһретдин бабам, аңардан кечерәк булган төпчек бала – минем инәм Минсорур...

Әйе, мин әнкәмнең сабый бала хәтерендә калган истәлекләре белән генә уртаклаша алам. Алар, әлбәттә, хәтер дәрьясыннан өзек-өзек, өлеш-өлеш булып калкып чыгалар. Балачак хатирәләре күпмедер күләмдә күңелдә яхшы саклanса, «олы чак» истәлекләре бөтенләй дә юк дәрәҗәдә яки бик аз күләмдәләр. Алар еш кына берсе икенчесе белән бәйләнмәгән дә кебек, әмма «инәй» дигән бердәнбер сүз аларның барысын бербөтен итеп ялгый да куя...

Шулай итеп, хәерле сәгатьтә!..

Бисмиллаһиррахман иррахим.

– Тор, балам! Рәхимә әбиләрең кайткан!..

Астан, тупсадан торып, абзар түбәсендәге мин төн чыккан куышка инәм эндәшә. Төнге һәм иртәнге салкын һава дымыннан авырайган, шушы дымны әле, күптән түгел генә тәмамланган сугышның такы-токы ризыгында какланган тәнем белән тойган иске паласны аякларым белән бер читкә тибеп очырам һәм шул ук салкын чыклардан чыланган баганаы инде әнкәмне кочкан кебек кысып кочып, аска – җиргә шуышып төшәм. Бр-р-р!.. Күзләремне ачам. Ярабби! Кояш! Меңләгән нурлар кайчысы меңләгән җемелдәвекләрдә уйнап актарыла. Кәркәлетау артыннан ишелеп төшкән нурлар инде безнең чокырда яткан авылыбызның каршысындагы Өязе тауларына да сикереп чыккан. Очасылар килә! Мин – Кеше!.. Бар дөнья, бар тирә-як үз-үзенә илтифат итәргә, саф һәм сак булырга, бәхетне күтәргә, сабыр итәргә куша. Әмма инәйнең мине күтеп торырга форсаты юк, ул инде шул вак борчаклы зәңгәрсу күлмәген, аның өстеннән изрәп беткән йон кофтасын эләктереп алган да, абзар артыбыздагы бәрәңге бакчабыз аша, тау битләвендәге ут-күршеләребез Мөсаббиха әби, Әбелшахма бабайлар, Гөлфаный әби, Гөлзифаттәй, Зөбәер абзыйларның ихаталары кырыеннан шушы җемелдәп балкыган чык тамчылары диңгезен ут капкандай чаштыр-

чоштыр китереп, үзе туып-үскән йорты – атасы Шиһабетдин карттәйләргә таба чаба. Чаба гынамы, җилдерепләр ята! Турыдан юл сапканда, ул йорт безгә, әткәм нигезенә күршеләребезнең ике-өч бәрәңге бакчасы аша гына. Әмма мин хәзер казык башлары аша турыга сикереп маташмыйча, инәйгә ияреп, Гөлфаный әбиләр янәшәсеннән титакларга мәҗбүрмен. Аякларым киндер ыштанымның балак очларына кадәр чыкта чыланган. Йокым ачыла. Әгәр хәзер шушы кояш нурлары кебек турыдан, читкә аугалаган читәннәр-киртәләр аша гадәтемчә очып кына үткән булсам, мин инде әллә кайчан картәтәйләр ихатасында булган булыр идем. Менә шундый якын ут-күршелек, атап әйткәндә, кода-кодагыйлык, әтәй мәрхүмгә, инәйгә өйләнгәч, «Мин киленне әллә кайлардан төшереп маташмадым, бакчабыз башыннан сызгырып кына китердем» дип шаяртырга мөмкинлек биргән. Алар 1928 елда өйләнешкәннәр. Әтәй белән, ул 1942 ел башында фронтка киткәнче, 14 ел бергә гомер итеп калганнар. Укучым мине аңлар дип уйлыйм: бу язмаларның биографик жанры таләп иткәнчә, мин үткән заман белән әле генә кичереп яткан бүгенгемне бәйләп барырга мәҗбүрмен. Миңа билгеле булуынча, инәй күпмедер гомер балага узмый тора. Шуның нәтиҗәсендә бу яшь гаилә, яратышып өйләнгән булса да, таркалуга кадәр барып җиткән булганнар, дип раслый кайбер чыганаклар. Булуы мөмкин. Тормыш бит. Ниһаять, 1930 елда беренче балалары Гали абзый, аннан янә өч бала (Нияз – 1934, Ингель (хатларында әтәй аны Энгель дип атый) – 1936, Борис (анысы мин булам) 1942 ел башында дөньяга килә. Ике балалары (Зыя һәм Ләлә) туганнан соң озак тормыйча тормыш белән хушлашканнар. Хәзерге бала үстерергә яратмаган чынбарлыктан чыгып уйланасың да, ул заман кешеләре, шаяртыбрак әйткәндә, бихисап корбаннар рухына «Бөек Ватан сугышы» дип аталачак сугыш алдыннан «патшадан калган иске байлыкта» баланы күп тапканнар да һәм «кулакны сыйныф буларак» юк итү кебек кискен чорларда исән-имин үстергәннәр дә икән, дип куясың. Тәкый гаҗәп!..

...Мин алтынланып куерган кояш диңгезендә юеш чәлтерләрем белән ялт та йолт чыбыркы ишә-ишә, инәмнең бер алдына, бер артына төшеп югыртам гына! Безнең якларда «йөгертәм»не шулай матур итеп «югыртам» дип әйтәләр.

Минем белән бергә ниндидер «Таҗикстаннан кайткан» Рәхимә әбине күрер өчен сукмак янәшәсеннән сузылган ат башы кадәр әрекмәннәр дә, учлап-учлап зәһәрләрен коеп утырган кычытканнар да, ат авызлыгыннан читкә чәчрәп калган солының яшел яралгылары да, арыш капчыгы сыман зур телле ат кузгалаклары да, сирәк-сарак күренгәләгән башаклы, кыяклы сарутлар да, үзе чәнечкеле, үзе аллы-гөлле кыңгырауларын йодрыклап күккә чөйгән шайтан таяклары да, кыскасы, без яшәгән Кәркәле үзәнлегенең кара, сазлык черетмәсеннән яратылган туфрагында үрчи алган барлык тереклек безнең белән киләчәккә таба чаба. Әйе, алар үлән-үсемлек затыннан булсалар да, һәммәсе дә – җанлы тереклек. Аларның һәммәсендә гакыл, йөрәк һәм буй-сын бар. Әнә шул сыннарның һәр буынына гүя кояш үзе бәбәй китергән. Безне каршылаган һәм озатып калган чык бөртекләре менә шуңа күрә бар нәрсәне сыйдыра да инде. Аларның эченә кереп оеган ике-өч тәрәзәле кечкенә өйләр, йөзьяшәр

өянкеләр җемелдәп кенә калмый, ә бәлки үзләре дә күңелләргә энҗе ташый. Безнең белән янәшәдән бозаулары белән сыерлар да, колынлы бияләр дә, бәрәнле кәҗә-сарыклар да мәгънә, сөйкемле холык, сабыр гореф-гадәт ташый. Син шул мәгънәне, гореф-гадәтне аңла һәм башкаларга аңлата бел! Бу чыклы җаныя куышлыкларында безнең бәрәңге бакчалары, туган-тумачаларыбыз, нәсел арбабызга утырган һәм утыра алмый чиратта басып торган якыннарыбыз, туган-тумачаларыбыз, ягъни бәгырь ялкыннарыбыз бихисап. Аларның да исемнәрен, нәсел-нәсәпләрен бел! Инәйнең кайчандыр утызынчы еллар башында сәяси эзәрлекләүләрдән Урта Азия якларына чыгып сызган һәм шуннан бирле туган ягына бер генә дә кайта алмаган Заһретдин абзасының җәмәгате Рәхимә әби белән күрешер өчен алар да артыбыздан чаба. Гүя безнең белән дөньяның бар әгъзасы кузгалган. Кәркәлетауның текә күләгәсендә кулларын сузып, инәлә-инәлә, алар да энҗе җыя...

Нәселнең тамыр башлары дигән төшенчә яши безнең халыкта. Бер караганда, бу сүз уйнату өчен генә әйтелгән кебек. Юк, бар ул нәсел тамыры, ничек кенә бар әле! Ул сине паспортыңны соратып түгел, ә үзе килеп таба. Паспорт дигән дәүләти таләп ул арттан гына өстерәлеп килә. Кайвакытта кеше заты паспорт дигән серле, керле һәм куркыныч кәгазьне бөтенләй дә танымаска тырыша...

Әнә минем балачак зиһенем буйлап әнкәмнең әнисе – тумышы белән Баязиттан, миңа билгеле булуынча, 1928 елда дөньялык белән хушлашкан Хәерниса картинәй, аның ире – минем Шиһабетдин картәтәй, аларның бераз гына югарыда телгә алган балалары Габдрахман, Габдулла, Заһретдин бабайлар һәм киләчәктә минем «Өч аяклы ат» дигән әсәремдә сурәтләнәчәк Зөлхия әбиемнәр йөгерә. Алар артыннан утызынчы елларда таланганнан соң ничектер сакланып кала алган «партманит-акча сандыгы»быз калкып чыга... Падишаһларыбыз сурәтләре белән бизәлгән каты, күн кебек ифрат та сыгылмалы катыргыдан ясалган тартма иде ул... Ул безгә шактый озак хезмәт итте, ни кызганыч, бу теләсә нинди музейларны бизи алырлык, сирәкләрдән сирәк бу экспонат бары тик үткән гасырның алтмышынчы-җитмешенче елларында, Ингел абзам иске йортны яңартып салганда гына, каядыр йорт бетерү мәшәкатьләрендәме, әллә бала-чага кулына эләгепме, байтак кына башка документлар белән бергә юкка чыкты...

Без, татарлар, үзебезнең тарихыбызга карата игътибарсыз бит!..

Шиһабетдин карттам бик сөйкемле кеше иде. Кеткелдәп көләргә ярата, шулай кабына алмаган трактор кебек «урынында дырылдап» көлгәндә, аның бит очлары алсуланып китә иде. Кырыгынчы еллар азагы – илленче еллар башында ул өлкән улларына караганда, күбрәк бездә яшәп, инәй тәрбиясендә булды һәм 1953 елны сентябрьнең ифрат та матур кояшлы көнендә вафат булып, мин Олы Кәркәле мәктәбендә бишенче сыйныфта укый башлаган сәгатьләрдә (хәзер өлкәннәргә аптыраплармы аптырыйм – мине шул көнгә генә укудан бушатып булмады микәнни?!) авылдашларым тарафыннан тиешле могътәбәрлекләр күрсәтелеп, Кәркәлетамак зиратына җирләнде. Аның кабере кызлары – минем инәм Минсорур, Зөлхия әби, уллары Габдрахман, Габдулла бабамнар зиратлары белән янәшәдә.

Мин карттамның Беренче Бөтендөнья сугышы фронтыннан хәрби формада төшеп җибәргән фотосурәтен хәтерлим. Ул сурәт тә юкка чыккан, кызганыч. Әйе, безнең басып алынган милли чынбарлыгыбыз гел шул «кызганыч»лардан тора: һәм башлана, һәм тәмамлана. Ул чакларда әле балигъ булмавым, бәндәчелек хәтерем уянып җитмәү сәбәпле, мин карттәм белән картинәмнең тормыш кагыйдәләрен, шәхси яшәү рәвешләрен үзем теләгәнчә киң итеп сурәтли алмыйм. Шулай да, туганнарымның берән-сәрән истәлекләре буенча, мин дә аның бик гайрәтле, кешеләргә рәхмәтле, ифрат та вәгъдәсендә тора торган зат булуын тәсдыйкъльйм. Сугыштан кайткач, ул күпмедер вакыт авыл старостасы вазифаларын үти. Әйткәнемчә, гайрәтле ир-узаман, хатын-кызга бик игътибарлы була. Кайбер ир-ат кавеме сыман, башына төшеп, «ятим» калган араларда һич кенә дә «карчыксыз» яши алмый, хәтта ки яшәп тә маташмый – шундук башлы-күзле булуны хәерле күрә. Хәерниса картинәм вафатыннан соң, озак та үтми, үзләренең (безнең!) тау битендә генә гомер иткән «ут-күршесе» Гөлфани «карчыкка» өйләнә. Аның белән ни сәбәпледер аерылышканнан соң Өршәк (икенче исеме Каен-Үзәк) авылыннан тагын бер «карчыкны» алып кайта. Мин аны төшемдә кебек кенә хәтерлим. Ташкеләткә кертеп, «Карттаң күрмәсен!» дип, катык эчергән картинәм нәкъ менә шушы әби булып чыга инде. Шушы картинәм вафат булганнан соң ул күрше Ишле авылыннан икенче бер «карчыкны» алып килә. Мин аны яхшы ук хәтерлим. Сугыштан соңгы ачлык елларында карттәйне күпмедер вакыт иң өлкән улы Габдрахман тәрбияләде. Карттәй белән шушы күзенә ак салган картинәм Габдрахман бабамнарның ишегалдындагы мунчасында яшәде. Хәтердә, баш өстемдә ачлык кояшы яктырта, ашказанымда шул ук ачлыкның тегермән ташы дырылдый башлаган саен мин, чакырылмаган кунак, чакырылган кунаклардан күпкә җәһәтрәк тизлек белән аларга килә, карттәм белән янәшәдән шул мунча ләүкәсендәге чүпрәк паласка менеп кунаклый һәм картинәм кулыннан кайнар арыш кабартмаларын «җыештыра» идем. Картинәй ак төшкән күзе белән миңа текәлеп карап тора да мунча мичендәге утлы көлдән тагын да берәр көлчә өсти...

Нәсел тамырлары белән мавыгып, мин бераз читкәрәк тә киттем бугай. Хәер, истәлекләр ядкяре булгач, алардан ничек котыласың?!

Әйе, Рәхимә әбиебезне күрер өчен безнең белән рәттән, 1905 елда туган атам Нәҗметдин ягыннан картатам Габделвәли, картинәм Гайнекамалның балалары Минеямал, Бәдриямал әбиләрем, Әхмәтвәли зур атам (Дим буе сөйләше белән «з»ны «д» әйләндереп әйтсәк, «дуратам-дуринәм»), Баязитка кияүгә чыккан Фәтхелкамал тутам һәм рәсми рәвештә 1910, үзе раславынча, 1909 елда туган инәкием Минсорур җилдереп ята!..

Алар белән бергә, күрәсез, барлык нәсел тамырларым йөгерә!

Менә без нурлар уйнатып җемелдәгән серле чык диңгезендә дымланып вә чыланып, картатабызның ташкоймалы ихатасына килеп керәбез. Шунысы кызганыч, минем хәтерем карттәйне дә, картинәйне дә сурәткә төшереп калдырмаган. Ул заманда фотоаппарат дигән могҗизаны каян һәм кемнән аласың? Йөзләрен хәтерләмим. Менә, астагы урам, абзар тарафындагы аралыктан йөзендәге нур ташкынында күзләрен чагылдырып,

эре чәчкәле яшькелт күлмәк кигән бер зифа түткәй йөгереп килеп чыга һәм инәмне кочып ала:

– Исәнме, Минсорур каенсеңлем!.. Исән-сау гыналармы?!.

– Һи-и, исәнме, җиңгәчәм!.. Җиңгәчәкәем!.. Күрешмәгәнгә биш былтыр!..

Сизенәм: минем Рәхимә әбием шушы буласы. Нурлы йөзле, түгәрәк битле, чәчләрен, уртадан сызык калдырып, майлап тараган. Бит алмалары да пешкән өрек сыман алсу. Чәчкәле, ефәк белән яртылаш әдрәс күлмәгеннән – аны безнең якларда «Бохара» күлмәге диләр икән – гүя барлык Кәркәлетау битләүләре чәчкә ата.

Алар бик сагынышсалар да, мөселман гадәте буенча сагынуларын сабырлык астына яшереп, тыйнак кына җанны – җанга, тәнне тәнгә теркәп күрешә-кочаклашалар да, озак күрешми торуыбызның үкенече калмасын дигәндәй, сак кына тагын-тагын бер-берсен җилкендереп куанышалар:

– Заһретдин абзам, башка туган-тумачаларым исән-сау гына калдылармы? Ерак юллардан йончымадыгызмы?

– Исән-аманнар!.. Ходайга шөкер!

Һәм китә, һәм китә үзләренә генә билгеле булган сораштыру-белештерүләр. Аларда аерым бер нечкәлек. Мине, кунак каршылаган сабыйны, болар әллә-ни кызыксындырмый. Мине Рәхимә әби белән кайткан апа һәм алар күтәреп кайткан серле йөк – мин үз гомеремдә беренче тапкыр күргән «чумадан» борчый. Ул апа миңа кем икән дә, шушы таҗик тарафларыннан кайткан чумаданнарында нәрсә булыр икән? Йокымны туяр-туймастан бүлдереп, абзарның салкын юеш баганасыннан чиркана-чиркана, юкка гына шуып төштем микәнни мин?!

Бер үк вакытта Рәхимә әбинең һәм аның белән кайткан, әмма әлегә миңа билгесез булган кызның кояшта янган йөзләренең безнең авыл хатын-кызларының йөзенә бер дә охшамаганлыгы, аларның, ихластан да, ниндидер көньяк җимеше кебек алсуланып җилсенгән булулары, бит очларының без күрмәгән, ишетеп кенә белгән алма-хөрмәләр сыман эчтән ялкынланып торулары гаҗәпсендерде мине. Ә бит кояшны бар дөньяга бер генә диләр! Әллә алар кайткан якларда кояш та икенче микән? Әллә киресе, Кәркәледән алар сөргенгә алып качкан кояш, туган якларга әйләнеп кайткач, бит-шәрәфәтләргә шундый төс өсти микән?!

– Бу матур җегет синең улың була мәллә, Минсорур? – диде Рәхимә әби, миңа кинәт кенә тутырып карап. – Тач үзең! Суйган да каплаган! Сөрмәле дә җитмәсә? Безнең нәселдә сөрмәлеләр сирәк!

– Әйе, сөрмәле безнең Барыйс. Атасы сугышка киткәндә, өч кенә көнлек булып калган иде. Беренче хатларын да «Йөзен күрмичә киткән улыма күп сәлам!» дип язды. Менә шушы төпчегебез дә ничек үсеп җитте, үзенә генә исән кайтырга насыйп итмәде, мәрхүмнең... – Инәй дымланган күзләрендә кинәт кенә яралган кайнар яшенташны сыпырган сыман өшенеп, яшьләрен сөртеп алды. – Кайтыр бәлки дип, һаман да көтәбез. Кешеләрнең әтәйләре кайткалый бит...

Һи-и, шушы инәйне! Яшь сыгар өчен вакытын да тапкан! Яратмыйм үземне ятим-фәлән-төгән дип кызгануларын!..

– Амин! Шулай гына була күрсен!.. – диде Рәхимә әби, минем баш өстемдәге чәч көнҗәләмне бармаклары белән тараштырып... – Барис... Барис... Тик... шушындый да матур җегетнең исемен генә, чалыш-полыш китереп, урысчага боргансыз бит әле...

– Атасы үзе кушып китте! Безгә болай бер дә чалыш-полыш күренми кебек... Аннан, ул исем русның үзенә бездән кермәде микән әле, Рәхимә җиңги? Шулай түгелме, Бар-рыйс улым?.. – Инәй мине кочагында башак өерелткәндәй өертеп алды. – Бездә дә бар бит ул «барыйс»лар – барыс, акбарыс, юлбарыс... Әтисе сөйләвенчә, үзенә күрә тарихы да бар инде аның... Сөйләсәң – сүз, төртсәң – күз, дигәндәй... Фронтка китәр алдыннан Нәҗметдин күпмедер вакыт ронода[1] эшләп маташкан иде. Шунда бер дусты – милләте ягыннан рус, исеме белән нәкъ шул Барыйс дигән укытучы белән очрашалар болар. «Мин фронтка чакыру алдым. Өч көннән китәм», – ди безнеке. «Бәй, ул повестка миңа да килде бит!» – ди теге. «Менә сиңа, мә!.. – ди безнеке. – Бергә китәбез икән! Сугыш башланып кына ята, минем кичә генә туган улымның күзе ачылмаган, ә миңа фронтка!» – ди безнеке. «Кайгырма, Нәҗми Габделвәлиевич, – ди теге. – Көенеч өстенә килгән сөенеч бу. Мондый чакта малайның тәпиләрен юмыйча буламы?! Әйдә!.. – Минем төенчектә... чәкүшкәм[2] бар... Китәбез бит, быррат, китәбез!.. Икәү китеп, берәү кайтып булмас!» Шунда, аулак почмакта... Ир-атныкын беләсез инде, чәкештерешәләр, күңелләре нечкәреп, малайга исем дә табалар – фронтка бергә китәчәкләр бит! Менә шулай рус дусты хөрмәтенә Барыйс була да кала минем төпчегем!.. Сугышлардан исән кайтсалар, бер-берсен югалтмаска, кайта алмаган хәлдә гаиләләренә балаларны үстерешергә сүз куешалар... Әйткәндәй, минем улым аларның икесе өчен дә яши!.. – Инәмнең әтәйне кызганудан күңеле йомшарып, беразга тавышы югалып торды да, исенә килеп, аркамнан каккалап куйды. – Тик икесенең берсенә дә кайтырга насыйп итмәгән шул, җиңгәчәкәем... Икесе бер булып ятып калдылар...

Бу юлы инәм белән янәшәдән керфекләрен челт-челт йомгалаштырып, Рәхимә әбекәй дә күзләрендәге яшьләрен сөрткәләде:

– Сау-сәламәт кенә үсә күрсен инде, балакаем. Яңа сугышлары килеп чыга күрмәсен.

Минем ачуым килә башлый. И-и-и, шушы инәмне, дим яңадан үзалдыма. Шушы энҗеле нурлар сикерешкән иртәдә әллә нинди бетмәс Барыйсларның исем тарихларын сөйләп, сүзне дилбегә буе сузды, шуның аркасында теге мин көткән чумадан әле һаман ачылмады, янәшәсендә генә басып торган апаның да кем икәнлеге ачыкланмый тора... Шулай да, әбием кебек пешкән җимештәй чырайлы, түгәрәк йөзле, төз гәүдәле булуын күреп, мин аның Рәхимә әбиемнең кызы икәнен чамалый идем...

Инәмнәрнең күзләреннән бөселеп чыккан яшь әле кибеп бетмәү генә түгел, киресенчә, кояш нурларында тагын да үткерләнә, чарлана төшкән чыклардан кайралып, тау битләвен көмеш тәңкәләр белән сипләгән иде. Кызкай исә, шушы тәңкәләрне үз гомерендә беренче тапкыр күргән кебек – хәер, ихластан да беренче тапкыр күреп! – үз алдына йомыла, йотыла,

[1] Роно – районный отдел народного образования — Халык мәгарифенең район бүлеге.
[2] Русча «четверть» — дигәннән «чекушка, четвертушка» дип кыскартып алынган.

вакыт-вакыт аларны тотарга, кочагына куып кертергә тырышып талпынып куя. Минем уйларымны белгән кебек Рәхимә әби үтеп барышлый гына таныштырып алмасынмы:

– Бу безнең өлкән кызыбыз Асия була... Бар, кызым, Минсорур тутаң, Барыйс туганың белән туган нигезләребездә яңадан күреш әле! – дип, бу апаны безгә таба этәргәндәй итте. – Әле быел гына урта мәктәпне тәмамлады. Госплан дигән институтка укырга керергә хыялланабыз...

Асия апа дигәнебез җитез адымнарда килә-килештән безнең белән күреште дә, уңайсызланып, әнисен чеметеп алды:

– Әни, болары нәрсәгә кирәк инде?

– Кирәк! Кирәк! – дип кабатлады инәм. – Безнең нәселдән дә зур кешеләр чыгарга тиеш!..

Асия апам миңа бик тә ошады. Ул чынлап та безнең инәй сыман төз, туры буйлы һәм якты уйлы кеше күренә. Юк, аның «болары нәрсәгә инде» дигәне бик тә урынлы, бик тә кирәкле нәрсә иде. Бигрәк тә миңа. Монда, әле Кәркәлетау артыннан балкып чыккан кояш нурларында коенып яткан «чыклы чокырда», минем, мәсәлән, урта мәктәп, институт Госплан дигән сүзләрне беренче тапкыр ишетүем иде. Алардан гүя минем колакларым шомрайды, мием яктырып киткәндәй булды. Тик мин көткән чумадан гына һаман ачылмады. Яңа сүзләр дигәннән. Берничә генә ел үтәр, мин урта мәктәпнең ун сыйныфтан торган урта, институтның югары белемле белгечләр чыгара торган югары уку йорты, Госпланның дәүләти планлаштыру оешмасы булганлыгын белермен. Кызык, гүя мин шушы беренче тапкыр ишеткән сүзләргә тотынып, ике куллап ябышып, олы дөньяга чыгармын! Алар миңа бу минутта шунысы белән кадерле иде: мин алар аша шушы туган «чокырымның» энҗе чыкларында коена идем!

Шулчак кемдер күлмәк итәгемнән тартты. Артыма борылсам, Асия апа! Әле генә алдыбызда елмаеп тора иде. Кай арада күздән ычкынган, диген! Ул яшен тизлеге белән мине әләктереп алды, ниһаять, әле һаман ачылмый яткан чумадан янына очыртып алып килде һәм ике ялтыр келәсен елгыр бармаклары белән «келт» итеп чирттереп ачты һәм алдыбызда яткан салкын кара фанер, җансыз, телсез чумадан Аллаһым, ничегрәк тасвирлыйм икән – минем күземә инде купшылардан купшы булып күренгән серле әрҗәдән, бар дөньяны балкытып, ниндидер күкшел тукыманы суыртып чыгарды һәм аны кош сыман канатландырып, шушы чыклы иртәнең энҗеләре чәчрәп торган җиләндә селкеде:

– Мә, киеп җибәр әле, туганым!..

Бу – күлмәк иде. Чын күлмәк иде!

Һәм мин инде үзем дә гади Барыйс кына түгел, ә «туган»нан туган зат идем.

Мин гомеремдә беренче тапкыр туганлыкның шундый канатлы һәм күлмәкле булганын белдем.

– Бу искеңне сал, – диде Асия апа, өстемдәге киндер күлмәккә ымлап. – Менә яңасын ки. Чалбар-костюмын үсә төшкәч, үзең юнәтерсең...

Кинәт кенә чишенеп, иске киемемне читкә ыргытып, хәзер үк бүгенге яңага төренүдән тартынып, мин Асия апа кушканны үтәргә ашыкмадым.

– Искесен сал да яңасын ки, дим! – диде ул туганнарча кискенлек белән. – Бу ниткән гадәт!..

Асия апа шул арада иске күлмәгемне өстемнән сыдырып төшереп, мине яңа күлмәгем белән бөтәйтте дә куйды. Миңа карап, инәм авызын ачты да катты.

– Менә ичмасам, Барыйс-барбарис!.. – дип куанды Асия апам.

Бу вакыйгаларга утызлап ел үткәч, мин бу аларны йөгертеп телгә алып китәм:

Туган җирем, синең шат тамырың –
Минем, тәүге күлмәк киюем!
Син ышанма сиксән шагыйреңә,
Төче була калса сөюе...

Әле чыклы иртәдәге могҗизалар моның белән генә бетмәгән икән. Асия апа серле чумаданның эченнән кечкенә төенчек чыгарды һәм бар тирәне хуш исләргә күмеп, миңа тапшырды:

– Бу сиңа дигән күчтәнәч, туганым!

Минем әле күчтәнәч дип аталган төргәкне беркемнән алганым да, аны ачканым да юк иде.

Асия апа гүя бу көтелмәгән тамашадан гаҗәпсенеп калган инәсе һәм Минсорур тутасына үрнәк биргәндәй, катгыйлык белән боерды:

– Миһман[3] күчтәнәчен шушында да бирмәгәч, инде кайда бирәсең? – Ул тагын да батырая төшеп, миңа мөрәҗәгать итте. – Син аны ач та, туганым, авыз ит!..

Асия апаның кыланышында безнең «Саесканнар» кушаматын йөрткән нәселебезгә хас кискенлек, боеручан катгыйлык бар иде. Урта Азия тарафларында үсеп, кеше булып тернәкләнеп тә, үз нәселенең горефгадәтләрен шундый иркенлек, үзсүзлелек белән алга сөрүе, татарчасын сатып җибәрерлек итеп яхшы белүе мине, әле канат төртеп кенә килгән сабый «саесканны», куандырды, билгеле. Кушаматыбызга килгәндә, югарыда телгә алынган сыйфатларга өстәп, саескан шикелле һәр багана башына кунаклап, һәр үткән-сүткәнгә һәр булган-булмаган яңалыкны хәбәр итеп шыкырдавына күрә биргәннәр аны безгә авылдашларыбыз.

Төенчек минем кулымда үзе үк чишелде бугай. Аннан, танауны әчкелтем кычыттырып, безнең өчен ят булган куе хуш ис бөркелде. Бу истән мин гүя тарлавыктай Өязе чокырларыннан киң галәм тарафларына аткарылдым. Авызларыма сулар килде. Минем өчен алар энҗе чыклар белән бергә өзелеп төшкән җәннәт җимешләре иде.

– Өрек!.. Тартынма, син аны ашап кара, туганым!..

Минем өрек дигән ят ризыкны да беренче тапкыр күрүем иде. Болай «туганым» дип өзелүчеләр дә берәү генә иде. Бу алсу-кызыл төстәге итләч хәзинәне һич кызганып тормыйча шартлатып уртлап өздем һәм тел өстемә салдым. Ул шундук диярлек, авызымда эреп, юкка чыкты. Тел өстемә тагын берне салдым. Тагын берне...

– Сабыр, – диде инәй. – Күчтәнәч күп булмый ул... Абзаларыңа да калсын!..

[3] Миһман (үзбәк) — кунак.

## Чана канатындагы очыш

Балачакның хәтергә уелып калган дистәләрчә хатирәләр йолдызлыгыннан сайланып тормыйча, кайсы күңелгә килә, шунысын алырга да куярга дип, үземә сүз бирдем мин. Алар чынлап та бихисап. Ул яшьтә адәм баласы тумышыннан ук даһи булып яратыла кебек. Аякка баскан һәр баланың аңга ия, балигъ булу чоры ул, гомумән дә, туктаусыз аккан илаһилык кебек. Анда гадилек һәм катлаулылык чыбыркы җепселләре сыман бергә ишелә. Биш яшьлекнең истәлеге бөек бер тарих, унбиш яшьлекнең истәлеге кечкенә сызат булып кына хәтердә калуы, яисә бөтенләй дә калмавы мөмкин. Юкка гынамыни чын даһилык шаукымына ия булган Мостай Кәрим кешенең гомере башындагы бу чорны бик хаклы рәвештә «Озын-озак балачак» дип атады. Бу Герон формуласына тиң билгеләмә иде.

Без гаиләдә дүрт бала, дүртебез дә ир бала идек: иң өлкәнебез Гали абый, икенче абыем Нияз (бишенче сыйныф укучысы, 1946 ел ачлыгында үлде). Мин аны чак-чак кына хәтерләгәндәй булам. Өченчебез, миннән алты яшькә өлкәнрәге Ингель абый белән без бергә – аллы-артлы үстек, дип әйтә алам. Кеше гомеренең моннан алдарак әйткән бер үзенчәлеген искә төшерик – бик бәләкәй, дүрт яшьтә генә булып хәтерли дә алмаска тиешле Нияз абыйны күпмедер микъдарда хәтерлим, ә менә бергә үскән, бихисап уртак хатирәләр булырга тиешле Ингель абыйны бөтенләй диярлек хәтерләмим. Әй, серле дә инде бу хәтер дигәнең!

Әлбәттә, аеруча истә калган, һәрвакытта да беренче булып искә төшә торган сирәк хатирәләр бар...

...Фронт шагыйрьләреннән кемдер – Давид Самойлов бугай! – безнең буынны «сороковые-роковые» дип атаган иде. Аның татарчасына мин чагыштырмача уңышлы исем таптым шикелле: «кырыгарлап кырылганнар». Аны «кырык бердән кырылганнар» дип үзгәртеп тә алырга мөмкин.

Әйе, без «кырык бердә кырылганнар». Әйе, без каршыбызда күтәреләчәк сугыш сөремен алдан исләп, алдан тоеп, ничектер «тота-каба, вакытлы-вакытсыз» туган балалар. Чынлап та, әниләребез әле башланып кына киткән сугыш хәвефләреннән арына алмыйча, кайгыдан, йокысызлыктан башлары чатнап, үзләрен-үзләре кая куярга белмичә, саташып, кочаклаган баласын коткарып калам дип, шарт-шорт бомба шартлап торган болдырга ташланган буын вәкилләре без. Чынлап та, без шаһиты булган, шул тормыш эчендә үскән, кеше булып җитешкән вакыйгалар рәтеннән бу. Мисалы күз алдымда. Сугыш башланган гына көннәр. Ул инде ирен сугышка озатырга да өлгергән. Кайгы-борчылулардан башы ауган, йокысыз калган түтки бу көннәрдә аеруча көйсезләнеп, туктаусыз елаган сигез айлык сабыен кызулык белән баш өстендә генә асылынып торган бишегенә ташлыйм дип, янәшәдәге «бушлыкка ыргыта». Әмма биләүдәге бала бушлык аша бишеккә түгел, янәшәдәге почмакка бәйләнгән бозау астына барып төшә һәм гомерлеккә гарип булып кала. Мин бу малай белән бергә үстем. Әмма шунысы хак: бу фаҗигане беркем дә, беркайчан да булмагандай, күрми дә, искә дә алмый иде...

Мин 1942 елның башында туганмын. Әнием сөйләгәннәрдән хәтердә калуынча, әтием мин туганнан соң – өч көннән фронтка китә. Бер атнадан

соң, ун көннән соң киткән дигән мәгълүматлар да бар. Кайсы дөрестер, әниемнең яшьли үлеп китүе аркасында мин моны ачыклый алмыйм. Хәзер инде моны аныклар кешеләр дә калмаган. Хәер, нигә аптырарга? Сугышның Германия белән үзара тынычлык турындагы пактка кул куйган көннәрдән соң, шундук башланып китүе үзе үк аптырарлык хәл түгелмени? Әйе, без чынлап та сугыш чорында туган һәм буынланган сирәк буын. Мине шунысы гына аптырата: без ничек исән калдык икән? Ничек? Менә монысы могҗиза! Шул ук әнием сөйләвенчә, ул мине, өч айлык сабыйны, корама юрганга төреп, юлдан юлларга, «чамалардан чаналарга күчә-күчә», ерак сәфәргә, әтием фронт алды карантинын үтеп яткан Абдуллино (чын исеме Абдулла, Габдулла) стансасына алып барган. Без әти белән бердәнбер тапкыр һәм – мәңгелеккә соңгы тапкыр! – шул Абдуллинда күрешкәнбез. Моңа кадәр ул хатларын «Йөзен күрмәгән улыма сәлам» дип яза торган булган. Шул ук әнием сөйләвенчә, без Абдуллинда бер атна чамасы яшәгәнбез. Әни белән мин әтиемне фронтка шуннан озатып калганбыз.

Без «кырык бердә кырылганнар»дан гына түгел. Без үзебезне барлык нәрсәдән мәхрүм итеп, ягъни заманыбызны, тормышыбызны тулаем «җитешмәүчелек-дефицит»ка әйләндереп «хәрби фронтта» кырылганнардан. Без, гомумән дә, «тылдагы дефицит» балалары. Юк, сүз нindидер төче тәм-том, кәнфит-мәнфит дефициты турында гына бармый, ә бәлки иртәгә иртән нәрсә ашарбыз-эчәрбез, шәрә гәүдәбезне нәрсә белән капларбыз икән дип кайгырган, шул чордан карлар аша «туңган аяклары белән» исән-сау йөгереп чыккан балалар без.

«Туңган аяклар» дигәннән. Бу чынлап та минем сабыйлык язмышыма тап булуы белән шаукымлы – кеше булып җиргә килгәч, тормышымны башлап җибәргән фаҗига буларак истәлекле. Ул чынлап та минем күңел түремне ачытып, яндырып торган беренчел вакыйга. Минем бу хакта язганым юк иде бугай. Бәлки кайчандыр телгә генә алып киткән булганмындыр. Яшьлегемдә язылмыйча калгач, инде «акылга утырып», шагыйрьлегем аяк-кулларымны тышаулагач, мин бу хакта бөтенләй дә язмый торырга булдым, чөнки Казанның якты күздән чүп эзләргә яратучы «мөхәррирләре» мине «Тукайга ишарәләүдә», ягъни Тукайга охшарга тырышуда гаепләрләр дип уйлый идем. Хәтерлисезме, Тукай «Исемдә калганнар»ында ике яшендә кече хаҗәте белән тышка чыккач, «бозга ябышып каткан» аяклары турында яза? Нишлисең, сугыш елларында, бәлки ике яшьтән дә артык булмагандыр, минем белән дә нәкъ шулай (бәлки, аннан артыграк фаҗигале?!) килеп чыкты бит. Гомеремнең башлам чоры ак бураннар, салкыннан зәңгәрләнеп уелган биек кар сырынтылары белән хәтергә сеңеп калган. Кайчакта мин шул зәңгәрлектән туганмын кебек. Без, авыл балалары, ул заманнарда яланаяктан зәңгәр боз булып каткан болдырга чыгып кына «чәпрәй» итә идек. Мин дә ыжгыр суыкта, инәем дә, абзыйларым да өйдә юк чакта, шундый хаҗәтем тугач, болдырга чыгам, әмма кире кергәндә, салкыннан катып өлгергән авыр ишекне ача алмыйм. Хәтердә, мин хаҗәтемне үтәп кар өстендә утырам, ә Сәнкә урманнары аръягыннан ач бүреләр улый. Минемчә, бүреләр улавында нindидер «мин хәзер сине ашыйм» дигән сихри моң бар. Сугыш башлангач, алар безнең якта нык үрчеде. Бомба шартлаган тавышлар китерде аларны

Көнбатыштан. Өйдә картәти (Казан якларында аны «бабай» диләр) барбарлыкка, ләкин ул атамның сугышта үле хәбәреннән паралич сугып, урын өстендә ята. Мин хәлсез кулларым белән ишекне дөбердәткән булам булуын, әмма өйдә картәтидән башка кеше юк, ә ул тора алмый. Аякларым бозга ябышып туңа башлагач, мин янәшәмдә торган ат (утын) чанасы канатларына менеп атланам. Аякларым салкыннан куырыла башлагач, чана канатларында биеп, сикеренгәләп җылынырга тырышам. Мин кычкыра да алмыйм, чөнки каушаудан тавышым качкан. Шунысын ачык хәтерлим, нык өшүдән миңа кар көртләре зәңгәрләнеп күренә башлады. Без, Хәлимовлар нәселе, барыбыз да диярлек зәңгәр күзлеләр. Ә мин үземнең күзләремнең зәңгәрлеген шушы туңудан зәңгәр төскә керүләре белән аңлатам. Күпмедер вакыт үткәннән соң мәктәптән кайтучы балалар, алар арасында күршебез Ниязир абый Сәхиев, мине күреп ала (мин моны да аз гына хәтерләгәндәй итәм) һәм «култык астына кыстырып», өйгә алып керә. Мин аңа мәңге рәхмәтлемен. Хәзер ул изге күңелле җан иясе юк инде. Минем укыган догаларым аңа рәхмәтләр булып барсын, урыны оҗмахларда булсын иде. Аның бу хакта минем исемгә язган шаһәдәт кәгазе дә сакланырга тиеш архивымда. Хәтердә калуынча, анда «Мин, икенче сыйныф укучысы Ниязир Минебай улы Сәхиев, Хәлимов Борис Нәҗметдин улын, кышкы суыкта аякларын туңдырган хәлдән коткарып, өйгә алып кердем» дигәнрәк юллар булырга тиеш. Ул аны киләчәк өчен кирәк булачак, дигән фикердән чыгып, минем үтенечем буенча язган иде. Бу язманы кырык җирдә таралып яткан архивымнан эзләп табу минем бүгенге халәтемдә мөмкин эш түгел. Аннары, мондый формаль язма бүген кемгә хаҗәт? Сугыш һәм сугыштан соңгы чордагы өзеклектә сирәк вакыйга идемени андый очраклар? Без соңгы берничә дистә елда Ниязир абый һәм аның гаиләсе белән бер шәһәр – Уфада бертуганнардай яшәдек һәм бу вакыйганы еш искә ала идек. Хәзер уйлыйм-уйганам да, тагын бер тапкыр уйганып куям: әгәр Ниязир абый коткармаган булса, минем язмышым ничек тәмамланган булыр иде икән?

Инәйнең һәм абыйларымның кайчан кайтуын, минем белән ничек мөгамәлә иткәннәрен хәтерләмәсәм дә, калганнарын шактый ук яхшы хәтерлим. Аякларым, тез капкачларыма кадәр, кымыз гөбесе кебек кабарып шеште. Алар безнең бүгенге заманның тын өреп тутырылган полихлорвинил капчыкларына охшаган иде. Аякларым бик тә әрни, чиләнгән тире астыннан саркып, сүле ага иде. Мин шактый вакыт тезләремдә шуышып йөрдем. Шушы халәттә мин карттәй юрганы өстенә дә шуышып менә идем. Юрган астында каты нәрсә – кеше гәүдәсе, (бу очракта паралич суккан карттәй гәүдәсе булган икән!) барлыгын тоя идем. Ләкин мин аның йөзен һәм рәвешен һич кенә дә хәтерләмим. Ул ничәнче елларда үлеп китте икән? 1945-46ларда булырга тиеш. Атамның фронттан 1944 елда язылган бер хатында картәтәйгә дип язылган урыны бар. Ул анда картинәмнең иртәрәк үлеп китүе, «бертуган Әхмәтвәли һәм Нәҗметдин балаларының язмышы бер житмеш яшьлек карт өстенә төшүе» турында әрнеп яза.

Әмма киредән теге «аяксыз» чорга кайтыйк әле. Чирле бала булгач, гаиләбездә минем авыртынып көйсезләнүләремне кичерәләр иде. Еламасын

дип, миңа хәтта «менә сиңа мең сум акча, ерта гына күрмә!» дип, бик тә матур итеп ялтыраган кәгазьләр, танклар, пушкалар һәм башка сугыш «кирәк-яраклары» сурәтләнгән лотерея, заём кәгазьләрен бирәләр иде... Кайчагында алар мондый матур кәгазьләрне алдау-йолдау өчен генә, кайчагында иснәтеп карау өчен генә дә кулыма соналар. Мин аларны мөмкин кадәр озак итеп сыйпый, ярата, капшый һәм исни идем. Бу сүзләргә керсез күңелдән ышана идем, чөнки алар минем өчен өлкәннәр табынып барган иң кадерле нәрсә – акча булган икән. Һәрхәлдә, көйсезләнгән чакларда лотереяларны күрү белән мин борын мышкылдатудан, елаудан туктый идем. Кайвакыт, өйдә ялгызым гына калган чакларда, җылы эзләп, өйдәге салкыннан өшеп, шуыша-шуыша килеп, мичкә сарылам һәм... кычкырып җырлый идем. Әмма искереп «картаюларыннанмы», әллә болай, үзлекләреннәнме, мичнең суынган кирпечләре ялтыравык кәгазьләрдәге танклар, пушкалар бирмәгән җылыны бирә алмый, шуңа күрә мин бары тик җырлап кына җылына идем...

Минем аякларны нәрсә белән дәваладылар икән соң? Без күз алдына китерә алырлык бүгенге дәвалар булмагандыр дип уйлыйм. Сугыш еллары баласының ямавы, кем әйтмешли, тән ярасында, ягъни «шинеле үз өстендә» иде. Шулай да бер һәм төп дару хәтердә калган – ул каз мае иде. Каз маен еш сөртүдән минем аяк чәлтерләрем шомарган шомпол кебек ялтырый иде. Әлбәттә, барлык дарулардан да кадерлерәге – ул инәйнең, абыйларымның минем хакта кайгыртулары, миңа карата булган сагынычлы мөнәсәбәтләре иде. Сугыш чоры анасының мәрхәмәте ачулы-кайгылы баштан әрнеп, нишләргә дә белмичә, үз баласын, якын туганнарын «Һи-и-и, дөмекмисең дә, ичмасам!» дип сүгү-сүгенүдән башлап, иң сөекле, иң кадерле сүзләр белән юату-ярату арасында тирбәлә иде.

Аякларым белән мин ике-өч ай җәфаландым бугай. Чана канатына басып та, утырып та өшегәнемне чагыштырмача яхшы хәтерләсәм дә, туңган аякларым төзәлеп, кайчан аякка басканымны хәтерләмим. Шунысы куанычлы, аякларымны шактый нык туңдырсам да, алдагы тормышымда алар мине ревматизм һәм башка шундый таралган «аяк чирләре» белән җәфаламадылар. Аякларыма рәхмәт. Гүя алар сабый чакта ук туңып, үзләрен чыныктырган иделәр. Шулай да, бер нәрсәне әйтеп китмичә булмый икән: мин балачакта, сигезенче сыйныфка кадәр, бәвелем тотмыйча, «астыма җибәрү» касафаты белән җәфаландым. Ул аякларымны туңдыру тәэсиреннән булгандыр, дип уйлыйм. Сигезенче-унынчы сыйныфларда район үзәге Кыргыз-Миякәгә егерме чакрым җәяү йөреп укыдым. Ул елларда, бигрәк тә чабаталарны ташлап, «гарадскуй» резин итекләрдә фарсит итә башлагач, аякларымны өшетмәскә тырыша идем. Резин итекнең нинди көйсез аяк киеме икәнен беләсез. Резин итек тиз суына. Аны, бер суытсаң, карлы юлда, салкында җылытып булмый, ул җылынса, кайнарлана, аяклар тирләп, тән пошлыга – инде суытып, нормаль хәлгә китерүләре бик читен.

Мин Аллаһы Тәгалә ярдәме белән бу газаплы аралыктан чыктым, аякларым мине беркайчан да авыр хәлдә калдырмады. Бу адәм организмының гаять түзем булуын раслый. Амин, алда да шулай булсын. Әлбәттә, 2016 елда йөрәгемә шунт – «чөй» утырту нәтиҗәсе аякларымда,

күзләремдә һәм башымда сизелде. Ләкин мин, Аллага шөкер, әле кешеләр рәтендә һәм кешеләр арасында йөреп һәм яшәп ятам. Мин бүген бу хакта уйланам да, Җир йөзендәге тормышны бар итүче Аллаһы Тәгаләгә очсызкырыйсыз, бетмәс-төкәнмәс рәхмәтләр укыйм.

## Нияз абыемны озату

Ул чакта мин, дүрт кенә яшьлек сабый, берничә вакыйганы «йокылы-өнле» булса да хәтерлим. Әүвәлдә Нияз абыем турында берничә сүз. Йөзенең, тәне-төсенең килеш-килбәте белән ул безнең гаиләдән беркемгә дә охшамаган: түгәрәк коңгырт йөзле, аз сүзле, туры борынлы, буе белән төп кебек чыныгып үскән егет иде. Инәм һәм соңыннан абыемның сыйныфташлары сагынып сөйләвенчә, ул бик яхшы укыган: авылыбызның башлангыч мәктәбен һәм соңыннан Олы Кәркәле җидееллык мәктәбенең бишенче сыйныфын да исәпкә алып, бары тик «бишле»гә генә өлгереп барган. Аның бала чактагы җан дусты, сыйныфташы, Бәләбәй бораулау эшләре идарәсенең күренекле хезмәт алдынгысы, бораулаучы, заманында «Социалистик Хезмәт Герое» исеменә тәкъдим ителгән, әмма бер «көнчел еланның» югарыга язган әләге аркасында гына шул хаклы бүләктән мәхрүм ителгән авылдашыбыз Хәйдәр Зөбәйдуллинның сүзләреннән чыгып бәя биргәндә, «Нияз дустыма хас булган тирән белем, яңалыкка, хаклыкка омтылыш, тырышлык һәм талант белән бары тик бөек кеше – затлы хезмәтчән, затлы галим һәм затлы гражданин гына булып була иде».

Ул мине сугыштан соңгы ачлыкта «Ач балалар йорты»на җибәрүдә хәлиткеч роль уйнады. Инәй-мәрхүмә әйтүенчә, ул 1946 елның кышында (чамалавымча, март башында) көтмәгәндә, нибары ике-өч көн генә чирләп ятып вафат була. Табибы түгел, хәтта шәфкать туташы да булмаган ач-ялангач авылда кинәт кенә китеп барган «бала-кеше» үлеменә аптырарлыкмы? Мин аны сабыйлыгында ярамаган нәрсә ашап, сукыр эчәге шартлаудан үлеп киткәндер, дип уйлыйм. Аз гына хәтеремдә: суык өй. Морҗабызга терәп салынган сәкедә юрган астында, бер йомарлам кебек кечкенә берәү ята. Соңрак – ниндидер ак халатлы апа безгә килеп керә. Ул тау артындагы Олы Кәркәледән төшкән «брач»ыбыз Зәйнәп исемле чатан шәфкать туташыбыз булган икән. Менә ул инәйдән нишләптер шикәр сорый. Кая? Нинди шикәр? Шикәр дигән нәрсә юк бит ул. Безнең аны күргән дә юк. Чирле балага, имеш, витамин җитми. Шатлыкка, ут-күршебез Фәтхулла абзыйның Тула дигән шәһәрнең шикәр заводында эшләгән апасы кайткан икән. Баласы кайгысыннан һәм йокысызлыктан күзләре чәчрәп чыгар хәлгә җиткән инәм йолдыз булып күршеләргә атыла һәм – ышанасызмы! – учында ватылмаган ап-ак таш сыман («комковый») шикәр йомарлап килеп тә чыга... Шикәрне коткаручы дару дип аңлау куанычыннан нишләргә белмәгән ананы бер читкәрәк этәреп, шәфкать туташы тимер кашык белән абзамның теш казналарын каерып ачтыра, авызына ширбәтле су коя башлый, әмма тешләр кысылган, алар үлем ачуыннан бирелми, бирешми, ачылмый, тимер кашык тешләргә бәрелеп, шак-шок килә. Апа исә һаман калагыннан авызга шикәрле су сала, үлем белән көрәшкән абзам

хәле барынча бу татлы суны эчмәскә тырышып, башын читкә бора, су түгелә, бала күкрәк кузгатып ютәлли, хәтта тончыгып йөткерә башлый... Кем уйлаган, абзам дару урынына шикәрле су эчмим дип түгел, ә бәлки үзенең өстенә килгән үлем белән шулай тешен кысып көрәшкәндер?!

Апа теш казнасын каерудан туктый һәм бөтенләй дә хәлсезләнгән абзамның башын мендәргә сала...

– Менә хәзер күзгә күренеп яхшырды... – ди ул, ширбәтле суын инәмә сузып. – Менә хәзер бөтенләй икенчеләнде...

Ул ара да булмый, минем газиз Нияз абыем тормыштан үтеп тә китә. Хәбәрне ишетеп, авылның барлык укучы балалары, мәктәптән кайтышлый китап-дәфтәрләрен күтәреп, уку отличнигы Нияз Нәҗметдин улы Хәлимовның үлем кайгысын уртаклашыр өчен безнең өйгә килеп тула... Салкын өйдә азан яңгырый. Бабайлар ясин намазын чыга башлый... Бу вакыйгалар минем «Ул елда» дигән поэмамда тасвирланган. Мине, күрәсең, җеназа вакытында бала башы белән күз көеге булып тормасын дип, ут-күршебез Мөсаббихә әбиләргә кертеп куялар. Мин боларны өзек-өзек кенә хәтерлим. Менә мин Мөсаббихә әбиемнәрнең куян күзе кебек кечкенә тәрәзә тупсасына басканмын да, үзебезнең капка ягын күзәтәм... Башымның түбәсе тәрәзә тупсасының өске агачына тиеп торганлыгын истә тоткан хәлдә, минем буемның бер метр чамасы булганлыгы аңлашыладыр. Менә безнең ихатаның урыс капкасы – уң канаты ачыла, аннан кәфен өстеннән юкагач кайрысына салынган абыемның гәүдәсен култык асларына кыстырып диярлек, бабайлар чыга башлый... Шундый тынлык. Мөсаббихә әбиемнәрнең ун бала туган-үскән Кәркәлетамак чокырындагы уймак тәрәзәле өендә шундый да тынлык!.. Ә дөнья үзе тирә-юньгә таралган азан моңнарыннан шартлар сыман. Мин елыйм. Кемне югалтканымны әле үз аңым белән аңламыйча да – елыйм. Буйга үсеп, акыл ягыннан камилләшеп, балигъ булып, бу югалтуны тирәнтен аңлагач нишләрмен?! Әле аңламыйча-нитмичә, мәсьәләнең эченә керүдән мәхрүм булып, Аллаһтан төшкән ниндидер кодрәт белән бу югалтуны илемне, нәселемне, милләтемне югалтуга тиң күреп елаганмындыр, күрәсең.

Нияз абыемның вафаты уңаеннан хәтеремдә сакланган икенче бер хатирәм дә бар.

Мөселман гореф-гадәтендә мәет чыккан йортта тәүлек эчендә ашамый-эчмичә тору, йокламау, мәет чыккан йортның башка мәшәкатьләрен күтәрешү дигән йола бар. Менә шушы йоланы үтәү ниятендә абзамны җирләгән көнне безне инәмнең бертуган абзасы Габдулла бабам һәм Хатирә әбиемнәр ашка чакырган булганнар. Бәләкәй чанага төреп салып, ашка мине дә алып баралар. Карлы кыш көнендә минем йөктән төшеп, таудан тәгәрәгәнем һәм мине котырган буран эчендә яңадан төреп, чанага бәйләгәннәре хәтердә. Дүрт яшьлек сабый моны ничек хәтерли ала? Алланың кодрәте белән мин бу «чанадан тәгәрәгән урыным»ның зират каршындагы Хәсбиттәйләр, Гариф, Латыйп абзыйлар яшәгән түбәдә булганлыгын бала күзеннән булса да, дөрес (ничек?!) чамалаганмын. Габдулла бабамнар ул чакта Качаган очындагы сазламык җирдә яши иде. Аларда барыбыз бергә идәнгә утырып, кызыл флаг сыман кып-кызыл чөгендер шулпасын эчкәнебез бик яхшы хәтердә. Таңда уянып, гадәт буенча астымны капшасам, юеш. Бу таныш халәт иде.

Күземне тырнап баксам, яктырып килә. Астымнан сары бояуга буялган идән тактасы буйлап җибәргән бәвелем аккан... Мин үзем кичергән мондый түбәнлек-гарьлекне, башкаларга сиздермәс өчен, сак кына ыштанымны салып, шуның белән үзем чылаткан тактаны сөртә, корыта башладым. Кыштырдавымнан, күрәсең, инәм дә уянды... Моннан соң бернәрсә дә хәтерләмим. Гүя хәтерем упкынга очкан...

Гомерләр үтте. Мин авылым зиратында Нияз абыемның каберен таба алмадым. Аны белүчеләр һәм тикшеренүчеләр бөтенләй дә калмаган иде. Дөрес, нәселдәшебез, Нияз абый белән бергә укыган Рәис абый Хәлимовның «Мин Нияз туганымның каберен беләм, аңа казык кагылган, ул, зират капкасыннан узгач та, сул кулда, сиңа күрсәтермен», дип әйткәләгәне булса да, тормышның иң кадерле нәрсәләрне дә оныттыра торган агышында, ни кызганыч, беребез дә моны җиренә җиткереп ачыкламаганбыз. Мин армиядә хезмәт иткән чакларда Рәис абыебыз вафат та булып куйган. Зиратта мин ул казыкны күп тапкырлар эзләп карасам да, таба алмадым. Күрәсең, иске каберне яңа каберләрнең үлән баскан ян-яклары күмеп киткән. Казык та югалган. Сугыш ятиме Нияз абыемның рухы тыныч булсын иде. Без аны онытмадык. Әмма мин үз гаебемне таныйм: заманында ул каберне эзләп табу өчен барлык көчемне җигәргә тиеш булганмын. Кабер өстендәге хәтер, ничек кенә авыр булмасын, ул беребезне дә туганлык тойгысыннан азат итә алмый.

### Бөртеген дә төшермәскә!

Сугыштан соң, ачыклап әйткәндә, кырыгынчы еллар азагы – илленче еллар башында, авылдан турыдан-туры Әкчин элеваторына ашлык ташу өчен килгән Мәскәү машиналарының агымы көчәйде. Гадәттә, колхозның иген келәтләре яны гөрләп тора. Текә маңгайларына МАЗ дип язылган горур машиналар, иген тузаны куптарып керә дә чыга, керә дә чыга. Инәләребез шул келәтләр алдындагы ындыр табагында: капчык ямыйлар, ындыр табагын себерәләр, ашлык чистарталар, илиләр, төйиләр, басудан килгәнен бушаталар. Без исә, биш-ун яшьлек малай-шалай, келәт янындагы Өязе буйларында казлар көтәбез, Өязене буып, «Черек күл»гә су куып кертәбез дә тәндәге йоннарыбыз ләмдә шыртлап карайганчы шул болганчыкта су керәбез, вакыт-вакыт, тамагыбыз йотлыкканда, ындыр табагында эшләгән инәләребез янына сугылып, барынча-булганынча «хәл белешеп» – капкалап та чыгабыз. Келәт янындагы ындыр табагындагы төп хуҗа – минем инәмнең бертуган абзасы Габдулла бабам. Кояшта ялт-йолт килгән калын күзлекле. Ул күзлеген хушбуйлы кульяулык белән генә сөртә. Бик купшы киенә. Авылдагы бердәнбер «гластук» аңарда гына. Аны шуңа күрә «культур Габдулла» дип атыйлар. Бер аягына бераз аксый. Сугыштан калган җәрәхәте бар. Җәрәхәт кенә түгел, зирек агачына охшап, күгелҗем төскә кергән «черек аяк». Язгы-көзгелектә ул аеруча аза, бозыла, бабам бөтенләй дә йөри алмастан урын өстендә ята. Аның дәүләт ашлыгын саклаучы «глубинка нәчәнниге» дигән вазифасы да бар. Ашлык «нәчәнниге» булса да, гүя ул үзе һәм аның гаиләсе бөтенләй дә ипи ашамый, бары тик дәүләткә озатуны гына белә.

Шулай бер көнне, кояшлы иртәнең Кәркәле тауларына җәелгән сәгатьләрендә, мин инәмне күреп чыгарга дип, иген төягән машиналар арасыннан борыла-сарыла килә идем, Габдулла бабам кулын изәп, мине үзенә чакырып китерде һәм:

– Улым, тыңла, сиңа дәүләт җаваплы бурыч йөкли! – диде. – Әнә машина, менә моннан кузовка сикереп мен дә, әйдә, туп-туры Әкчингә! Кара аны, игеннең бөртеге дә йөктән сикереп төшмәсен! Коелып калып, юлны яктыртып ята күрмәсен! – Аннан шофёрга мин аңламаган телдә нидер мыгырдады да, мине, ул чакта алты яшеннән дә узмаган баланы, әрҗәсендәге игене белән ярылырдай булып киерелгән МАЗ кабинасы янына китерде. – Әгәр машина сикертә салып, игене коелса, кабина янына үрмәләп кил дә түбәсенә дөбердәт, ярыймы, дип, ындыр табагыннан олы юлга чыгарып та җибәрде. Шулай итеп, мин үземнең «дәүләт йомышы» белән Әкчингә китәчәгемне инәмә әйтеп тә өлгерә алмадым. Ә-әй, бабам аңа үзе әйтер әле, дип уйладым. Мине бит дәүләт йомышы белән бабам үзе зур юлга чыгара. Шушы ук шофёр белән мин кире урап та кайтачакмын инде!..

Моңа кадәр минем авылдан чыкканым юк иде әле. Күкрәгемә ачык изүем аша ярсу җил бәрде. Барабыз! Җилдерәбез! Очабыз! Мине малайлар күрә микән? Әле башланып кына килгән гомеремдә «Дәүләт йомышы»н үтәгән баланың беренче тапкыр машина хуҗасы булып, Әкчингә алып бару шатлыгын күз алдына китерәсездер. Юл буена инешләр, елгалар, таулар йөгерә. Мин аларның исемнәрен дә белмим. Ә нигә ул исем? Кемгә кирәк ул? Бераз үсә төшкәч белермен әле: мин яшәгән җирнең елгаларының исеме Өязе, Кәркәле, тауларның исеме дә шул ук Өязе һәм Кәркәле таулары булган икән. Бу калкулыклар да Бөгелмә-Бәләбәй калкулыклары дип аталачак икән. Без авылдан чыкканда озатып калган инешнең исеме аңа киләчәктә Кырлыган буларак ачылачак. Тау башындагы ачыклыкта баһадир кебек җәелеп утырган һәм без узып киткән имәннең исеме күп буыннарга билгеле Түгәрәк Имән булып хәтергә керәчәк. Мин шуны аңладым: үз җиреңне белү һәм бәяләү өчен читкә чыгып карарга кирәк икән. Баш миемдә бернинди икеләнү, шикләнү, борчылу, курку юк, иң мөһиме – чокыр-чакырда лап-лоп килеп куйган кузовтан без үстергән иген генә чәчрәп коелмасын. Хәзер мин тулы иректә! Казлар көткәндә бәбкәсен югалткандагы кебек аны инәсе дә әрли алмый. Рә-ә-әхәт! Әлегә кузовтан бөртек тә иген коелмый. Кызык бит: игенне авыл үстерә, әмма аны мәскәүләр Мәскәүләрдән килеп, мәскәүләргә ташый. Гүя иген тумышыннан ук Мәскәүнеке. Әнә, игенне Габдулла бабасы үзе үк мәскәүләргә озата бит. Мин аңламыйм: игенне үзең үстермичә дә үзеңнеке итеп була икән?

Каршыма әүвәлдә авыл араларындагы ат-арба юллары, аннан ташлы юллар буйлап нindидер күрсәткеч такталар, атлы йөкләр һәм машиналар, печән төягән фургоннар агыла башлады. Мин ул язуларны укый алмыйм, чөнки әле мәктәпкә төшмәгәнмен. Юл буена урманнар чаба. Аларга керәбез дә чумабыз. Чумабыз да чыгабыз. Бар тирә-як нindидер калтыранып, дерелдәп торган көмеш рәшәдә айкала-чайкала. Күк йөзендә айның кавын телеме кебек нәзек алкасы йөзә. Кара әле, Ай дигән тере җан иясе булып көндезен дә күккә калка икән. Андый нәзек ай элпәсен мин авылымда төнлә

генә күргәнем бар иде. Ярый әле, бабасы нәкъ үз вакытында җибәргән аны Әкчингә, югыйсә кайчан күрер иде ул бу кадәр матурлыкларны!

Юл бик зур авылга алып кереп килә. Ике катлы зур таш йортны үтеп киттеләр. Соңыннан беленер, ул Йәрлекәү белән Кыргыз-Миякә арасындагы пар тегермәне икән. Таш юл һәйбәтләнә төште. Шофёрым да һәйбәт, машинасын лерек-лерек йөгертә генә! Игенем дә үзен тәртипле тота. Бу иген әрәм-шәрәм булмас өчен миңа ышанып юлга чыккан. Күп тә үтми, уң яклап, гүя рәт-рәтләп салынган таулар тезмәсе башланды. Тауарның түбәләренә мамык эскертләре сыман ап-ак болытлар оялаган. Минем аларны бармак очларым белән чеметеп кенә алып телемдә эретәсем килеп китте. Бу тойгыдан ашказанымда нәрсәдер кузгалып та куйды. Бәй, минем, ачыксам, юлда бер тапкыр тамак ялгарлык ризыгым да юк бит! Үзем тулы машина ризык алып барам. Шулай да мин күргән бу ипле матурлыклар ашказаным талавыннан көчлерәк булып чыкты – мин шушы кадәр матурлыкларны онытылып тирбәлер өчен күзләремне йомдым. Куе җил кылган кыяклары белән бергә рәхәт итеп мине иркәли, назлый иде. Гүя мин бишектә тирбәләм. Уң тарафтан, аста, мине озата барган уйсулыктан чыгып чамалаганда, ниндидер зур елга агымы барлыгы төсмерләнә. Таулар ындыр табагындагы иген өемнәре кебек бергә кушылып җөпләнә дә, бераз гына ара калдырып югалып тора, аннан тагын каяндыр калкып чыгып, үзара үксешеп, мәңге аерылмаслык итеп кочаклаша. Минем кочаклашкан тауларны күргәнем юк иде, билләһи! Менә шулай күренмичә, ничектер астан аккан елгалар табигатьне ничек итеп үзгәртә икән! Бер караганда шактый биек тау булып, икенче караганда инде калкулыкка әйләнгән тауларны уч төпләре белән капшап, хәтта тотып, бармаклар белән кети-кети кытыклатып карыйсым килә башлый. Алар чынлап та безнең очның үсмер кызларының күкрәк төеннәре кебек төртелеп тора. Кинәт машинам ниндидер бер түмгәләктә сикертеп куйды һәм кузовтагы иген шактый каты итеп урынында җилгәрелде, кушуч чамасындагы бодай читкә сибелеп калды. Миңа яндырып, салкын тир бәрде. Ут капкан сыман ашыгып, япмасы-ние булмаган иген өстеннән кабинага таба шуышып бардым һәм кечкенә йодрыкларым белән дөбердәтә башладым:

– Бөртекләр коела!.. Бөртекләр!..

Машина туктады. Кабина ишегеннән кырынмаган, бит алмаларына кадәр кара сакал баскан абзый чыкты һәм кычкырып, мин аңламаган сүзләр белән акырынырга тотынды.

Бу кадәр ачулы сүзләрне моңа кадәр ишеткәнем булмагач, өстәвенә, аларны аңламагач, мин бары тик ниндидер җиденче тойгы белән төшенә идем: болай дошманнарча кулларын селтәнгәләп сүгенгән кеше мине ни өчендер яратмый, бер дә мәгънәсезгә кычкыра... Әллә ишетми?

– Бөртекләр коела! – дидем мин, үзем дә кычкыра салып. – Бөртекләр!..

Ул ачуы тәмам да кузгалган кыяфәт белән тагын да нәрсәләрдер мыгырданды һәм кабинасы ишеген доңгылдатып ябып китеп тә барды. Мин гарьлегемнән йөк өстенә капланып, кулларымны җылы бодай эченә тыктым да, гүя теләр-теләмәстән, мәҗбүри рәвештә игеннең даулы һәм шаулы тавышын тыңлый башладым. Ул инәм тавышы кебек таныш тавыш

һәм моңлы табыш иде. Сизәм, ул тавыш мине, ир баланы, туган авылымнан читтә елый-елый юкка чыгу, югалу куркынычыннан коткарды.

Уңда һәм сулда, алда һәм артта төрле урманлы култыклар һәм авыллар калдырып, юлыбыз дәвам итте. Таулар мине монда да үз игътибарыннан ычкындырмады. Мин инде шушы яшемдә сабый бала булудан туктаган һәм өлгергәнлеккә әҗәткә кергән халәттә идем.

Хуш, ятимлек! Хуш, мескенлек! Хуш, сабыйлык!..

Бу таулар миңа атам-бабамнардан васыять ителгән бүләк икән. Алар мине үзләренең сөйдергеч дикъкате белән хәтта хәзер, шофёр белән ике арада булып алган шушы кечкенә чәкешүдән соң да дәүләткә дип алып барган яшь, хуш исле бодай биләмәсендә дә биләп алган иде. Алар хәзер үзләре мине җибәрмичә, үзара яратышкан, бер-берсенең кадерен якыннан һәм тирәннән белгән горур һәм иманлы кыяфәт белән ярыша-ярыша, алга чаба иде. Алар шулкадәр мөлаем, шулкадәр төгәл һәм шулкадәр игътибарлы сабыр иде ки, гүя аларны кемдер махсус шулай үлчәп, биеклеккә күтәргән һәм үлчәп, үзәнлеккә төшереп, гакылын тирәнәйткән дә, бары тик шушы шартларда гына дөнья көтәргә кушып, җир йөзенә урнаштырган иде.

Тизлеген югары тоткан, аны торган саен арттыра барып, каядыр күзе тонып чапкан машинабыз бер сикәлтәдә тагын да бик каты сикертте. Йөк тагын чайпалды. Тагын да берничә кушуч... юк, бер... ике... юк, сиземләвемчә, чиләктән дә ким булмаган яшь бодай байлыгы машиналар тарафыннан изелеп өзлеккән юлга чәчрәп коелды. Мин кискен селкенүдән айнып, янә дә кабина авызына таба шуыштым һәм аның түбәсен төя-төя, җан ачуым белән кычкырып җибәрдем:

– Бөртекләр!.. Бөртекләр коела!..

Ул туктап, кабинасын ачты һәм тупсасына басып, мине ачулы караш белән коендырды. Йөз сүрүе аның үзеннән качкан иде. Бик куркыныч кыяфәттә миңа җикеренде дә төшеп, машинасын тирә-яклап әйләнеп чыкты һәм нәрсәдер сорагандай итте. Нишлим, ул мине бу юлы да аңламый, ә мин учымдагы бодай бөртеген кулымда әвәли-әвәли, игенне коярга ярамаганлыгын ымнар белән аңлата алмый идем.

Без бер уртак илдәге ике бөек тел балалары – мин татар, шофёр рус телендә бер-беребезне аңламый идек.

– Бөртекләр коела! Нишлим соң, абый?!..

Абый миңа карап, нәрсәдер сөйләнгәләгәндәй итте дә янә кабинасына кереп югалды һәм тормозларын шыңгырдатып китеп тә барды. Безнең икебезнең арабызда хәләл элемтә булмаудан бигрәк, аның юл өстенә иген чәчеп баруын туктатуын, моның ярамаган эш булуын аңларга теләмәве, моңа хәтта «Мин үстергән нәрсә түгел әле» дип төкереп каравы мине ифрат та нык борчый иде. Мин бәләкәй булсам да, инде бәләкәй булудан туктаганмын икән шул. Ул моны әллә белми, әллә белеп аңламый иде. Мин аның мине сүгеп һәм сүгенеп сөйләнгәләвен түгел, ә бәлки миңа, телне белмәгән сабыйга һәм бигрәк тә үзенә, үз акылындагы өлкән кешегә, булдыра алганча, куллар-күзләр ымы белән булса да аңлатуын, мәсьәләне ачып салуын тели идем. Әмма ул ни сәбәпледер бу иң гади кешелек гамәлләреннән читләшә иде. Уң тарафтан безне озата килгән таулар үз итәкләрендәге якты каенлыклары, бөдрә таллары белән бу мизгелдә бик

тә уйчан, бик тә моңсу күренәләр иде. Алар белән ярышып, без тагын бер зур гына авылга килеп кердек. Минем шофёр каршындагы юл аша, инде канат чыгарып каңгылдау чорына кереп барган каз бәбкәләрен чак-чак кына чыркылдатып-сытып узмады. Үсә төшкәч белүемчә, бу озынлыгы йөз чакрымга тарткан Кәркәлетамак-Әкчин юлындагы Миякәтамак дигән зур татар авылы булган икән. Юллар ифрат дәрәҗәдә ватылган, тетрәнгән, урыны-урыны белән тәмам җимерелеп беткән иде. Машиналар күп йөрү нәтиҗәсендә чыгырдан чыккан таш юллар безне туктаусыз сикертә, селкетә, кузовтагы игенне пыран-заран китереп, тирә-якка чәчрәтеп коя башлады. Минем түземем төкәнде. Тагын да, инде өченче тапкыр шуышып барып, түбә калаен төйдем. Үзеннән алда кабинадан чалшаеп, аның кырык ел кырынмаган йөзе балкыды.

– Бөртекләр!.. Абзый!.. Бөртекләр!..

Абзый янә дә машинасыннан төште һәм сүзсез генә, хуҗаларча кыланып, машинасын тагын урады да, аннан кузовка күтәрелеп, исән калган игенне күздән кичерде дә, күкрәге белән руленә капланып, яңадан таулар белән ярышка чыкты. Күп тә үтми, без иген төялгән атлар-арбалар, машиналарның озын чиратына килеп юлыктык. Алда Дим дигән елга һәм каршыбызда аны аркылыга кичүче паром дигән нәрсә икән. Чират көтә-көтә, мин машинамнан калышмыйча алга бардым да бардым. Шофёр минем белән аралашмый-аңлашмый, бер нәрсә сорашмый, юлда табышкан Мәскәү шофёрлары белән ярашып алган да, рәхәтләнеп кәрт сугалар. Мин машинам белән аймылыш була күрмим дип шикләнеп, шофёрны күз уңыннан ычкындырмыйча атлый бирәм. Менә озакламый Димнең үзенә, аның аша чыгачак паромга да килеп җиттек. Мин аякларымдагы чүәкләремне салып, яланаяк, беренче тапкыр тез капкачларыма кадәр су ерып (соңыннан беленүенчә, җырларда җырланган!) Дим елгасына кердем. Мин шунда ук шәрә балтырларымда нindидер йомшак кымту, капшану, тешләргә, чеметергә тырышуны сизеп, көмеш дулкыннарга иелеп карадым. Өн-некәй-генәм!.. Вак кына балык сабыйлары якты борчак бөртекләре булып як-якка сибелделәр! Минем балтырларымны йөзләгән вак балык – безнең тел белән әйтсәк, маймычлар сырып алган икән! Алар үзләренчә тавыш-тынсыз скрипкаларда уйнап, Дим елгасын мактап зурлыйлар иде. Алар кайнаша, сикерешә, тәнемне тешләргә, хәтта яратудан гына өзгәләп ташларга тырышып, кечкенә, әмма ачык авызлы борыннарын тәнемә төртә, кытыклый һәм сәрпәләнә...

Мин иелеп, су өстенә шәүләмне төшерү белән алар тагын яшен тизлеге белән берсе дә калмыйча читкә сыдырылалар. Аларның шулай ут чыккандай читкә чәчелүе гүя минем бөртекләрне коткару өчен көрәшемдә акланып кабатланган сыман иде...

Кояш баш түбәсенә җитеп барганда, без дә паромга кердек. Ул теге ярдан бу ярга тартылган корыч, яисә елга агымына карап, сүстән ишелгән аркан һәм тактадан ясалган күпер икән. Мин Дим елгасының нәкъ уртасында паромны агызып алып китәргә тырышкан көчле агымын тойдым. Су шушы ук суны үзенә буйсындырган кеше белән көрәшә иде. Паромга җәелгән калын такталар буенча без теге як ярга күтәреләбез. Соңыннан, 1957 елның июнендә сигезенче сыйныфны тәмамлаган укучылар белән без Приют

дигән бораулаучылар шәһәрчегенә экскурсиягә барганда-кайтканда, шушы паромны тагын да ике тапкыр үтәчәкбез. Менә без теге ярга да аяк бастык. Дим маймычлары, киләсе очрашканда, безне зу-у-у-р үскән балыклар булып каршылагыз! Әле вактин-вак маймычлар, кайткан чакта бирегә эре сөякле ата-инәләрегезне дә алып килегез!

Шофёр туктамый. Мине артыннан йөгертә. Аны куып җитүемне теләп кенә шулай йөгертә дип уйлыйм.

Мин йөгерәм. Әмма ул һаман туктамый. Кызурак йөгерәм – ул тагын да кызулый. Мин чабам, ул янә дә тизлеген арттыра. Нәрсә бу? Шулай йөгерә-йөгерә минем, болай да иртәдән бирле валчык та капмаган сабыйның, хәле төкәнә башлый... Хәзер-хәзер... Егылам! Авам!.. Ниһаять, бер ачыграк төштә машинам туктый. Тик кузовка менәргә көчем җитми...

– Больше стучать не будешь! – ди кара сакал һәм мине песи баласы кебек бөтереп алып, кузовка ыргыта...

Әлбәттә, мин аның сүзләрен аңламыйм, әмма тәнемнең тиресе белән тоям: ул миңа кабина түбәсен бүтән дөбердәтмәскә – үзен борчымаска куша...

Шулай да мин бирешмим: безнең Кәркәлетамак ашлыгы коелмаска тиеш! Барган уңайга сикерткән саен калай түбәне дөбердәтәм, әмма шофёр туктамый, чабуын гына белә. Без, һаман да шул соңыннан гына үз исемнәре белән хәтергә керәчәк ниндидер зур Никифар, Айдагол, КИМ дигән авыллар аша игенебезне кабул итәчәк элеваторы белән әллә кайлардан күренеп торган Әкчин станцасына якынлашабыз.

Әкчингә керү белән безне тагын да шул иге-чиге булмаган игенле ат йөкләре, ашлык ташыган машиналар чираты каршылады. Элеваторга җиткәч, шофёр мине «Слезай!» дип, кузовтан төшерде һәм, аңлавымча, элеваторга кермәскә, миңа аны күтмәскә кушып кузгалып китте. Мин аңладым: авылның алты яшьлек яланаяклы «икмәк сакчысы», паровозларның кешеләрне аерган һәм кавыштырган гудоклары белән йөрәксетеп торган бу минутымда, югалып калмыйча, адашмыйча үз юлымны үзем табып, авылыма кире кайтырга тиеш идем...

Хәзер, менә хәзер, сиксән яшь өстенә баскан, шушы хикәят язылган мизгелдә аптырыйм: еракта, көтмәгәндә туган тупсасыннан йөз чакрым диярлек ераклыкта аерылып калган сабый, кайлардан, нинди көчләр табып, берни булмагандай тыныч булып калдым икән? Моның өчен бит пәйгамбәри сиземләү, пәйгамбәри көч кирәк! Хәлемне аңлап елыйсым килә, тик яшем чыкмый; шул ук вакытта тынычмын, гүя мин бирегә Аллаһы Тәгаләнең сагы астында килгәнмен...

Шулай итеп, мин һич уйламаганда, Әкчин дигән станцада сәяхәттә булып чыктым. Әле көннең уртасы гына булганлыктан, минем күпмедер вакыт туган авылым тарафларына кайтырга кузгалганчыга кадәр, Әкчин буйлап йөрергә, булган вакытымны ничек телим, шулай үткәрергә тиеш идем. Минем бер тиен дә акчам юк. Элеватор янында, шофёрым кушканча, аңардан тәмам аерылып, кире Әкчин уртасындагы юллар чатына килдем. Андагы чиксез чиратлар арасыннан йөреп, үзем таныган кешеләрне, ягъни авылдашларымны эзләдем. Әмма алар юк иде. Бер эзләдем, ун эзләдем. Ашказаным суыра башлады. Шулчак кешеләр

кергәләгән-чыккалаган бер бина күзләремә чалынды. Аш-су исен сизенүдән тәкатем бетеп, аның «Ашханә» икәнлеген тоемладым. Монда өстәлләрне җыештыручы бер апага кайгымны сөйләдем. Ул җиңелчә генә булса да, минем тамагымны туйдырды һәм кесәмә бер телем ипи тыгып, кичен, әгәр авылыма кайтып китә алмасам, яңадан бирегә килергә кушты. Бу бәхет иде. Мин аңа хәзер, бу вакыйгаларга җитмеш биш ел үткәч, билемне бөгеп, рәхмәтләр әйтәм.

Йөкчеләр, машина шофёрлары арасында авылдашларымны эзли-эзли, минем күзләрем күгәрде. Хәлләрдән тайдым. Вакытны сузу өчен бер өй нигезенә утыргач йоклап та киткәнмен. Уянып, яңадан станса буйлап йөрергә чыгам. Тимер юлдан килгән һәм үтеп киткән кап-кара паровозларны карарга барам. Инәмне юксынып елый-елый шешенеп беттем дисәм дә була. Көн кичкә авыша башлады. Мин инде кунар урын эзләп, тагын Әкчин буйлап киттем. Өй нигезендәге апаларга тагын да зарымны сөйләдем. Алар мине «Борчылма, машинаңны табарсың. Шушында утырып, үткән машиналарны гына күзәт», – дип, мине юаталар иде. Менә авыл буйлап мөгри-мөгри сыер, аннан вак мал көтүе дә кайтты. Аларның күзләре бик моңсу иде. Мин үзебезнең малларны сагынган идем. Елыйсым килеп китте. Әкчин маллары арасыннан мин үзебезнең малларны эзләдем. Офыкта күңелне көйдереп, шәфәкъ кызарды. Шулчак каршыма минем «МАЗ»га охшаган машина суырылып чыкты, аннан кабинадагы берәүнең күзлегендә тәмам баеп барган шәфәкъның көчле алсуы ялт-йолт итте! Бәрәкалла! Минем бабам түгелме? Ул бит! Габдулла бабам! Машинаның туктавын, бабамның мине үзенә чакыруын көтеп тә тормый йөгереп барган уңайдан туп-туры аның кабина баскычына сикерәм һәм бабамның тез башларына менеп кунаклыйм!

Куанычтан күзләремә яшь бәреп чыга.

– Кайда йөрисең син, таз малай! – дип, ачулангандай итә миңа бабам. – Без сине кайтыр дип авылда күпме көттек! Инәң елый да елый...

«Таз малай» дип, бабам дөрес әйтә: мин үзем таз булмасам да, безнең авылда барлык Хәлимовларны «Таз» дип атыйлар. Моңа беркем дә, шул исәптән мин дә, каршы торалмыйм һәм үпкәләмим.

– Менәтерәк... Әүвәлдә әниең һәм Гөргери Әликсәевич белән без сине кайтмады микән дип, авыл буйлап эзләдек. Инде көн уздырып, ыштан туздырып, Әкчин буйлап эзлибез, ә син монда, өй нигезендә, арка кыздырып ятасың икән! – дип дәвам итә бабам, миннән берни сорашып тормыйча. Һәм ул минем руль артындагы кырык ел кырынмаган шофёрым Гөргери Әликсәевичкә дустанә караш ташлап елмая. Әкчиннән кайтып керергә дә өлгермичә, шушы бала хакына яңадан Әкчингә юлга чыккан Гөргери Әликсәевич, сиңа зур рәхмәт!..

Гөргери Әликсәевич исә миннән карашын яшерә, миңа таба бөтенләй дә карамый. Ә мин, бабамның тез башында утырган сәяхәтче, телсезгә әйләнеп, бу мизгелдә беркемне дә мактый да, хурлый да алмый идем. Бәгъремдәге ниндидер көч миңа кичергәннәремне беркем белән дә уртаклашмаска куша иде. Алар өчен мин һаман да сөннәтеннән чыкмаган, иң мөһиме – Дим буйлары тауларын, аның вак балыкларын күрмәгән сабый бала идем...

Без бер кабинадагы өч кеше, ничек дүрт төрле итеп бөртекләрне саклавыбыз турында ләм-мим дәшмибез.

Алда юл. Алда безне көмеш өянкеле, ак каенлы Кәркәлебез көтә...

## Бисмилла әйтсәң, җитә ул

Ахирәттә «Күршеләрең белән ничек яшәдең?» дип соралыр, ди. Балачагым ачлык-юклык заманнарына туры килсә дә, җаным-тәнем белән берегеп, ут-күршеләрем (бездә «ут-күршесе» диләр) белән яхшы яшәдем, беркайчан да низагка кермәдем, дип әйтә алам.

Күршеләр дигәндә, минем телемә бал тәме калка. Бу тәм мине урам рәтебез буенча алдан һәм арттан, уңнан һәм сулдан булган күршеләремне исемә төшерә. Мин аларның исемнәрен архивтан тикшереп түгел, ә яттан беләм. Исемнәр ике катламнан тора. Беренче катламда борынгы төрки-болгар, саф, чиста мөселман исемнәре. Алар тарих сагында торган һәм тарих сагына торган исемнәр. Ут-күршеләрем арасында ике Мөсаббиха, Әбелшахма, Сәйфетдин, Гайнулла, Лотфулла, Ярыяхмәт, Садыйка, Сания, Гөлфани, Гөлзифа (Гөлди) иде. Нинди мәгънәле, нинди матур исемнәр! Бу кадәр матур исемнәрне йөртеп, ничек начар кеше буласың, ди?

Икенче катламда югарыда телгә алынганнарга көчләп өстәлгән, беренче катламны юкка чыгарган «валерьянка»лы исемнәр. Фәнситләр, Маратлар, Артурлар, Тимурлар, Валерийлар һәм башкалар.

Күршеләрем турында уйлау белән минем тирәмне бал тәме баса. Онытылмас тәм. Балачагымның бал тәме. Сүзләре бит ничек килешеп, ятышып тора! Бу бал тәме авыр заманнарда да ничек итеп матур яши алу өлгесен күрсәтә һәм раслый. Каршыбыздагы Ярыяхмәт бабамның карлыган-куражиләк бакчасы һәм ике баш умартасы бар. Алар безнең юанычыбыз. Серле, безне кыш чыгып көткән почмагыбыз. Җәйге чилләдә умарталар күчләрен аерып чыгаралар һәм Ярыяхмәт бабай тас кагып, очып китәргә җыенган күчне тотып калырга, читкә җибәрмәскә тырыша...

Ярыяхмәт бабайның тас каккан тавышы ишетелү белән без, сабыйлар, колакларны шомрайтып сагаябыз. Гүя без уянабыз. Көт тә тор, бабабыз умарталарын караячак һәм безне бал белән сыйлаячак, Алла боерса. Һәм шулай килеп чыга да! Миңлениса әби (әле күзе күпмедер күрә!) белән Ярыяхмәт бабай кычкырып азан әйтеп, Коръән авазларын яңгыратып намаз укый... Аннан алар безнең урам балаларын җыя, зур җәйпегә телгә йогарлык кына бал сала, кулыбызга кашыклар тоттыра да, безне, мөмкинлегеннән чыгып, җае килгәндә тезләндереп, җае килгәндә яткырып, йә утыртып, бал ашата (дөресрәге, ялата) башлый. Бер кашык бал, кашык сырты белән тәмләп, сагынып һәм бер-береңә сыгынып ялагач, бетми, урамга гына түгел, Кызыл Армиягә җитәр дәрәҗәдә арта. Кашык тавышлары калай тәлинкәдә такылдап кына тора. Беркем артыгын ашамый, аның артыгы юк та, әмма ул бар, җәмәгать, әмма ул, бисмиллаһ әйткәч, барыбызга да җитә!

Шушы без ялаган балдан барлык дөнья бал исе белән тула. Умарта кортлары иң газиз җан ияләренә әйләнә. Ярыяхмәт бабай безне Коръән аятьләре укып, дога кылдыра һәм үзләре яшәгән мөлаем йортның такта капкасына кадәр озата чыга.

Без бу баллы йортка карап, хәтта кышкы карларда да куанабыз.

Һәм бер кашык балдан мәңге баллы, мәңге маллы булып, дөньяга таралабыз.

Бисмиллаһ әйтсәң, җитә ул!

## Юллар башында

Әйе, «Әти-әни, миңа ничә йөз яшь?»

Истәлекләремә шундый көтелмәгән исем куюыма кемдер аптырар да кебек, әмма ул, минем фикеремчә, урынлы һәм дөрес. Мин аларга башка исем таба да алмыйм кебек.

Әтиемне хәтерли алмасам да, миңа ул калдырган дөньяны яхшы хәтерлим. Мин шул дөньяда үстем. Шул дөньядан чыктым. Аны нәселебезгә картатам Габделвәли һәм картинәм Гайнекамал калдырган. Атам-анам, туганнарым шунда яшәгән. Нинди иде ул дөнья мин белгәндә? Бердәнбер дип әйтерлек урамы белән Өязе һәм Кәркәле елгалары буйлап ике чакрымга сузылган авылның Кәркәле елгасы күперенә җитәрәк төшендә мәһабәт, калай түбәле, ике якка ачыла торган урыс капкалы, алты почмаклы, ике яктан өчәр, ягъни алты зур тәрәзәле карагай йорт. Безнең йорт. Йөзеңне Кәркәлетау артыннан күтәрелгән кояшка юнәлтеп, ишегалдына кергәндә, уң кулда түбә бәпкәләренә кадәр таштан салынган, түбәсендәге саламы кышкы кытлыкта малга ашатылган, нәтиҗәдә бастырыклары ачлыкның үзе сыман тырпаеп торган бик зур келәт, аңардан алдарак, төшкәч, колакларыңны туңдырырлык салкын кар базы, аннан эре, кызыл балчыгыннан алтындай сары салам җепселләре янып торган саманнан салынган күхнә, аннан – абзарга кадәр сузылган япма, анда сыер бәйләп сава торган баганалар, аннан – бүрәнәдән салынган, мөгезле эре һәм вак мал өчен куш абзар, аннан чалбар балагы кебек тар, озын, мәйданы белән зур булмаган, нибары уналты (йорт урыннарын да керткәндә егерме) сутыйлы, буе белән Кәркәлетауга кадәр күтәрелгән бәрәңге бакчасы. Бу уң яклап булды, ди. Хәзер инде сул яктан килик, шул ук ишегалдыннан, болдырдан, димәк, Кәркәлетауга карап барганда – утын һәм утынлык, аннан – суы күз яше кебек тозлы булып, малга гына эчерә торган кое (баганасы юк иде, аны үсмер чагымда иптәшләрем ярдәме белән агачын Кыска Кул урманыннан алып кайтып, үзем куйган идем), аннан шул ук тар балак булып бәрәңге бакчасының икенче, сул тарафтагы яртысы, аннан – суынган таш өеме генә калган мунча урыны, аннан – тауга кадәр тагын да бәрәңге бакчасы... Инәмнең йорт-җирне исәпкә алып йөргән силсәвит агентларына «башка кешеләрнең йорт-җирләре кырыгар сотка булуын, ә минә аның бакчасының йорт урыны белән нибары уналты соткадан да артмавын, аны киңәйтүләрен үтенгән, алынган бәрәңгенең дүрт ир балага, малга ашатырга җитмәвен» әрнеп-әрнеп сөйләгәнен һич онытырлык түгел. Шулай да, ихатабызга сәяси яктан бәя биргән очракта ул сыйнфый дошман – кулак итеп тамгалану өчен классик мисал булган инде...

Ә минә әниемне бик яхшы хәтерлим. Әмма ничек кенә сәер күренмәсен, мин аны беләм дип раслый алмыйм. Сәбәбе бик гади: белеп өлгермәдем. Ул бакыйлыкка киткәндә, мин хәрби хезмәттәге солдат, нибары унтугыз

яшьтә идем. Әйдәгез, бергәләп уйланыйк: шушы унтугыз елымның күпме өлешен әнкәм тәрбиясендә үткәрдем икән? Җиде яшьтән унбер яшькә кадәр – авылыбызның башлангыч мәктәбендә белем алганмын. Тулысынча әнкәм кочагында булган бердәнбер чор булган бу. Минем иң бәхетле елларым. Бишенче сыйныфтан, бу кочактан очып чыкканмын һәм шуның белән «бәхетле ана тәрбиясе» чоры тәмамланган. Сигезенче сыйныфка кадәр мин көн саен кара таңнан торып, ыжгыр суыкларда һәм кара яңгырларда, елның теләсә нинди фасылында, әнкәмнән аерылып, аркадагы букчама китап-дәфтәр белән бергә, булса, бер кыерчык икмәк һәм мичтә тәгәрәткән чикмәнле бер-ике бәрәңге салып, бер кат ситса чалбарда, бер кат юка сырмада, бүгенге мәктәпләрдәге шикелле яхшы ашханә ашларын күрмичә, ачлы-туклы, көн саен, иртәнге briштән кичке бишләргә кадәр, баруы-кайтуы ун чакрымга баскан юлны үтеп, белем эстәгәнмен. Һәм бу хәл көн саен кабатланган. Көн саен!.. Моны, тулысы белән ана тәрбиясе алганмын дип булганмы? Юк, әлбәттә. Сигезенчедән унынчы сыйныфны тәмамлаганчы аркама бер чиләк бәрәңге, булса, бер баш ипи, бер йомарлам май, тагын да булса, берәр кисәк ит ишарәте салып, атна саен илле чакрымга якын юл үтеп, урта белемле булганмын. Бер генә фәннән өчлесе, калганнары дүртле-бишле генә булган өлгергәнлек аттестаты алганмын. Тумас борын «читкә китәргә» мәҗбүр ителеп, берсе икенчесенә ялганып килгән көндәлек газапларны «ана тәрбиясе» дип раслый алабызмы? Бу бит әниле килеш әнисез яшәүгә тиң. Гомернең өчтән ике өлеше анамнан читтә, салкын дәүләт интернатларында үткән ләбаса!

Унынчыны тәмамлаганнан соң мин үз теләгем белән хезмәткә – туган авылыма кайттым. Һич арттырмыйча әйтәм: минем бар теләгем авылда калу, ат караучы – конюх булу һәм Ингель абыем Ишембайдагы икенче санлы һөнәрчелек училищесена киткәннән соң ялгыз калган анамны тәрбияләү иде. Әмма колхозыбыз баш бухгалтерының авылдашларга дигән печәнлекләрне читкә сатуы турындагы сигналым район газетасында басылганнан соң купкан җәнҗал минем алга кичектергесез рәвештә авылдан китү шартын куйды. Мин Октябрьск шәһәрендәге бораулаучылар хәзерли торган техник училищега китеп бардым. Биредә алты ай укып, бораулаучы ярдәмчесе һөнәрен үзләштердем. Безне бергә укыган төркемебез белән практикага Каспий диңгезе буендагы Калмык АССРга – Стрелец бораулау конторасына җибәрделәр. Монда бер елга якын эшләдем. Үз эшемне бик яраттым. Әмма сагыну чире белән түзә алмас дәрәҗәдә чирләдем. Саргайдым-киптем. Туган якларга кайтып китәргә мәҗбүр булдым. Туган авылыма юл бикле иде. Октябрьскиның «Девон» кунакханәсенә кайтып егылдым. Нишләргә дә белмичә ун көн түшәмгә карап ятканнан соң «тукта, миңа берәр эш эзләргә кирәктер бит» дигән фикер башыма килде. Шулчак эткәмнең сугышка киткәнче эшләгән эше – укытучылык һөнәре исемә төште. Әмма мин, уйлавымча, бары тик татарча гына укытучылык итә ала идем.

Биредә тагын да бер «әмма» бар икән: «социалистик юл белән бик тә алга китеп, туган телендә укытудан туктаган» шәһәрдә татар мәктәпләре юк иде. Алар «болай да алга киткән халыкка кирәкми» иде һәм әле булса «кирәкмиләр». Мин Туймазы районының мәгариф бүлегенә киттем.

Анда мине Балтай дигән авылның урта мәктәбенә «укытучы» итеп җибәрделәр. Аның исеме генә «укытучы» булган икән. Бирелә мине мәктәп каршында эшләп килгән акылга зәгыйфь балалар мәктәбенә тәрбияче итеп тәгаенләгәннәр. Мин барыбер эш табудан шатланып килештем: авыл бар! Яшьләр бар! Ашка катарга катык бар! Мин бу эшнең нindirәк, хезмәт хакының күпме икәнлеген сорашып-белешеп тә маташмадым. Әйткәнемчә, авылның катыклы ашларын, яшьләрен һәм елга буйларындагы зифа талларын үлеп сагынган, күкрәгендә энергиясе ташып торган яшь егет, дөньямны онытып эшемә бирелдем. Аңлашылды: икенче-өченче сыйныфларда укырга тиешле булып та һаман беренчедә укып азапланган, баш миләренең үсеше тоткарланган, күп очракларда гәүдәсенең нindider әгъзасы бигүк төзек булмаган, ачыктан-ачык әйткәндә, ярым-йорты гарип балаларны тәрбияләү, аларга хәтта шартлы рәвештә ата-инә булу икән минем бурычым. Ничек кенә булмасын, мин үз эшемне бик тә яраттым. Еш кына төнгелеккә фатирыма кайтмыйча, мәктәбемдә куна калам һәм балаларга кызыклы китаплар укып, аларның киемнәрендәге сәдәпләренә кадәр тага, тишек-тошыкларын ямый идем. Шушы җиңел булмаган шартларда мин яшьлегем хыялларына да тугры идем. Авыл яшьләрен оештырып, авыл клубында тамаша куярга да форсат таптым. Әле бит мин үзем дә ана куенынннан чыгып өлгермәгән унтугыз гына яшьлек егет кисәге идем!

Миңа Балтай мәктәбендә озак эшләргә туры килмәде. Гүя Туймазының хәрби комиссариаты, план үтәү өчен мине генә көтеп торган. Армиягә хезмәткә алынуым турындагы чакыру кәгазе мине кичектергесез рәвештә Балтайның үзенә үк килеп тапты. Хәрби хезмәткә без авылдан икәү – Фатих дигән егет белән киттек. Фамилиясе, ялгышмасам, Рәхмәтуллин иде бугай. Күп гомер үтте бит. Ә менә Балтай урта мәктәбе, шул исәптән үзем тәрбияләгән балалар белән хушлашуым хәтердә яхшы сакланган. Алар бу вакыйганы өлкәннәргә караганда тирәнрәк аңлаган булган, күрәсең: гүя мине армиягә җибәрмәс өчен безне алып китәргә тиешле йөк машинасының әрҗәсенә менеп утырдылар да: «Сездән калмыйбыз! Без дә армияга барабыз!» – дип төшмиләр тек, төшмиләр бит! Мин аларга озакламый әйләнеп кайтачагымны яхшылап аңлатканнан соң, төштеләр.

Әнием мине озатырга килә алмады. Гомер буе авылдан чыкмаган ятимә хатынның ялгызын гына Миякәдән Туймазы кебек ерак җиргә юлга чыгару җиңел түгел иде. Хәер, военкоматтан чакыру алганнан соң, мин бер генә көнгә авылга кайтып, әнкәм белән хушлашып килгән идем. Балтайга мине озатырга күптән түгел армия хезмәтеннән кайткан бертуган абыем Ингель озатырга килгән иде. Ихластан да нәкъ халык җырындагы кебек: «Берсе кайта, берсе китә, берсе комиссиядә» дип җырларлык булган икән шул...

Армиядә сержантлар әзерли торган танк полкы мәктәбендә укыдым. Мин ни өчен бу хакта басым ясап язам әле? Үземнең әтисез калган ятимлегемне армия шартларында да дәвам ителгән булуын, хәтта ки аның тагын да тирәнәйгәнлеген исегезгә төшерү өчен генә язам. Бер ел чамасы хезмәт иткәч, 1962 елның ноябре башында, миңа коточкыч фаҗига кичерергә туры килде.

## Инәм белән мәңгегә хушлашу

Мин тумышымнан бик сагына, юксына торган кеше. Бу хакта кабатлансам, кичерерсез. Иҗатымның башы «Сезне юксынам» дигән шигъри цикл белән башлануы очраклы хәл булмаган, күрәсең. Ул чорда армиядән кайткан Ингель абыем урманчылык хуҗалыгында «лесник» булып эшкә урнашкан иде. Мин аңа «Син – лесник, аларның сүзе үтә, – дип язган идем үземә хас табигыйлек белән. – Мин әнине һәм сине бик тә сагындым. Полк мәктәбендә йөзләгән курсант, отпускага кайту мөмкин түгел. Сезне кайтып күрү өчен военкоматтан берәр сәбәп тапкан юньле генә телеграмма сук әле...» Телеграмма озак көттермәде. Ул көнне безнең взвод каравылда иде. Кичен, каравылдан кайтып, автоматымны пирамидага урнаштырып маташканда:

– Халимов, телеграмма! – дигән өндәү ишетәм.

Кулыма кунган кәгазьгә ашыгыч рәвештә күз йөгертәм: «Мать умерла. Срочно приезжай».

Беренче итеп килгән фикер – вәт, булдырган! Маладис, абзый кеше! Үзем дулкынланудан нишләргә дә белмим. Бер яктан эчемнән генә куанам: абыем военкоматларның тынычлыгын куптарып, шундый көчле тәэсир ясый торган сәбәп табып, телеграмма суктыра алган! Хәтта аңа хәрби комиссариаттан раслатып, мөһер дә куйдырган. Икенче яктан – борчылам да. Мондый хәлләр белән шаяртмыйлар дип, эчемнән генә сызып, кара кайгыга батам. Әмма һаман да бу хәлнең булуы мөмкин түгел, дигән ышаныч белән башыма да китермим. Әниемә әле 52 генә яшь дип, үземне-үзем юатам. Янымда басып торган комбат – майор Попов телеграмманы укый да: «Это правда! Надо немедленно выехать, – ди. – Бүген шимбә көн. Командировка алыр өчен штаб эшләми. Көтеп торырга мөмкинлек юк. Кемнең кесәсендә күпме акча бар, өстәлгә чыгарып салыгыз... – Үз кесәсеннән ун сум өлеш чыгара. – Син кайдан әле? Башкортстаннан? Аксённан? Безнең Самара Аксённан качкан җир түгел. Биш-алты сәгатьлек юл». Имеш, мондый «кеше ышанмастай хәбәр»гә майор кадәр майор да ышангач, аның «хак түгеллегенә инану» миндә тагын да көчәя төшә. Юлга акча мәсьәләсендә ярдәм иткәннәре өчен иптәшләремә, командирым майор Поповка зур рәхмәт. (Казанда, КДУда укыганда, 1966 елда булса кирәк, без инде подполковник Попов белән Бауман урамындагы китап кибетендә очраштык. Ул минем әдәби уңышларым белән кызыксынды. Теге вакыйганы исенә төшерде. Колагыма пышылдап кына болай диде: «Вьетнамга җибәрәләр. Алда күрешергә насыйп итсен».)

Солдат кесәләреннән җыйналган акчага мин төнгә каршы Самара вокзалыннан юлга да чыктым. Таң атып, иртәнге сигезләргә Аксён станцасына кайтып та төшәм. Аның миңа күптән таныш вокзалының кушучтагыдай җылысын тойгач, туган якны күрү куанычыннан үксим. Фаҗигале хәбәргә ышану дигән нәрсә уйда да юк. Тукта, әнкәй янына бер күчтәнәчсез кайтып булмый бит. Кесәмне кармалыйм. Хезмәттәшләрем биргән акчадан калган күчтәнәчлек өлеш бар икән. Инәм дүрт почмаклы бәс төстәге карамель ярата. Сәгать тугызга кадәр станца кибетенең ачылганын көтәм. Ниһаять, кибет ачыла. Бәхеткә, теге карамель дә бар икән. Кәнфитле

төенчекне юл капчыгыма салам. Хәзер миңа кырык чакрымдагы Миякәгә кайтырга кирәк. Аннан тагын егерме чакрым – авылга. Ул заманда такси, шәхси автомобиль, маршрут автобуслары дигән нәрсәләр юк иде. Барлык транспорт чарасы – ат. Миякә борылышында миннән башка беркем юк. Шулчак битне чәнчеп, вак күзле яңгыр ява башлый. Ул энәләр кебек тәнгә үтеп керә. Мин шинельдә. «Тукта, – мин әйтәм. – Нишләп әле мин үзебезнең авыл советына шалтыратмыйм?» Әнә бит почта! Анда телефон-автомат бар! Алтын тапкандай куаныч белән почтага йөгереп керәм һәм Олы Кәркәле авыл советына шалтыратам. Телефонда – кардәшем, колхозыбызның зоотехнигы Гаяз абый Хәлимов. «Гаяз абый, мин солдаттан кайтып төшкән идем. Аксёнга таба берәр атмы, машинамы...» Сүземне әйтеп тә өлгерә алмыйм, Гаяз абый: «Их, туган, кайтып җитешмәдең, әниеңне кичә җирләдек бит...» дип, һушымны ала...

Телефон трубкасы гүя тамырыннан өзелеп, кулымнан төшеп китә. Берничә секундка мин аңымны югалтам. Идәндә ачыргаланган телефон трубкасының кемнедер – мине мәллә? – чакырып зеңгелдәвеннән айныйм. Менә шулай итеп, әтиемнән үк килгән ятимлек мине Аксенда куып җитте. Тома ятим итте. Әтием шушы стансадан фронтка китеп һәлак булган иде. Хәзер бу станца мине әнисез дә итте. «Әти-әни, миңа ничә йөз яшь?» диярсең. Тукта, миңа нишләргә кирәк әле? Башымда бер уй: «Авылга кайтырга? Нигә?» Меңләгән сорау баш миемне бораулый. Авылга кайтырга? Нигә? Кемгә? Яңгыр яңадан коеп ява башлый. Миңа бертуган абыем янына кайтырга кирәк икән. Нигә? Мин әле кая китеп барам? Әнием кая киткән? Нишләп ул юкка чыксын, ди?! Мин урам чатындагы телеграф баганасы төбендә үзем дә баганага әверелеп катканмын. Шинелем балчыкка капланып, лычма су булды. Сыгып алырга мөмкин. Тукта, бу озын йөк машинасы кая бара? Трубовоз икән. Бораулаучылар машинасы. Мине алмас микән? Әүвәлдә шофёр «Урын юк» диде. Мин үземә ничек кенә булса да кайтырга кирәклеген аңлаткач, ул бераз йомшарды. Әмма мондый куркыныч йөкле кузовка пассажир алырга башым ике түгел дип, тагын да киреләнде. Мин үземнең дә һөнәрем белән нефтьче-бораулаучы икәнлегемне сөйләп, аңарда үземә карата профессиональ теләктәшлек капшап карадым. Янә дә елар чиккә җитеп ялындым. Ниһаять, ул килеште. «Кузовка сикер. Әмма сак бул, борылышлардагы чалуларда торба астында калып изелә күрмә». Мин бу минутта шашкан хәлдә идем. Нигә? Изелсә, ни була? Кемнәрнеңдер уйлавынча, кырык чакрымлык алама, чокырлы-чакырлы юлдагы транспортка минем шушы үземнән дә артык шашкан торбалар астында калырга теләп кенә утыруым мөмкин иде. Бу машина йөртүченең холкына бәйләнгән нормаль кеше халәте түгел иде. Мине шушы иләс-миләслеккә керткән фаҗига инде икенче, үз тормышымдагы яңа фаҗигагә тару мөмкинлеге белән яный иде. Миңа гүя минем белән нәрсә булса да, барыбер иде. Гүя ул тормышымдагы иң зур фаҗигамне оныттырды. Үземнең унтугыз яшьлек гомеремдә мин беренче тапкыр бер кайгының икенче кайгыны, бер куркынычның икенче куркынычны баса төшүен, йотуын кичердем.

«Әти-әни, миңа ничә йөз яшь?..»

Менә шушы минутларда яратылгандыр инде бу китапның табигый булмаган исеме.

Борылышларда торбаларның сыкрана-сыкрана, бер-берсенә бәрелеп, мал суйган тавышлар чыгарып, үкерә-үкерә, минем өскә килүләреннән качарга, котылырга теләп, йөк өстендә сальтолар ясый-ясый, бии-бии, тегендә-монда сикерә һәм бер төштән икенче төшкә күченә-күченә, ниһаять, без Миякәгә, Миякәдән минем юл уңаендагы Ишле тарафларына киттек. Мине инәй хәтере озата бара иде. Гүя шушы йөк өстендәге матди тарлавыкта, яңадан котырып коя башлаган яңгыр астында, мин анамның тәрҗемәи хәлен-биографиясен күз алдыннан үткәрә идем...

...Минем инәм Хәлимова (тумышыннан Хисамова) Минсорур Шиһабетдин кызы, таныклык белешмәсе буенча Җилдәр улысының Кәркәлетамак авылында (икенче исеме Бәләкәй Кәркәле) 1910 елда урта хәлле крестьян гаиләсендә дөньяга килгән. Әмма ул үзен 1909 елда туганмын дип исәпли иде. 1928 елда, унсигез яшендә, әтәй-инәенең йорт-нигезеннән бер тыкрык, ике бәрәңге бакчасы аша гына яткан Хәлимов Нәҗметдин Габделвәли улына кияүгә чыга һәм аның белән гомер итү чорында (1928–1942) алты бала таба. Шулардан бер мин, үзем генә исән калганмын. Аллаһы Тәгалә озын вә бәрәкәтле гомер бирсен.

Инәй классик мәгариф күзлегеннән чыгып караганда, «белемсез кеше» иде. Ул үзен адәмзат итеп тоеп, укый башлыйсы чорда революция давылы күтәрелеп, искечә, гарәби әлифба нигезендә уку гамәлдән чыгарыла. Татар өчен бик тә уңайсыз әлифба – безләрне надан калдырган «балта әлифбасы» – кириллицада белем алу гамәлгә куелып өлгермәгән була. Шулай итеп, ул ике-өч төр мәгариф арасында ятимә кала. Әмма инәбез ифрат та башлы, якты фикерле, хәзерге заманда бәлки югары белемгә торырлык зиһенгә ия иде. Шул ук вакытта ул үзлегеннән гарәпчә хәреф танырга һәм кулыннан килгән тизлек белән укырга, кирәкле документларга, аның теле белән әйткәндә, халыкны «талый торган налук кәгазьләренә» фамилиясен зур хәрефләр белән тулысынча «Хәлимова» дип кул куярга өйрәнгән иде, мәрхүмә. Бу хакта үзе: «Укытучы хатынына томана булу оят. Әлегә авазларны өйрәнеп, кирәк вакытта фамилияңне тулысынча имзалап тор да, форсаты тугач, сине үзем укытырмын, дия иде Нәҗметдин», – дип ныгытып куя иде ул үзенең бу мәсьәләгә карашын.

Ул биш вакыт намазын, еш кына хакимият вәкилләренең күзләренә чалынмыйм дип, аларның сәяси басымы астында, яшеренеп, бүленгәләргә мәҗбүр булып (заманы бит нинди!), даими рәвештә башкарырга тырышты. Хәтта кызу эш өстендә булса да, аеруча кичләрен, йокларга ятар алдыннан, көйләп, үзенә хас мәкам белән гарәби хәрефләр өстеннән бармакларын йөгертә-йөгертә, «Коръән»нән сүрәләр укырга тырыша иде. Ул дини бәйрәмнәрне тирәнтен зурлый, җентекле мәгънә белән билгели.

Яңгыр һаман да, инде бармак башы кадәр эре кисәкләп, коеп ява иде. Менә Ишлегә дә килеп җиттек. Зират каршында, шофёрга рәхмәт әйтеп, машинадан төштем. Кәркәлетамак юлына борылдым. Әмма мине яңгырдан тыш икенче бәла сагалаган – авылыма юл юк иде: Ишле белән Имәнлек урманы арасындагы ике-өч чакрымлык юл әле кичәле-бүгенле генә көзге парга сөреп ташланган. Берничә адым атлавым булды, кирза итегем теземә

кадәр диярлек сөрентегә кереп батты. Аякларны сөйрәү авырлашты. Бу тиз арада хәлемне алды. Ач булсам да, ачлыктан түгел, авыр кайгыдан өзлеккән идем мин. Атлагандай итәм дә тезем тотмый егылам. Иң кыены – утырып, йә булмаса, чарасызлыктан, инде тәмам аптыраганнан, каядыр янтаеп, терәлеп, аякларыңны ял иттерү мөмкинлеге бөтенләй юк иде. Озак та үтми орлыксыз калган ашказаным ач тегермән ташларын әйләндерә башлады. Мин инде ике тәүлеккә якын ашамаган идем. Ифрат та үзле, сары камыллы балчык белән сылашкан итекләремне авырлык белән алыштыра-чалыштыра, кечкенә адымнар ясап өстерәп азаплана идем. Читтән караганда сөрелгән җирдә түше белән җир сөреп барган һәм үзе дә кара җир рәвешенә кергән шинелемнең чабу очларын бил каешыма кыстырган хәлдә мин бу минутта үз артымнан шушы чем-кара басу белән бергә гүя ул да үз анасын югалтып кара кайгыга баткан барлык Җир шарын өстерәп барган кешене хәтерләткәнмендер, мөгаен.

Сукмаксыз-нисез, буразналар белән ерткаланган басу аша юл сабу торган саен кыенлаша бара иде. Шулчак әнкәмнең үлем хәбәре турындагы кара телеграмма күз алдыма килде. Кинәт бер секундка күз алларым яктырып алды һәм тезләремә китереп сукты. Мин тагын егылып киттем. Соңыннан аңлавымча, мин гомеремдә беренче тапкыр аягөсте инсульт дигән халәтне кичергәнмен икән. Ходай биргән сиксән яшьлек гомеремдә мин бу инсультларны ничә тапкыр үткәрдем икән дип уйлыйм хәзер.

Әлегә без басу белән генә икәүдән-икәү алыша идек. Мин авырлык белән тезләнә алдым. Аннан аягыма да бастым. Колак төбемдә әнкәм тавышы белән кемдер пышылдады: «Тамагыңны ялга. Аркаңдагы капчыкта». Әйе, минем әнкәмә күчтәнәчкә дип алган кушуч кәнфитем бар иде. Капчыгымдагы өлештән берничә карамель алып, берсен авызыма кабып суыра башладым. Анам рухы булып гүя миңа илаһи көч керде. «Теге агачка кадәр бер кәнфит, Имәнлек урманы авызына кадәр икенче кәнфит». Мин шушы араны кайда атлап, кайда мүкәләп диярлек ике сәгать чамасы вакытта үттем һәм урман аша Өязе үзәнлеге буйлап сузылып яткан туган авылымны күрдем. Мин түзә алмыйча үксеп елап җибәрдем. Әйе, ул өнсез һәм тынсыз иде. Ярдәмгә киләлми иде.

Мин Имәнлек урманының «Кантур тавы» дигән түбәсендә идем. Риваятьләр раславынча, XVII-XVIII гасырларда биредәге карурманнарда бакыр чыгару рудниклары һәм шул рудникларның конторалары эшләгән. «Кантур тавы» дигән атама шул заманнардан калган. Минем кайгымны уртаклашырга дип, гүя борынгы бабаларыбыз килеп чыгар кебек иде... Моннан туган авылыма күренеш тагын да киңрәк ачыла. Әнә, 1918 елда бабайларыбыз ташкойма белән уратып алган зират. Мин гүя йөрәгемне учыма салдым. Зират тарафына карарга һушым җитми. Йөрәгем ярылыр дип куркам. Гүя ул якка миңа карарга ярамый. Анда кара кан упкыны. Кан юшкыны. Аннан газиз әткәмнең, газиз туганнарымның тәрәзә пыяласыдай таш атудан чатнаган карашлары карап тора. Фронтларда һәлак булган авылдашлар, ятим балалар, ятимә солдатка-хатыннар... Чынлап та зират ягына карарга курка идем. Гүя минем үзем белән нәрсәдер булыр, җир җимерелер, күк йөзе җиргә төшеп капланыр кебек. Андагы җир куенында мине имезеп үстергән һәм минем кадерләремне күрмичә үлеп киткән газиз

әнкәмнең гәүдәсе ята. Мөмкинме бу? Нигә бу кадәр гаделсезлек? Хакмы бу? Мин аны саклый алмадым! Ачлыкларда, юклыкларда мине ашаткан-эчерткән, кеше итеп аякка бастырган, миңа пакь тормышка иман-ышаныч биргән әнкәмә галибанә рәхмәтләр әйтеп, зурлап, тәрбия күрсәтеп тә өлгермәдем. Ул тормышка шулай изелер өчен генә туды микәнни? Әйтерсең бу үлемдә мин үзем генә гаепле идем. Җир йөзендәге барлык имансыз-кансыз кыйралышларда, минем әнкәмне шундый яшь килеш алып киткән сугышларда мин нишләптер үземне генә гаепли идем... Тукта, ул нинди сәбәп белән шулай кинәт кенә өзелде икән? Ул кичергән хисапсыз кайгылар алып киттеме аны? Дүрт ел буе передовойда булып, сугыш бетәргә биш ай калганда гына һәлак булган атам... Әнкәмнең Кралов урманнарында ачлы-туклы килеш фронт өчен умарта сыман юан имәннәрне аударулары... Кипкән телләрдә ялмарга төкерек тапмыйча, дин кушканча уразалар тотып, көненә дүртәр йөз көлтә бәйләүләр... Безне, дүрт ятимне тәрбияләп үстергәндәге зарлар-юклыклар, кайгы-борчылулар... Сугыштан соңгы ачлыкта ун күз белән карап торган бердәнбер сыерыбызның бозаулый алмыйча зыянлавы... Абзарыбызга бүреләр төшеп, өч сарыгыбызны бугазлавы... Йортыбызга төшкән караклардан өс киемнәребезгә кадәр урланулар... Азмы алар, минем газиз әнкәмнең гомерен кыскарткан, вакытыннан алда гүргә керткән вакыйгалар!..

Мин ярсыйм. Ат юлын ташлап чыгып, басулар, иңкүләр һәм чокыр-чакырлар аша зиратка таба турыдан юл сабам. Тез башларыма җиткән Өязе елгасын ерып, суны – суга, утны утка тапшырып, турыдан, кызыл балчыклы текә ярларны очып диярлек үтеп, мин зиратыбызның таш коймасына килеп капланам... Аһ, әнкәм!.. Кайда син?! Әлбәттә, мин әнкәмнең зиратның кай төшендә җирләнгәнен белми һәм белә дә алмый идем. Исерек сыман, аякларым кай тарафка тартса, шул тарафка бардым. Әмма мин дөрес юнәлеш белән барганмын. Күрәсең, мондый хәлиткеч мизгелдә миңа Аллаһы Тәгалә үзе юнәлеш биргән. Кесәләремдәге тиеннәре исәбенә, мине хәбәрсез килеш әнкәм рухын яд итәргә кайтарган хезмәттәш солдатларым, батальон командиры майор Попов, юл буендагы трубовоз йөртүче иманлы кеше үзе алып килгән мине бирегә. Ниһаять, зират капкасыннан кергәч тә, мин үзем эзләгән өр-яңа, кап-кара кабергә килеп капландым. Анда кагылган карама казыкның юнылган йөзлегенә Хәлимова Минсорур Шиһабетдин кызы дип язылган иде.

Бу минутта үземнең ниләр кичергәнемне аңлата алмыйм. Мин гүя тере түгел идем...

Әти-әни, миңа ничә йөз яшь?..

Соңыннан санармын: унөч адым. Бу кабер зират капкасын кергәч, унөч адымда булган икән. Ялгышмасам, инглизләрнең көндәлек фәлсәфәсе раславынча, унөч – сыналу саны. Бәхетлеләр саны түгел. Алда яшәләчәк, Аллаһ насыйп иткән, ягъни калган гомеремне мин шушы унөч адым аша кичерермен...

Әлегә мин бу кайгыдан исерек.

«Зияратка кергәч... унөч адым» –
Нигә әле искә төштегез?

Әле адым атлый алмаганга
Шулай күз алдымнан үттегез?
Нигә әле искә төштегез?
Бу арада кемнәр кая китте?
Намуслылар кайсы якка үтте?
Унөч адым. Гомер буе унөч
Адымны үтәлми хәлем бетте.
Җәсәдеңә туфрак салалмадым.
Бер тәүлеккә, солдат, соңладым.
Кабреңдәге казыкка кадалгач,
Исәрләнәм, диеп уйладым...
Күз алдыма бастыралмыйм... Гаҗәп! –
Кермисең төшкә дә – билләһи! –
Шул кадәр дә сөям – хәтерем җуеп,
Ходай итә сине илаһи!..
Нинди генәләр иде йөзең? Күзең?
Хәтерем рухы – бары елгадан
Каңгылдый каз: һаман зарлы, диеп,
Һаман ятим, диеп, бу бала...
Юк, юк, милләт ятим итәме соң?!
Син бит шундый йөрәк биргәнсең:
Тәнем дә юк минем – тоташ йөрәк,
Шундый йөрәк бирә алгансың да,
Җилкән булып җилгә сеңгәнсең...

Мине үзенә чакырган ниндидер аваз ишетәм.

Айнып китәм. Ташкойманың тышында авылымнан беренче булып күргән кешем – ут-күршем Зәргать абзый. Аллаһы Тәгалә үзе очраштырган, диярсең: ут-күршем үзе бит! Аның янында – Мәрьям Рәфыйкова, бәләкәй чакта «Ач балалар» йортыннан икәү бергә качкан идек. Зәргатьнең аңа өйләнүе, төп йорттан аерылып чыгып, авылның бирге очына күченүләре турында язганнар иде шул. Бергә икәннәр. Бик яхшы. Ниндидер зур мәшәкатьтән кайтып киләләр, күрәсең. Хәтеремә төшә: миңа өч-дүрт яшьләр чамасы булгандыр. Күршебез Зәргать, чолан тәрәзәсеннән өебезгә үтеп кереп, Гали абыйларым әвәләгән черек бәрәңге коймакларын урлаган һәм шуның өчен өлкән абыйлары Мөхәммәт тарафыннан каеш чыбыркы белән «Урлашма! Урлашма!» дип тукмалган, Зәргать исә минем күз алдымда «Абзыкаем! Бүтән урлашмам! Абзыкаем, бүтән урлашмам!» дип, һавага сарылып үрсәләнеп-үрсәләнеп елаган иде...

Әлегә аларның кулларында миңа кирәкле бер чиләк су икән. Рәхмәт. Диңгезен дә эчеп бетерерлек итеп сусаганмын. Чүмече дә бар. Кара кайгыда янып килеп үземнең үтереп эчәсем килүе исемә килеп, чиләктән су белән тулы чүмечне тартып чыгарам һәм аңа капланып, тын да алмыйча чөмерә башлыйм... Бер чүмеч... Ике...

– Кайгың зур, энем, әмма чамалап! – ди Зәргать. – Самагун куып киләбез! Мунчадан!.. Бура буратырга!..

Тормыш үзе шундый. Нәкъ кинофильм. Ике дә уйламыйча сюжет ясый да куя.

Мин егерме яшем өстендә иң ачы шәрабның да кайгыны баса алмавына үзем дә сизмичә инанып, яңадан үз әнкәм янына – зиратка юнәләм...

## Ач балалар йортында

1946 ел, аеруча аның кышы, үзенең үзәккә үткән салкыны, ачлыгы белән хәтердә калган. 4-5 яшьлек чагымда бу ачлык үзенең «фәнни-гамәли яктан камил» булуы, тормышта, ягъни хезмәттә һәм акыл-аңда коточкыч дәрәҗәдә нечкәлеге, күп тармаклылыгы, сугышта җиңеп чыкканнан соң тагын да көчәя төшкән фаҗигаи котылгысыз булуы белән аңыма уелган. Бәлки мин бала акылы белән ул заманнардагы авыр тормышны бер төрле киңлек, киеренкелек белән, ничектер уртаклап кабул итә алмаганмындыр? Мин вакыйгаларны дөрес, үз вакытларында, тиешле мизгелләрендә тотып алганмынмы, аларга хаккый-билхаккый бәя биргәнменме? Өч-дүрт яшьлек, әле балигъ та булып өлгермәгән сабыйның Сталин заманнарының коллык режимындагы, көтелмәгән барлык очраклы һәм табигый вакыйгаларын, анык, төгәл итеп теркәп тә өлгермәве, киләчәктә сагынычлыга әвереләчәк кайбер минутларының төбенә дә төшеп тормыйча, яхшы ат кебек, безнең якларда әйтелүенчә, юыртып кына үтүе дә мөмкин бит әле. Әйе, бик мөмкин. Әмма мин сикәлтәләрне «йөгертеп кенә» үтмәскә сүз бирәм.

Минем «детдомга» китү вакыйгасын гына алыйк.

Ничектер бер тапкыр, малайлар белән качышлы уйнаганда, мин үземне гаиләмнән, менә шушы минутта, еракка – абзар сәндерәсенә кадәр качып уйнаган малайларым – минем чыбыркы каешлары шикелле бергә ишелеп үскән яшьтәшләремнән аерып, ниндидер «детдом» дигән куркыныч урынга җибәрергә җыенулары турында ишеттем.

– Анда эләккән балалар кире кайтмый икән! Аларны нифте базларына салып, майларын сыгалар икән! – дип тә өстәде арадан кемдер.

Мин шыр җибәрдем. Детдом шундый кайтмый торган җир була микәнни?

Минем кечкенә, әле башланып кына килгән тормышымда моңа кадәр «ранный, артиллерия, бомба, госпиталь, фронт, алгы сызык, наступление» һәм башка шундый таныш булмаган сүз-атамаларны күп тапкырлар ишеткәнем булса да, «детдом» дигән сәер, көпчәкле трактор кебек урынында дырылдап утырган сүзне ишеткәнем юк иде. Ул үзенең моңарчы ишетелмәгән катылыгы, гасабилыгы белән һушымны алган иде: нәрсә булыр бу «детдом» дигәннәре? Бу сүз шул ук вакытта буш йорт, буш бүлмә кебек, ниндидер көтелмәгән ераклык, чит-ят, ниндидер өнсез аралык белән яңгырап тора иде. Шунда ук мин күп тапкырлар күреп белгән, хәтта шуннан шулпа чөмергән калай кәтилүкләрнең үзара чәкешкән-чүкешкән тавышлары да ишетелә иде. Нигә буш аралык? Нинди кәтилүкләр? Бар, аңлат син аны кичә генә бишектән төшкән авыл баласына!

Ничек кенә булмасын, мин бу куркыныч сүздән айнып киттем. Өйгә кайтып керәм һәм хуҗаларча аһәң белән ярып салам:

– Мин сезнең детдомыгызга бармыйм! Анда балаларны үтерәләр!

Абыйларым бу сүзләрне ишетеп, урыннарында катып калдылар:

– Авызыңнан җил алсын!.. Син нәрсә сөйлисең?!

– Анда балаларны туйганчы ашаталар! – ди Гали абый.

– Көненә өч тапкыр! Корсакларын пух иткәнче! – ди Нияз абый.

Инәй-мескен бөтенләй дә югалып калды:

– Кем сине шулай куркытты? Хәзер һәммәгезне кычыткан белән!..

Иртәгә силсәвиткә барам да кемнең сәвит детдомы турында шундый әшәке хәбәр таратуларын әйтеп салам. Кем безнең сугышта үлгән ирләребезнең балаларын әллә ниткән детдомга җибәрү турында... шыр ялган сөйли?!.

Инәй сүзен дә сөйләп бетмәстән елый башлады. Соңыннан аңлашылуынча, инәбез кемнәрнеңдер балаларын ниндидер ачлар йортына җибәрергә җыенулары турында алдан ук хәбәрдар булган, әмма бу хакта тәфсилләп торуны кирәк санамаган. Аннан, чынлап та, балаларны вакытлыча оештырылган ач балалар приютына озаталармы, әллә «кайтмаслык детдом»га алалармы – моны кем белгән?!

Абыйларымның кайсысы бу хакта белеп, кайсысы бөтенләй дә белмичә, үзләренчә фикер йөртә һәм, күрәсең, һавадагы истән дә безнең гаиләнең озакламый ниндидер үзгәрешләр кичерәчәген алдан сизенә иде бугай. Алар мине, араларындагы төпчекне, тынычландырырга, хәтта бераз шыттырып булса да куандырырга тырышалар:

– Карбазларында бәрәңгеләре ишелеп яткан бай детдом бит ул!..

– Анда туйганчы сөт эчерәләр!..

– Киендерәләр!..

– Шартлаганчы ашаталар!..

Мин исә:

– Юк, мин детдомга бармыйм!

Абыйларым:

– Тиле син!

– Яңа күлмәк киярсең!.

– Бармыйм!

– Ашаганыңнан калганын безгә җибәрерсең!..

– Бармыйм!..

Минем башкаларыннан аерылып торган, коңгырт йөзле, ниндидер серле, бик тә кечелекле уртанчы абыем Нияз бар иде. Ул инде бишенче сыйныфка күчкән. Мин аны төштәге кебек кенә хәтерләгәндәй итәм. Шул көнне ул мине читкәрәк алып китә дә зур ышаныч белән минем «туңган» колакларыма пышылдый:

– Син детдомга түгел, нибары ачыккан балалар йортына... Приют дигән җиргә барасың... Мин синең урында булсам, йөгереп барыр идем, энекәем!.. Анда тәмледән дә тәмле... без гомердә дә күрмәгән прәннек бирәләр!

Күзләрем маңгайга сикерә. Чынлап та шулаймы?

Гүя бу сүзләрдән һушымны җуйгандай иләс-миләс торганда, Нияз абыем мине тагын да очындырып ала:

– Ач балалар приютына һәркемне дә алмыйлар. Прәннекне дә һәркемгә бирмиләр. Ә менә сиңа бирәләр. Чөнки син – сугышта үлгән укытучы... коммунист Нәҗметдин Хәлимов улы. Бар син анда, энекәш, бар...

Мин «прәннек» дигән сәер сүзне беренче тапкыр ишетә идем.

– Прәннек... нәрсә соң ул?

– Ул, энекәш... – ди абзый һәм кирәк сүзен таба алмыйча, телен йоткандай басып тора да әйтеп сала:

– Ул шундый нәстәкәй... Шундый нәстәкәй инде, хәтта аңлатып та булмый. Прәннекнең тышы да, эче дә шикәр генә!.. Бал гына! Авызда эри. Мин аны үзем дә тәмләп караган булыр идем! Миңа тәтеми шул ул...

Абзам телен дә шартлатып куя.

Телемдә шикәр дигән күзгә күренмәгән нәрсә эрегәндәй, колакларым шикәр кыштырдавыннан чукраклангандай булды. Күтеп торырга теләк тә, әмәл дә юк иде.

– Мин анда барам! – дип кычкырып җибәрдем һәм урынымда тыпырдап та алдым.

Икенче көнне кояш Кәркәле таулары артыннан күтәрелеп кенә чыгуга, безнең капка төбенә арбалы ат килеп туктады. Бригадирлар утырып йөри торган андый җәйпәк арбаны бездә «ящик» диләр. Арбада хәлсез башлары муеннарыннан салынып төшкән ике карт та бар. Хәтердә калуынча, беркем бернәрсә эндәшмәде. Кочаклашып аерылышмады-елашмады. Нинди елау, ди?! Мин приют дигән серле җиргә, прәннек дигән серле нәстәкәйне ашарга барам. Абзыйларым мине тавыш-тынсыз гына күтәреп, аякларымны суздырып, арбага, кучер Хәниф абзый белән янәшәдән алга каратып, арбаның нәкъ кендеге турысына утырттылар. Әнкәм тезләрем өстеннән уч төбедәй уймак корама юрганымны, аның өстеннән мендәремне куйды, аларны кушарлап кочкан кулларыма әлүмин тәлинкә һәм агач кашык тоттырды. Кашыкны «Кулыңнан ычкындырма, нык тотып утыр, бер югалтсаң, табалмассың!» – дип тә кисәтте. Шул заманнардан алып, бүгенге көнгә кадәр кашык дигән атамага мин бер бөек бәрәкәт итеп карыйм.

Без кузгалып киттек. Ике яктан япмалы такта капкабыз безне ыңгырашып озатып калды. Әмма башка беркем дә кычкырып елашмады. Ул чакта абайламасам да, инәмнең күзләре яшь белән чылангандыр дип уйлыйм. Күрсәтмәгәндер: ул бит балаларын ачка үтермәс өчен шушындый сынауларга бара! Бу минем туган авылымнан беренче тапкыр юлга чыгуым иде. Көн җылы кебек хәтердә калган. Мин Кәркәле тауларына күтәрелгәнче авылны, үзәннән сузылган Өязе елгасы буйларын күздән кичереп бардым. Арбадагы кешеләрнең бер нәрсә турында да авыз ачып сөйләшмәве мине, шактый күтәренке күңелле (приютка прәннек ашарга барган кунак!) малайны хафага сала иде. Вакыт-вакыт мин артыма борылып, бу ике тере мәетне хәтерләткән бабайларга караш ташлап алам. Мин аларны телсезләр дип тә уйлап куйдым. Ачлыктан тәмам хәлсезләнгән бабамнарның сөйләшерлек хәлләре дә булмаган икән. Озакламый без Кәркәле тауларына күтәрелеп, соңыннан белүемчә, Ташлы елга дип аталган кечкенә сусыз үзән аша үтеп, «Бүләк» урманына якынлаштык. Кәефе килеп, Хәниф абзам җырлап та җибәрде:

Сарман буйкайлары тугай-тугай,
Тугаенда сайрый бер тургай.
Иртәсен дә сайрый, кичен дә сайрый,
Саргаеп ла үлсен, ди бугай...

Саргаеп үлмибез без, эчтән дә, тыштан да татлы прәннек ашарга барабыз!

Безне уратып алган дөнья кабатланмас сурәт булып хәтеремдә калган. Әнә барлык тирә-як, офыкка кадәр, зәңгәр чәчкәлектә тирбәлә. Каян килгән безгә бу кадәр зәңгәр чәчкә?! Җиңү бәйрәме алып килгәнме? Бу кадәр матурлык кайда, ничек яратыла?

Соңыннан, өлкәнәя төшкәч аңлавымча, бу матур, үтә күренмәле

зәңгәрлек чәчәргә ашлык булмаудан зәңгәр чәчкәлеккә-чүплеккә әйләнгән басулардан килгән булган икән. Бу матурлык ясалма рәвештә, кешелекне генә түгел, табигатьне дә тупас көчләү нәтиҗәсендә яратылган ятимлек күренеше булган икән. Бу Аллаһның кешеләрне чәчәргә орлык булмау аркасында кысыр калган яланнарны басып киткән кыргый матурлык аша искәртүе, сискәндерүе булган, күрәсең. Аллаһы Тәгалә миңа шул чакта ук чиксез кыргыйлыкның матурлык аша да раслана алу мөмкинлеген иңдергән...

«Ач балалар йорты» дигәндә, күңелемдә беренче пәйда булган күренеш – ул анда ашаган беренче «аш»ым иде. Аны аш дип тә атап булмагандыр. Мәңге бәйләнми торган нәрсәләрне тиз генә бәйләп куя торган төшенчәләр түгелме болар – «ач» һәм «аш». «Ачлык» һәм «ашлык». Үзе ачлык, үзе ашлык. Әйе, мин ул йортка килгәч тә, минем тустаганыма салынган шулпа иде. Ул кап-кара, эчендә берничә кара фасоль борчагы йөзеп йөргән кайнар су иде. Әмма аның кызыгы суның каралыгында түгел, мине уратып алган булачак дусларым, язмышташларым – шушы ач балалар йортында «тәрбияләнеп яткан» балаларда иде. Алар мине сырып алдылар да бертуктаусыз:

– Бер генә каптыр әле, әй!

– Мин дә бер генә кабыйм әле, әй! – дип кабатлый-кабатлый, минем тустаганымнан кара су чүмерәләр иде. Мин башымны күтәреп, яңа танышларымны күздән кичерергә өлгермәдем, бушап калган тустаганымның төбе генә ялтырап күренә иде.

Ул йорттагы башка «аш-су, блюдоларны» мин әллә ни хәтерләмим. Әй, хәтерлим икән. Хәтерлим. Ул теге мин күптән көткән «прәннек» дигән нәрсә. Тукта, үз тәртибе белән сөйлим әле. Безнең көнебез иртәдән кичкә кадәр ашарга сорап үтә иде. Без яши торган ач балалар приюты Олы Кәркәленең киләчәктә үзем тәмамлаячак җидееллык мәктәп бинасында булып чыкты. Соңыннан мин аның җиденче сыйныфы бүлмәсе идәненең сары, калын сайгакларын күреп, «үзем йоклаган ачлар йорты» булганлыгын таныдым. Мәктәп ихатасында турник кебек физкультура җайланмалары булса да, без аларда уйнарлык, уч төбен төкереклэп, баганалардан югарыга үрли алырлык дәрәҗәдә хәлле түгел – хәлсез идек. Аның каравы без, әйткәнемчә, ашарга даулап, янәшәдәге кечкенә йортта урнашкан «ашханәбез»гә тынгы бирми идек:

– Ашарга пешәме әле?

– Ашарга кайчан пешә?

Анда безгә дигән «кара су»ны, чөгендер яфрагы боткасын пешерүче апалар, шул ашны пешерергә комачауламасыннар дип бикләнеп утыралар. Без күләгәдән күләгәгә елышып кына киләбез дә ишекләрен дөбердәтәбез:

– Ашарга пешәме әле?

Кинәт ишек ачыла, апалар табагач, уклаулары белән селтәнеп, безне куарга чыга һәм без шул пешмәгән фасоль борчагы кебек тирә-якка сибеләбез. Ләкин мине сәерсендергәне шул – безгә теге Нияз абый вәгъдә иткән серле «прәннек» дигән татлы нәрсәне һаман да бирмиләр иде...

Мин бик сагына торган кеше. Сагыну – минем үземнән калмый торган чирем дип, бу язмаларымда әйткән дә идем шикелле. Сагынган чакларымда

мәктәп ихатасында аулак урын табып җырлап та алгалый идем. Мин моны сабый чактан ук җырчы булганмын икән дип раслау өчен әйтмим. Шундый мизгелләрнең хаклыгын куәтләү өчен генә әйтәм. Менә шулай бер көнне, без, берничә малай актыгы, ашханәбез ишегенә чираттагы «ашарга пешәме әле?» дип дөбердәтергә киттек. Кычкырдык. Дөбердәттек. Шул чакта ашханәдәге апаларыбызның берсе мине күлмәк итәгемнән эләктереп алды:

– Кичә утынлыкта син җырладыңмы?

– Юк.

– Син җырладың, алдашма.

– Алдашмыйм.

– Прәннек бирсәк, җырлар идеңме?

– Җырлар идем.

– Аһ, син прәннекне беләсеңмени!

– Мин монда прәннек ашар өчен килдем, – дидем мин олыларча кыяфәт белән.

– Кара син аны! Каян беләсең? Кем әйтте?

– Бертуган абыем Нияз.

– Ул каян белә?

– Ул күп нәрсәне белә. Ул бишенчедә укый инде...

– Прәннекне иртәгә пешереп куярбыз. Шушы вакытка. Кара аны, утыннар арасында җырлаган җырыңны җырларсың, ярыймы! Тик ишекне җимерердәй итеп какмагыз. Иптәшләреңне дә алып килерсең...

Икенче көнне көтә-көтә күзләр күгәрде. Болай да саргайган йөзләребез тагын да саргая төште. Без, малайлар, ашханә болдырына килеп утырдык. Апаларны көттек. Алар чыктылар. Мине барысының каршына бастырдылар.

– Әйдә, җырла!..

Мин, аңлавымча, «утынлыкта җырлаган», безнең гаилә өчен изге булган «Төрмә җыры»н җырларга тиеш идем. Без аны, өебез белән дүрт бертуган, салкын мичкә аркаларыбызны терәп һәм мөмкин булмаса да, үзебезне җылытырга теләп, берсе икенчесеннән аерылып торган дүрт аһәң белән башкара идек. Ул җырны минем нәселем буыннан-буынга тапшырып килгән. Туган авылым Кәркәлетамакның, риваятьләргә ышанган хәлдә, Пугач каторжнигы Әкри (Әкрәм) тарафыннан нигезләнүе дә бу фикерне тәсдыйклый кебек. Әмма бу юлы мин аны берүзем башкарырга, абыйларымның ышанычын акларга тиеш идем. Халык азатлыгы өчен көрәшкәне өчен егерме биш елга хөкем ителгән, инде елы тулыр алдыннан сагынуына түзә алмыйча төрмәдән качкан һәм шуның өчен чыгарып атылган каторжник турында ул җыр. Авыр җыр. Йөрәкне актарып чыгара торган җыр. Бисмиллаһиррахман-иррәхим. Башладым. Хәерле сәгатьтә, туган кешеләр.

Шулай итеп, мин, кызыл киндер күлмәк-ыштандагы дүрт-биш яшьлек малай, ятимлектән ач балалар йорты күтәрмәсендә үземдә булган моң ишарәте белән җырымны суздым. Бар дөнья тынган иде кебек. Минем колагыма сулар акмас булып, яфраклар, үлән кыяклары үсүдән туктап тора иде кебек...

Мин шуларны тойдым. Үземдәге нәфсене тыйдым. Бу минем бәхетем

иде. Әгәр мин шуларны тоймасам һәм үземне нәфсемдә тыймасам, бу җырны башкара һәм саклый да алмас идем...

«ТӨРМӘ ҖЫРЫ»
Төрмә бит ул, төрмә бит ул,
Анда сыер сатмыйлар.
Алтын-көмеш, алтын-көмеш-
ләрдин артык саклыйлар...
Егерме биш ел буена,
Әткәм, ничек чыдадың?
Күрешкәнгә өч көн дә юк,
Атылырга чыгамын.

Ык елгасы буйларында
Бәләбәй төрмәләре.
Яшь йөрәккә курку сала
Караңгы бүлмәләре...

Чагыштырмача яшь булсалар да, утызынчы еллардагы репрессия касафатын йә турыдан-туры, йә читләтеп кичергән бу хатыннар күзләреннән аккан яшьләрен тыя алмыйча һәм безгә күрсәтмәскә тырышып елыйлар, хәтта үксиләр иде. Сабый бала башкаруындагы бу фаҗигаи моң күңелләрне кузгата иде. Мин бу кеше күзләреннән коелган күз яшьләрендә үземне гаепле тоеп, үзем дә елый идем. Әмма безнең сабый күңелләр җырдан җуелмыйча прәннек көтә иде. Апаларның берсе кухнәгә үтеп, алъяпкычы астында ниндидер «нәмәрсә» алып чыкты һәм безнең һәркайсыбызга берәрне таратып чыкты да, монысы җырың өчен дип, миңа тагын берне бирде. Прәннек дигән «нәмәстәкәй» шушы икән: арыш оны камырыннан ясалган, кечкенә, уч төбенә сыярлык, йөзенә шикәр таты буялган тәбикмәк. Уч төбенә сыеп, авызларда сайраган сандугач! Их, аның тәмлелеге! Их, аның күзләребезне ачып йомганчы юк булуы!

Прәннек өчен мин тагын да җырларга әзер идем!..

Яңа танышларым белән дуслашып, туганлашып барсам да, андагы кырыс тәртипләрдән, бигрәк тә мине «туйдырган-тукландырган ачлыктан», ягъни андый «ач балалар да туймый торган йорттан», хәлем барынча әмәлен табып барыбер кача алдым. Чөнки бик сагынган идем. Мин ишегалларымны, андагы яшел хәтфәле каз бәбкәсе үләнен, авылымның йөзьяшәр өянкеләрен, «Түгәрәк Имән»нәрен сагынуыма түзә алмый башлаган идем. Шулай да, дүрт кенә яшьтә булсам да, качкан чакта уңайсызга, читенгә төшә дип, күрәсең, кашык белән калай тәлинкәмне генә алып, мендәр белән корама юрганымны калдырып торырга башыма җиткән. Әмма әллә кая китә алмаганмын: Олы Кәркәле авылы башында агып яткан инеш янына килеп җитеп, хәлем бетеп егылганмын. Мине кире «ачлар йортына» алып кайтканнар.

Шулай да тагын бер ун көн чамасы үткәч, хәл җыеп, мин аннан барыбер кача алдым. Иртәнге якта булды ул. Авылдашым, шул ук ачлар йортында яткан сугыш корбаны Габдерафыйк абзыйның кызы Мәрьям Рәфыйкова белән качтык без Олы Кәркәледән Бәләкәй Кәркәлегә. Бу юлы да кашык белән тәлинкәне генә түгел, качкан чакта авырга туры килмәсен дип,

күрәсең, мендәр белән юрганымны да алып тормаганмын. Авылларыбыз арасында яткан Тырын Түбәсе дигән җирдән кайтып килүебез бүгенгедәй истә. Үземне «геройларча» хис итүем авылыбызда үткәрелгән беренче Җиңү бәйрәменә бәйле рәвештә шулай хәтердә калган булгандыр дип уйлыйм. Чөнки Җиңү бәйрәмен күрмәгән сабыйның зиһене боларны болай ук итеп күз алдына китерүе, үзенә сыйдыруы һәм үзен шулай батырларча тотуы мөмкин түгел. Имеш, мин «ваянный» формада җиңүче булып, авылыма кайтып киләм. Күкрәгем тулы орден-медаль. Безне авыл халкы барабаннар кагып каршылый. Өемә кайтып кергәнем дә хәтердә. Абыйларым, сәкегә аякларын чәнчеп утырып, иртәнге аш – ямь-яшел чөгендер яфрагыннан пешерелгән, минем иң яратмаган, телемә сылашып йөдәткән яшел боламыкны сыпыртып утыралар. Сагынганмын! Барыбер дә «үз боламыгым»! Энекәшләре кап-кара бобый борчагыннан кара төскә кергән шулпа йортыннан котылып кайтып килә дип уйлыйм мин, пнимаеш, билендә сары каеш, ә абзалары, корсакларын бүлтәйтеп, ботка ашап утыралар! Минем беренче сүзем «Миңа ашарга калдырдыгызмы?» дип аваз салу булды. Җавабында Гали абыем: «Башта исәнләш!» дип, мине, «чит илләрдән» кайткан герой-энекәшен, үз урынына менгезеп утырта...

Абыйларым бу вакыйганы бик еш телгә алалар һәм көлешәләр иде...

Тагын да бер истәлек. Минем беренче тапкыр «кина» каравым. Миңа күп булса, биш-алты яшь булгандыр. Караңгы. Инәм мине җитәкләп, беренче тапкыр клуб дигән җиргә алып барды. Клубның ихатасында дөпелдәп эшләп утырган дбижук (движок) тавышы аша авыр ишекне ачып керүгә безне гомердә күрмәгән якты нур көлтәсе каршылады, бөтенләй ят, чыелдаган, гөрелдәгән, шул нурда яктырып шуышкан кинотасма тавышлары зиһенемне чуалтты. Инәм, күрәсең, кинага кергән өчен механикка акча түләргә дип, мине бер мизгелгә кулыннан ычкындырып торды. Шул мизгелдә гомеремдә беренче мәртәбә күргән экранда эшелон килгәне шәйләнде һәм кинәт көчле шартлау яңгырады. «Заслонов, Заслонов» дигән сүзләр хәтергә сеңеп калды. Вагоннар очты, рельслар актарылып күтәрелде-бәрелде. Мин курыктым. Берьялгызым, инәйсез дә калган караңгыда кычкырып елап җибәрдем...

– Нәрсәгә елыйсың, улым? Кина бит ул! Кинада еламыйлар!.. Елмаялар!..

Бу мин елмаеп карамыйча, елап караган беренче тавышлы фильм – атаклы белорус партизаны Константин Заслонов турында нәфис фильм булган икән...

Бу урында татар милләте һәм кино темасына кагылышлы берике фикер әйтеп китсәм, урынлы булыр кебек. Кино – милләтне тәрбияләүнең иң нечкә, иң үтемле формасы. Без кино белән рухланып, ашыбызның юклыгын, киемебезнең ертыгын күрмәдек. Кино безнең никадәр бәхетсез һәм хокуксыз икәнлегебезне оныттырды. Кино безне ду китереп, «матур алдакка» алып керде. Ул безне елмайтты да, елатты да. Татар авылына кино, безнең тел белән әйткәндә, «кина», сугыштан соң – кырыгынчы еллар азагы – илленче еллар башында килде. Сталин ипигә туймаган халыкларының тамагын «кина ашатып» туйдырды. Без үскән елларда район кинофикациясеннән дистәләгән «кинамеханиклар», тынгы белми, колхозлар биргән атлы арбаларда авылдан авылга кино

күрсәтеп йөриләр иде. Халык кино куеласы көннәрдә шатлыгын кая куярга белмичә «котыра» иде. Күз алдыгызга китерегез: җылы җәйге кич. Иң каты күңелле бәндәләрнең дә һушын алырлык һинд фильмы «Бродяга» күрсәтелә. Ул ике, әллә өч сериядән тора иде. Әллә мин ялгышаммы? Халык клубка сыеша алмый, акча җыю планнарын тутырган киномеханиклар канәгатьлек белән «кинаэкраннарын» тышка чыгарып, йолдызлар астында күрсәтәләр иде. Икенче көнне бар халык дөньясын онытып, «Аварая, бродяга я»ларны җырлап мәш килә. Шушы кадәр кытлыкта яшәп, шушы кадәр матур күңелле булырга кирәк бит! Без ул чорда дөньякүләм киноларның иң кәттәләре – шедеврлары белән танышып калдык. Мин исемдә калганнарын гына санап китәм: Голливуд куйган «Тарзан», «Сказки Венского леса» фильмнарын онытырлыкмы? «Падение Берлина»ны хәзер нигә күрсәтмиләр икән?

### Абыйларыма көтү көтешәм

Анык кына раслый алмыйм, 1946 елдамы, әллә 1947дә микән, минем иң өлкән Гали абыем үзеннән алты яшькә кечерәк, миннән алты яшькә зуррак Ингель абыем белән икәүләп ялланып, халык көтүен көтте. Инәмнең «Укытучы баласы көтү көтәр көнгә калгач, алда безнең өлешкә тагын да нинди газаплар төшәр инде?» – дип өзгәләнгәне хәтердә.

Кемгә ничек тоелгандыр, мин үзем ул көтү дигән табыштан бик канәгать идем. Хәтта ки андый эшнең табылуына шат идем. Көтүче чыбыркысы мине Шигъри тау башына – Парнаска алып менде дип, һич тә икеләнмичә әйтә алам.

Ул хакта шигырем дә бар:

Мин Парнасны күрдем. Шарты катгый:
Әмма Пегас миннән уңмады.
Җырлап яшәргә бик хыялландым,
Җырлап кына яшәп булмады.

Заман миңа «Талант – шартсыз, – диде. –
Пегас ярсый сабан тартканда».
Шигырь яздым эшкә барган чакта,
Шигырь яздым эштән кайтканда...

Мин мал көтүчесенең чыбыркы шартлатулары астында табигатьнең барлык нечкәлекләрен күрдем, тойдым-кичердем һәм ләззәтләнеп үземә сеңдердем. Аеруча, аның ул чактагы, әле техника измәгән, имгәтмәгән, кеше кулы кагылып бозмаган чактагы матурлыгын. Мин, дүрт-биш яшьлек сабый, уянам һәм күрәм: Кәркәлетау артыннан минем өстемә тәгәрәп, Кояш үзе төшеп килә... Тау итәкләре әле күләгәдә, чирканыч салкында, анда меңләгән көмеш чык тамчылары җемелди...

...Көтү кайта. Тоташалар таулар
Үзәннәрне алып култыкка.
Мал каршылый халык. Урам тузган.
Урам тузан белән тутыккан.
Төн куера...

Нәҗагайлар уйный.
Игеннәрдә яшькелт шәүләсе.
Төн йокыда, өлгергән кыз сыман,
Буй җиткерә арыш гәүдәсе...

Мин ул кояш дигән могҗизаны колачым җиткәнче кочаклыйм да янә дә шәрә кулларым белән үземчә тәгәрәтеп, таллар, йөзьяшәр өянкеләр арасыннан агып яткан Өязе елгасына алып төшәм. Өязе дулкыннарында миңа каш сикертеп, чүлт-чүлт сикерешеп, вак кына көмеш балыклар да йөзә. Бик бәләкәй булсам да, Ингель абыем һәм миннән дүрт яшькә өлкәнрәк булган ут-күршеләрем Зыя һәм Камил өйрәткәнчә, тимерчыбыктан таш белән чүкеп ясаган кармагым да бар. Мин талчыбыктан кыркып алынган сапны, кармагына суалчан кидереп чөгермәккә ыргытуым була, салып та өлгермим, кызыл канатлы маймычлар бер-бер артлы каба гына тора! Әмма мин балык белән артык мавыкмыйм. Мине яланда таң белән көтү көтәргә киткән абыйларым көтә. Инәм өйдә юк, ул колхоз эшендә. Һәм мин инәй әзерләгән кечкенә токчайны (аны никтер капчык диясем килми) аркама киеп, абыйларым янына юлга чыгам. Токчай эчендә шешә. Буш. Әмма бөкесе бар. Бөкене нык сакларга кирәк. Әгәр югалтсам, баш бетте. Мин кояш нурларында нурланып, хәтта әйтер идем, шул нурларга төренеп, уралып һәм кыйгач-кыйгач туралып, авылымның бердәнбер булып сузылган урамыннан киләм дә, колхозның таш ат абзарын, сарык абзарларын үтәм һәм урамдагы соңгы йорт – инәмнең бертуган абзасы Габдулла бабайлар тәңгәлендәге тау юлы буйлап, сулга кырт борылып, Мендәрле Кул чишмәсе янындагы табырга юнәләм. Колакта гүзәл Кәркәле, Өязе. Кырлыган буйларының йөзләгән төр бөҗәге, йөзләгән төр кигәвене, корты, дуплы кәүсәләр – түмәр умарталардан очып килгән кыргый бал кортлары, черки-чебененең гөжләгән, жуылдаган тавышлары озата килә. Кырлыган инешенең исемен төбәк тарихчысы Газиз бабай Вафин «кырылган» дигән сүздән алынган дип раслый иде, мәрхүм. Урыны оҗмахта булсын. Булуы мөмкин. Бик мөмкин. Шунда ук, күп тә үтми, мине кыңгырау кебек зеңгелдәп аккан салкын Кырлыган инеше каршылый. Анда, борылышта өч мәһабәт карама. Алар юан кәүсәле. Минем андый карт карамаларны бүтән беркайда да күргәнем булмады. Мин Кырлыганның Мендәрле Кул (исемнәренә игътибар итегез!) чишмәсе белән кушылган тәңгәленнән турыга, үргә – Кралов урманнарына таба үрлим.

Төрле урында типченеп аккан чишмәләрнең үзәннәре сазланып яткан кыяк үлән, вак камышлык белән капланган. Мин яланаяклы килеш саз-камышлыкларга кермәскә, чыланмаска, балчыкка батмаска-буялмаска тырышам. Яр буйларын карлыгачлар кәрәз кебек тишкәләп бетергән. Мин сандугач-карлыгачларның ничектер пышылдап сайрауларын тыңларга яратам. Алар безнең абзар түбәсенә дә оялыйлар. Җырларының соңгы авазларын ничектер сызгыртып тәмамларга яраталар. Нидән шулай икән? Газиз бабайдан сорармын әле. Игътибарымны карлыгач тишекләренә охшаган башка оялар җәлеп итә. Йомран һәм әрлән оялары алар. Берсен икенчесеннән аерып та булмаган бу җан ияләре гамәлдә нинди сыйфатлары белән аерыла икән? Газиз бабайдан сорармын әле. Башка вакыт булса, мин

аларның тишекләренә су салып, тончыктыра-тончыктыра, җир өстенә дә чыгарыр идем. Әлегә вакытым һич кенә дә юк. Мине абзыкайларым көтә. Әнә, моннан күренеп торган Ялгыз Каен төбендәге мал табырыннан алар кабызып җибәргән учакның сыекланып, күккә ашкан ак җепселләре шәйләнә. Минем ашказаным суырып куя. Алар хәзер төшке ашларын пешерә булыр. Кәҗә сөтендә болгатылган боламык ул. Өч кешегә өч уҗау. Дүрт кешегә дүрт уҗау. Уҗауның мин соңрак русча «половник» дип аталганын белермен. Их, ул боламыкның тәмлелекләре! Мин килде-китте, вак-төяк кеше аламасы түгел: мин нәкъ алар әйткән урынга, нәкъ алар әйткән вакытка шул төшке ашны ашарга дип барам да бит инде. Аркамда капчык. Токчай. Анда буш шешә. Ашау дигәннән. Авылда көтүче халкы ике төрле итеп туклана: үз исәбенә һәм чираттан, ягъни өйдән-өйгә йөреп. Инәбез безнең үз исәбебезгә пешереп ашауны мәгъкульрәк күрде: үзебез хәстәрләп ашаган очракта очсызгарак төшә. Көндезен, абыйларым пешергән боламыкны мин, дүрт-биш яшьлек сабый, көтүгә үз аягым белән килеп ашыйм. Минем борын тишекләремне шул учак төтене витаминнары кытыклаган кебек. Бәлки шулайдар да. Бәлки, ач кешенең ачуы яман, дигәндәй, шулай тоела гынадыр? Тамагымны туйдыру өчен кемгәдер нәкъ ашар вакытта гына баруым миңа яңалык түгел һәм ул сәгать аныклыгы белән үтәлә иде. Минем безнең урамнан югарыдарак, тау буенда яшәгән инәмнең атасы Шиһабетдин картатама төшке аш вакытын туры китереп барганым хәтердә. Әйе, барам. Өйгә үтәм. Чишенәм. Табынга чакыруларын көтмичә, сәкегә картатам янына менеп кунаклыйм. Картатам ул «чын» карт. Аңа ул чакта бәлки сиксән тирәләре булгандыр. Ул бик җыйнак, матур кеше иде, мәрхүм. Бит алмалары алланып тора. Кап-кара сакаллы. Бөркет борынлы. Шунда минем өчен иң җаваплы мизгелләр башлана. Күзләрем ялт-йолт уйнап кына тора. Картинәм (минем үз картинәм үлгән, бу Ишле авылыннан килгән икенче, үги картинәм) карттам янындагы зур сандыкны ача, андагы кечкенә савытны ала. Капкачын ача. Аннан мин көткән сары бал күренә. Күренә генә түгел. Бал агач кашыктан картинәмнең юмарт кулы белән алдымдагы катлама сыныгына куна. Мин аны «эһ» дигәнче юкка чыгарам. Башка бернәрсә дә хәтердә түгел. Картатамның хуҗасыз яткан, ташландык хәлдә гомер кичергән ишегалды, җимерек буш абзары, сыер бәйли торган борынгы баганалары, ташлары суынган иске кара мунчасы, таш белән буралып, кайчандыр азык-төлек белән тулып торган зур подвалы төштәге кебек кенә истә. Кышын күпмедер вакыт картатам белән картинәм инәйнең бертуган абыйсы, урманчы булып эшләгән Габдрахман бабамнарның мунчасында яшәделәр. Өченче сыйныфларга кадәр минем анда төшке аш вакытларында гына «калкып чыгып», җылы мунча шартларында тамак туйдырганым хәтердә. Ашау турында күп сөйләгәнем өчен гафу үтенәм. Нишлим соң, ашарга ризык табу – ул борынгы заманның гына түгел, бүгенге чорның да стратегик бурычы бит, туганкайларым...

...Мендәрле Кулның култыксалары буйлап, мин чишмәнең үзенә килеп чыгам. Халык ничек итеп аңа шундый тирән мәгънәле исем кушкан диген. Мендәрле Кул. Ят та йокла. Мендәре-юрганы әзер. Ул бабайларыбыз чокып ясаган тирән улак буйлап шарылдап агып ята. Бу безгә үткәннән килгән хатлар. Һәм үлемсез Такташ әйтмешли, киләчәккә хатлар. Аның

ярларында ошбу сихри аһәңне тыңлап ике шомырт куагы дөньядагы иң татлы шомырт җимешләрен өлгертә. Иң иртәләгән шомыртны мин биредә ашыйм. Шомырт кына түгел. Иң иртәләгән балтырганнар, көпшәләр, кузгалаклар, җир җиләкләре биредә җитешә. Шомырт сутын суырып изеп, орлыкларын шатырдатып чәйнәп, энҗедәй ап-ак тешләребез кара күмергә әйләнә. Мин шул тешләремне сындырырлык чишмә суын авыз итәм. Соңыннан ачыклануынча, мин 1945 елдагы беренче Җиңү бәйрәмен монда каршылаганмын икән. Байрак урынына юкагач таягыбызга кечкенә кызыл яулык бәйләп, Минебай абзый Сөбханколов мәктәп балаларын рәт-рәт итеп тезеп, Мендәрле Кулга алып менгән иде, рәхмәт төшкере.

Минебай абзый дигәннән. Аның да әтисе гражданнар сугышында кызылгвардияче булып катнашып, Бөек Ватан сугышында һәлак булган. Сөбханколовлар нәселенә без бик рәхмәтле. Минебай абыйның өлкән агасы Исраил абый мине урта мәктәпне тәмамлаганнан соң Октябрьский каласына алып китеп, икенче санлы техник училищега урнаштырган, Шәрифә җиңги белән икәүләп, тормыш ничек кенә авыр, яшәү шартлары ничек кенә тар булмасын, беренче айларымда мине үзләренең бер генә бүлмәдән торган баракларында яшәткән кеше. Авылдан килгәч, мин аның теләктәшлеге белән шәһәрдәге яшь хәбәрчеләр, яшь шагыйрьләр түгәрәген эзләп тапканмын, әдәбиятка беренче адымнарымны алар ярдәмендә ясаганмын, дип авыз тутырып әйтә алам. Боларның барысы өчен Исраил абыем белән Шәрифә җиңгәмә еллар һәм чорлар аша бил бөгеп рәхмәт әйтәм.

...Мин Мендәрле Кул чишмәсенең текәсеннән тагын да үргә үрлим һәм ябалдашын як-якка иркен итеп җәйгән Ялгыз Каен астындагы мал табырына килеп чыгам. Мине кояш нурларында балавыз сыман эрегән баллы һава һәм вак малның бәэлдәве, чебен-черки куып кырт-кырт төрткәләнүе, эре мал кебек, төкерекләрен чәчеп, мышкылдау-пошкырыну авазлары каршылый. Абзыйларымның ара-тирә мал куалаган һайт-һайтлары ишетелеп алгалый. Мин вак малдан бүленгән нәҗес һәм әчкелтем чәпрәй-сидекнең йөзләгән текә тояк тарафыннан изелеп каешланган, таптала-таптала кайтарылып, көзгегә әйләнә башлаган даирәсендә торып калам. Килешәм: минем сарык-кәҗә малыннан җәйге челләдә килә торган йөзләгән «хуш исләр»не аңкытып яткан табырның үзенчәлекле тын алышын һәм эчке халәт-үзенчәлекләрен сурәтләргә көчемнән килми. Шушында мин йоклап калып, көтүен иртәләп алып чыгып киткән Гали абый белән очрашам. Ул иңенә салган озын чыбыркысын сабы белән миңа суза һәм бераз читкәрәк китеп үлән кимереп маташкан берничә кәҗәгә күрсәтеп:

– Нишләптер мал тыныч түгел. Әллә тагын бүре исен сизәләрме? – ди. – Соңгы вакытта бүре халкы бик азды. Алла сакласын... Бар, әнә ул киребеткәннәрне табырга китереп куш әле... Аннан Ингель абыең белән кеше күзенә күрсәтмичә генә, табыр эченә чумып...

Ул әйтеп бетерми. Шулай кирәк.

Өлкән абыем бүреләрнең соңгы вакытта ифрат та котырулары турында бик дөрес әйтә. Моннан бер атна чамасы элек, без табырда вакытта, чак-чак кына малларыбызны бугазламый калдылар. Көтүебезне урталай ерып

килеп, берәр сарык алып китәргә чамалаган бүредән Гали абыемның нәкъ вакытында сызгыртып шартлый торган чыбыркысы гына коткарды. Шушы вакыйгадан соң, абыйларым көтүне, җәядән тартылган ук кебек ифрат та зур дикъкать, дүрт күз белән саклап көтәләр. Аннан бүре халкы күбәйде дә. Минем күргәнем булды. Алар сарыкны тешләре белән умырып алып, иңбашларына гына ыргытып олагалар. Алар төнлә «Сәнкә» урманнары тарафыннан мөкиббән китеп улыйлар. Ешаеп хәйләкәрләшкән ерткычларны авылның атаклы сунарчысы Халыйк бабай берданка мылтыгыннан да чәкетеп алалмый...

Мин Гали абый күрсәткән малларны йөгертеп, көтүебезгә китереп кушам һәм Ингель абыемның кочагына кереп чумам. Безнең үзебез генә белгән эшебез бар. Ул минем аркамдагы токчайны салдыра, аннан буш шешәне чыгара һәм, мине җитәкләп, табырланган малны өркетмәс өчен шым гына, башларыбызны тезләребезгә таба иеп, чүгәләп, җиргә елышып, табыр уртасына алып керә һәм үзе теләгән берәр сөтле кәҗәне арткы аякларыннан эләктереп ала да:

– Кер! – дип боера. – Нәрсә катып калдың? Им! Кеше-кара күрмәсен!..

Мин бер төерем ноктага әверелеп, табырның каеш кебек ялтырап каткан балчыгына уң ягым белән ятам һәм кәҗәнең кайнар имчәге астына башымны тыгып, җиленнәрендәге сөтне нәзек кенә бармакларым белән кысып, авызыма турылап сава башлыйм. Куанычым куенга сыймый: минем шундый кайгыртучан абыйларым бар!..

Тиргә батам. Җиленнән савылган сөт турыдан-туры авызыма туры килгән мәлләрдә мин үземне икенче галәмдә итеп тоям. Шул галәмдә күккә күтәреләм. Шул галәмдә үткәннең Муса Җәлилләре, Гази Заһитовлары, Юрий Гагариннары үсеп чыккан. Кәҗәм тыпырчына, тынычсызлана, сөтен бирмәскә тырыша, мин аның тынычсызлыгыннан да зуррак тынычлык белән савылган сөтне голт-голт йотып җибәрергә ашыгам, әмма талпынган саен урынымны үзгәртергә мәҗбүр булып, сауган сөтем күз чокырларыма, борын, колак тишекләремә туры килеп, барлык йөземне куе, татлы, майлы, үзле кәҗә сөте белән юешләтеп бетерәм. Тирә-якны сөтнең үзенә генә хас булган хуш исе, сагынычлы җылылыклары баса. Болай итеп, авылдан төш алдыннанрак табырга килеп, җиргә яткан килеш кәҗә имеп, тамагымны туйдыру – үзебез генә белгән мотлак күренеш. Көндәлек күренеш. Кәҗә сөтенең кеше өчен ифрат та файдалы булуын, аның батырларны, хәтта борынгы грек халык авыз иҗатының төп каһарманы Гераклны да үстерүен, аның кәҗә имеп үсеп, дөньякүләм батырлыклар кылуын мин соңыннан китаплардан укып кына белермен...

Ләкин абыем озаклап юандырмый:

– Тукта! – ди. – Син бигрәк тагын! Хуҗасына да калсын!

Мин беләм. Бер кәҗәне тамчысына кадәр имеп бетереп, аны кичен авылга сөтсез калган, сөте корытылган имчәкләр белән алып кайтырга ярамый. Хуҗалар кәҗәләренең көтүдә савылганын сизенсә, кичен көтү кайткач, тавыш күтәрә. Бирәсе хакын да түләмәскә мөмкин...

– Тукта, дим бит! – ди абый. – Ул икенче кәҗәне шулай ук аякларыннан эләктереп ала да миңа тапшыра. – Тотып тор!..

Инде, ниһаять, кәҗә астына үзе керә һәм аны шешәсенә саварга тотына.

Тымызык һавада безелдәп һәм скрипка тавышы кебек күңелне телеп, шешә авызына кәҗә сөте ага башлый...

Бу – сугыш, ятимлек дучар иттергән, шул ук сугыш, ятимлек өйрәткән тәртипләр, язылмаган законнар. Бу – адәм баласының җирдә яшәү өчен көрәше.

Абзам ярты литрлы шешәне «эһ» дигәнче тутыра һәм бик зур эш башкарган кыяфәт белән тирә-якка каранып, кәҗә астыннан елмаеп килеп чыга. Мин аеруча шат. Өйгә, авылга алып кайту өчен ризык булды. Менә без Ялгыз каен астындагы табырдан өстәрәк, көтүебез барлык яктан да яхшы күренгән ачыклыкта, аякларыбызны бабайларча бөкләп, тормышыбызның иң тантаналы, иң тавыш-тынсыз өлешенә керешәбез. Ул – төшке аш. Үсә төшкәч, мин аны шаяртып «листират» (ресторан, имештер ки) дип атармын. Минем абыйларым янына табырга килүемнең көндәлек мәгънәсе. Ихластан да: бер тавыш-тын ишетелми. Иреннәр чәпелдәве, агач кашыкның агач коштабак белән бергә саңгырау «пышылдашулары» гына колакка чалына. Кәҗә сөтендә оннан болгатылган һәм кояш нурында пешкән боламык ул – безнең аш. Сөтнең процентлы ак мае матур эркелеп, боламыкның йөзенә калкып чыга. Аның тәмлелекләрен сез сорамагыз, мин әйтмим. Чәй кебек нәрсәне эчкән-эчмәгәнлегебез хәтердә түгел. Амин тотып, Аллаһка рәхмәт әйтүебез хәтердә.

Абыйлар күккә карап, кояш нурларының авышын чамалый. Көтүне табырда озак яткырырга ярамый. Күктән төшкән шәүләңнең буе бер адымнан артмасын. Малның сөте кимемәсен. Ул мөмкин кадәр озак итеп үләндә чемченсен. Вак кына ак тешләре белән үлән кертләтсен. Төптән кырсын. Халык монысын да тикшереп тора. Абыйларымның кояш белән «киңәшеп» алуы миңа авыл ягына кузгалырга вакыт дигән сүз. Ингель абый, кеше-кара күрмәсен дип, як-якка карангалап, шешәне бугазы белән өскә каратып, токчайга сала, аны урынында борылгаламасын өчен кысып бәйли һәм минем арык иңнәремә чалыштырып кидерә. Һәм Мендәрле Кул чишмәсе авызына ук алып килеп туктый да миңа көн дә кабатланган боерыкларын бирә:

– Беркайда да туктама. Сөтне эчәсе булма, түкмә. Чайпалтма, мәтри аны. Башыңның түбәсе кеше күзенә чалынмасын. Олы юлларга чыкма. Үзән чокырлары буйлап кына өйгә кайт. Чокырлардан башың тырпаеп күренмәсен, чүгәләп кенә йөр...

Һәм мин абыемнар тарафына «соңгы карашымны ташлап», кичен ашарга дигән сөтне «чайпалтмыйча һәм түкмичә, беркемне күрмичә һәм беркемгә күренмичә», Мендәрле Кул чишмәсенең чокырлы үзәне буйлап юлга чыгам. Күңел түренә җыр калка: зимагурлар баеганнар, илгә кайтабыз, диләр... Кайтырга, өйгә!..

Бу чакта миңа нибары дүрт-биш яшь булса да, гомер искән җил кебек үткән дә киткән. Мин һаман юлда. Мин бүген дә өйгә кайтуда. Түгәрәк Имән белән Мендәрле Кул чишмәсе мине каршылый һәм озатып кала. Мең рәхмәт аларга. Бәлки мин абыйларымнан шушы кечкенә яшемдә алган сабакларымны гомерем буе да үтәп бетерә – үтәп җиткерә алмаганмындыр. Әмма мин аларны сәгать аныклыгы белән үтәргә тырыштым. Шушы сабакларым яктысында гомерем буе шигърияткә тугры хезмәттә булдым.

Беләсез, шигырь дигәнең башын биргәннәрне, йә баш түбәсен күрсәтмичә, чүгәләп йөргәннәрне яратып бармый. Ул бәйсезлекне яклау юлында. Шуңа күрә иелеп тә, чүгәләп тә йөрмәдем. Аллага шөкер, башым да туры кояш астында – югарыда булды. Мин бу шартны абыкайларым белән көтү көткәндә – төрки миллиятнең милли билгесе булган күк бүреләр карашы астында үзләштергән идем. Нәтиҗәдә халкым да, кешелек тә мине күрде. Рәхмәт аларга. Чиксез рәхмәт.

## Башына казан кигән кешеләр

Ул чакта миңа шулай ук дүрт-биш кенә яшь булгандыр дип уйлыйм.

Тымызык кына көн. Кояшның балавызы эреп беткән кебек. Мин абзарыбыздан капка төбенә таба чыгып киләм. Шул чакта кинәт кенә ике якка канатлы капкабыз ачыла һәм аннан «ящик» дип атала торган атлы арба килеп керә. Карбазына җиткән төштә инәм атны туктата, арбадан төшә. Мин аның итәгенә уралып бөтереләм. Арбадан инәмнең гомерлек ахирәте, җан дусты Садыйкаттәй дә төшә. Инәм юл өстендә чабып салган печәнне күтәрә биреп, аннан шул ук юл уңаеннан кышын мунча кергәндә чабынырга дип сындырылган бер кочак яшь каенның вак, дымсу яфраклы ботакларын актарып чыгара. Ух, ул себерке яфракларының урман салкынын саклаган хуш исләре! Андый хуш исләрне нинди, никадәр хуш исле үләннәр үзләрендә туплый һәм безнең Кәркәлетамакка алып кайта алды икән? Барлык ихатаны, шәрә калган келәт бәпкәләренә кадәр һаваны әчкелтем яшь каен яфрагы исе баса. Кышларын, ягылган мунчаның уттай кызган ташларына су сибеп пешергәндә, бу исләр дә борынны кытыклар әле, мин сезгә әйтим!.. Инәм аркалыкны төшереп, атның башын шулай ук хуш исләрен аңкытып яткан печәнгә төртә дә ялт итеп – кай арада алып өлгергән диген! – күлмәк җиңе астыннан ниндидер бер савытта моңа кадәр мин белмәгән-күрмәгән җимеш галәмәтен китереп чыгара:

– Аша, улым, – ди ул изге бурычын үтәгән кыяфәт белән. – Бу – карлыган дигән җимеш. Безнең авылда аны бик үстереп бармыйлар... Сезгә Карамалы базарыннан алып кайткан юл күчтәнәчем... Үсә төшкәч, карлыганны үзең дә үстерерсең әле, шулай бит? Әлегә авыз итәрлек кенә. Абыйларыңа да калдыр...

– Калдырам, инәй, калдырам! – дип, чәбәкәйләп урынымда биим. Һәм дөньямны онытып, гомеремдә беренче тапкыр карлыган дигән искиткеч тәмле, әчкелтем һәм баллы «нәмәстәкәй»ләрне ашказаным шәрифләренә озата башлыйм... Җир йөзендә шундый тәмле ризыкны үстергән кешеләргә, беренче чиратта, Садыйкаттәй белән икәүләп, бездән унсигез чакрымдагы Карамалы базарына барырга ат-арба биргән бригадирыбыз Зәйни абзыйга кадәр рәхмәт укыйм...

Шулвакытт җан-фәрман чаптыртып безнең рәттән ике генә йорт аша яшәгән Садыйкаттәйнең кече улы Камил килеп керә. Минем кулымдагы карлыганны күреп, күзләре шар була:

– Инәй, миңа да бир! – ди ул Садыйкаттәйгә, инәлеп. – Миңа юкмыни?

– Бар, улым, бар! – ди инәсе аны, тынычландырып. – Мин аны сиңа өйгә

кайткач бирермен, дигәнием... Анда Минебикә картинәң, Вәкил абыең да бар бит әле...

Камилнең көтәр сабырлыгы юк. Менә әнкәсе аңа да карлыганнан өлешен чыгара. Без ычмык-ычмык китереп карлыган сыпыртабыз. Камил белән без – дуслар. Икебез дә сугыш ятимнәре. Миннән дүрт яшькә олы булса да, ул мине читләтми. Аның алты яшькә зуррак абыйсы Вәкил минем Ингель абыем, аларның инәсе Садыйкаттәй безнең инәй белән дус-ахирәтләр. Камилләрнең әтисе Садыйк абзый белән минем әтәй дус булганнар, икесе дә фронттан кайтмаганнар. Инәйләр бергә кич утыралар, оегын, бияләен бәйлиләр, өмә ясап, тула басалар. Өязе буйларында беренче бодай, киндер орлыгын калай өстендә бергә куырабыз. Алар сөйләми калган сүз, җырланмый калган җыр юк.

Дөрес, Камил минем бәләкәйлегемнән, дәресрәге, һәрнәрсәгә ышанып баруымнан файдаланырга һәм моны үз максатларында кулланып, ягъни алдаштырып-йолдаштырып шомартырга, үзенә кирәген эшләтергә, аеруча бакчасындагы бәрәңгене утатырга, тавыкларга кычыткан туратырга, нәрсәдер ташытырга, күтәреп илттерергә ярата. Ул нәрсә әйтсә, нәрсә кушса, мин шуңа ышанам, шуны башкарам. Мин әле үземнең юкка ышанганымны һәм матур итеп алданганымны аңламыйм. Мин әле бәләкәй. Мәсәлән, ул мине утынлыкка алып чыга да:

– Бар, әнә ул утыннарны бирегә ташы, – ди. – Без хәзер ыңгырчак дигән афтаматтан утын туратабыз...

Аларның утынлыгында әтәйләрдән калган, бөятләре кубып төшкән борынгы ыңгырчак тимере аунап ята. «Афтамат» дигәне шушы була. Мин утыннарны шунда таба өстерим.

– Син аларны афтамат астына кертә тор... – ди ул, мин ташыган ботак-сатакны иске ыңгырчак янына өештереп. – Шуннан үзләре туралып чыга алар... Мин аңа балачакка хас булган керсез даһилык белән ышанам. Абыйсы Вәкил белән алар минем алданудан кызык табып көләләр. Мин көлмим. Мин үземчә җитди эш башкарам.

Без Садыйкаттәй гаиләсе белән ашарга булганда бер кашыктан ашап, булмаганда, шул кашыкны ялап, бер гаилә булып яшибез. Иртән бездә капкаласак, төшкә аларда тамак ялгыйбыз. Урманга утынга – бергә. Печәнгә – бергә. Җиләк җыярга – бергә. Су керергә, кыяр, кишер, өй кәрнизләрендә кибеп азапланган «ак болыт», ягъни әчегән катыктан корытып ясалган «корыт»ны сыдыртырга (моны «урларга» дип аңларга кирәк) – бергә. Хәтта чиргә сабышканда да бергә идек. Сугыштан соң, 1946 елда булса кирәк, авыл тиф авыруыннан егылган. Мәктәп ябылган. Авыл советы эшләмәгән. Ингель, Вәкил һәм Камил абыйларым бер караватта аркылы төшеп чирләгән. Мин аны төш кебек кенә хәтерлим. Шул ук кырыгынчы еллар азагында барлык авыл корчаңгы белән йончыды. Кашына-кашына йөри торгач, кашынмаган багана калмый иде. Минем бот араларым чиләнде, кутырлар белән капланды. Бу авыру Садыйкаттәйләрне дә читләтеп үтмәде. Инәләребез Миякәдән «Вишневский мае» дигән дару алып кайтып, Сәми бабайларның ташландык мунчасын ягып, безне дәвалаганнары хәтердә. Вишневский маена буялган хәлдә без кара тәнлеләргә охшап калдык, без хәтта бер-беребезне танымый тордык. Өченче сыйныфта укыганда,

авылларда, шул исәптән безнең авылда, трахома чире котырды. Миякәдән «өерләре белән» шәфкать туташлары килде. Безнең мәктәп балалары трахомадан күз кабакларын эчтән кырдыру өчен чиратка басты. Бик газаплы, авырта иде ул күз кабагын кырдыру. Авыртудан үрсәләнгәнем истә...

Минебикә әби Вәкил белән Камилнең картинәсе була. Аларның бакчасында берничә бик татлы шомырт агачы бар. Башка җирләрдәге шомыртлардан иртәрәк өлгерәләр. Эреләр, баллылар – телеңне йотарлык. Камил аны җыймый, җыярга яратмый. Иренә. Миннән дә җыйдыртмый. Агачка мендереп тә ашатмый. Минебикә әби аның кытыгын кузгату өчен миңа:

– Бар әле, Барыйс улым, җый әле шул шомыртны. Камил җыймый, – дигән була.

Мин кәефем килеп, шомырт агачына үрмәли генә башлыйм, Камил, «кытыгы кузгалып», мин менгән агач янына килә һәм балагымнан эләктереп, кәүсәдән өстерәп төшерә. Бу хәл күп тапкырлар кабатлана. Кабатлана торгач, еш кына болай да пешкән шомырт коелып, болай да кара җирне тансыклый башлый...

Минем балалар өчен язылган «Казанбаш» дигән китабым бар. Ул китапны мин ифрат та яратам. Һаман да шул сабый чагымда Камил белән Вәкил абзыйлардан керсез алдануым турында шигъри кыйсса ул. Аның тарихы шуннан гыйбарәт. Сугыштан соң, 1946–48 елларда булса кирәк, безнең якларда нефть эзләүчеләргә мөнәсәбәтле шундый сүз йөрде: имеш, ниндидер казан кигән кешеләр, «казанбашлар», балаларны тоталар да нефть коесына салып – тәүбә-тәүбә! – майларын чыгаралар икән. Бу нәкъ мин ышана торган яшьтәге «матур ялган» иде. Ярый, хуш. Шулай, без бер тапкыр бәләкәй арба белән Мендәрле Кул чишмәсен үтеп, Кралов урманнары башланган җиргә утынга бардык.

Сентябрь башларында була торган җылы кояшлы көн иде.

Алдыбызда сугыш вакытында киселгән карт имәннәрдән калган ботак-сатак, чыбык-чабык тулып ята. Бәләкәй арба Камилләрнеке. Утын да аларга, әлбәттә. Кралов урманының авызына барып җиткәч, без арбабызның тәртәләрен авылга таба борып куйдык та коры-сары утын төйи башладык. Вәкил белән Камил, күрәсең, мине шаяртып, үзләренә «хезмәт иттерергә» – утынлы арбаны миннән өстерәтеп кайтырга булганнар.

Утынны төяп, бәләкәй арбаның өстеннән бау белән бәйләдек. Мондый калтырча кебек җиңел арбаны түбән таба келтер-келтер китереп тартырга яраткан, күңеленнән тизрәк олыгаерга тырышкан сабыйны абыйларым арба эченә кертеп, уртадан ук «бикләделәр» һәм мин, арбага берүзем мәҗбүри җигелгән хәлдә кайтырга чыктык.

Ялан аякларыбызның чәлтерләре, билсәпит тәгәрмәче кебек, энәләре белән кояшта уйнаклап, кызган юлдан түбән якка – авылга сыптырталар. Вәкил белән Камил, әйткәнемчә, арбаны миннән тарттырып, көлешә-көлешә, артымнан йөгерәләр.

Кинәт Вәкил абый:

– Тукта! – дип кычкырып җибәрмәсенме!

Мин туктадым. Тәртә арасыннан чыктым.

– Әнә ул, башына казан кигән кеше! Күрәсезме? Алар күпләр!.. Әнә, безгә таба чабалар! Әнә, офыкка кара! Өязе-тау артыннан!

Мин ераkларга карыйм, чынлап та күземә куркуымнан куш күренә: офыкта, Өязе-тау артында тауларга елыша-елыша, тулы бер рәт булып казанбашлар чаба кебек!.. Аларның башларында фриц каскаларына охшаган казаннар иде. Хәзер килеп уйлыйм да, мондый тиз, бөтенләй дә булмастай нәрсәгә җиңелчә, мөкиббән китеп ышануым минем сабый чактан ук шигъри җанлы булуыма бәйле булгандыр дигән нәтиҗәгә киләм.

– Әйдәгез, авылга сыпыртыйк! – дип кычкыра Вәкил һәм мине куркыту өчен өстәп тә куя: – Кер арбага тизрәк! Халыкны кузгатыйк!.. Безне казанбашлардан коткарсыннар!..

Мин калтырчабызга яңадан кереп җигеләм һәм аны утыны-ние белән өстерәп, Мендәрле Кул түбәсеннән бар көчемә түбәнгә, авылыбызга карап атылам. Абыйларымның арттан шырык-шырык көлгәннәрен дә абайламыйм. Күзем тонган, йөрәгем уңган – казанбашлар килә, алар безне йота!..

Менә без тырылдап, авылга килеп керәбез. Вәкил абый йөкне туктата, арбага үзе җигелә дә миңа яңа күрсәтмә бирә:

– Бар, йорттан йортка кереп, Рәхмәтулла абый, Нигъмәтулла бабай, Фатыйх абый, Рабига әби, Насыйр, Хуҗи картларның барысын да кузгат! Коралланып чыксыннар да, казан кигән кешеләрдән авылны коткарсыннар!.. Бар, тизрәк!

Һәм мин, үземә булган шундый зур ышанычтан эреп китеп, ихатадан ихатага, йорттан йортка кереп:

– Коралланып чыгыгыз! Казанбашлар авылны йотарга килә!.. – дип аваз салам.

Аптыраган халык ышаныргамы-юкмы дип, нишләргә дә белми аптырап кала. Кайсыбер Барый, Сабирҗан кебек аксакаллар, әби-сәби, бабай-сабайлар, берсе – уклау, икенчесе – җәмкә, өченчесе мич арасындагы кисәү агачы белән коралланып, без чапкан якка чабарга тотына да абынып егылып, тукталып кала...

Ә без, инде халык ярдәмендә үзебезгә үзебез тугры калып, тау артыннан җилдерткән казанбашларны да онытып, инде Вәкил, Камил абыйлар кушкан тарафка трафка бербөтен булып төенләнеп, өстәвенә, казанбашлардан котылу куанычы белән дә куанып, Шәрифҗан күперләре аша авыл уртасына килеп җитәбез. Мин яныш-тирләп, өебезгә кайтып керәм. Әлбәттә, бик тә ашыйсым килә. Йөк тартып ачыктым бит! Менә ишек. Минекеләр кайда? Ишектә, гадәтенчә, йозак юк. Гадәтенчә, элгече генә эленгән. Тирә-якка каранам. Бакчабыз ягына күз ташлыйм. Анда инәйләр бәрәңге чыгаралар. Гали абзый күрәгеннән алдыма төбе-ние белән бәрәңге ташлый:

– Кайда йөрисең, малай? Бәрәңге чүплә, давай!..

– Казанбашлар килгән!.. Шуларны куып йөрдем...

– Анысы нинди казанбаш тагын?

Алар мине аңламыйлар иде. Елыйсым килеп китте.

Мин, кашык тотып ашарга җыенган «казанбаш», теләр-теләмәс, елак кыяфәт белән җылы кара туфрактан актин-ак, нәзек бармакларым берлә бәрәңге чүпли башлыйм...

Казанбашларга килгәндә, алар минем балачагымның Тукай бүләк иткән «Шүрәле»ләре бурычын үтәгән булган икән...

Аларны истәлекле сәхифә итеп күңелем түренә салган Вәкил, Камил абыйларыма да рәхмәт.

## Мин ничек укырга бардым

Бу 1949 елның сентябрь азакларында булган булырга тиеш.

Җылы көзге көн. Мин кызгылт киндер ыштанда, берни булмагандай, болдырыбызга утырып, кишер кимерәм. Безгә бер таныш булмаган, үзен бик тә тыныч тоткан апа килде. Алар инәй белән икәүләп сөйләшә-сөйләшә, безнең бакча башларын, ишегалларын урап йөрделәр. Сүз мине мәктәпкә укырга йөртү турында, әмма «мине читләтебрәк» барган икән. Яныма килеп җиткәч, каршыма ук килеп туктадылар һәм бу таныш булмаган тыныч апа миңа игътибар итеп:

– Сорур апа, Борисыгыз бик тә кишер ярата икән, – диде.

– Әйе, хәтта кирәгеннән артык, Мәгъмүрә сеңлем. Тирә-яктагы кишер түтәлләреннән чыга белми. Патрау арты патрау. Ут-күршеләребез Мөсаббихә әбиләрнең кызыл кишереннән табыр ясап бетергәч, сары, мал кишере түтәлләренә күчте, биглый...

Алар көлешеп алдылар.

Кишер хакында булганны сөйлиләр. Мин безнең очның бер генә кишер түтәленә дә тынгы бирми идем. Авызымны тутырып, мине кишер генә саклап калды, дип әйтә алам. Бу хакта «Туган йорт тупсасында» дигән шигыремдә дә әйтелгән.

– Кишер яратып, улыгыз дөрес эшли, – диде Мәгъмүрә апа. – Әмма ашар өчен аны үзеңә үстерергә кирәк. Кишернең күзгә файдасы күп. Мәктәптә күп укырга туры киләчәк, шулай бит, Борис?.. Укыйсың киләме?

– Ки-лә!..

Укытучы, башлангыч мәктәп мөдире Мәгъмүрә апа Гомәрова (җәяләр эчендә генә әйтеп китим: Кыргыз-Миякәдә туып үскән күренекле язучы, башкорт совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе Гариф Гомәрнең бертуган сеңлесе) безгә мине беренче сыйныфка язарга дип кергән булган икән.

Бу кичтән башка бернәрсә дә хәтерләмим. Иртәнгесен генә хәтерлим. Салкын иртә. Кырау төшкән. Мин яланаяк Ингель абыем артыннан мәктәпкә барам. Күрәсең, миңа инәкием алып барырга кушкан булгандыр. Әмма абыем минем мәктәпкә баруымны теләми. Үзен олыларча усал тота. Тота да «барма!» дип, таш ыргыта. Тота да, җирдән алып, таш ыргыта. Менә мәктәп ихатасына да кердек. Мин бит мәктәп дигән җиргә беренче тапкыр, кая барырга да белмим. Менә мәктәпнең болдырына да җиттек. Абзам ишекне ачып, билгесезлеккә (ул дүртенчедә укый, үзе укыган сыйныфка, мин укыячак беренче сыйныф аша үтә икән) чума, ә мин аның артыннан кереп, парталар артында утырган балалар каршында торып калам.

– Килдеңме, Борис? – ди кечкенә буйлы бик сөйкемле апа. – Бирегә үт. Менә монда утыр...

Мине ул иң арттагы партага утырта. Анда башка бер малай да утыра

икән. Ул минем булачак сыйныфташым, ач балалар йортыннан бергәләп качкан Мәрьям Рәфыйкованың бертуган энесе Минехай булып чыгачак. Күп тә үтми, Сөйкемле апа балалардан нәрсәдер сорап мөрәҗәгать итә. Балалар – алар сыйныфта утыз-кырыклап булгандыр – кулларын күтәрә. Мин дә күтәрәм.

Сөйкемле апа килә һәм миннән:

– Ә син нигә күтәрәсең? – дип сорый.

– Белмим, – дим.

– Дөрес. Белмисең, – ди Сөйкемле апа. – Мәктәптә нәрсәнедер белгәндә, яисә белергә теләгәндә генә кул күтәрәләр. Аңладыңмы?

– Аңладым...

Менә шулай башланды минем белем хәзинәсенә салган беренче сукмагым. Биредә ачыклап китәсе нәрсәләр бар. Сөйкемле апа дигәнем минем беренче укытучым Кәримә апа Газнанова була. Ул мине беренче-икенче сыйныфларда укытты. Мин аңа бик рәхмәтлемен. Тумышы белән күршедәге егерме йортлык Җидегән авылыннан, безнең төбәктән беренче булып югары белем алган инженер, Губкин исемендәге Мәскәү нефть һәм газ институтын тәмамлап, соңыннан КПССның Ишембай шәһәр комитетының беренче секретаре дәрәҗәсенә күтәрелгән авылдашым, башлангыч белемен минем әтәй – «учитель Нәҗметдин»нән алган, минем кендек әбием – Раһиба абыстайның улы Минеяр Бәхти улы Газнановның җәмәгате иде. Шунысы тетрәтә: бер заманда яшәгән инәйнең дә, Минеяр абый, Кәримә апа, Раһиба әбинең дә, башка туганнарымның каберләре дә бер зиратта – авылда, Кәркәлетамакта, берсе икенчесеннән берничә генә адымда. Шуларны күрәсең дә, зиратның очрашып-күрешеп булмый торган иң изге урын, тормышның никадәр дә үкенечле булуы турында уйланып китеп, күздән яшь сыгыла башлый...

Биредә беренче тапкыр мәктәпкә барганда, абыйның артына әйләнеп караган саен «Барма!» дип таш ыргытуы турында укыган укучы «абыйсы ифрат та бәгырьсез кеше булган» икән дип, ашыгыч һәм ялгыш фикер чыгара күрмәсен. Юк, Ингель абый – мине аркасына йөкләп, җил-яңгырдан саклап үстергән ифрат та кешелекле җан иясе. Аның тормышы, чынбарлыгы шундый катгый һәм «каты куллы», русча әйткәндә, «сюсюкать» итәргә урын калдырмый иде. Ачлык кушканга гына шулай каты күңелле булып күренгән ул. Мин тормыш дөреслегенә хилафлык китермичә, хакыйкатьтә булганын, кичергәнемне яздым. Бераз соңрак сыйныфта мине киләчәктә авылда гомере буе бригадир булып эшләячәк җан дустым Ринат Камалов белән бергә утырттылар. Аның инәсе тегеп биргән бишмәте шактый сыйдырышлы иде. Без аңа икәүләп сыя идек: ярты ягын мин, ярты ягын – Ринат киеп җылына идек...

Кышкы айларда булса, җил-буран аша чыккан юка бишмәт, бер генә катлы бияләйләрдә булып, туңган кулларыбыз белән аларны бер салып – бер киеп, хәрефләр язарга өйрәнү ифрат та газаплы иде. Аның өчен токчайдагы сыек караны махсус савытында түкмичә-чайпалтмыйча мәктәпкә алып барасы, дәресләр барышында кулларны һәм караны туңдырмыйча саклыйсы, чабаталарыбызны саласы, язар өчен салкын бугазлаган кулларны җылы тыныбыз белән өрә-өрә җылытасы бар иде... Минем «л» хәрефен яза

алмыйча җәфаланганым хәтердә. Арка үзәгем туңган. Кулларым туңган. «Л» хәрефе ике өлештән тора – беренче өлеше көлдән утлы күмер өстери торган кисәү агачына охшаган, икенче өлеше – туры таяк. Шушы ике өлешне кушып кына булмый бит! Бияләеңне сал. Кулларыңны тының белән җылыт. Аннан каләмеңне, туңмаган булса, карага манчы һәм бу «ысбулыч» хәрефнең ике өлешен кушып, мәгънәле аваз барлыкка китер! Менә шулай!..

Дүртенчедә безне яше егермегә дә җитмәгән яшь укытучы, Бәләбәй педагогия училищесын тәмамлап кына килгән Олы Кәркәле кызы Рауза апа Кәримова укытты. «Укытты» дип әйтү дә урынлы түгелдер. Дөресе «укыта алмады», «укытырга бирмәделәр» дигәне хактыр. Рауза апабыз атаклы укытучы Кәримовлар гаиләсеннән чыккан, этик-эстетик яктан нечкә тәрбияләнгән «кыз бала» иде. Без исә тәртипсезлекнең, укытучыны тыңламау дигән чирнең аргы ягына чыккан «Кәркәле хулиганнары» идек. Сыйныфтан сыйныфка күчми калып, «яңа укытучыларны» тыңлаудан бөтенләй дә баш тарткан идек. Сыйныфта төрле өлгерештәге, яшь аралары зур булган тәртипсез малай-шалайлар байтак иде. Күз алдына китерә алсагыз, китерегез: без апабызның кулыннан перчаткасын, хушбуй исләре аңкып торган кулъяулыгын тартып алабыз. Аларны үзенә бирмичә газаплыйбыз. Парта өсләренә менеп сугышабыз. Мич арасындагы утын пүләннәрен алып, бер-беребезгә ыргытышабыз. Еш кына пүләннәр апабызның өстәленә дә барып төшә. Ул үзе дә җавапсыз калмый: безнең «котырудан котылу өчен» мич арасыннан үзе бер кочак утын пүләннәре алып килә, аларны дөбердәтеп, өстәленә бушата, аннан шул пүләннәрне дәрес вакытында укытучыбызны бөртек тә тыңламыйча, «котыру»ның чигенә чыгып, парта өстенә менеп сугышкан «егетләребезгә» төбәп атып җиффәрә, «егетләребез» йә урынында сикереп, йә башларын парта астына яшереп котыла һәм шушы күренеш торган саен төрлеләнә, байый-баега барып, бүлмәбездәге һава бер-беребезне шәйли дә алмас дәрәҗәдә тузан белән куера... Бу хәл безнең атмосферабызның гадәти басымы иде.

Мин Рауза апаны ярата һәм сыйныфташларымның тәртипсезлекләреннән коткара, ярдәм итә алмаганым өчен үкенә һәм кызгана идем. Хәтердә, инәм үзенең ахирәтләрен ашка җыеп алырга булды. Укытучымның борчылуларын аз гына булса да җиңеләйтү өчен мин инәмнән шул ашка Рауза апаны да чакыруына ирештем. Апа ул мәҗлестә булды. Моңа миннән дә шатрак кеше булмагандыр дип уйлыйм.

Уку елының азагы шактый үкенечле булып чыкты. Без, дүртенчеләр, сабый корыннан үсмерлеккә күчеп маташкан бала-чага, көчебезне кая куярга белмәгән «яшьләр», районның мәгариф бүлеге карары белән, хәтердә калуынча, кырык баладан нибары өч-дүрт кенә бала, шул исәптән мин дә, бишенчегә күчерелеп, калганнарыбыз сыйныфта утырып калды. Бу атасыз ятимлекнең, сугыш алып килгән әхлакый җинаятьләрнең берсе иде: кеше үсми. Үсеш туктала. Белемсез кала. Таркала. Адымы белән. Авылы белән. Әмма без үзебезчә, сабый акылы белән әйткәндә, шат һәм канәгать идек. Мин, дусларымнан, «компания»мнән аерылып, һич кенә теләмәсәм дә, бишенчегә дип, Олы Кәркәле җидееллык мәктәбенә укырга мендем. (Бездә «мендем-төштем» дип сөйлиләр.) Әмма һич кенә дә кабул итмәдем мин Олы Кәркәле мәктәбен. Аның моннан ун ел чамасы элек миңа «Ач

балалар йорты» булып хезмәт иткәнлеген танысам да, мин Олы Кәркәле мәктәбенә берьялгызым менә, берьялгызым төшә торган идем, чөнки минем «үз бандам» авылда, Кәркәлетамакта калган иде. Барганда «Бармыйм! Бармыйм!» дип ялгызым елап барам, кайтканда «Бармыйм, Бармыйм!» дип елап кайтам. Кичләрен, караңгы төшкәндә, кеше күрмәгәндә, туган мәктәбемә барам, аның тупсасына утырам һәм өнсез тәрәзәләренә һаман да шул «Бармыйм!»нарны кабатлап елап утырам. Мин сагына торган кеше дигән идем бугай. Бу хәл минем сагынуымның классик үрнәге иде. Мин туган мәктәбемне, иптәшләремне сагынып саргайдым. Киптем. Сагынуым соңгы чиккә җиткәч, елый-елый инәмә чишелдем. «Укырга барасым килми, – дидем. – Әйдә, Олы Кәркәле мәктәбе директорына барыйк. Мине тагын бер ел иске дусларым белән Бәләкәй Кәркәле мәктәбендә укытсыннар».

Шулай итеп, мин инәкине Олы Кәркәле мәктәбе директоры Барый абый Садыйров белән очраштырдым.

Барый абый сүзне кыска тотты:

– Сорур апа! Сугышка кадәр без Нәҗметдин абзый белән бергә укыттык. Аның истәлеге безнең өчен изге. Улы Бористан да сугышларда ятып калган атасы кебек яхшы кеше тәрбияләү – безнең бурыч. Бишенче сыйныфка күчкән килеш дүртенчедә икенче ел утырырга теләве класста тузан куптарган иске дусларыннан аерыласы килмәүдән генә. Без ни өчен укытабыз балаларны? Кызыл Армиядә яхшы хезмәт итсен, үрнәк кеше, хезмәт алдынгысы булсын өчен! Бар кайт, энем, Бәләкәй Кәркәлеңә һәм иртәгә иртән, башка балалар белән бергәләп, тегендә укыйм, монда укымыйм дип, инәңне җәфаламыйча гына, Олы Кәркәлеңнең бишенче сыйныфына укырга кил, ярыймы? – Ул минем аркамнан кагып сөйде һәм тагын да өстәде. – Нәҗметдин абзыйның рухы тыныч булсын. Аның улы Бористан зур кеше чыгачак, Алла боерса... – Ул янтая биреп, инәйнең колагына пышылдауга күчте. – Син, Сорур апа, безнең депутатыбыз... улыңны бер мәгънәсезгә дүртенчедә ике ел утыртырга дип тырышып йөрмә инде...

Без инәй белән шулай итеп, чишмә суына булган сусавыбызны Барый абый биргән татырлы су белән басып, Кәркәленең би-и-ик «бәләкәйсе»нә кайтып киттек. Шулай итеп, миңа туган авылымдагы «тузан куптарып» күчми калган үз сыйныфташларым белән дүртенчедә тагын бер ел утырырга насыйп итмәде...

Бала кайгысы тиз үтүчән. Ул таң җиле кебек нәзберек. Олы Кәркәледәге яңа сыйныфташларыма да бик тиз өйрәнеп киттем, әмма бу тарихны, җитмеш елдан артык гомер үтүенә карамастан, беркайда да телгә алганым, сөйләгәнем булмады. Аңа менә шушы «Сайланма истәлекләр»емдә генә кагылам...

## Тор, балам, иртән мәктәпкә!..

Менә, игътибар итегез, ничек итеп әнкәй мине һәр кара таңда Олы Кәркәле мәктәбенә озаткан. Мин, күземне тырнап булса да ачарга, бик иртә торырга тиешмен. Чөнки гадәт буенча авылның башка – минем белән укучы «безнең оч шәкертләрен» йорттан йортка тәрәзәләрен кагып уятып

чыгам. Мине укырга озату өчен әнкәм миннән байтакка иртәрәк тора. Уянгач, бер мизгел торырга иренеп ятам. Юрган урынына мин ябынган палас астында – җылыкай, мич арасыннан инәмнең кыштырдаганы, мичтә янган утыннарны ботарлаган тавышлары шәйләнә. Аның уй белән тулган йөзендә мичтә янган уттан төшкән ялкын шәүләләре уйнаклый. Ул миңа кичә кичтән пешергән ашны җылыта. Ниһаять, мин торам. Төнлә җылысы тартылып калган өйдә суык, әмма мине мичтән төшкән ялкын шәүләсе җылытадыр кебек – эчтәгесе киндер, тыштагысы ситса чалбарымны, аннан төн аралаш сагынып өлгергән оекбашларым, тула оекларымны, аннан, янә дә зур сагыныч белән сайрап торган өч тәңкәгә Гайнулла бабайдан сатып алган «вак тешле» яңа чабаталарымны киям, – алар тальян гармун тавышлары чыгарып шыгырдыйлар, мин шат, мин бәхетле, мин укырга барам! Өстәлдәге тустаганда кайнар буларын чыгарып, әнкәм җылыткан умачлы аш, теленгән ипи түтәрәме көтә! Ашыма куанып, ачы катык катам, катыклы аш миңа көч бирә, аннан өстемә бишмәтемне киям – кәчтүм, мәктәп формасы дигән нәрсә юк! – муеныма Яүһәрә апам кияве Рәшит җизнәм бүләк иткән ак шарфны урыйм һәм дәфтәр-китап салынган токчаемны аркама асып, йокысын бүлеп, мине ашаткан-эчерткән инәкәем белән хушлашып торуны да кирәк санамыйча (андый иркәлеккә без өйрәнмәгән!), болдыр ишеген йортны кузгатырлык итеп яңгыраткан тавышлар чыгарып, төн караңгылыгына чумам...

Беренче итеп Вәрис дустымның тәрәзәсен шакыйм. Күрәм, өйдә мезелдәтеп кенә, җиделе куыкка ут алына. Мин төне буе йокы «хуш исләре»ндә оеган һәм почмактагы бозау һәм кәҗә бәтиләре бәэлдәгән авазларда куерып тынчыган авыл өенә тыштагы суыкны өстерәп керәм. Каяндыр чыбылдык артыннан Вәриснең әнисе Кәбирәттәйнең тыштагы салкыннан да салкынрак тавыш белән мыгырдаганы ишетелә:

– Сөт чоланда!.. Алып кереп аша!..

Вәрис туң чиләкне алып керә, бозын ватып, савытка агыза һәм лачтыр-лочтыр китереп көне буена – ашказаны кичке дүрт-алтыларга кадәр түзәргә тиеш – сөт белән ипекәен ашык-пошык умыра башлый... Шулай, инәйләр дә тормышның үзе кебек төрле, баласын укуга төрлечә озата һәм төрлечә каршылый...

Аннан без – Вәрис, Вәкил, Һәдия, Гөлнур һәм башка дусларым кыр казлары кебек тезелеп, салкын кыш көннәрендә, юл буендагы эскертләрдәге саламны яга-яга җылынып, дүрт-биш чакрымлык юлга чыгабыз... Мәктәпкә еш кына мич ягучылардан да иртәрәк килеп, беренче утларны алабыз, форсаты чыккан икән, каен чыра белән мичләрен дә тергезеп җибәрәбез. Мәктәптә ашханә, ашату дигән нәрсәне ишеткән юк, булса, токчаеңдагы ипи кыерчыгын аша да эппәр ит... Хәзер уйлыйм да таң калам: без ничек түздек икән? Без ничек үстек икән? Шунысы беркайчан да онытылмас: без үзебезне җир йөзендәге иң бәхетле кешеләрдән дә бәхетлерәк итеп тоя идек! Үзебез ятим булсак та, дөньяны ятимлектән коткару уе белән яна һәм шуның хакына тырыша идек! Без шат идек! Чын, атасыз ятимлекнең социаль күренеш буларак ачылган чагылышы иде ул. Бәхетсез «бәхетлеләр», кайгылы «кайгысызлар»!.. Без гел хәрәкәттә, гел бәрәкәттә идек! Безнең барлык кайгыларыбызны, ятимлегебезне бөек туган телебез – илаһи татар

теле, бөек Тукай шигърияте, җыр һәм шаян сүз оныттыра һәм бәхетле итә иде!

Еш кына безне авылыбыз башында эшләп утырган буровойдан килгән доңгыр-даңгырлы дизель, скважинага төшерелгән торба, компрессор тавышлары озата бара иде. Әй, онытып торам икән, 1948–1951 елларда безнең авылда Ишембай бораулау конторасыннан килгән нефтькә бораулау бригадасы эшләде. (Минем урта мәктәптән соң бораулаучы булып китүемдә бәлки шуның да тәэсире булгандыр!) Андагы эшчеләр – руслар, татарлар һәм башкортлар иде. Алар квартирага авыл өйләренә сыендылар. Бездә, мәсәлән, буровой эшчесе Иван, аның хатыны, буровойда измә әзерләүче Елена һәм аларның теле ачылып өлгермәгән күкрәк баласы Нина яшәде. Хәзер аптырыйм: Елена түткигә мондый кечкенә сабый белән кышын, шулкадәр еракка китеп, шулкадәр сынауларга ничек түзәргә мөмкин булган?! Әмма без тыныч, тавыш-тынсыз, бердәм гаилә булып дөнья көттек. Инәй ул чакта аеруча сабырлык һәм түземлек күрсәтте. Елена сменада булганда, бәләкәч Нинаны инәй белән без карый идек. Алар өйдә чакта Елена Ниночка белән русча, алар эштә чакта без Ниночка белән татарча сөйләшә идек. Ул чактагы тормышыбыз гүя бераз соңрак, XX гасырның алтмышынчы елларында зур яңгыраш тапкан ике – капиталистик һәм социалистик – системаның сыенып, тыныч яшәвенең безнең авыл шартларында расланган үрнәге булган икән, дип уйлап куям мин хәзер. Күз алдыгызга китерегез: Иван белән Елена эштә. Сабыебыз Нинаны, әйткәнемчә, инәй белән без карыйбыз. Инәй, русча бер сүз белмәгән мөселман хатыны, беренче эше итеп бисмилласын укый-укый, шушы гүзәл баланы, тәре кидереп, ничек ямьсезлиләр, дип, Нинаның тәресен муеныннан салдыра, аны һаман да белгәннәрен укый-укый, шүрлеккә куя. Елена, татарча бер сүз белмәгән христиан хатын, эштән кайта, бернинди тавыш-тын куптармыйча, итагать саклап, тәрене шүрлектән ала һәм яңадан Нинаның муенына кидерә...

Һәм шушы күренеш көн саен диярлек кабатлана. Өй уртак, казан уртак, мичтә гүләп янган ут уртак. Әмма системалар, диннәр төрле. Шулай да сыешып, тыныч яшиләр. Шунысын да әйтеп китим: бездә бораулаңган скважинадан нефть чыкмады. Халык сөйләвенчә, нефть табылуын табылган, әмма хуҗалыкта кулланырлык зур күләмдә түгел, имеш. Бер яктан, нефтьнең чыкмавы да хәерле булган дип уйлыйм мин хәзер. Әгәр чыккан булса, ул табигатебезне мазутка батырып, авылыбызны да «йоткан» булыр иде. Бүгенге көндә, Аллага шөкер, авылыбыз Кәркәлетамак, яки Бәләкәй Кәркәле, нинди өзеклектә булуыбызга карамастан, исән-сау гомер кичереп, бәрәңгесен-игенен, бала-чагаларын үстереп ята. Илаһи амин!..

## Сталин үлеме

Тагын да бер истәлек. Монысы шактый соңрак. 1953 ел. Март башы. Бише иде бугай. Сталин үлеме. Без Сталин исеме белән саташкан, тилерешкән идек. Мин, дүртенче сыйныф укучысы, олы тәнәфестә, шул замандагыча җиңеллек белән күлмәкчән генә килеш, нәрсә генә булса да капкалап алу теләге белән өйгә кайткан идем. Кире мәктәпкә барырга дип капкадан чыккач та, мине авыл советы – Олы Кәркәле тарафыннан ыргып

чапкан ат, ат өстендә ниндидер ир, атының тоякларыннан йодрык-йодрык кар тузгытып куып та җитте, узып та китте:

– Мәктәптә әйт, Сталин үлгән!

Бу хәбәрне авылда беренче булып ишетергә миңа насыйп иткән иде. Мин ядрә кебек атылып, мәктәпкә килеп кердем һәм укытучыбыз Рауза апага кычкырып «Апа, Сталин үлгән!» дип әйтеп өлгерүгә үк ул минем авызымны томалады:

– Кит аннан, кеше ишетмәсен! Була торган хәлме?!

...Сталинны җирләү матәме менә шулайрак итеп хәтердә калган. Мәктәпнең зал бурычын үтәгән зур бүлмәсе чишенеп тә тормаган халык белән шыгрым тулы. Изүләр ярымачык, тирләттерә. Минем хәтеремдә җыелышта нишләптер бары тик ятимә хатыннар гына калган: бер йодрык булып тупланып утырган Рафигаттәй (тулы итеп әйткәндә, Рафига түти була инде) Кәбирәттәй, Гайнияттәй, Гөлзәйнәптәй, Камиләттәй, Садыйкаттәй, Санияттәй, Хәйрәттәй һәм башкалар, һәм башкалар. Аларның һәркайсының итәге, тез башлары сугышта атасыз калган ятим балалар тәлгәше белән тулы. Алма төшәрлек тә урын калмаган бу аралык радиодан агылган авыр моңнардан үкси-үкси шешенеп, Мәскәү Кремленнән килгән Юрий Левитан тавышын тыңлый. Әйе, мин ялганламыйм: ул чакта беркайда да, беркемдә дә, бер генә авылда да булмаган радиокабулиткеч, рәхмәт төшкере, безнең авылда гына бар иде! Каян килгән иде безгә андый байлар байлыгы? Ә менә кайдан: безнең мәктәбебезгә күптән түгел генә мөдирә булып килгән Мәгъмүрә апа Гомәрова, әүвәлдәрәк әйткәнемчә, Кыргыз-Миякәдән чыккан күренекле язучы Гариф Гомәрнең бертуган сеңлесе, заёмга тарихта күрелмәгән зур сумма – 25 мең сум акча откан  һәм шул акчадан өлеш чыгарып, тарихыбызда беренче «Родина» радиокабулиткечен сатып алып, Халыклар атасы бөек генералиссимус Сталинны җирләү матәмен тыңлау өчен мәктәп түбәсенә ак әлүмин антенна сикерткән иде. Бу чынлап та безнең генә башка сыймас күләмдәге зур вакыйга һәм зур сумма иде. Хәзерге акчага күчергәндә, ул 25 миллионнан да ким булмас иде кебек.

Иреннән дүрт ир бала белән калган инәм Сталин үлемен ифрат авыр кабул итте. Мин исә бу фаҗигане инәмнең җылы тез башына кунаклаган килеш күтәрдем. Беркайчан беркем ишетмәгән, авыл өчен битабигый булган радиоэфирдан агылган гадәттән тыш авыр музыкадан ярсыган, Сталиннан башка яшәүне күз алдына китерә алмаган гади, эчкерсез, әйтик, тыштан караганда, үтә дә беркатлы, әмма гаять тә акыллы, зиһенле халыкның туктаусыз елашы дулкын-дулкын булып, кайнар бүлмәдә йөзә, актарыла, гүя миңа килеп ябырыла һәм мин инәмнең үксеп елавыннан үзем дә кая барып бәрелергә, нишләргә белмичә үкси башлыйм да туктыйм, үкси башлыйм да очкылык тота башлагач кына туктыйм...

Сталин үлеме язмышымда мин кичергән иң тетрәткеч вакыйга булып хәтердә калды. Ул чакта без шәхес культы дип аталган, ул алып килгән миллион корбаннар турында бернәрсә дә белми идек. Озакламый булачак һәм бу чирнең коточкыч нәтиҗәләрен ачып салачак атаклы Егерменче съезд турында уйлый да алмый идек. Без күңелебез белән саф һәм сабыйларча эчкерсез идек. Без бөек юлбашчыбыз генералиссимус Иосиф Виссарионович Сталинны югалту кайгысыннан аңгырайган, Тукайның

«чаттагы баганага сөялгән татар кызы» сыман һушыбызны югалткан идек. Бераз алга китеп шунысын да әйтим: Сталин үзенең «шәхес культы» дигән феномены белән барлык кешелеккә «Кеше, адәм баласы һәм шәхес нинди булырга һәм нинди булмаска тиеш?» дигән альтернативасыз тәгълимат калдырды. Дөнья җәмәгатьчелеге бу тәгълиматтан беркайчан да арына да, котыла да алмаячак. Мондагы каршылыклар бәйләме һәм каршылыклар гармониясе минем күңелемдә беркайчан да искермәс, һәркемне кеше бөеклегендә кешелек биеклеген саклау культына чакырып торыр.

Кинәт арттан кемдер йөрәк ярып: «Сталинсыз ничек яшәрбез?!» – дип аваз салды һәм үксеп елап җибәрде. Кемдер «Аh!» итеп куйды һәм идәнгә ауды. Өч бала анасы, минем балачак дустым Флүрнең анасы Гайнияттәй икән. Сталин үлеме кайгысын күтәрә алмыйча йөрәге тотып егылган. Аның ире, Гали абзый, сугыш башланган көннәрдә дәһшәтле ачлыгы белән даны чыккан, шушы «данның» сәбәпләрен тикшерү өчен хәтта нарком Клим Ворошиловны да килеп тикшерергә мәҗбүр иткән Суслонгер лагереннан качып, авылыбызга кайта. Озак та үтми, аны алып китәләр һәм ул шул китүдән бөтенләйгә югала...

Мәскәүдән агылган моңлы радиоаваз безнең өчен, хәзерге тел белән әйткәндә, «митинг» бурычын үтәгән булган икән. Шулай да аның үзәге бар – ул вакыт-вакыт радионы боргалап, аның белән идарә иткән укытучыбыз Мәгъмүрә апа үзе иде. Ул диктор сөйләгәннәрдән халыкка аңлашылып җитмәгән кайбер гыйбарәләрне тәрҗемә итеп аңлатып бара. Аның минем инәм – «авыл советы липутаты» Минсорур апага сүз биргәне хәтердә. Инәйнең сүзенең азагын шулай тәмамлаганы хәтердә: «Кыз бала ир балага караганда азрак ашый. Минекеләр дүрт ир бала – ашын умырып ашыйлар, киемен өзеп кияләр. Элек ятимнәр турында даhи Сталин кайгырта иде. Хәзер, ул да китеп баргач, безнең ятимнәрне кем кайгыртыр икән?»

Балачагым хатирәләреннән менә тагын нинди вакыйга күңелемне өйки. Безнең йортыбыз алты почмаклы, пыялаларында кояш уйнаган алты тәрәзәле, калай түбәле иде. Аның бурасын 1905 елда Бөрҗән якларыннан кайтарган карагайлардан чөйләп (шкантлап) бураган булганнар. Картатабыз Габделвәли урта хәлле исәпләнсә дә, утызынчы елларда аны кулак ясап, йортыннан куып чыгаралар һәм йорты-бакчасы белән бар ихатабызны ярлы-батракларга бирәләр. Әтием Нәҗметдин, авыл активисты, соңрак коммунист, әле 1926 елда ук Бәләбәй педучилищесын тәмамлаган укытучы, бу хәл белән килешми һәм бик күп органнарга шикаятьләр язып, анда-монда йөри-йөри йөрәкләрен сыздырып, аяк табаннарын туздырып, йортыбызны үзебезгә кайтаруга ирешә. Мин боларны хуҗалыгыбызның авылда чагыштырмача маллы, иркен булуын, инде колхозга куып кертелгәннән соң бригад җыелышларының безнең йортта үткәрелүен билгеләр өчен язам. 1946 елның марты тирәләрендә булса кирәк, шундый зур җыелышларның берсе безнең өйдә – минем күз алдымда үтте. Ул авылдашларыбызга Бөек Ватан сугышын йомгаклаган, ягъни аңа нокта куйган «Безнең эшебез гадел. Без җиңдек. 1941–1945» дип язылган Җиңү медален тапшыру тантанасына багышланган иде. Идән сайгаклары чабаталардан эреп аккан кар суыннан чыланган, җепшегән. Халык бик еш кереп-чыгып йөргәнлектән, йортыбыз суынган, әкияттәге

Ак Әби кебек юан янбашлы мичебезне салкын алганлыктан, сөялсәм дә, ул барыбер җылытмаганлыктан, мин бик өшегән идем. Авыр өс киемнәрен дә салып азапланмаган халык тәрәзә тупсаларына кадәр менеп утырышкан. Аларның күбесе мин яхшы белгән авылдаш җиңгиләр, түткиләр. Өстенә погонын салган хәрби гимнастёрка (аны авылыбызда «димнәрүчке» диләр) кигән ниндидер таныш булмаган абзый (мин аны хәзер Олы Кәркәле авыл советы рәисе булгандыр дип уйлыйм) ниндидер кәгазьдән исем-фамилияләрне укый, шунда ук икенче абзый кечкенә каплардагы сары медальләрне һәм аларның катыргы таныклыкларын кешеләргә тарата... Хәтердә калуынча, җыелышның эчтәлеге, көн тәртибе тантаналы булса да, кешеләрнең йөзләрендә бернинди дә тантаналылык сизелми дә, күренми дә иде. Сугышлардан кайтмаган ирләрен әле һаман да көткән, көтәчәк һәм бу көтүдән беркайчан да туктамаячак ятимә солдаткаларны бары тик ирләрен кызыл балчыклы окоплардан өйләренә кайтартып кына куандырып була иде. Алар якты сагышлы иде. Уен-көлке яңгыраганын хәтерләмим. Медальле булу алар өчен гүя ирләренең башларын сугыш яланында салып калдыру белән килешү иде. Бу медаль гүя рәсми кәгазьгә мөһер сугып, барлык рәхимсезлекләр белән килешү иде. Рафигаттәй дә, Камиләттәй дә, Гөлзифаттәй дә, Садыйкаттәй дә, аның җан ахирәте – безнең инәбез Минсорурттәй дә, мин хәтерләгән һәм хәтерли алмаган дистәләгән хатыннар, фронтлардан исән кайткан ирләр, егетләр дә алдылар ул медальне. Мин аларның берсенең дә йөзендә куаныч күрмәдем. Уйлавымча, әдәбиятыбызда сурәтләнми калган бу вакыйга мине үзенең кайгысын эчкә йотып, тынсыз калган күренеш булуы белән тетрәтә.

Шунда хәрби гимнастёрка кигән абзый тагын бер тапкыр җыелышны Ватан сугышының тәмамлануы белән котлады да:

– Бөек Ватан сугышына багышланган медальне алучылар, кулларыбызны күтәрәбез, – диде. – Яшәсен юлбашчыбыз даһи Сталин!..

Барысы да дәррәү кул күтәрде.

Бу вакыйгадан соң күпме еллар үтте, күпме сулар акты, хәзер анык кына әйтә алмыйм, алдан уйланылган бер провокация булдымы бу, әллә җыелышның көн тәртибе шулай куелган идеме? Минемчә, кешене кимсетү, рәнҗетү, аны өстәмә сыйнфый дошман ясап «тәрбияләү» чарасы булган ул.

– Төшерегез!.. Медаль алмаган кеше калмагандыр бит? Андыйлар бармы?

– Ба-а-ар...

Гөнаһ шомлыгына каршы, «андый» бар һәм берәү генә булган икән. Ул әнкәйләребезнең бераз югарыда телгә алган ахирәте, өч бала анасы, минем Флүр дустымның инәсе ятимә хатын Гайнияттәй иде. Бу Ватан сугышы башланганда хәрби лагерьда хөкем сөргән ачлыкка түзә алмыйча авылына качып кайткан һәм дезертирлыкта гаепләнеп, кулга алынган, шул китүеннән хәбәрсез югалган (озын колаклар сөйләвенчә, строй алдында атылган) Гали абзабыз Булатов өчен совет хакимиятенең «бүләге» иде.

Йөрәге ярсыган Гайнияттәй бу газап талкышын җиңел генә үткәрә алмады. Ул җанны телгәләгән авазлар чыгарып елап җибәрде. Барлык халык гүя телсез калып елый иде. Кайбер ахирәтләре Гайнияттәйне юатырга,

тынычландырырга тырышты. Әмма аны туктату мөмкин түгел иде. Ул ярсый-ярсый үкси иде...

– Ватан сугышында һәлак булган иремне... нахак бәлаләр тагып... ул дезертир түгел! Ул хезмәттән качып кайтмады!.. Ул бер тапкыр булса да туйганчы ашар өчен... өч ятим баласын күрер өчен кайтты!.. Бер кыерчык ипекәй өчен кайткан иремнән, балаларымны аталарыннан мәхрүм итәргә кемнең нинди хокукы бар?! Колхозда изелеп, фронттан ирен көтеп эшләгән хатынга шушы медальне бирү түгел, аның өстеннән көләр өчен бирегә чакырдыгызмы?!.

Тантаналы җыелышның көтелмәгән буразнадан кереп китүе күпләрне һушсыз итте. Медаль тараткан хәрби үзе дә югалып калды.

– Җыелышны тәмам... игълан итәм... – диде ул, аптырап ни дияргә дә белмичә. – Ник таралмыйча торасыз?!

Бу вакыйга минем йөрәк түремдә кичә генә булган кебек тере килеш саклана. Ул түткиләрнең инде берсе дә исән түгел. Бер телем ипи өчен кыелган гомерләр диген. Хәзерге көндә шушы вакыйгаларны кичереп бер ялгызы калган туган йортымны күрү белән теге мизгелдә авыр кимсенүдән күзләре чәчрәп чыгарга торган Гайнияттәй, аны ничек кенә булса да тынычландырырга тырышкан ятим хатыннар, алар арасында аеруча өзгәләнгән инәм күз алдына килә. Мондый кеше үтергеч формализм, кешелексезлек һәм гаделсезлек – нә иҗтимагый органнар, нә хөкүмәт, нә матбугат тарафыннан үз бәясен алмый калды. Монда барлык күпмилләтле совет әдәбияты, шул исәптән мин үзем, матур татар әдәбияты вәкиле, үзем дә гаеплемен. Мин мондый кискен сюжетларга корылган биографик әсәрләремне бераз соңрак, өлкәнәйгән көннәремдә язармын дип, махсус җыентыкта саклап килгән идем, әмма көтмәгәндә авырып киттем. Аннан без кичергән мондый вакыйгалар мондый сәяси басым, мондый шәхессезлек диктатурасы хөкем сөргән шартларда җәмгыятьнең гадел бәясен ала да алмый иде. Аны, көтелгәненчә, йомып та калдырдылар. Бүгенге күзлектән караганда, Гайнияттәйнең бу җыелыштагы чыгышы аның Нобель премиясен алуга тиң вакыйга, искиткеч югары гражданлык батырлыгы булган. Ул – шәхес, башкалар вак җанлы адәмчекләр генә булып калган. Хәзер инде бу вакыйгаларны хәтерләгән кешеләр да тормыштан китеп барган. Гаепсезгә атылган иренең кешелек горурлыгын саклаган Гайнияттәйне бары зират капкасы, андагы үлән баскан кабере генә хәтерлидер кебек...

Аһ, ничек кенәләр дә үкенечле вә кызганыч!..

## Мин ничек кәчтүмле булдым

Без – сәер буын. Кайдадыр бер урында мин бу сәерлекнең төп «сере»н хәлемнән килгәнчә аңлаткан идем бугай. Ул – революцияләр, кыйралышлар, сугышлардан туган җитешсезлек, ягъни «Дефицит» галиҗәнапләре. Ихластан да, дәүләт «упалнамучлары» тарафыннан бәрәңгенең кабыгына, соңгы күзәнәгенә кадәр исәпкә алынган, кешеләрнең шул күзәнәк хакына таланган, хәтта гомерен җуйган шартларда да бирешмичә, утта янганда да, суга батканда да исән-сау кала алган искиткеч көчле буын без. Алай гынамы? Өстәвенә, барлык кешелеккә Кеше булып калуның үрнәк

өлгеләрен биргән буын. Халкыбыз кичергән тетрәткеч вакыйгалар, җанны өшеткән заманнар, кеше башы сыйдыра алмаганны ун тапкыр арттырып сыйдырган югалтулар турында уйланам, күз алдымнан кичерәм дә үз-үземә сорау бирәм: без ничек исән калдык икән? Безне, сугыш еллары балаларын, кем үчтек-үчтек итеп иркәләп үстерде? Безнең күпләребезне хәтта әти-әниләребез, үз туганнарыбыз, бихисап сынаулардан җаннары телгәләнгән чакларда «Һи-и-и, дөмекмисең дә, ичмасам» дип, имчәктән аерган сыман ачлык ызаннарына ыргыталар иде. Һич арттырмыйча әйткәндә, шунысы хак: без үлемгә дучар ителгән буын идек. Без, ятимнәр буыны, социаль мохтаҗлар буыны, көчле буын булганга исән калдык.

Кием. Кием дигән бәхет. Хәзер мин уйланам да, без нәрсә киеп үстек икән дип, тагын бер тапкыр уйланып куям. Без кигәннәрне кием дип атап була иде микән? Үземне болә башлаганнан алып, без гыйнвар салкыннарында да яланөс, яланаяк килеш «тышка чыгу өчен» чынлап та тышка – кышка чыга идек. Укучым «тышка чыгу» дигән гамәлнең нәрсә икәнлеген беләдер, белмәсә, сизенәдер, дип уйлыйм. Белмәсә, йә әнисеннән, йә әби-бабасыннан сорасын. Туңудан чирканып, карлы бозга ябышкан аякларыбыз бу хаҗәтебезне үтәп беткәнче генә түзә.

Гомумән алганда, безнең гаиләбез шәрә түгел иде. Без моның белән юкны да бар иткән инәбезгә бурычлы идек. Бер кат булса да ситса күлмәк, ситса ыштанда да «фарсит» итә идек. Киндер кебек каты тукымадан тегелгән күлмәк-ыштаннар, сарык, теләсә нинди мал тиресеннән тегелгән бүрекләр, шундый ук сарык йонынннан басылган тула оеклар да, чикмәннәр, кыска сырмалар (фуфайка) да кидек. Мондый кием-салым хәзер, калса, архив киштәсендә генә калгандыр. Әйе, инәбез безне ялангач, ертык-тишек киемдә йөртмәде. Ертылган киемне ул шунда ук ямый һәм баласының шәрә тәнен көн яктысына күрсәтми иде. Ул күлмәк-ыштаннарны безгә зур осталык белән үзе типчеп, үзе тегеп кидерә. Тегәргә яратса да, аның «тегү машинкасы» юк иде. Ул заманнарда машинкалы кешеләр түгел, машинкасы булган авыллар да юк, йә бик сирәк иде. Инәм машинкада тегү өчен Габдрахман абзасының хатыны Камилә әбигә, ул үлеп киткәч, аның яшь хатыны Хәмидә әбигә бара иде. Кемнәрне телгә алсам, барысының да урыннары оҗмахта булсын.

Безнең өчен иң гади, иң табигый, иң кечкенә, яңа күлмәк кию кебек көндәлек гамәл дә күктән төшкән яңалык, дәһшәтле шатлык, куанычлы тарих буларак кабул ителә иде. Шуңа күрә татар киеме агымдагы тарих белән аерылгысыз бәйләнгән иде. Без хәзер теләгән нәрсәне сатып алабыз да киябез. Теләгән нәрсәне алабыз да ашыйбыз. Ә безнең киресенчә, без аларның булмавыннан, була алмавыннан, гомумән, ачлык-ялангачлыктан гарык идек. Безнең буын өчен күлмәк-чалбарлы, чабаталы-итекле, тула оеклы булу, бишмәт-куфайкалы (фуфайка) булу – серле куаныч иде. Коточкыч, битабигый хәл бит бу! Адәм заты мотлак аның үзенеке булырга тиешле күлмәк-ыштан (чалбар)дан, бишмәттән (пальто-манто), пинжәк-кәчтүннән (костюм), итек-читектән мәхрүм булсын әле! Әгәр безнең заманның һәр кешесе аларны нинди юллар, газаплар белән табуы, ничек итеп беренче тапкыр киюе турында китап яза калса, без яшәгән җир йөзе шундый китаплар белән капланган булыр иде...

Инәй бик тә чисталык ярата иде. Татар хатынының җыйнаклыгы, чисталыгы турында риваятьләр күп, алар барысы да мотлак безнең инәй турында чыгарылгандыр кебек. Миңа өч-дүрт яшь булгандыр, инәй Ингель абый белән икебезгә бит сөртә торган вак шакмаклы тастымал тукымасыннан күлмәкләр тегеп кигезде. Аларны кигәч, без ап-ак фәрештәләр рәвешенә кердек. Шулай, безгә бәрәңге алу өчен өй базына төшәргә кирәк иде. Без идән сайгагын ачтык та, базга төшәргә дип торганда гына инәй безне туктатты:

– Сез шундый ап-ак бәзне кап-кара базга төшеп карайтырга җыендыгызмыни? Кемдер ул бәзгә кул гына сөртсә, без исә аны киҗеле тукымадан күреп, күлмәк итеп киябез!.. Беләсезме, аны табу һәм машинкада тегү өчен инәгез күпме йөз суларын түкте?!.

Бу аның сабыйларына биргән сабагы иде:

– Базга, бәрәңгең булса, шәрә килеш тә төшеп була...

Мин, хәер, барыбыз да, эчке киемнең (трусик, майка) нәрсә икәнен белми үстек. Бүгенге заман яшьләре өчен бу хәл бәлки кызыклы да булмас. Әмма мин аны теркәп куйыйм әле. Бу үзе генә дә Бөек Ватан сугышының ялангач тарихы түгелмени?! Өстемдәге барлык киемем инәмнең искиткеч оста кулы белән, артык күзгә күрсәтмичә ямалган бер кат ситса чалбар, теткәләнеп, киптергечкә әйләнеп, абзыйлардан калган юка бишмәт, аякларымда йә Качаган базарыннан, йә Галимулла бабайдан өч йомыркага алыштырып алган чабата, тула оек иде. Өч-дүрт көн эчендә мунчалага әверелә торган чабаталарны кию секунд эчендә башкарылса да, аларны табып өлгерү җиңел эш түгел иде. Мин үзем чабата тукый (үрә) белмәдем. Миннән өлкәнрәк абыем Ингель, шактый оста үрсә дә, башкага түгел, үзенә дә теләр-теләмәстән үргәнгә күрә, миңа дигәндә бөтенләй ашыгып бармый иде. Хәер, мин аны үзем үрергә өйрәнергә тиеш идем лә! Әмма булмады. Аннан, чабата безнең, татарларның, милли киеме дә түгел иде. Без аны Бөек Ватан сугышы кебек өзеклекләрдә генә кияргә мәҗбүр идек. Без, болгар-татарлар, читекле, сафьян күненнән тегелгән итекле милләт идек.

Әмма без итекле-читекле булырга тырыштык һәм шундый булып калдык. Без итек-читекне телебезне саклагандай саклый алдык. Татарның теш казналарының чагыштырмача нык, түземле булуы итек-читек урынына чабата кияргә мәҗбүр ителүе фаҗигасеннән, ягъни туктаусыз «теш кысу» касафатыннан шундый хәләткә кергән иде. Чабата кию бездә гарьлек тойгысын тагын да көчәйтте, ул антидепрессант буларак, безне гомуммилли депрессиядән саклады. Алай гынамы, аның яктысы безнең татар җырына да төште, дип уйлыйм мин. Шушы антидепрессант аны аеруча моңлы итте. Татар башка бер генә милләттә дә кабатланмаган, пентатониканың сигезенче нотасы аша чыккан МОҢ ИЯСЕ булып калды. Аеруча атасыз-анасыз ятимлек шартларында ул тагын да йөрәксеп, моң белән сугарылды... Җир йөзендә татар моңын аңлаган кавемнәр сирәк. Моның өчен изелү касафаты булган МОҢ ШИФАСЫН аңлау кирәк. Юл уңаеннан миңа, шагыйрьгә, берүк вакытта публицист та булган кешегә, әйтеп китсәм, урынлы булыр кебек: Явыз Иван безне басып кына, дәүләтебездән-хокукыбыздан мәхрүм итеп кенә калмады, зур уңыш берлә яңа гореф-гадәт, яңа сыйфатлар белән дә баетты: ул безне, әйткәнемчә, итек-читекне салдырып, чабата кияргә,

аракы эчәргә һәм русның үзенә биргесез рәвештә биш катлы итеп сүгенергә дә өйрәтте.

Сугыш һәм юклык-ярлылык татарга ничек кенә булса да «шәрәлектән» котылырга, өс киемле булырга этәргеч бирде. Татар кызлары бер сатин күлмәк, бер пар резин калош хакына Урал-Себер урманнарында агач екты, торф чыгарды. Татар егетләре шахталарда таш асларында кала-кала ташкүмер чыгарды, атлы юлдан кайтып кермәде. Татар баласы ничек кенә булса да матур киенергә, астрономик күләмнәрдә бөтен, гүзәл күренергә хыялланды һәм шуның өчен, кирәк икән, гомерен дә кызганмады. Ул ошбу хакта да җырсыз калмады. Үзебезнең атаклы шедеврыбыз булган «Шахта» көен хәтерлисездер? Минем өлкән абыем Гали аны җырлаганда, табыннар гына түгел, басулар да тын алудан туктый һәм сиздермичә генә яшьләрен сөртеп ала иде...

Сабыйның киемгә мөнәсәбәте ананың киемгә мөнәсәбәтеннән килә. Кеше тормышындагы бик кечкенә, бик бәләкәй генә штрихлар, шартлылыклар да соңгы чиратта характер булып, бергә яратыла һәм шул характерда чагыла. Бер генә сызат та игътибарсыз калмый. Бер генә сызат та читкә китми. Барысы да шәхес үзенчәлеге булып бергә төйнәлә. Кигән киемдә чагыла. Яраткан, теләгән киемеңне ничек кенә булса да табып кияргә, шуңардан ләззәт алырга кирәк. Татарда бер-береңә күлмәк бүләк итеп куандыру борынгы чорлардан килә. Хәтта милли бәйрәм тантанасына әверелә.

Бу билгеле социаль шартларда яклаучысыз, карауч ысыз калган ятим балалар өчен аеруча мөһим шарт – ул киелмәгән кием. Киелмичә калган кием күңел китеклегенә китерә. Яратып кигән кием яшәртә һәм яшәтә. Яратып кигән кием белән күңел түгәрәкләнә. Киелмичә калган киемнең бурычы кешене кайда барса да озата бара. Килешеп торган кием балада, аеруча ятим балада, горурлык, үзең белән канәгать булу тойгысын тудыра.

Бу нисбәттән минем беренче кәчтүм алуым үзенә күрә бер символик мәгънәгә ия иде. Гомумиләштереп әйткәндә, ул ничек кенә булса бар булу, шәхес булып формалашу – соңгы чиктә бәхетле булу өчен көрәшнең үзенчәлекле чагылышы иде.

Мин бит сезгә үземнең ничек костюмлы (ул татарча бик серле рәвештә «кәчтүн» дип йөртелсә дә, мин аны шушы урында гына үз яңгырашында «костюм» дип алырга мәҗбүр) булуым турында сөйләргә тиеш идем. «Туктагыз, нибары ундүрте тулып килгән, дефициттан башы чыкмаган авыл малаена нинди костюм?!» – диярсез сез. Һәм бу дөрес тә булыр. Әмма минем, нәкъ әнә шул авыл малаеның, башкалардан аерылып торып, эчтән дә, тыштан да матур, бөтәйгән күренергә тырышуы да бар бит әле. Мин кулдан тегелгән, терсәкләре теткәләнеп беткән, ямаулары аша да җил сызгырып торган пинжәктән тыш, беренче тапкыр фабрикада тегелгән чын кәчтүмне кайчан күрдем икән? Хәзер анык кына әйтә дә алмыйм. Әлбәттә, андый «чын кәчтүн» турында хыяллану өчен мин аны кем өстендәдер күрергә тиеш булганмын, шулай бит? Әмма мондый нечкәлекне хәтер сакламаган.

1956 елда Олы Кәркәле җидееллык мәктәбен тәмамлагач, мин Кыргыз-Миякә урта мәктәбенә барырга тиеш идем. Бу мәктәпкә мин, үземнең уйлавымча, бары тик кәчтүндә генә бара ала идем. Бу минем ант рәвешендә

бирелгән нәзерем иде. Кистереп кенә әйткәндә, мин сигезенче сыйныфка кәчтүнсез бару хокукыннан мәхрүм идем. Мин, радио-телефон-телеграф баганаларын, электр куыгын, кара эшләпәле радиоалгычны беренче тапкыр күргән сабый, Кыргыз-Миякә кебек «шәһәр җирендә» үзем дә «гарадскуй»га әйләнергә тиеш идем! Ләкин моңа ничек ирешергә? Бу кадәр акчаны каян табарга? Үземнең бала акылым белән мин кәчтүмнең бик кыйммәт торачагын, хакының илле-алтмыш, бәлки йөз сумнан да ким булмаячагын чамалый идем. Акча табуның бердәнбер юлы – миннән өлкәнрәк замандашларым тәҗрибәсеннән чыгып, урманчылар бригадасына урман кисәргә яллану иде. Ә кем мине, гәүдәсе «бер чемтем булган полк малаен» андый бригадага алыр?! Урман кисәргә дигәндә, минем юньле балтам да, аннан хәтәре, аркылы пычкым да юк! Мин аларны теши дә, үткерли дә белми идем. Аннан, мин бит әле гәүдәм белән дә тал чыбыгы кебек сыекмын. Мускул-сумитләрем юан агачларны ега, иңенә салып, өемгә ташый, кубатурага тезә алырмы? Минем бит әле беркайчан да урман кискәнем, урманда яшәгәнем-ашаганым юк!

Мин теләгем турында башта инәй белән киңәштем. Каршы булу гына түгел, ул куркып ук калды.

– Син нәрсә, бүрәнә астында каласың киләме?! Атаң фронттан кайтмады, инде сине дә үлемгә җибәримме? Мин сиңа, ипи дигән нәрсәкәйне комбайннан да шәп урган урманчыга, нәрсә ашатыйм? Минем сине туйдырырлык ипием дә, ылкынганчы ашатырлык итем-маем да юк!.. Бу уйны башыңнан чыгарып ташла!..

Әмма Вакыт галиҗәнаплары минем тегермәнгә су коя иде. Нәкъ шушы көннәрдә минем дусларым, дөресрәге, абыйларым (алар миннән ким дигәндә дүрт-биш яшькә өлкәннәр иде) Наил, Вәкил, Кыям, Зыя урманчылар командасы оештырып, Стәрлебаш комхозына утын хәзерләү өчен бер төркем кешеләр туплап маташалар иде. Мин үземнең теләгемне зур саклык белән миннән биш яшькә зуррак ут-күршем Зыя Борхановка җиткердем. Шытырдап торган шома кара чәчле, чекрәеп торган зәңгәр күзле, моңлы тавышы белән җырчы даны таралган, моңа кадәр урман эшендә берничә тапкыр катнашып, үзенә күрә ярыйсы гына тәҗрибә туплаган Зыя дустым, әүвәлдә күзләреннән зәңгәр ут чәчрәтеп, минем буй-сынымны күздән кичергәннән соң шаркылдап көлде. Аннан, сузып:

– Ай-һай, малайкаем, – диде дә белемле кыяфәт белән өстәп куйды: – Үзеңә авыррак булмасмы?.. Синең кебек малай-шалайны кем генә урман эшенә алыр икән? Урманда, быррат, закун – тайга, мидвид хозяин...

Бу кадәр аңлашылмаган сүз тезмәләреннән соң нишләргә белми торганда, күпмедер вакыт үткәч, хәлемә кереп, ул миңа теләктәшлек күрсәтте.

Бу минем беренче уңышым иде. Арабызда иң өлкәнебез Наил Булатовка чират җитте. Аңа егерме бер яшь. Үз ихтыяҗларыннан башка нәрсәләргә әллә ни тыкшынып бармаган Наил абзый:

– Син Вәкил белән сөйләш. Безнең старшой ул бит... – диде дә танау астыннан нәрсәдер мыгырдап тынды.

Әмма мин Вәкилгә кадәр иң якын дустым, миннән шулай ук биш яшькә зур булган Кыям Мифтаховка тишелдем. Шаянлыгы бит алмасындагы чокырыннан башлап аягына кадәр төшкән оста тальянчы, абыем Ташкент

тарафларыннан алып кайтып, калдырып киткән тальянда уйнаган һәм мине тальянда уйнарга өйрәткән «Кыяметдин-балакаем» (аны әнисе Бәдигелъямалттәй шулай атый иде), анысын-монысын уйлап тормыйча, минем урман кисәргә бару теләгемне күтәреп алды:

– Әллә кайчан кирәк иде, малай. Син пионер гына түгел, октябрят яшеңнән үк урман өчен яратылгансың. Урман сине көтә. Давай!..

Ниһаять, чиратта «старшоебыз» Вәкил Мостафинны кодалыйсы калган иде. Без барыбыз да әтиләре сугышта үлгән фронтовик балалары идек. Минем атам Нәҗметдин белән аның атасы Садыйк дус булганнар. Без шулкадәр туганнарча якын идек ки, бер көнне Вәкилләрдә кунсак, икенче көнне Вәкилләр бездә куналар иде. Бу шарт минем үземне иркенрәк тотарга дәртләндерсә дә, ул, «старшой» булган абзам, баштан ук үзен коры тотты һәм урман егу кебек катлаулы, куркыныч эшкә мине, «мондый бәләкәй» кешене, үзләре белән алырга батырчылык итмәвен ярып салды. Мин сөйләшүнең шундыйрак булачагын алдан ук чамалаган һәм үземне ничегрәк тотарга икәнен күз алдына китерә биреп куйган идем. Көтелгәненчә, мин үзем һөҗүмгә күчтем һәм үземне кызгандыру, хәлемә кертү өчен алдымда торган каршылыкларны каһарманнарча җимерергә керештем:

– Вәкил абзый, син мине урманчылар командасыннан сызып ыргытырга тиеш түгелсең! Хакың юк! Өч айдан мин Миякә урта мәктәбенең сигезенче сыйныфына укырга барам, анда кәчтүне булмаган кешене алмыйлар. Кәчтүн урынына мин сине алып барыйммыни?! Юк, мин синең бригадаңда урман кисеп, кулыма төшкән акчама сатып алырга тиешмен ул кәчтүнне!..

– Сиңа шушы яшьтән урман аударырга?! – дип кызып китте Вәкил абый. – Ундүрт ел кәчтүнсез йөргәнсең, тагын ундүрт ел гына йөрерсең әле. Син нәрсә, диләнкәдә качышлы уйныйлар дип белдеңме? Анда авыр пычкыны көннәр буе җырлатып тартырга кирәк, энем! Ярар, мин сине алдым да, ди. Юан кәүсәне аудара алмагач, нәрсә, аның ботагында сандугач булып сайрарсыңмы? Әгәр киселгән кәүсәң урынында әйләнеп китеп, үзеңне гөрселдәтеп басса, инәкиеңә нәрсә дип җавап бирермен? Юк, ала алмыйм!..

Күз алларым караңгыланып китте. Бер мизгелгә шул ук «гарадскуй» кәчтүн күз алдымда пәйда булып җем-җем итте. Мин театрдагы кәмитче сыман елап җибәрдем:

– Вәкил абзый! Мин бит инде хәзер өлкән кеше. Мин синең боерыкларыңны катгый үтәячәкмен! Күр дә тор, киләчәктә мине үзең белән алып, дөрес эшләгәнеңә ышаначаксың, Алла боерса!.. Мине бит кәчтүнсез мәктәпкә кертмәячәкләр... – Тора-бара, мин тагын да батырая төштем. – Сугышта ятып калган әтиләребез хакына, безнең ахирәт инәйләребез хакына алыгыз инде мине, Вәкил абзыкаем!..

Һәм көтмәгәндә, кемдер кушкан диярсең, мин театрдагы сыман аның алдына тезләндем.

Йөзе-кыяфәте белән гел йомышлы, гел уйчан, барыбыздан да озынрак, чагыштырмача таза гәүдәле булган Вәкил абзам, коңгырт күзләрен челт-челт йомып, теш араларыннан черт итеп җиргә төкерде дә:

– Әйдә, синеңчә булсын! – диде. – Әмма эш авыр дип, борыныңны салындырасы түгел! Мәтри аны, малай!..

Шулай итеп, мин урман кисүче булып киттем.

Безнең авыл белән Стәрлебаш арасын егерме чакрымнан артмый, диләр. Кәркәлетамак ике район үзәге Кыргыз-Миякә белән Стәрлебашның нәкъ урталыгында ята. Без кисәргә тиешле урман делянкасы Стәрлебаш юлы өстеннән уң кулда яткан рус авылы Николо-Берёзовканың култыгына кереп чумган икән. Без анда җәяү барырга тиеш идек. Безнең ишләрдән өчебез – Наил, Зыя, Кыям бездән берничә көнгә алдарак кузгалып, без яшәячәк куыш хуҗалыгын әзерләргә, кирәк булачак нәрсәләрне хәстәрләргә, Вәкил белән без килгәнче урманны ега да башларга тиеш иде. Ул шулай булды да. Берничә көннән аркабызга авыр гына капчык-биштәрләр асып, ике аркылы пычкыны бил тирәли бөгә салып, без дә таныш булмаган Николо-Берёзовка тарафларына юлга чыктык. Юлыбыз башында, дөресрәге, Стәрлебаш борылышына кадәр, без нииндидер юлчының озын арбасына утырып бардык. Мин үз уңаемнан юлда очраклы рәвештә очрап, мине теге хыялымдагы ялтыравык сәдәпле, ике япмалы, русча әйткәндә, «двубортный» (була шикелле) кәчтүмгә якынайткан абзыйга эчемнән рәхмәтләр укып бардым. Шул ук вакытта үз өстенә җаваплылык йөкләп, мине урманчылар арасына алган Вәкил абыйга рәхмәтләр укый идем. Гүяки ул үзенең тырыш, иҗтиһадлы куллары, йөгерек бармаклары белән минем иңнәремә менеп утырачак кәчтүнемнең сәдәпләрен эләктерә-каптыра... Теләсә нинди эшнең, юлның уңышлы, яки уңышсыз чыгуының очрак дигән серле нәрсәгә бәйле һәм хәтта ки лаек булуын мин менә шундый зур тормышка чыгуымның беренче адымнарыннан ук аңладым.

Минем җаным җырлый иде. Ничек җырламасын? Уйларым бит мине әллә кайларга очыртып алып китә. Менә мин авыллардан җыелган малай-шалай арасында бердәнбер «җегет», ялтыравык сәдәфле кәчтүн киеп, дәрескә керәм. Кыргыз-Миякә мине күрер өчен аякка баса! Таныйсызмы мине? Карап калыгыз, җәмәгать!..

Әмма ләкин безнең татар колагы өчен ят яңгыраган Николо-Берёзовка авылын уратып үтеп, аны Стәрлебаш лесхозының аскы өлешенә китереп ялгаган кырык сигезенче кварталына килеп төртелгәч, әле генә урманчылар хозурына эләгүем шатлыгыннан җырлап килгән җаным кинәт кенә җырлаудан туктады: без делянкага аяк басу белән мондагы күренештән таң калып, авыз ачуым булды, егетләребезнең аны-моны уйламыйча, як-якка каранып тормыйча төптән киселгән агач кәүсәсе, кояш белән икебез арасында әйләнә биреп, урынында катып калды... Мин бу матурлыктан аһ иттем. Аннан ул кәүсә урынында бөтерелә, кояшны да үз тирәсендә әйләндерә башлады. Мин үз өстемә ауган сыман булып күренгән кәүсәдән котылырга, дөрес юнәлеш алырга теләп, кая да булса качарга тотындым. Әмма соң иде инде. Агачның төбеннән унбиш-егерме метрларда булган очы мине шундук куып җитте һәм усак агачы, гөрелдәгән тавышлар чыгарып мине бәрде дә екты...

Бу хәл гүя елларга сузылган секундлар эчендә булды. Моның шулай килеп чыгачагын мин түгел, тәҗрибәле урманчы Вәкил абый да абайламый калды. Әйтерсең кисентебезгә аяк басуыбызны котлаган сыман, бу мәһабәт усак агачы гүя култык астыбыздан суырылып чыгып, «Бездә ачык

авызларны шулай зурлыйлар» дигәндәй, мине, кәчтүм артыннан йөгереп килгән малайны, шулай җилләп кенә очырган иде...

Гарьлегемнән җир ярылмады, мин анда төшеп кенә китмәдем. Ачык авыз! Оялуымнан нәрсә эшләргә дә белмәдем. Читтән карап торганнарга мин балтасын суга төшереп җибәргән бәндәне хәтерләткән булганмындыр. Шулай да егетләр мине күтәреп алдылар. Башым тишелеп, ярамның аз гына кансыравын исәпләмәгәндә, барысы да тәртиптә иде. Яшь тән ярасының ямавы үзендә дигәндәй, мин бу хакта уйлап та бирмәдем. Бәла сизелмичә килде һәм сизелмичә-сүгенмичә китеп тә барды. Иң мөһиме, иң шатлыклысы: мин менә шушы рәвешле урманчы сынавын үткән идем. Бу очрак минем күңелемдә мәңгегә уелып калды. Адәм баласы никадәр көчле итеп теләсә, ихтыяр кылса, шул кадәр түземле һәм сабыр була икән.

Безнең диләнкедәге яшәеш өч өлештән гыйбарәт иде: эш, шул эш белән бәйле көндәлек тормыш, йокы һәм өч тапкыр ризыклану. Аны ашау дип тә, туклану дип тә булмый, ул чынлап та нәрсә бар, шуның белән әппәр итү, ягъни ризыклану иде. Азыклар исемлегендә беренче урында авылдан алып килгән, шарты чыкса, Стәрлебаштан китерткән ипи, бәрәңге, такта чәй, макарон, булса, шул ук авылдан килгән йомарлам май, катык-сөт... Маебыз булган очракта, без аны кояшта эрүдән саклап, борыны белән куышыбызга килеп төртелгән чишмә суы салкынында саклый идек. Ит пешергәнебезне нишләптер хәтерләмим. Ит дигән нәрсә, деликатес саналса да, бөтенләй булмый калмагандыр ул. Тозланган ит, әлбәттә. Кара әле, төп ризыкларыбызның берсе булган чишмә суын әйтергә онытып торам икән бит. Сабый чакта, аеруча йөрәге сау-таза яшьлектә, бары тик чишмә суын эчеп кенә дә яшәп була. Суның иң зур, иң куәтле ризык икәнен мин дистә еллар үткәч кенә, милләт азатлыгы өчен тотылган сәяси ачлыкларым чорында гына аңлармын. Бу хакта очрагы чыкканга гына әйтеп китүем.

Безнең тормышыбызга карата, әгәр шулай әйтергә яраса, «төп ямь»не чебен-черки, озынборыннар, көннәр җылына төшкәч, аеруча майның икенче яртысында котырыпмы котырган кигәвеннәр китерә иде. Шулай да, алар арасында ул елны иң куркынычы, иң дәһшәтлесе чынлап та озын борынлы Черки галәйһиссәлам иде. Урнашкан урыныбыз сазламыграк һәм уйсурак җир булганга, ахрысы, куышыбызны уратып бөтерелгән-кайнашкан эре черкиләрнең куерымын кәтилүкләребез белән чумырып алырга мөмкин иде. Ун сыйныфны тәмамлаганнан соң, миңа калмык далаларында – Каспий буе камышлыкларында бораулаучы ярдәмчесе булып эшләргә туры килде. Шундагы бармак башы кадәр черкиләрне исәпләмәгәндә, миңа үз гомеремдә Стәрлебаш урманнарындагы кебек зәһәрле-каһәрле, канечкеч черкиләрне күрергә туры килмәде. Ул заманда хәзерге кебек черки кыра торган дарулар юк иде. Алар безгә көнен дә, төнен дә тынгы бирмәде. Энәләре безнең ябынган кырык корамаларыбыз аша җиңел үтә иде. Көне буе башкарылган авыр эштән соң ишелеп йоклар урында шатыр-шотыр кашынып чыгу бер дә күңелле гамәл түгел иде, мин сезгә әйтим. Аннан, безнең ябыныр нәрсәләребез дә такы-токы иде. Баш астыбызга элпә кебек җиңел пинжәк, сырма фуфайка (без аны «куфайка» дип йөртә идек), башыңнан ябынсаң, аякларыңа, аякларыңнан ябынсаң, башыңа җитмәгән бишмәт, кырык урыннан тишелгән, ямалган һәм

типчелгән чүпрәк палас һәм башка сәләмәләр иде. Безнең һәркайсыбыз ул нәмәстәкәйләрне үзенең тарафына тартып төн үткәрә. Кайбер аеруча тынгысыз төннәрне черкиләр талауга түзә алмыйча, йә шунда йокы аралаш саташып китеп, башларыбызны күтәрәбез һәм бер-беребезгә «Без кайда икәнбез? Без нишләп монда икәнбез?» дигән сыман карашып утырабыз...

Кайчагында, шактый яшь булсам да, үзләренә иш күреп, мине куеннарына сыендырган, хәзер исә гүя бары тик минем аркамда йоклый алмыйча черкидән талатып газапланган өлкән дусларыма, аларның миңа кылган изгелекләренә сабыйлыгым аркасында төпле, тирән бәя бирә алмастан, нииндидер алтынчы-җиденче, рәхмәти тойгы белән һушым китеп карап тора идем. Без биш үсмер, канатлы чагыштыру белән әйткәндә, бишектән буразнага төшкән «колхоз атлары» идек. Менә иң өлкәнебез Наил абый. Тырышларның тырышы. Татар авылында көчләп ачтырылган беренчеләрдән беренче дуңгыз фермасында иң яхшы дуңгыз көтүчесенә бирелгән беренче приз – җиз кадаклы ботинка белән бүләкләнгән Наил Булатов ул. Мин аңардан үрнәк алып эшли, хәтта ки, аңарга охшарга тырышып, ун сыйныфны тәмамлагач, колхозыма кайтып, бары тик ат караучы булып эшләү турында хыяллана идем. Атаклы көрәшче, сукса, тимер өзгән Булат-батыр оныгы. Наил дә картатасы сыман бик көчле иде. Мин үз гомеремдә аның кебек колхозга җаны-тәне белән бирелеп, «яратып изелгән» үсмерне хәтерләмим. Әнисе Гайнияттәй, туганнары Флүрә һәм минем дустым Флүр. Менә мине тальян телләренә билге сыза-сыза гармун уйнарга өйрәткән дустым, шулай ук сугыш ятиме Кыям. Дөресрәге Кыяметдин. Әниләре Бәдигыльямалттәй теле белән әйткәндә, «Кыяметдин-балакаем». Әтисе Каюм. Исемнәренә игътибар итегез, һәркайсы җәүһәр. Сбердлау урманнарында вербовка белән урман кисүдән кайтып кермәгән апалары Рәйхан, Мөслимә. Абзыйлары Инсафетдин, Әхнәфетдин... Өченчебез Зыя Борһанов. Безгә кич утырырга керүче Сания әбекәйнең улы. Моң ягыннан алганда, Илһам Шакиров нәселеннән. Радио юк заманнарда ул эшкә барган-кайткан авыл халкы өчен өянкегә менеп утырып җырлый иде. Минем Зыяга багышлап язылган «Җырлар вакыт» дигән хикәям дә бар. «Гүзәлем» дигән җырны мин, Илһам абзыйдан кала, аңардан да моңлы итеп җырлаган җырчыны хәтерләмим. Зыя да – сугыш ятиме, әлбәттә. Әтисе Юныс, әнисе, әйткәнемчә, Санияттәй, апасы шулай ук оста җырчы Фәния апа. Әтисенең беренче хатыныннан туган абыйсы, нәфис сызгыру остасы Исмәгыйль (шулай ук минем «Искитмәле Исмәгыйль» дигән хикәямнең каһарманы), апасы шундый ук тирән моң иясе Гафирә апа... Куыш эчендә шатыр-шотыр кашынган дүртенчебез – «старшой» Вәкил абзый. Алар минем өлкән абыем Ингель белән ут-су да аера алмас дуслар-шәриктәшләр. Шулай ук фронт ятиме. Инәсе Садыйкаттәй белән минем инәм Соруттәйнең ахирәтләр булганлыгы кат-кат әйтелгән иде бугай. Вәкил абыемның бердәнбер туганы, минем балачак дустым Камил бар иде... Гел «иде дә иде» дияргә туры килә. Чөнки аларның берсе дә юк, сугыш күрсәткән ятимлек газапларыннан алар теге дөньяга бик яшьли китеп бардылар...

Әйдәгез, җәмәгать, черкиләребезгә әйләнеп кайтыйк әле. Төнлә ничек кенә ачыргаланмыйк, иртәсен барыбер дә эшкә дәрт, гәзит теле белән

әйткәндә, хезмәт илһамы белән тотынабыз. Шуңа да яшьлек дип аталгандыр инде ул. Черки патшалыгында, битләрен-йөзләрен ерттыра-ерттыра, ялтыр сәдәфле кәчтүн турында хыяллана бит ул.

Черкиләрдән котылу өчен без нәрсә генә эшләмәдек тә, нәрсә генә кыланмадык. Куышыбызның тишек-тошыкларын юнәтү, сипләү дисеңме, төнгелеккә, тирә-яклап, үзебезгә дә ут капмагае дип курка-курка гына учаклар белән урату, дисеңме – әмма боларның берсе дә черкиләрнең көн-тире аша да җиңел үткәзә торган энәләреннән коткармады. Кычкыртып талаган черки бимазасыннан арыган җырчы егетебез Зыя Борһановның, аптырагач, нишләргә дә белмичә, бар тавышына яңгыратып, «Кара урман»ны җырлап җибәргәне хәтердә... Черкиләр агрессиясен җыр белән туктатып була, диме?! Әмма без черки хорында да татар моңын тыңлап юана идек. Безгә алар белән ул елларда модада булган социализм-капитализм системалары арасындагы кебек, «килешеп яшисе» генә калды...

Бригадта бишәү булсак та, хуҗалык эшләрендә, мәсәлән, аш пешерү, башка азык хәстәрләүдә дүртебез генә катнаша иде. Ни өчен дигәндә, бишенчебез Наил абзый Булатов бик авыр, авылдашларыбыз әйтүенчә, «моңарчы күрелмәгән» авыру белән чирли иде. Моны ничегрәк аңлатырга икән? Аңлата алырмын микән? Чөнки хәтта бүген, сиксән яшемә җитеп барган көннәргә кадәр мин мондый сырхауны башка беркемдә дә күрмәдем һәм башка беркайда да очратмадым. Мин аны сугыш һәм сугыштан соңгы елларда кешегә аңлата алмас дәрәҗәдәге антисанитария шартларыннан килеп чыккан вирус-малярияның бер төре булгандыр дип уйлыйм. Ул сугыш ятимлеге алып килгән гариплек, кабатланмас афәт иде. Аның куллары, бармаклары өрелеп шешкән. Ул үзенең нинди авыру белән авырганын белми, зарланмый, сиздерми, бернинди «янбалитлык» турында уйланмый да кебек. Бу тыштан гына шулай күренә. Тәненең тиреләре ярылып-яргаланып кансырый. Аның һәр бармагы шешенгән-кабарган иде. Моны нинди рәвешле булганын фаразлау өчен һич арттырмыйча һәм бәлки урынсыз күренәчәк чагыштыруым өчен гафу үтенгәндәй әйтәм – беләк юанлыгындагы кишерне күз алдына китерергә кирәк. Гүя, биш бармагың һич кенә дә биш бармак түгел, ә биш юан кишер. Уңышсыз чагыштырганым өчен гафу үтенәм. Мин башкача чагыштыру таба алмыйм. Наил кардәшебез гәүдәсе, асылынып төшкән куллары-беләкләре белән уңга-сулга җәелебрәк атлый башласа, ул торганы белән аюга охшый да куя иде. Аның тиреләре ярылып, кансырап торган бармаклары-куллары кутырлый, җепши, сулана, болардан ничек тә котылырга теләп, ул чишмә буена төшә һәм берьялгызы яраларына, киптереп-корытып булмасмы дип, пудра сибә, йомшарту өчен вазелин-крем сөртә, марля (татарчасы ничек икән?) белән ураштыра. Гел шаярырга яраткан «Кыяметдин-балакаем» иртәле-кичле егетебезне куышта күрми торса, «Наил чишмәгә бизәнергә төшеп китте, озакламый кайтыр, көтегез», дип көлдерә иде...

Урман кисүнең язылмаган кануны – тел үткерлегең түгел, ә бәлки пычкың һәм балтаң үткерлеге иде. Аларны һәркем дә үткерли алмый. Анда үткер күз һәм үткен зиһен кирәк. Пычкыны тешәү, ягъни кырын салып, телләрен бер уңайга төзәтү, «тешләү» аеруча нечкә хезмәт. Безнең биш кешелек түгәрәктән ике кеше – Вәкил белән Зыя гына пычкыны

һәм чалгыны үткерли дә тешли дә белә, Наилдән башка калганнарыбыз, тартып-сузып, аеруча мин фәкыйрегез, бары тик үткерләп кенә мәтәшкән була идек. Наил абзам үз язмышы белән килешкән: аның пычкы тешәү белән үткерләүдә кайгысы юк: ул киселгән агачларны кулыннан килгәнчә өемгә өстерәп китерә, балтасын тота алганчы тотып, ботакларын туный, агачларны өемгә өя; ул ифрат та көчле, бу эштә аның белән башкалар ярыша алмый. Шуңа күрә аны Кыяметдин «трахтырис» дип атый...

Бер уңайдан күпмедер вакыттан соң Вәкилнең Флүрәгә – Наилнең сеңлесенә өйләнеп, бик яхшы, килешеп яшәгәнлекләрен, балалар үстерүләрен әйтеп китсәм, бер дә артык булмас кебек.

Безнең төп ризыгыбыз, бәрәңге белән макароннан тыш, чишмә битләүләрендә, урман эчләрендә үскән күп төрле ашарга яраган үсемлек – инде ката-картая да башлаган балтырган, кузгалак-кымызлык, сарана һәм башка шундый үләннәр иде. Безнең кечкенә казаныбызда бар нәрсә дә, хәтта ит шәрифләре дә (булсын гына!) җырлый-җырлый пешә иде. Эшебез авыр булса да, мондый эш җимертеп ашауны таләп итсә дә, безнең мөмкинлекләр, әйткәнемчә, бик такырдан иде. Гадәттә, без Стәрлебаштан китерткән кара-соры ипи, шулай ук сирәк эләккәли торган шакмаклы шикәр, былтыргы мәтрүшкә чәе, сирәк кенә такта чәй, коры суда йә бәрәңгеле-итле ашка маргарин, булганынча макарон, токмач салып пешергән аш белән тамак ялгый идек. Безнең рационыбыздагы төп ризыкларга өстәлгән иң мул ризык ул – теләсә нинди вакыйга, теләсә нинди күренешкә үз бәясен биргән, бер генә адымыбызны да көлкесез калдырмаган атаклы «Кәркәле юморы» иде. Без чишмә суын үлчәмичә тотына, үлчәмичә эчә идек. Әмма кирәгенчә күләмдә, безнең аңлавыбызча, «артыгын», бары Наил генә куллана ала иде. Мәсәлән, Кәркәле юморы раславынча, безнең иң майлы ашыбыз – нәкъ әнә шул су, кайнаган су иде. Азык-төлек исемлегендә, урыны әллә ни зур, хәлиткеч булмаса да, әле яңа гына өлгереп азапланган кыяклы суган иде. Без аны каян ала идек? Үзебез үстермәгәнбездер бит инде? Юк, әлбәттә. Азык рационының бу өлеше өчен арадан «иң бәләкәй һәм җитез малай» булган мин җаваплы идем. Яшел суган ипи белән ашар өчен «үтрический» ризык иде. Шушы кыяклы суганның урынын ачыклау, аның белән ничек кенә булса да, аш өстәлебезне баету бурычы минем өскә төшә. Моның өчен миңа төннәрендә Николо-Берёзовка бакчаларын уташтырырга туры килә. Бу адым ул кадәрле гөнаһлы булмаса да, караклык, дөресрәге, малай-шалайлыкка тарткан вак угрылык иде. Мин, гадәттә, төн караңгысы төшеп, күзне биләгәч эшләнә торган бу гамәлгә кайчан да булса бер чик куелачагын белә һәм аны көтә идем. Һәм ул чынлап та озак көттермәде.Төннәрдән бер төнне, үземнең көндәлек бурычыма әйләнеп киткән «сәяхәтемне» башкарып маташканда, бер кырынмаган Николо-Берёзовка мужигы ботымнан эләктереп, йомшак җиремнән сизелерлек итеп тәпәләп тә өлгерде. «Әгәр дә тагын бер мәртәбә бакчаларыбызга төшсәң, теге җиреңне кисеп ыргытам» дип, миңа бик тә аңлашылган аһәң белән җикереп тә куйды. Башым исән чакта тиз генә бакчадан чыгып сыздым. Сатып алырга җыенып кына торган ялтыравык сәдәфле кәчтүнем күз алларымнан югалып торган бу минутларда мин бу шырткак

сакаллы абзыйга чагыштырмача җиңел ычкындырганы өчен рәхмәтле идем. Кая ди тагын да тамак өчен борыным белән суган түтәлләрен сөрү?! Ул бит мине кулларымнан каерып, авылларына алып кайта һәм базларына ябып куярга, милициягә тапшырырга да булдыра иде. Менә ул чакта инде, кәчтүн абзыкаем, бөтенләй дә хуш, исән бул!

Озакламый без барлык җитешмәгән нәрсәләрне җиңел генә күтәрергә өйрәндек. Монда безнең яшьлегебез, авырлыкларны моң-шаян сүз белән үткәрү, күңел көрлеге, юклык-мохтаҗлыкка махы бирмәү, аннан, бишегеннән үк, барлык милләте белән ятим булган татар баласының чиктән тыш тырышлыгы, һәвәслеге һәм үҗәтлеге ярдәмгә килде. Мин хәзер уйлап-уйлап торам да бу тормышның бөтенләй дә икенче, без бүген күз алдыбызга да китерә алмаган тормыш, без сөйләшкән телнең бөтенләй дә икенче, атап әйткәндә, искиткеч анык, төгәл, тирән мәгънәле, бай, газап-югалтулардан нечкәргән һәм шомарган тел булганлыгын искә алып китәм. Болай да ачлы-туклы яшәгән үсмерләрнең, хәзер инде боларга өстәп, авыр физик хезмәттә тагын да йотыгып, черки-кигәвеннәрдән талана-талана, битләрен-кулларын ерттыра-ерттыра урман кисүләрен, агач өстерәүләрен без бер бәхетле язмыш, табигый шигърият, тыныч тормыш куанычы дип кабул итә идек. Без бу хәлләрдән туйганчы көлә һәм шушы хәлсезлек безгә хәл кертә иде. Гүя җирдә бездән дә ирекле, бездән дә бәхетле җан иясе юк иде. Бер айга якын урман кисүебез чорында ике тапкыр коеп яңгыр яуды. Бездә аны «коен» диләр. Без «биш персоналык» куышыбыз белән бергә су эчендә калдык. Су хәтәре, үзен хәстәрләп, астыбызга, хәтта бот араларыбызга кадәр үтеп керде. Баш очына сала торган бишмәтләр сыгып алырлык итеп лычма булды. Шырпылар чыланып, юкка чыкты. Учактагы күмерләр яңгырда пышкылдап сүнгән. Яралы кеше сыман ыңгырашып яталар. Утны тергезеп булмый. Үзенә күрә бу фаҗигаи мизгелләрдә дә Кыяметдин-балакаемның Наилгә, урман кискән өчен алыначак акчасы исәбенә «парахут» белән больниска алып барырга «билет сатуы» безнең барыбызның, шул исәптән Наилнең үзенең, онытылып көлешкәннәребез хәтердә калган. Утсыз-кулсыз аптырагannan соң Кыям белән минем Николо-Берёзовкага барып, теге мине өшкергән «иске танышым» – шул ук кырынмаган мужиктан шырпы, казан белән утлы күмер кузы алып килгәнебезне онытырлыкмы? Кабатлапмы кабатлыйм: шушы заман балалары ничек тырыш, акыллы булмасын да, ничек мәгънәле һәм мәгърураңә горур булмасын?!

Диләнкедә без кискән урман мәйданы киңәйгәннән-киңәя, өелгән агач өемнәребез арткannan-арта барды. Без ул өемнәрне кабарту вә күпертү өчен сөйрәлеп китерелгән агачларның чыбыгын да читкә ташламыйча, өемнәребезгә өсти, күтәртә идек. Штабельләр саны арткан саен күңелебез югарыга талпына барса, исәп-хисап мәшәкатьләрен куркыныч рәвештә искә төшереп, комхоздан килүче «булгахтерларның» ешаюы күтәренке күңелебезне бик тә сагайта, сабырсызландыра иде. Шул ук вакытта бер сүнеп, бер кабынып янган йөрәкләребезне «коммунистик җиңүләр»гә өндәп, бөтәйтеп, безгә сугыштан соңгы елларда беренче тапкыр Миякәдә Сабантуй үтәчәген ишетү безне тагын да дәртләндереп җибәрде. Алга, бары тик алга! Мин бит бу Сабантуйга яп-яңа кәчтүмдә барачакмын, Аллаһ

боерса! Минем авылыбызга кәчтүмсез кайтып керергә хакым юк! Комхоз белән исәп-хисапны уңышлы гына өзәргә язсын!

Без ничә көн буена урман кискәнбез, күләме белән алганда, ничә кубометр кискәнбез – болар берсе дә хәтердә сакланмаган. Югарыда әйткәнемчә, бер айга якын булгандыр. Менә күп тә үтми безнең комхоз белән исәп-хисап сәгатебез дә килеп җитте. Оешманың вәкиле, ул директор урынбасары иде бугай, штабельләрне кубометрларга салып, ике өемгә өстәмә агач түшәтеп, безгә бераз сынаулы мәшәкатьләр тудырды да, моннан да артыгын кыланмыйча, киселгән агачның гомумкүләмен исәпләп чыгарды. Ул якынча без көткән күләмгә туры килде. Күздәге яшь чыкмаган килеш кипте. Шушы күләмне туры китергән хәлдә без комхоз вәкиленә күчтәнәчкә ул замандагы бер «акбаш»ны да хәстәрләп куйган идек. Аның күзләре, мин сезгә әйтим, шундук майланды. Тиешенчә җылынып алганнан һәм диләнкене тагын бер тапкыр тикшереп чыкканнан соң, хисаплашыр өчен Стәрлебашка килергә кушып кайтып та китте.

Тегендә-монда күзгә кереп барган ботак-сатакларны өештергән-җыештырганнан һәм өйрәнеп беткән «сараебыз» – куышыбызны, аерыласыбыз килмичә, елар чиккә җитеп сүткәннән соң, без булган барлык хуҗалыгыбызны аркаларыбызга йөкләп, Стәрлебашка карап, юлга чыктык. Егетләребезнең күңелләре күтәренке иде. Шулай булмыйча! Без бит икенче, чит, күрше район үзәге өчен кирәкле хезмәт кылып, хәзер шуның әҗерен алыр өчен китеп барабыз. Минем кәеф инде аңлатып бетермәс дәрәҗәдә күтәренке. Күпме бирерләр икән? Мин беренче тапкыр ишеткән «падахудный налук» дигән нәрсәләре күпме акчамны суырып калыр икән? Минем баш мием бары шушы уй белән кайнады: миңа ничә сум тияр? Алдамасლармы? Алтмыш? Җитмеш? Сиксән? Бу алынырга тиешле дип хыялланган әҗер. Ә кәчтүн үзе, кәчтүн үзе күпмегә төшәр? Миңа тигән акча җитәрме? Җитмәсә, күпмерәк? Җитмәгәнен кемнән алырмын? Миңа бу минутларда җиңел дә, авыр да иде. Җиңел, чөнки мин ул акчаны үз көчем белән табарга тырыштым. Авыр һәм шунысы белән авыр, мин авылдаш малайлар, үсмерләр – шәриктәшләрем арасыннан беренче булып кәчтүм дигән ифрат та сирәк кием сатып алырга җыенам. Ярый, акчасы акча, ә менә без барасы кибеттә кәчтүме булмаса, нишләрмен? Ничек кенә булмасын, бу минутларда мин куанычымнан юл буендагы һәр агачны, һәр үлән кыягын, Стәрлебаш халкының үзен, бар кешеләре белән тоташтан кочаклап үбәргә әзер идем. Менә шул чактан ук миндә Стәрлебаш дигән иманлы тарафка карата ниндидер аерым ихтирам, аерым олылау вә зурлау тәрбияләнгән. Аннан, ул бит әле безнең ут-күршебез – район үзәге генә түгел, миңа билгеле булуынча, әллә кайчаннан, кем әйтмешли, хан заманнарыннан университетларга тиң атаклы мәдрәсәләр торткан, байтак күренекле акыл эше, фән һәм дин эшлеклеләрен, язучы-шагыйрьләрне тәрбияләп үстергән мәдәният һәм мәгърифәт үзәге!

...Без, әйткәнемчә, аркаларыбызга биштәрләр асып, өч пычкыбызны бил тирәли бәйләп асып, җай гына Стәрлебашка таба атлыйбыз. Июнь кояшы аяусыз кыздыра, аркаларыбыздан, битләребездән аккан тирне сыгып алырлык. Наилгә аеруча читен, ул колачын җәйгән бөркет кыяфәте белән поф-поф килеп, арттан атлый бирә. Иңнәребезгә аскан капчыкларыбыз,

кулдагы пычкы-балталарыбыз җәяүле хадимгә шактый уңайсызлык тудырса да, безне көткән күңелле исәп-хисап хакына сер бирми түзәбез. Акчаларыбыздагы Ленин бабай төшкән ялтыр сурәтле кәгазьләребез күз алдыбызда шытырдаган аһәңнәр чыгарып куандыра, атламнарыбыз гүя үзебезне генә түгел, барлык кешелекне куандырыр өчен киңәйгәннән-киңәя бара. Алга, бары тик алга!.. Читтән карап торган кеше, бездәге күңел күтәренкелеген, максатка омтылышны абайлап алып, болар һич кенә дә гади кешеләр түгел, болар барлык нәрсәләре җитеш булган, шул җитешлекне куярга урын эзләп, киләчәккә ашкыныпмы ашкынган, очышлары җирдән күпкә югары булган батырлар заты дип уйлар иде. Һәрхәлдә без шундый булып күренгәнбездер. Бу укучыга да аңлашыладыр, шәт.

Хәтердә калуынча, миңа шул замандагы хак белән алтмыш сум чамасы акча тиде. Минем куанычымны күрсәгез! Үз акчам җитмәсә, мин дусларыма әҗәткә кереп булса да, ул кәчтүмне алачагыма инанган идем. Учыма төшкән акчаны учмарлап, дусларымнан алда, беркая, беркемгә карамыйча, ул чактагы Стәрлебашның бердәнбер булган «универмаг»ы кибетенә Тукайның Кисекбашы кебек тәгәрәп барып кердем. Әнә ул кәчтүм! Әнә ул!.. Күкшел төстә, җиңнәре-балаклары, күкрәгендә кечкенә кесәсе дә бар! Сатучыдан сорыйм: «Күпме тора?» Аһ, илле алты сум! Мин барлык кибеткә кычкырып җибәрдем: акчам җитә, малайлар! Мин Миякәгә укырга бары тик шушы кәчтүмдә генә барачакмын, Алла боерса. Өстемдәге агач ташый-ташый изрәп беткән иске-москыларымны салып ташлап, кәчтүмне киям. Менә дигән. Кып итеп кенә тора! Әмма, каһәр төшкере, ике үлчәмгә зуррак, җиңнәре-балаклары озын иде. Егетләрем ал дип тә, алма дип тә әйтә алмый, чөнки әгәр дә аларның берәрсе «Бу кәчтүмне алма!» дисә, мин аны тотып ашарга әзер идем. Алар телләрен йотып, бу тарихның нәрсә белән тәмамланасын көтә. Сатуда башка кәчтүмнәр бар, әмма алар төшеп югалыр дәрәҗәдә зурлар, минем фикеремчә, килбәтсез фасоннар иде. Минем үземә ошаган бу кәчтүм төсе-тегелеше белән минеке, бердәнбер, әмма ул, әйткәнемчә, зур иде. Мин шул чак, ундүрт яшьлек ятим, Стәрлебаш универмагындагы үземнән кала дүрт сугыш ятиме арасында, күңелемнән генә инәм белән киңәшеп алдым. «Әгәр бик ошый икән, ул кәчтүмне ал, улым. Җаны теләгән җылан ите ашаган, диләр халыкта. Җиңен дә, балакларын да эчтән бөгеп кыскартырбыз... – диде миңа инәмнең тавышы... – Ал да куй, күңелеңне сындырма...»

Кәчтүмне кабаттан киеп карадым. Иңбашлары бераз сәленкерәк иде шул. Ничава, сигезенчегә барганчы үсәм бит әле. Алда өч ай гомер бар әле! Шулай итеп, сатып алдым да куйдым мин ул кәчтүмне. Ышаныч белдереп, үз араларына керткән, шушы зу-у-р һәм мату-у-р кәчтүмне үз көчемә сатып алырга юл күрсәткән өчен бергә черки ашаткан өлкән дусларыма рәхмәтләр әйттем. Инәм аны таманлап кыскартып бирде. Мин шул кәчтүндә туган телем – Тукай телендә укып, урта белемгә ия булдым. Беренче шигырьләремне яздым, матбугатта басылдым, кызларга күз кысып, беренче мәхәббәтемне кичердем. Соңгы чиктә, мин ул кәчтүмдә сигезенче-унынчы сыйныфларда сыйныф старостасы һәм Миякә урта мәктәбенең комскомитет әгъзасы булып, урта белем аттестатын алдым...

Николо-Берёзовка урманнары белән хушлашып, шул урманнарны кискән

өчен күпмедер акча, шул акчага теге кәчтүмне алып, аны күз алмасы кебек бөкләп, капчыкка салып, шаян сүзләр белән бер-беребезне көлдереп, без финанс «башкалабыз» Стәрлебаштан Кәркәле тарафларына кайтырга чыктык. Биш-алты чакрым чамасы җир үткәч, безне бер йөк машинасы узып китте. Безгә күренүенчә, ул буш яки яртылаш буш иде. Туктатам да, кесәләребездәге калган акчабыз исәбенә байларча кикереп, машиналарда гына җилдереп кайтабыз, дигән хыял белән, аны-моны уйламыйча, кузовка сикереп мендем. Барган уңайга кабинага таба атлыктым. Машина шып туктады. Кабина баскычыннан шофёрның җимерелгән кыяфәте калыкты. Аның алгы тешләре арткы азау тешләренә кадәр ачылып, үткен келәшчә сыман мине өзгәләргә әзер иде. Ул нәрсәдер сөйләнеп, бик каты сүгенде һәм төкерекләрен чәчеп, кулындагы рукояткасы белән селтәнә-селтәнә, минем тарафка ыргыды. Минем алга таба үтеп киткән машинага сикереп менәргә хакым булмаган, әлбәттә. Шофёрның котыруы урынлы – гаеп миндә. Әмма хәзер ничек итеп бу бәладән котылырга? Шофёр чынлап та куркыныч – аңардан мәрхәмәт көтү мөмкин түгел иде. Әгәр кулындагы кәкре тимере белән минем башыма кундырса һәм мин аяктан егылсам?!. Ул мине кәчтүмем-нием белән алып та олакса? Бу минутта үлем миннән берничә генә адымда – юл өстендә иде. Иң курыкканым: капчыкта бөгәрләнеп яткан кәчтүм язмышы иде. Шушы кадәр хезмәт куелган байлык ятларга китеп барырмы? Мин аны шулай итеп суга салырмынмы?! Шофёр белән мин: ул – алга, мин – артка, ул – артка, мин – алга атлыгып, кузов өстендә өерелә, куыша идек.

– Килегез, егетләр! – дип, җан ачуы белән кычкырып җибәрдем үземә таба ярдәмгә йөгерә башлаган дусларыма. – Коткарыгыз!..

Шофёр миңа ярдәмгә йөгерүче егетләремне күреп, бәладән – башаяк дип, мине эзәрлекләүдән туктады һәм һаман да сүгенә-сүгенә, кабинасына кереп чумды һәм китеп барды. Мин шул арада машинадан сикереп төшеп калдым.

Иптәшләрем зур юллар чатында шулай «батыр» кыланганым өчен мине шактый үтемле итеп кыздырып алдылар. Юл өстендә сабак дигәнең бихисап тулып ята, ә менә мин аласы кәчтүм бирәү генә иде. Бу вакыйга юлга чыккан кешенең, аеруча беренче мәртәбә, аеруча сабый баланың нинди генә хәлләргә тарырга мөмкин булуы турында сөйли иде. Ул безгә авылга кайтып җиткәнче, хәер, алай гына түгел, киләчәктә озак еллар буе искә төшереп (сагынып!) сөйләргә дә ризык булды.

*(Ахыры киләсе санда.)*



Мөхәммәт
Мирза

# АДӘМ БАЛАСЫ

БИШЬЮЛЛЫКЛАР

## I

*Гел үзгәреп тора:*
*Бөгелә, турая...*
*Адәм баласының*
*Яраша белгәне*
*Бер башка зурая...*

М.Мирза.

***

Түбәнгә төшмәде,
Биеккә менмәде.
Адәм баласы гел
Ансат урталыкта
Калырга теләде.

***

Иртәләп килде яз,
Соңармады көзе:
Адәм баласының
Йөзенә сарылды
Басынкылык төсе...

***

Җиле тисә – сүнәр,
Кулы тисә – сынар...
Адәм баласының
Килбәтсезлегенә
Бер анасы чыдар...

***

Сихерче, багучы –
Уйдырма табучы:
Адәм баласының
Йокысын качырып,
Хафага салучы.

***

Юлында таш кыя –
Болытта түбәсе...
Адәм баласына
Урап үтәм дисә –
Кыйммәтрәк түләсе.

***

Ямап, ялгап, сузып
Бөтенәйтә барын –
Адәм баласының
Алтын баз тапса да,
Басылмас бу зары...

Мөхәммәт МИРЗА (1953) – *шагыйрь; Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Биш томлык «Сайланма әсәрләр», «Киек каз юлында», «Адәм баласы» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Үткән көн – үткән ич,
Бүген дә үтәчәк.
Адәм баласының
Ачлы-туклы көне
Гомренә җитәчәк.

***

Йола, юрамалар –
Ихтыяҗ, яраумы?
Адәм баласына
Күргәннән күрмәкче
Кыланып караумы?

***

Ниятенә каршы
Атламас бер атлам:
Адәм баласы үз
Туа-тумышыннан
Күп тапкан-югалткан.

***

Бәйгеләр... Бәйгедә
Атлар ак күбектә:
Адәм баласының
Атка җеназасын
Белгертә кебек тә...

***

Бәйгеләр ишәйде –
Кем җиңәр кемнәрне?
Адәм баласының
«Каймагы!» – дигәне
Ирдә көннәре...

***

Хөкемдары кемнәр? –
Мәңгелек бу сорау.
Адәм баласының
Көткән җавабыннан
Узып китәр урау...

## II

*Залимлек хас икән*
*Яратылмышыннан,*
*Адәм баласының*
*Күзәтсәң күрерсең*
*Эчтәген тышыннан.*

М.Мирза

***

Күтәрелеп менгән,
Тибәрелеп төшкән:
Адәм баласының
Яшәеше тора
Этештән-төртештән.

***

Риялы әшнәлек
Мөнәсәбәтендә
Адәм баласының
Икейөзлелеге –
Ас(ы)лы-сәләте дә...

***

Бер-берсен кәкрегә,
Терәүгә калдыру –
Адәм баласының
Ыруы хәт(е)рендә
Җуелмас фалдыр ул.

***

Соранып алган дан –
Шул ук ришвәтчелек.
Адәм баласының
Кемнән өстенлеге
Исбат итмәкчелек?

***

Өлеше – төренчә
Бөлүдән башлана.
Адәм баласының
Кулына кергәнче
Күзенә ташлана.

***

Теле телгә йокмый,
Тын тормый бер тын да.
...Адәм баласына
Тотыныр берни юк
Тар-кысан йортында.

***

Базарда бар да бар:
Тамыры, төшедер...
Адәм баласы гел
Һәммәсен алмакчы
Бәясен төшереп.

***

Ничә кат «ут кабып»
Салдырды бүреген...
Адәм баласының
Чәлдерү – чиреме:
Шунда рас беленер...

***

Алтын балык тотып
Мантымакчы иде.
Адәм баласының
Рыбинспектор
Авын чабып өйде.

***

Күлен камыш каплый,
Бакчасын чүп баса...
Адәм баласы үз
Сукмагын да тапмый –
Көне-төн йокласа...

***

Үкчәсен өстәр дә –
Күтәрелер буе...
Адәм баласының
Корсагы – барсыннан
Өстә тормак уе...

***

Шәрәлек – ишарә
Кемнән кай тарафка?
Адәм баласының
Һәркайсын шайтаны
Үзенә караткан.

***

Сукыр – капшап күрә,
Чукрак – күреп тыңлый.
Адәм баласының
Нияткә кергәне
Бер хәбәрсез тормый.

***

Карында сын ала
Иң әүвәл кашлары.
Адәм баласының
Һәр төге, тамыры –
Җиргә ярашканы.

***

«Син – син микән?» дип,
Башын катырмагыз.
Адәм баласының
Теш саны тулуга
Ими каптырмагыз!

## III

*Юлларда бозлавык,*
*Юлларда сикәлтә:*
*Адәм баласының*
*Иләмсез илендә*
*Яшәвен искәртә.*

М.Мирза

***

Сәясәт – мал бүлеш,
Алдап, йолдап, талап...
Адәм баласының
Имансыз илендә
Бу хупланган таләп.

***

Күрәчәген күрми
Гүргә кермәсенгә,
Адәм баласының
Чиген чикләгән ил –
Читкә йөрмәсенгә...

***

Кирәгеннән бүскән
Иңенә салганы.
Адәм баласының:
«Ил өчен!» дигәне
Нәфесе ялганы...

***

Һәр орыш – бер тына,
Кан исе онытыла.
Адәм баласының
Зәгыйфь хәтеренә
Ялган тарих тула.

***

Килмешәк түрәлек,
Килмешәк идарә...
Адәм баласына
Бастырып төйиләр
«Кол, ишәк» диләр дә.

***

Тауларга сыенып
Сакланган ыруы...
Адәм баласының
Бүген кем хакына
Бер-берсен кыруы?..

***

Баскак ялчысының
Булалса камчысы –
Адәм баласына
Акмаса да тамып
Торачак тамчысы...

***

Йөз елдан – йөз елга,
Гасырдан – гасырга
Адәм баласына
Дошманы каршына
Ут тотып басарга...

***

Көтүдә тәкәнең
Бүсте биләмәсе...
Адәм баласының
Тәү күреп әйткәне:
«Белеп өйләнәсе?!»

***

И цензор, син зурсың,
Үткен күз, сау колак.
Адәм баласының
Кай тарафта уе –
Тиз әйтәсең мотлак.

***

Күршеңне күреп кер –
Күрсен кергәнеңне:
Адәм баласының
Ярты гомре үтә
Күреп күрмәвеңне...

***

Ялган сүз, хак хәбәр
Айры-айры йөрмәс.
Адәм баласының
Үзе ияртканен
Югалтасы килмәс.

***

Меңләгән көянтә
Суырта җир маен.
Адәм баласы тик
Ятларга юнәлтә
Чокыры тулган саен...

***

Өлеше – алтыннан
Әшнә әшнәсенә.
Адәм баласына
Тамганы бакырдан –
Күреп дәшмәсенгә...

***

Битараф төссезлек
Җиһанны каплады...
Адәм баласының
Күзле сукырлары
Бер-берсен тапмады...

## IV

*Өммәтен, милләтен*
*Санга сукмадисә,*
*Адәм баласының*
*Иманын-имәнен*
*Иблис чабып кисә.*

М.Мирза

***

Нияте – тәм белән,
Тән белән наздыру:
Адәм баласының
Шайтаный нәфесе –
Суырып саздыр ул...

***

Сабагы – якты нур,
Тамыры дым алыр.
Адәм баласының
Гомере агачын
Иманы сугарыр...

***

Өммәте, милләте,
Мәзхәбе, мәктәбе –
Адәм баласының
Кальбендә сакланыр
Мәңгелек ядкаре!

***

Уңы да, сулы да
Бер хакның хозуры...
Адәм баласының
Бар гомре тыйганнан
Тыелмый узармы?!

***

Җәберсетелгәннең
Яше төшми калмас,
Адәм баласының
Соңарган тәүбәсе
Языгын йолалмас...

***

Тамырына төшеп
Көйдерде корылык...
Адәм баласына
Мең кат тәүбә кылып,
Сәҗдәдә торырлык.

***

Кисәткән көн килер:
Төн үтмәс, таң атмас.
Адәм баласы үз
Чарасызлыгыннан
Чыгар юлын тапмас.

***

Чиксезлек чигендә,
Төпсезлек төбендә
Адәм баласының
Нияте, хисләре
Кемдер хөкемендә.

***

Мәчет, мәдрәсәдә
Эстәгән белеме
Адәм баласына
Галәмнәр серенә
Төшенер уш бирде...

***

Саны исәбенә
Сызган чикләрен дә...
Адәм баласының
Сузылган гомере
Саплам җепләрендә.

***

Канаты атында
Күңеле күкне гизәр...
Адәм баласы тик
Уйнашчы катында
Иманыннан бизәр.

***

Тамчы бөртекләре
Чакма ташны ярды:
Адәм баласының
Чигәсе төкләре
Чиләнеп чаларды...

***

Көрәшү – бер гомер!
Әйтелмәгән юктан:
Адәм баласының
Тиңен табалганы
Бәхеткә юлыккан.

***

Кисәтелмәгәне
Бер хәвефкә тормас,
Адәм баласына
Хак хәбәр ирешер
Кырык көне калгач...

Равилә
Шәйдуллина-Мурат

# ТАУ БАШЫНДА БҮРЕ БАР

РОМАН

* * *

...Ишектән зур чәчәкләр гөлләмәсе тотып, елмаеп-балкып, Газиз килеп керде. Асиягә бүлмә эче ничектер яктырып, нурланып киткән кебек тоелды.

– Асия, бәгырькәем, белсәң иде син минем ничек кайгырганымны, өзелеп-өзелеп сагынуларымны! Өч ай гомерем ишек төбеңне саклап үтте бит! – дип, ул кызның ятагы янына килеп, янәшәсенә чәчәкләрен куйды да тезләнеп, кызны кочып алды.

Асия җәймәсен янә күзләренә кадәр тартып китереп:

– Әй, Газиз, мин бу очрашуга әзер түгел бит әле. Минем бу кыяфәтемне, чөгендер кебек кызыл йөземне, сөяк белән тиредән генә торган гәүдәмне күреп куркырсың бит син, – дип туктап калды. Син яраткан элеккеге Асия юк бит инде.

– Җаным, барысы да үтәр, – диде егет. – Яһүд докторы соңгы тапкыр очраганда әйтте: «Егет, инде барысы да артта калды, – диде. Баштагы мәлләрдә, Асенька өчен авыр, берни белән дә чагыштыргысыз газаплы көннәрдә минем аның исән калуына өметем юк иде. Ә йөзенең әүвәлгечә матур, шома булуы турында әйтеп тә торасы юк. Ул шулкадәр түземле, сабыр һәм акыллы кыз. Аның сабырлыгына без улым белән сокландык. Сиңа повезло!» – дип, күңелемне күтәрде. Минем сине шундый күрәсем килгән иде. Күпме генә үтенсәм дә, яныңа кертмәделәр.

– Әгәр күргән булсаң, Газиз, әгәр күргән булсаң, – дип кабатлады Асия, – котың очар иде. Мин бит нинди кыяфәттә генә булмадым. Яшел крокодил, гөберле бака, ташбака кебек, панцирь каплаган кыяфәттә. Ничек үләргә, кайдан гына агу табарга икән дип хыялландым. Ул чакта бу Җир йөзләреннән юк буласым килде минем. Ишетеп тордым, әмма докторлар мине ишетми, дип уйлады. Яһүд докторы әйтте: «Бу бала үләчәк, моның чаклы тән тиресе пешеп, кеше исән кала алмый. Хәер, аның өчен үлем хәерлерәк. Чөнки ул кеше куркытырлык кыяфәттә калачак», – диде. Шунда карт доктор калтырана-калтырана елаган иде. Мине кызгангандыр инде. Ә

*Дәвамы. Башы узган елның 11, 12 нче саннарында.*

аңыма килгәч, үзе мине юаткан була! Кайгырма, мин сине үзем дәвалыйм. Син әле элеккедән дә чибәррәк булачаксың, ди. Юата инде. Әлбәттә, ышанмадым. Миңа беркем кирәкми иде. Ул авырту, сыктаулар соң! Мин баштарак үземне тәмугта дип уйладым. Чын әгәр.

– Асия, Асия! Ничекләр генә түздең син? Ничекләр генә исән калдың? – дип өзгәләнде Газиз. – Ә бит докторларның бер ай буена синең исән калуыңа өметләре юк иде. Яһүд докторы бер ай узгач, синең температураң төшкәч, Аллага шөкер, кризис узды, диде. Исән калуына минем шигем юк. Тик йөзендә, тәнендә бик ямьсез җөйләр калачак... Улым белән яңа дәвалау ысулын куллануыбыз булышса гына инде, дип, бераз күңелемне тынычландырды.

Асиянең сагыш, моң тулы күзләреннән яшь акты. Күз яшьләре кызыл бит тиресен ачыттырып-ачыттырып ага иде.

«Әллә үземне-үзем кызганам инде, җебегән нәрсә! – дигән уй кызның баш миен көйдереп үтте. – Еламаска, нык булырга!» Әнә Газиз сүзләрендә дә кызгану шәйләнә, әле күз төпләре дә дымланган бугай.

– Син бигрәк нык ябыккансың, Асия, бары тик күзләрең генә элеккечә калган. Тик алар да моңсу, сагышлы... Элеккеге шат, шаян күзләр түгел! Син бүген бөтенләй икенче, Асия!

– Мин бит коточкыч авыр, бер кеше башына да төшә алмаслык газаплар кичердем. Тәмугның үзендә булдым бит мин, Газиз.

Асия егетнең зур зәңгәр күзләрендә дә кызганудан башка берни күрмәде. Кызгану күрде, ә мәхәббәт, ярату хисе юк иде.

Ә ул үзен кызганганнарын яратмый. Җене сөйми.

– Ярар, Газиз, мин бик арыдым. Хәзергә сау булып тор, рәхмәт сиңа! – дип озатып калды кыз өч ай буе бер күрергә тилмереп яшәгән егетне.

Газиз артыннан ишек ябылгач, нәрсәнедер югалтканын, йөрәк түрендә зеңгелдәп, нәрсәнеңдер өзелгәнен тоеп, күзләренә яшь тулды аның.

Иртәгә сеңлесе белән абыйсы Асияне изолятордан алып чыга. Өч ай буе ятып кына торган кызның әле аяк атлап йөрергә хәле дә юк. Әгәр Алансуына кайтса, өйдә булса да йөрер иде. Монда, тар бүлмәдә йөрергә түгел, күкрәк тутырып суларга һава да юк, тынны кыса, ә Асиянең тизрәк урамга чыгасы, күкрәк тутырып, язгы тымызык һава сулыйсы килә.

Ләкин Газиз белән бүгенге очрашу кыз күңеленә җиңеллек китермәде. Әллә нинди аңлата алмаслык авыр хис калды айлар буе интегеп яткан кыз күңелендә. Болай да Газиз алдында югалып кала торган Асия бүген үзен шундый өтек итеп тойды. Әллә ниткән дару исе килеп торган кечкенә изолятор бүлмәсе. Юа-юа соргылт төскә кергән пичәтле урын-җир һәм буяулары кубып беткән бер кешелек иске ятакта тәмам сөяккә калган кып-кызыл йөзле кыз бала ята. Ул бит әйләнеп тә ята алмый. Яшь тире сыдырылырга гына тора. Пешми калган җилкәсендә ята-ята Асия тәмам гаҗиз булды. Өстәвенә, астында – мамыклары оешып беткән, Алансу хатыннары әйтмешли, «горда-горда» матрас. Анда сау кеше дә ятып йоклый алмас.

Ә Асия түзде. Якты киләчәк киләсенә, тиздән коммунизм таңы атасына бөтен җаны-тәне белән ышанып түзде Асия.

Тик менә аның күңелен шундый пөхтә, матур итеп киенгән Газиз дә

җылыта алмады, ул үз артыннан Асия ярата торган хушбуй исе, ә кыз күңелендә ниндидер бушлык, өметсезлек калдырып чыгып китте. Әйе, бабасы әйтмешли, «Тибенгәндә тиңең белән тибен» дигән әйтемнең дөрес икәненә тагын бер кат ышанды ул.

Кыз акрын гына торып, аягына басты. Аяклары шундый нечкәргән. Тире астыннан кан тамырлары юан булып бүртеп-бүртеп тора. Ул алпан-тилпән атлап, тәрәзә янына килде. Ә анда яз! Арлы-бирле кешеләр йөри. Бәхетлеләр! Асиягә урамда йөрүче бар кеше дә бәхетле булып тоелды. Ул гына мескен. Әллә инде аны әнисе ак биләүгә биләгәндә, «Бәхете булсын» димәгәнме? Алай дисәң, менә бит нинди газаплардан котылды. Тәнендә бернинди җөй калмады, элекке кебек матур булачак бит ул! Сөякләрең исән булса, ит үсәр лә. Нәрсәгә дип кайгырып утырасың соң әле син, Асия? Әнә Газиз, чыгып киткәндә, иртәгә тагын килəм, дип хушлашты бит.

– Юк, Газиз, килмә әле син, мине иртәгә авылга кайтарып куячаклар. Ә анда ике айлап булачакмын. Күрешербез әле, күрешергә язсын, – дип озатып калды кыз егетне.

– Шулай булсын, шулай булырга язсын! – дип елмайды Газиз. Изолятор эче яктырып киткән кебек булды.

* * *

Асия, изолятордан чыккач, авылларына кайтып китте. Җитен комбинатында аңа эш көннәре куеп баралар иде. Әйтерсең унҗиде яшьлек кыз бала өч айдан артык яшәү белән үлем арасында, газаплы, өметсезлек тулы көннәр, төннәрдә: «Ал мине үз яныңа, Раббым Аллам! – дип, үлем килүен теләп ятмаган.

– Мин сиңа ике ай ял бирәм, – диде директор, елмаеп. – Ял итәрсең, ә мин сиңа акча түләп торырмын. Эшләмәгән килеш ике айга 140 сум акча алачаксың, Асенька. Нинди бәхет! Тебе повезло.

Асия, аптырап, бу адәмнең күзләренә карап, катып калды. Нәрсә сөйләп тора бит, ә? Аның үз кызына да уналты яшь, диләр. Үз баласы белән шушы хәл килеп чыкса, нишләр иде икән бу кеше?

– Мин исән-сау килеш, бу тәмугларны узмыйча, акчамны хәләл көчем белән эшләп алсам, күпкә яхшырак булыр иде, – дип саубуллашып чыгып китте Асия.

...Куллары бинтка уралган, кып-кызыл йөзле кызларын күреп, әти-әнисенең исләре китте. Кочаклашып елаштылар.

– Кызым, кызым! – дип өзгәләнде әнисе. – Уйлаган идем аны, сизгән идем. Йөрәгемнең бер минут та тыныч була алганы юк. Нишләдең, балам, нишләдең? Ничек бу хәлләргә төштең?

– Әни, барысы да яхшы. Инде барысы да үтте. Кайгырмагыз. Менә ике айга ялга кайттым. Тик мин, әни, сиңа булыша алмаячакмын. Миңа озак йөрергә дә, кием кияргә дә ярамый. Яшь тире шунда ук сыдырыла, – диде Асия.

– Миңа синең эшләвең кирәкми, кызым. Ярый әле, исән калгансың, ярый әле, йөзеңдә җөй калмаган. Алла саклагандыр инде.

– Әйе, әни, Аллага шөкер, йөземдә дә, тәнемдә дә бернинди җөй калмады. Алла саклады һәм яһүд карты үзенең профессор улы белән мине

коткарып калды. Аллага шөкер, менә авылга кайтып җитә алдым. Ә анданиләр булганын минем сезгә сөйлисем килми, әни. Йөрәгегезне бозасым килми... Әни, менә миңа 350 сум акча бирделәр. Мин бит өч ай изоляторда яттым. Ал әле, бурычларыңны түләрсең.

–Үзеңә калсын, кызым. Берәр нәрсәгә кирәге чыгар әле. Кирәк дисәң, кассага салып куям.

– Кирәкми, кассага салма. Сеңлем белән икебезгә яңа киемнәр алып киярбез.

Авыл, авыл! Могҗизаи, җаннарны җылытып, йөрәктәге яраларга сихәт бирә торган нинди шифалар бар соң синдә? Казан каласында килмешәк булып яшәгән авыл баласы сиңа кайткач кына, үзен кеше итеп тоя. Авылның самими кешеләре – барысы да сиңа бертуган кебек якын. Әти-әни йортының һәрбер бүрәнәсе, түшәм такталарындагы ботак эзләре – һәммәсе дә сиңа таныш. Чөнки бала чакта ул эзләрдән кем генә ниндидер җәнлек башы эзләмәгән дә, бала хыялында ул җәнлекләр йә төлкегә, йә тиенгә әйләнеп, кара урманнарга кереп адашмаган?! Ишегалдындагы чыклы бәбкә үләннәре авыл баласына йомшак яшел келәм, төрле-төрле тавышлар белән сайраган кошлар авазы оркестр булган. Шул кошлар җырына сөенеп, бала җанына бетмәс-төкәнмәс моң сеңеп калган. Чирәмдә, яшел хәтфә чирәмендә ятып бер аунасаң, туган туфрак синең чирләреңне дәвалый, сихәтләндерә.

Авылымның кычытканнары да сине үзенчә яратып чага. Көмешсыман әрем, мәтрүшкәләр исе сирпелеп, синең тәнеңә ягылып кала да, авылың искә төшкәндә, шәһәрнең асфальт, бензин, корым исе аңкып торган урамнарында сине сискәндереп, йокымсыраган җаныңны уята. Нинди хикмәтле сереңбар синең, туган як? Син шәһәргә китеп барган авыл баласын еллар узган саен үзеңә ныграк тартасың. Читкә киткәннәр сабый чакның яланаяк эзләре уелып калган сукмакларны сагынып кайта. Чебиләп беткән, чатнап канап торган нәни тәпиләреңнең колыннар кебек йөгерек чагын сагынып, кешеләр туган авылына ашкына, инде аягына шәп «фасунный» ботинкалар кигән, авылын ташлап, шәһәргә киткән авыл баласы шәһәр асфальтында авыл туфрагын сагынып яши. Зур-зур калаларда ул төрле-төрле зур планнар корып яши-яши дә, картаймыш көнендә аны туфрак, әти-әнисе яткан изге туфрак үзенә дәшеп кайтара...

Асия авылда әти-әнисенең яратуын, туганнарының кайгыртуын тоеп, җанындагы яралары, күргән газаплары турында оныта төште. Әнисе, «бисмилла» әйтеп, каз мамыгыннан гына ясалган ап-ак мендәрен кабарта-кабарта җәйгәндә:

– Кызым, менә тагын бер көн үтте. Алла теләсә, савыгырсың, – дип, Ян Михайлович биреп калдырган майлар белән Асиянең бөтен тәнен майлап, йокларга яткыра.

Асиягә бала чагындагы кебек рәхәт иде. Башын әнисенең күкрәгенә куеп иркәләнәсе, кабат балачагына кайтасы килә иде аның.

«И, җүләр дә инде мин. Ник Янсуарга гына барып укымадым икән? Ник әти-әни сүзен тыңламадым», – дип, инде менә ничәнче көн үзен-үзе битәрли кыз. Аның бит ак канатлы алъяпкыч, көрән күлмәк киеп, тугызынчы сыйныфка шундый барасы килгән иде. Ләкин... Әти-әнисенә

булышасы килү теләге зур булып, үзен җиңә алды. Шуңа күрә өлкән сыйныф укучылары белән Янсуарга бару ниятеннән баш тартты. Асия әле студент тормышын да белмәячәк. Бала чагында җәен ял итүче сыйныфташларына ашарга әзерләп торса, кичен институтта укучы кызга үз яшендәге студентларны тукландырып торырга туры килер. Әлегә Асия бу турыда белми, шуның белән бәхетле дә иде. Аның күңелендә хәзергә Ялантау болынында үскән күксел кыңгыраулар нурлы бер аһәң таратып, тау асты чишмәсенә кушылып, чыңлап, Асияне каядыр еракларга, ул үзе дә белмәгән кыйтгаларга чакырып тора иде.

**Тугызынчы бүлек**

Мишараб Латыйфаны урлап алып кайткан кичне Галихан «үлде». Ул инде дөнья йөзләрендә яшәрлек хәлдә түгел иде. Әйтерсең Җир йөзен мәңге ачылмаслык караңгылык басты. Үзәкләре өзелде егетнең. Сөйгәненең дөньяның бер явызы, авылларының иң кансыз, иң явыз һәм тупас, шадра йөзле шакал Мишараб куенында бәргәләнүен күз алдына китереп, йөрәгеннән кан тамды. Алар әти-әнисе белән киләсе җомгада кыз сорарга барырга җыенган иде. Йоласына туры китереп өйләнергә җыенган иде Галихан. Әтисе өлкән улын башка чыгарырга уйлап, авылның яшьләр урамында йорт урыны да алып куйган иде. Саба урманыннан йорт салырга бура, кайчылыклар, идән такталары белешеп кайткан иде. Барысы да яхшы буласы иде. Ләкин... Бер мизгел эчендә барысы да юкка чыкты. Бер мизгелдә егет өчен кояш сүнде, яшәүнең мәгънәсе бетте.

Мишараб Латыйфаны урлап алып кайтканан соң, икенче көнне Галихан Абдуллаларга чапты:

– Абдулла абзый, алып кайт Латыйфаны, әле никах укылмаган, диделәр. Алып кайт, рәхәт күрсәтмәячәк ул шакал кызыңа. Ник үз балаңны тәмуг утларына саласың? – дип ялынды.

– Юк, Галихан, Абдулла башым белән авылдашлар алдында адәм хуры буласым килми. Аннан соң ничек яшәмәк кирәк? Кеше күзенә ничекләр итеп күренмәк кирәк, әйт әле син миңа шуны. «Әгәр никах укытмасагыз, бөтен авылга данын чыгарам. Латыйфа миңа килгәндә үк кыз түгел иде, дип әйтеп әйтәм», – ди бит. Ярар, күрәчәге шулдыр, бүген кичкә Солтан хәзрәтне чакырып, никах укытабыз. Тора-тора ияләнер әле. Кызымның язмышы шулай булгандыр. Шулай язгандыр. Син инде алар тирәсендә бик йөрмә. Ир хатыны бит, тормышларын бозарсың, – дип озатып калды Абдулла Галиханны.

Икенче көнне иртән авылны ташлап чыгып киткәндә, Галиханга судан кайтып килгән күз төбендәге күгәреген бәсле шәл астына яшергән Латыйфа очрады.

– Латыйфа җаным, әйдә киттек минем белән. Мин беркайчан да сине ирдән кайткан, дип битәрләмәм. Беркайчан да, ышан миңа, бәгърем, – дип ялынды егет.

– Юк инде, Галихан! Язмышым шулдыр. Әти-әниемне утларга салыр хәлем юк. Аларга бит авылда яшәргә кирәк. Хуш, җаным, сау бул. Үз бәхетеңне табарсың әле. Әгәр күрсә, имансыз бит ул, атып үтерер, Алла сакласын!

Ап-ак карны шыгырдатып, Мишараблар ягына – бәхетсезлегенә таба атлады Галиханның сөйгәне.

Ә егет, биштәрен асып, авылын ташлап, билгесезлеккә, ялгызлыкка таба китте. Җаны тулы рәнҗеш иде. Йа Раббым, шундый язмыш турында хыялланган идемени соң ул? Авылда матур тормыш корырбыз, балалар үстерербез, киләчәгебез шундый матур булыр, дип хыялланганнар иде. Инде менә Галихан кышкы җилләргә йөзен куеп, билгесезлеккә таба атлый. Алда ни көтә аны – белми. Кайда торыр урын табар – белми. Кайда эшләр – белми. Аңа тизрәк-тизрәк авылдан чыгып китәргә кирәк. Кеше күзеннән юк булырга кирәк. Калганы Аллаһ кулында.

Буран, йөзгә бәреп искән ачы җил егетнең утлар булып янган йөзен кисә. Әти-әнисе Галиханның йорт ташлап чыгып китүенә риза булмады.

– Улым! – диде әтисе. – Син минем төпчек улым. Апа-сеңелләрең кияүгә чыгып китәр. Нигездә, төп йортта син калырга тиеш. Картаймыш көнебездә безне кем карар? Кемгә барып сыенырбыз? Китмә, улым. Өйләнер булсаң, Латыйфадан башка да кыз бетмәс!

– Юк, әти, – диде Галихан. – Мин авылда кала алмыйм. Ничек итеп кеше күзләренә карамак кирәк? Рәхәт күрмәячәк Латыйфа, шакал аңа бер көн дә рәхәт күрсәтмәячәк. Иманым камил, интегеп яшәячәк. Ә мин шуңа түзеп тора алыр дисеңме? Йә кыйнап, имгәтеп атармын. Алла сакласын! Әти, картаймыш көнегез өчен дә кайгырмагыз. Мин сезне мәңге ташламам. Гомерем буйларына яратып, тәрбияләп торырмын. Тотмагыз мине, фатихагызны биреп, чыгарып җибәрегез.

– Кайларга гына барып баш төртерсең икән соң, улым? Туганнарыбыз да юк.

– Әти, Аллаһ җан биргәнгә җүн бирер әле. Юкка чыкмам, югалмам. Барып җиткәч, хәбәр итәрмен. Печән базары янында постоялый двор бар, дигәннәр иде...

* * *

Мишарабның үлеменнән соң шактый гомер узды. Латыйфа, барлык йолаларына туры китереп, иренең ашларын уздырды. Коръән укытты. Ел буена бер генә тапкыр да төшенә кереп карамады ире. Әллә теге дөньяга баргач, үзенең дөньялыкта кылган явызлыклары өчен җавабы каты булды инде. Әллә үзен санлап торган хатынынннан канәгать иде.

Латыйфаның да җаны тынычланып калды. Йортка да тынычлык кайткан кебек булды. Ләкин кара күләгәң барыбер үз артыңнан ияреп йөри икән. Син аннан котылырмын, димә. Кая гына барсаң да, ул сураеп артыңнан иярә.

Улы – бәгырь җимеше Вәкиленең нәкъ әнисе язмышын кабатлап яткан көннәре. Йортларындагы фәрештәләрне качырып, ызгышып, талашып, берничә ай яшәгәннән соң, туачак баласы белән калага чыгып киттеләр. Белмәссең – әллә бәхеткә, әллә бәхетсезлеккә таба юл тоттылар.

Капка баганасына сөялеп, күзләреннән туктаусыз аккан яшьләрен сөртеп, улын, уйламаганда-көтмәгәндә килеп төшкән киленен, туачак оныгын озатып калды Латыйфа.

Әллә ничек кенә узды бу гомер. Әнә, авыл хатыннары, улының никахы

узганнан соң, бармакларын бөгә-бөгә, инде көмәне шактый беленә башлаган киленнең бала табар вакытын саный.

Адәм баласы, тугыз ай узгач: «Мин дөньяга килдем, яшәр өчен килдем!» – дип аваз сала. Нәкъ тугыз ай узгач! «Ул бала вакытыннан алда туды, әле алты гына айлык иде», – дип, кешене алдап булмый. Үз-үзеңне генә алдый аласың. Менә шулай итеп, Вәкиле авыл хатыннары теленә менде.

Җилләрне уздырып, тузаннар туздырып биюче, авыл кызларының һушын алган, ефәк күлмәк, брошкалар ябыштырылган үкчәле туфли киеп йөрүче Сөмбелә аркасында харап булды Вәкил. Беренче мәхәббәтен – Асиясен югалтты. Унсигез яшендә егерме ике яшьлек Сөмбеләгә өйләнеп, инде туачак улынмы, кызынмы көтә. Алда тормышы ничек булыр, ничек яшәр, Вәкил белми. Ул, әлбәттә, йортка кермәячәк. Кайда булса да эшкә урнашыр, ә кичләрен укыр. Әнә культура институтына керер. Армиягә китәр. Шулай вакыт узар. Тормыш барысын да үз урынына куяр. Хәзер авылдан китеп барырга, әнисен, уналты яшеннән әтисенең явызлыгыннан интеккән әнисен бу мәхшәрдән коткарырга кирәк.

Латыйфаның уйларын өчпочмак булып тезелеп, туган якларына кайтып килүче торналар тавышы бүлдерде:

–Торрыйк-торрыйк, торрыйк-торрыйк!

Туган якларын сагынып кайтучы торналар аның күңеленә тагын да күбрәк сагыш өстәде. Аның улы, бәгырь кисәге, туган җирен, нигезен ташлап чыгып китте, ә торналар киресенчә...

Улы хатыны белән калага китсә дә, ялгыз иде. Икәү, ләкин ялгыз.

Латыйфа да гомере буе ялгыз яшәде Мишараб белән.

Ул, кулларын каш өстенә куеп, зәңгәр күккә карап, кошларын каршы алды:

– Кайттыгызмы, җаннарым, барыгыз да исән-имин әйләнеп кайттыгызмы? Сез китәсез дә кайтасыз, китәсез дә кайтасыз. Ләкин узган гомер генә кире әйләнеп кайтмый.

Өчпочмак ясап, тезелеп-тезелеп киткән торналар күк еллар үтә, гомерләр уза. Киткән кошлар язын әйләнеп кайта, ә узган гомер, яшь гомер – юк. Бигрәк тә Латыйфа кебек, бер чеметем бәхет көтеп, яратмаган ир белән яшәгән хатынга авыр.

Заяга узган гомер! Алай дисәң, әнә пәһлевандай улы, бер кашык су белән кабып йотардай Нуриясе бар. Кызының бәхете генә булсын инде. Әнисе язмышын кабатламасын.

Алла боерса, барысы да яхшы булыр. Сөмбелә дә үзгәрер. Бала көткәндә, хатыннар шулайрак, көйсезрәк була инде ул. Бәхетләре булсын. Оныгы исән-имин тусын. Бала мәхәббәте, бәлки, улы белән килене арасын якынайтып җибәрер. Шулай була күрсен инде. Оныгы ятим үсмәсен.

– Нихәлләрдә, Латыйфа, киттеләрме? – дигән тавышка сискәнеп куйды Латыйфа. Маһруй икән.

– Әйе, Әнвәр ат белән Күкчәгә илтә китте.

– Кайда торырлар икән соң? Ничек яшәрләр? Вәкил эшкә урнашыр инде. Сөмбеләләргә пропискага керер.

– Үзләре белерләр әле, Маһруй. Мин бу эштә аларга булыша алмыйм инде.

– Корсагы шактый зур киленеңнең, дип әйтүем. Гаиләне ашатырга, киендерергә кирәк бит.

Латыйфа дәшмәде. Хәер, дәшәргә сүзе дә юк иде. Вәкил улы салган бу яра Мишараб салган ярадан күпкә тирәнрәк, газаплырак иде. Шуңа күрә көтү куганда да, Латыйфа тизрәк кеше күзеннән югалырга, ялгызы калырга ашыга иде.

Латыйфанын бүген нигәдер күңеле нечкәреп, елыйсы килеп торган мәле. Күңеле әллә ничек кенә, әллә кайларга ашкынып тора. Әллә яз кояшының җетелеге җанында тилмереп, елап яткан хисләрен уятты шунда, үзе дә аңламый.

Өенә кереп, вак-төяк эшләрне эшлим дип уйлаган иде, Нуриясе ду килеп, өй җыештырып йөри.

– Әни, мин идән-сәкеләрне юып чыгарыйм әле, – диде ул. – Юкса тәмам тузанга баттык. Сөмбелә йоклый торган урыннан әллә ни хәтле конфет кәгазе, җимеш төше җыеп ташладым. Ризыкны ашагач, чүбен ташлап булмыймы икәнни?

– Ярар инде, кызым, бала табасы хатынны гаепләмә!

– Әни, Аллага шөкер, котылдык бу имгәктән, диген. Ник соң син бер дә кешенең начар ягын күрә белмисең ул, ә? Алай ярамый бит инде.

– Кызым, аның абыең белән яшисе бар бит. Алай ук каты бәрелмә инде. Балалары туасы бар. Минем онык туасы бар.

– Әй, әни, кем белгән әле аның кем баласы икәнен. Авылда кызлар әйтә, ул абыеңа килгәнче үк тегенди-мондый иде, диләр.

– Кит, кызым, кеше ышанмаслык сүзне чын булса да сөйләмә, диләр. Ишетмим башка бу сүзеңне. Аллаһ орыр.

– Ярар, әни, башка әйтмәм. Кеше сүзен генә әйтүем. Аллага шөкер, китте. Инде кире әйләнеп кайта күрмәсен.

Нурия мичне акшарлады, җил-җил килеп, идән-сәкеләрне юып чыгарды. Өйгә агач исе, сафлык исе таралды. Өй эче ялт итте. Күңелләре ачылып китте Латыйфаның. Нинди уңган-булган балалары бар. Икесе дә югалып кала торганнардан түгел. Тормышны төбеннән тартып алып бара торган балалар.

Латыйфа ишегалдына чыгып китте. Яз кояшы шундый якты һәм серле иде. Ялантау буе яланы ап-ак булып, күзләрне камаштырып, җәйрәп ята.

Нәрсә булды бу дөньяга? Латыйфа йөрәгендә ниндидер җиңеллек тоеп, мал абзарларына керде. Иртән иртүк торып, улы пөхтә итеп барысын да җыештырган. Маллар астына салам җәйгән. Эш коралларын урынына тезеп куйган. Әнә, сарайның бер диварында Мишарабның эш кораллары. Улы этисеннән өйрәнеп калган төгәллек, пөхтәлек. Диварга иске каешларны тарттырып, кадаклап куйган да һәрбер әйберне үз урынына тезеп чыккан. Шөшле, келәшчә, без – тагын әллә ниләр. Мишарабның әйбәт яклары бар иде шул. Пөхтә, эшчән иде. Мал таба белде. Их, явызлыгы, кешелексезлеге дә булмаса...

Кичен Латыйфага күршесе Маһруй керде. Килене каядыр чыгып киткән иде.

– Менә борай бәлеше пешергән идем. Сез дә авыз итегез, – диде ул. – Алып кердем әле, иллә дә мәгәр унды соң камырым. Үзеңә пешергәндә,

шулай була ул камыр ашы, ә бәби ашы пешерә башласаң, бәлешең тишелеп, үзәгеңә үтә. Ник алайдыр ул, шаккатмалы хәл.

– Әйдүк, әйдүк, Маһруйбикә, хәзер самавырымны җырлатып җибәрәм. Өйдә үзем генә. Аулакта чәй эчәрбез.

– Кая китте? – дип, чаршау артындагы сәкегә ымлап күрсәтте Маһруй.

– Каядыр киткән, миңа әйтеп тормады.

Маһруй авыр сулап куйды:

– Әйе, алманың асылын корт ашый шул аның, Латыйфа. Инде кызарып пеште, дисең, ә эченә корт төшкән була.

– Алай дип әйтмә әле син, күрше. Бала тапкач үзгәрер, Алла кушса.

– Һай, белмим. Баланы без дә таптык, ләкин болай итеп аунап ятмадык. Эштән кайтып та, шул көнне үк бала таптык. Моның ише кеше булмас!

– Шәһәр кызы бит, безнең авыл тормышына ияләнмәгән.

Латыйфа кече якка самавыр куярга кереп китте.

Маһруйның нидер әйтәсе килгәне, тик никтер тыелыбрак, сагаебрак калуы сизелеп тора иде.

– Вакытым күп, Латыйфа. Минем кыз бу ялда кайтмыйм, дип китте. Кибеткә тәмле кәнфит кайтачак дигәч, барасы иттем менә. Сиңа да кирәк булыр дип, бер кило алып кайттым. Шундый сбежий кәнфите, пумадка кәнфит.

– Рәхмәт төшсен инде сиңа, күрше, мине искә алганың өчен. Аллаһның рәхмәте яусын. Менә хәзер бергәләп кәнфитләп чәй эчәрбез.

– Кибеттәге халыкны күрсәң син, шаккатмалы. Чират торып, малай, җаным, алып бетерделәр кәнфитне. Аннан соң... – дип сузды Маһруй күршесе. – Өйгә таба кайтып килә идем, каршыма Галихан очрады. Аның белән бер класста укыган идек бит. Мәктәптә укыганда, озын гына, ябык кына малай иде. Хәзер күрсә-ә-әң, мин аны танымый тордым. Гөрнәдир хәтле, билләһи, чибәрлегенә хәйран калырсың. Шаккатарсың. Военный дисәң, военный түгел, ниндидер яшькелт кием кигән. Битләре янып тора.

– Нихәл, классташ? – ди бу. – Исән генә яшәп ятасыңмы?

– Аллага шөкер, Галихан, мин әйтәм, танымый торам. Үзгәргәнсең, дим. Үзең генә кайттыңмы, гаиләң беләнме? – дим.

– Ялгыз бит мин, Маһруй, – ди сабакташ. – Ялгыз башым яшәп яткан көнем.

– Ник бу көнгә кадәр өйләнмичә йөрисең?

– Шулай була икән инде. Ярларыңны ятлар алгач... ялгыз аккош, ялгыз торна кебек ялгыз йөрисең икән инде ул. Аларның да сөйгәннәре бер генә була бит. Әгәр сөйгән ярларын югалтсалар, алар да сагыштан үләләр, ди. Синең турыда сөйли инде ул, малай, җаным. Латыйфа дип, исемеңне генә әйтми.

– Кит булмаганны, Маһруй, мине, тол хатынны, ике бала анасын, инде әби булырга җыенган, онык-оланнар көткән хатынны ник истә тотсын ул? Икенче сөйгән кызы булгандыр. Егерме елдан соң мине искә алыр дисеңме? Син дә инде җыен юк-бар сөйләп утырасың.

– Малай, җаным! Мин бит сизеп тордым. Хатын-кыз тоемы белән тоемладым. Бу сүзләрне сиңа тапшырсын дип әйтте инде ул. Латыйфа белеп торсын, мин аны онытмадым, мәңге онытачагым юк, дип, күзләре

үк әйтеп тора иде. Менә шулай, күрше, гомерең буйларына рәхәт күргәнең юк бит синең! Мишарабың газраил иде бит инде.

– Маһруй, әйдә, мәрхүмнәр турында сөйләшмик әле. Ахирәттәгеләр хакында яхшы сүз генә сөйләргә кирәк, йә эндәшмәскә! Аның да яхшы яклары бар иде.

Күршесе эндәшмәде. Юк, Латыйфа ире турында беркайчан, беркайда начар сүз сөйләмәячәк. Татар хатыннарына гына хас булганча, ирне саклау, ирне беренче урынга куеп мактау Латыйфаның канында. Ата-бабалардан гасырлар дәвамында күчеп килгән күркәм гадәт.

– Ярар, – диде Маһруй, чыгып китешли. – Рәхмәт сый-хөрмәткә, чәең тәмле булды. Әйтәсе сүземне әйттем. Кичәдән бирле, ничекләр итеп кенә Галихан сүзләрен сиңа җиткерим икән дип кайгырып йөри идем. Тик Галиханнан берәр хәбәр килсә, аң бул. Әле син яшь, балаларың да каршы килмәс, дип уйлыйм. Аңлы, акыллы балалар.

– Кит, күрше, булмаганны сөйләмә! Тузга язмаган сүз сөйләп, башымны катырма. Балалардан оят, валлаһи, нәрсә сөйли бит, нәрсәләр сөйли, – дип, Маһруйны озатып калды Латыйфа, әллә нинди җылы бер хиснең дулкын-дулкын булып күңеленә тулганын тоеп.

Искереп беткән аяклы көзге каршына килеп, ул үзенә күз салырга да онытмады. Көзгедән аңа ябык кына, әле сылулыгын җуймаган ыспай гәүдәле, ике калын толымы җилкәләренә салынган, сагышлы зур кара күзле хатын карап тора иде.

Кара, күптәннән көзгегә күз салганы юк икән бит Латыйфаның. Әллә җае туры килмәде, әллә кирәксенмәде. Ә бүген күршесенең сүзләре аның күңелендә йокымсырап яткан хисләрен уятты.

Галихан бар бит әле. Әле дә өйләнмәгән, ди. Ник ялгыш башы каңгырап йөри икән? Өйләнсен иде инде. Үзенә тиң яр тапсын иде. Ир кешегә ялгыз йөрү авырдыр, бик авырдыр.

Латыйфаның Галиханны бер тапкыр да очратканы булмады. Кешеләрдән ишетеп белде белүен. Урманчылыкта зур гына нәчәлник булып эшли икән. Урманчылык буенча институт тәмамлаган, ди. Булыр, булыр. Мәктәптә дә яхшы укыган иде. Аннан соң табигатьне, урманны ярата иде. Менә бит, җаны теләгән эшенә кергән. Әгәр Латыйфаны Мишараб урлап алып кайтмаган булса, ул да авылда калыр, колхозда эшләр иде. Моны да язмышка юрарга кирәктер.

Мишарабны да кызгана Латыйфа. Ире куенында мәңге эремәслек котып бозы булып, Галиханны уйлап ятты бит ул. Унтугыз ел буена бер генә минутка да исеннән чыгармады.

Булса да булыр икән шундый ярату. Беренче тапкыр Гайшә түтиләргә аулак өйгә баргач, йолдыз санарга алып чыккан иде аны Галихан. Егет Латыйфаны кочагына алды. Шунда күктәге йолдызлар, август аеның караңгы төнендәге сихри йолдызлар – барысы да җиргә, Латыйфаның аяк астына коелышты. Күктә санарга йолдыз да калмады. Уналты яше яңа гына тулган кыз тәмам юкка чыкты, эреде. Аның өчен Җир йөзендә Галиханнан башка беркем дә, берни дә юк иде. Уенда ул аның белән генә таңын аттырды, кичен йокларга ятты.

...Галихан яшәгән йорт та Латыйфага патша сарае булып күренде.

Тиздән-тиздән аларның туйлары булырга тиеш иде. Дөнья шундый матур буласы иде. Ләкин... Бер мизгел эчендә барысы да юкка чыкты. Шадра йөзле, зур итләч борынлы, дөньяның бер явызы, авыл кызлары үз янына да китермәгән шакал Мишарабы авылның иң чибәр, иң булган кызы Латыйфаны, Балыклыдан кайтышлый, кара айгыр белән куып җитеп, чанасына утыртып, толыбына төреп, урлап, өенә алып кайтты. Яшь болан баласы кебек сылу кыз, котылырга теләп бәргәләнде, кычкырмакчы булды, ләкин Мишараб тәмәке исе аңкып торган зур кулы белән Латыйфаның авызын томалаган иде. Шуннан газаплы, авыр тормышы башланды кызның. Егерме елга сузылган газаплы, сагынулы тормыш...

Хәер, аның тормышында да истә калырлык матур көннәр булды анысы. Мишараб бераз йомшаграк, сабыррак булса, Латыйфа күңелендәге котып бозы да, бәлки, эри төшәр иде. Юк шул, юк.

Дөрес, Вәкиле тугач, азрак йомшый төште ире. Баласын кулына алгач, йөзенә бераз елмаю да кунган кебек булды. Ә менә Нуриясе тугач...

Бала табу йортына колхозның холыксыз кара айгырын җигеп килде Мишараб. Чанасына бер чеметем салам да түшәлмәгән иде. Анда ничек бала белән утырып кайтмак кирәк. Килгәч, ул Латыйфаны:

– Ник малай алып кайтмадың, ник үзең шикелле ана мәче, кыз алып кайттың? – дип талады.

Доктор исерек ирне куып чыгарды.

– Әгәр исерек килсәң, балаңны бирмим, – диде.

Нуриясе бигрәк тере булып туды Латыйфаның. Яңа туган бала димәссең, чекерәеп карап ята.

Иренең шундый дорфалыгына кайгырып, күкрәкләренә сөт тә төшмәде яшь хатынның. Ә бала илереп-илереп елады. Каенанасы, каз маенда коендырып, коймак пешереп килгән иде. Ул коймак ашап туймаслык тәмле иде. Күп уйлап тормады Латыйфа, бала кендеген бәйләгән марляны пычак белән кисеп алды да, коймакка аз гына писүк сибеп, чәйнәп, имезлек ясады. Рәхәтләнеп суырды бала имезлекне. Аннан соң арып-талып йоклап китте. Озак итеп, төшендә фәрештәләрне күрә-күрә, елмая-елмая йоклады сабый. Ләкин күршедә ятучы керәшен хатыны докторга барысын да сөйләп биргәч, Латыйфаны эттән алып, эткә салып сүкте доктор:

– Әгәр балаң үлсә, төрмәгә утыртам, – дип куркытты.

– Ни эшләп үләргә тиеш соң ул, ә? Әйе, каз маенда коендырып пешергән коймак ашап үлгән ди берәүләр. Берни булмас кызыма, – диде Латыйфа, тыныч калырга тырышып.

Ә менә холыксыз кара айгыр җигеп килгән исерек Мишарабка сабыйны бирмәделәр.

– Чыгып утырган бул, – дип акырды Латыйфага ире. – Әгәр яшисең килсә, хәзер үк чанага чыгып утыр. Ә теге ана мәче баласы калсын шунда. Берәрсенә биреп җибәрерләр. Миңа кирәк түгел ул.

Кара айгыр алагаем алдырып чабып китте.

Латыйфа яңа гына баладан котылган хатын, бер чеметем салам түшәлмәгән чана мичәвенә чытырдатып ябышты. Үлемем шушы икән, балаларым ятим калачак икән, дип уйлады.

Юлда акрын гына атлап килүче бер юлчы очрады. Ситдыйк карт икән. Мишараб атын көчкә туктатты:

– Әйдә, Ситдыйк абзый, утыр. Буран чыгарга тора, – диде.

– Ник бу чанаңа салам җәймәдең? Ничек утырып кайтып булсын бу гәлиш чанада? Ходабәндә, әле хатыныңны да утырткансың.

Мишарабның кара-турыга китереп оруы булды, чана чалулап, Латыйфа бер якка очты. Ярый әле кар күп, йомшак иде.

«Аллага шөкер, котылдым бугай», – дип сөенде хатын. Яңа гына баладан котылган хатын!

Ә Ситдыйк абзый:

– Мишараб, зинһар өчен, җәяү генә кайтыймчы, – дип, күпме генә ялынса да, картны чанасыннан төшермәде Мишараб. Аны авылга кергәндә үсеп утырган карт өянке агачы янында кар өстенә бәреп төшереп калдырды кара-туры.

Авылга кереп килгәндә, колхозның җирән карт алашасы куып җитте тәмам хәлдән тайган Латыйфаны. Баксаң, каенанасы улының исерек икәнен күреп, күршесе Фәттахтан ат алып кайтарткан да, йомшак болын печәне түшәп, толып салып, килене белән оныгын алырга килгән. Җылы толып эчендә нәни кызчык, төшләр күрә-күрә, елмаеп йоклап ята иде. Латыйфа да кызы янына, толып эченә кереп утырды.

Тәмам хәлдән тайган, арыган иде ул. Инде үләм, бетәм, дигәндә генә дөньяга китергән кызының үз әтисенә кирәк булмавы канын тәмам катырган иде Латыйфаның. Ул, кызын куенына алды да:

– Ярар, әти, сиңа кирәк булмасам, мин әниемә, әбиемә кирәк, – дип, кызы булып сөйләште. Кызының йөзен үзенә якын китерде. Баладан шундый тәмле ис – яңа тормыш исе, яшәү исе килә иде. – Үсәрбез әле, үскәч, яратырсың әле, әти, дисеңме, кызым? Шулай диген. Менә үсеп кенә җитим, мин әниемә шундый зур таяныч булырмын. Мин сине әниемә күрсәткән газапларың өчен гафу итмәм, әти, андый әти булмый, дисеңме? – Алай димә, кызым, әти белән әнине сайлап алмыйлар. Аларны ничек бар, шулай яратырга кирәк. Шундый явыз булып тууына ул гаепле түгел бит. Аңа явыз кеше җаны иңгән. Ни эшләсен инде ул, шундый булып тугач? Берни эшли алмый. Әтиеңә үпкәләмә, кызым. Ә мин сине якlармын, саклармын. Җил-давыллар тидертмәм мин сиңа, балам. Дөньяга килгәнсең икән, тәүфигың белән кил, кызым. Исән-сау бул! Бәхетле була күр. – Өенә кайтып җиткәнче кызы белән сөйләште Латыйфа.

Ә өйдә сәкедәге ястык, түшәкләрне идәнгә бәреп төшереп, өс киемен дә салмыйча, Мишараб гырлап йоклап ята иде.

– Әни, Вәкилне генә алып чыгыйм әле. Нуриямә күз-колак була күр, – диде Латыйфа.

– Кызның исеме Нурия буламыни?

– Әйе, әтисе, исемен үзең куш, миңа ана мәче кызы кирәк түгел, диде.

– Әстәгъфирулла, бу ни дигән сүз, Раббым бер Аллам! Нинди бәндә бу! Ниләр кылана бит, ниләр кылана. Ничекләр итеп үләр икән бу бәндә? Яшәве дә рәтле булмады, үлеме дә кешенеке кебек булмас. Адәм тәганәсе. Оятсыз. Матур итеп, мулла чакырып, исем куштыру мәҗлесе үткәрәсе урынга үз баласын үзе танымасын әле! Аллаһ орыр әле үзен.

– Ярар, әни, Вәкилне алып чыгыйм инде. Күршеләрне ялыктырмасын.

Латыйфа, күпме генә исенә төшереп карамасын, егерме ел яшәү дәверендә бер генә бәхетле мизгелен дә исенә төшерә алмады. Әйтерсең лә егерме ел гомере дәрья суларына агып киткән, аннары җиргә сеңеп, җир канына әйләнгән.

Юк, юк! Алла сакласын. Ике нарасые: «Дөньяга без килдек яшәр өчен, әни, сине саклар, яклар өчен дөньяга килдек», – дип аваз салган ике баласы, пар канаты бар Латыйфаның.

Мишараб исән вакытта, кичке уенга чыккач та, кайтып, өйләрен әйләнеп китә иде улы.

Латыйфа йоклаганга сабышып ята. Вәкил акрын гына ишекне ачып карый да, өйдә тынычлык булса, акрын гына тагын чыгып китә иде.

Менә нинди балалары – улы, кызы бар Латыйфаның! Кемгә тигән әле бу бәхет!

Шулай да күршесе Мәһруй әйткән сүзләр хатынның талгын гына, тыныч кына йокымсырап торган күңелендә нindидер дулкыннар уятты. Әгәр Галихан чынлап та Латыйфа янына килсә, ни булыр икән? Әгәр ул: «Латыйфа, әйдә кушылыйк», – дисә, хатын ни әйтер икән?

«Кит, җүләр, кеше көлдереп, дияр, балалардан оят, дияр. Теле бер нәрсә сөйләр, ә күңеле: «Мин сине шундый яратам, җаным. Әгәр мөмкин булса, тыным белән тартып алыр идем», – дияр. «Үткән тормышымнан ике баламны алып, калганнарны сызып ташлар идем», – дияр.

Егерме ел гомер! Егерме ел газап – Латыйфаның кар сулары булып, дәрьяларга аккан җиләк чаклары, ә алда – гомернең калганы. Ә нинди гомер киләчәк? Бернинди шатлыксыз, рәхәтсез, куанычсыз гомер! Ә бит яшәлгән, алдагы тормышым матур, кайгы-хәсрәтсез булыр, алда әле бәхетле көннәр көтеп торадыр дигән өмет белән яшәлгән. «Өметсез – шайтан», ди. Латыйфа Ялантау болынында җәйрәп яткан, инде өсте бәллүрдәй язгы кояшта ялтырап яткан киңлеккә сокланып, озак карап торды. Бүген аның күңел төпкелендә әллә нинди ашкынулы хисләр ташкыны бөтерелә, җанында егерме еллык газаплы тормышыннан тетрәп чыгып, нindидер сөенечле бер халәт уянып килә иде. Инде йөрәгенең иң түрендә күмелеп бөреләнгән, ләкин чәчәк атарга өлгерми калган, еллар буе җанына җыелган беренче мәхәббәт уянуы иде бу. Мөлдерәмә күңеленең кемгәдер нидер сөйләп, түгеләсе килгән мәле. Ничә еллар буена мөлдер-мөлдер тулган сагыш касәсе, әгәр Латыйфа берәүнең нык иңнәренә башын куеп, серләрен сөйләсә, бәлки, түгелер дә бушап калыр. Бәлки, җанына күптән көткән тынычлык иңәр.

Әлегә Латыйфаның җанында мөлдерәмә сагыш һәм мәхәббәт касәләре зеңгелди. Ләкин Латыйфа аңлый: йә, Галиханга тиңме инде ул? Юк, тиле күңел генә, ашкына-ашкына, каядыр очына. Нидер эзли. Кемнедер көтә. Нәрсә көтәсең син, йөрәк? Соң бит инде, барысы да бетте. Әле син нәрсәдер өмет итәсең. Кемнедер көтәсең.

Латыйфаның йөрәгендә беркемгә дә бирергә өлгермәгән сөю хисе мөлдерәмә! Күңел кемнедер, нәрсәнедер көтеп сулкылдый. Әйтерсең уналты яшьлек кыз бала! Әй, җүләр, нәрсә дип тилерәсең инде, әби булыр вакытың җиткәч. Тукта инде, тукта.

Назлы җилләре, туган якны сагынып кайткан кыр казлары, торналары белән, Латыйфа күңелендә шатлык-куанычлар уятып, Алансуга яз килә.

* * *

Вәкил дә калада үз тормышы белән яшәп ята икән. Сөмбеләләрдә торып калмаган ул. Алар яшәгән Кабан күле буендагы фатирдан бик ерак булмаган агач йортка фатир төшкән. Фатир хуҗасы Галия карчык:

– Ярар, улым, мин синнән фатир, прописка хакын күп алмам. Утыннарымны ярып, карларымны көрәп торырсың, – дип, егетне бик сөенеп, үзенә фатирга керткән. Уңъяк Кабан урамындагы кечкенә генә, иске генә йорт янында гына серле Кабан күле җәйрәп ята.

Сөмбеләнең әти-әнисе: «Бу ни хәл инде, ничек инде син хатыныңнан, туачак балаңнан башка яшәмәкче буласың?» – диюләренә каршы Вәкил:

– Бабай, азрак акча эшләгәч, мая туплагач, бала тугач, мин гаиләмне үз яныма алдырырмын! – дип, кырт кискән.

Сентябрь айларында улы туган Вәкилнең. Шул хакта хәбәр итеп, Нурия Асиягә хат та язып салган иде. «Асия, абыйның баласы туды бит. Шундый матур бала. Абый шундый ярата улын. Баласы өчен үлеп тора. Әле һаман шул Галия әбиләрдә яши. Хатыны, баласы янына килеп кенә йөри. Кодалар Сөмбелә янына күчәргә һич күндерә алмыйлар үзен.

Аннан соң, Асия, мин бер кызык хәл турында языйм әле.

Абый бит культура институтына укырга керде. Тик төннәрен вагон бушатырга вокзалга йөри инде. «Бер төнгә әллә ничә вагон бушатабыз, шундый арып кайтам, – ди. – Зарланып әйтүем түгел, сеңлем, гаиләне ашатасы бар бит. Бер ялгышуның түләве шушыдыр инде. Бер көнне укудан соң вокзалга киттем. Мин анда үзем шикелле акчасызлыктан интеккәннәр белән дуслашып беттем инде. Шунда безнең янга Галихан абый килеп төште. Шундый шәп киенгән, мине шундук танып алды да, сүз катты:

– Вәкил, син нишләп йөрисең монда? – диде.

– Галихан абый, менә азрак акча эшләп булмасмы, – дип килгән идем, мин әйтәм.

– Ник, укырга кермәдеңмени?

– Кердем дә, гаилә бар бит, хатыным авырлы. Акча эшләргә кирәк.

– Алай-й-й, – дип, ул миңа бераз текәлеп карап торды да:

– Вәкил, әйдә болай сөйләшәбез. Урманчылыкта эшчеләр җитми. Минем монда килүемнең сәбәбе – эшчеләр җыю. Әйдә, миңа эшкә кер, – диде.

– Эшли алырмынмы икән соң? Уку да бар бит әле.

– Кичке укуга күч. Шулай яшьли гаилә корасы булгач, көндезге укуны булдыра алмассың.

– Әгәр мөмкин булса, барып карыйм, Галихан абый. Гаиләмнән ерак була инде.

– Транспорт йөреп тора, болай цемент капчыклары бушатып... саулыгың озакка җитмәс, Вәкил. Әле яшь генә башлагансың. Гаиләңне карыйсың бар.

Менә шулай итеп, ул Галихан абыйда эшли башлады. Эш хакы да яхшы, дип, үзе сөенеп бетә алмый.

«...Минә бервакыт Галихан абый әнигә минем абый аркылы төрле-төрле бүләкләр, күчтәнәчләр җибәрә башлады. Әни баштарак абыйга:

– Кит, булмаганны, алмыйм, ник әле мин чит кешедән бүләк алып торыйм оялмыйча, – дип, каршы торып маташса да, абый:

– Әни, ник алмыйсың инде, ул бит аны сиңа чын күңеленнән җибәрә. Ялгыз бит ул Галихан абый, парсыз калган аккошлар кебек ялгыз, – дип, әнине күндергән.

Быелгы Сабан туена әни Галихан абый җибәргән крепдишиннан үзенә шундый да матур, кояш итәкле күлмәк текте. Күрсәң син ул күлмәкнең матурлыгын, Асия, һушың китәрлек. Ә инде башына зәңгәр җирлеккә ал гөләп чәчәкләре сибелгән ефәк яулыгын да бөркәнеп җибәргәч, әни, бәгърем, кызлар кебек булды да куйды. Озын чәчләрен ике толым итеп үреп, күкрәкләре өстенә төшереп куйган, керфекләре озын, кашлары карлыгач канаты кебек сызылып киткән, бераз гына чөелеп торган борыны, күперебрәк торган иреннәре... И Асия, җаным, мин бит аның болай матур икәнен белми идем. Әти белән яшәгәндә рәхәт күргән кеше түгел бит инде ул минем әни. Исеме гел каклаган каз, кипкән нәрсә, үләксә булды – шуннан башка сүз ишеткән әни түгел бит ул! Ә хәзер, азрак тулыланып китсә дә, билләре өзелеп тора, толымнары озын! Үзем дә сокланыпплар карап тордым.

– Әни җаным! Син шундый матур, шундый сөйкемле! – дип, үзен кочып алдым.

– Шулайдыр, кызым, оныклар тугач, матур булырсың да, – дип көлде. Күрәм инде, әнинең битләре янып тора.

Сабан туена төштек. Авыл хатыннары килеп, әнинең күлмәген тотып-тотып карады.

– Латыйфа, малай, җаным, әллә зәңгәр күкләрдән сорап алдыңмы бу күлмәгеңне, җилләрдән дә җиңел күлмәк бит бу, – дип шаккаттылар. Безнең авыл хатыннары киҗе-мамык сатиннан башка күлмәк күргәнмени алар.

Әни белән икәү ат чабышы карап тора идек. Шунда яныбызга Галихан абый килеп басмасынмы! Әни егылып китә язды.

– Исәнме, Латыйфа, – дип, әнигә кулын сузды бу.

Әни, Галихан абыйның күзләренә карап, торараштай катты да калды. Бер кәлимә сүз әйтә алмый. Ярый әле янында мин бар идем. Үз-үземне кулга алып:

– Әй, исәнме-саумы, Галихан абый, әйбәт кенә яшәп ятасызмы? – дип, кулымны суздым.

– Нихәл, Нурия! Кара әле, Латыйфа, нинди матур кызың бар икән ләбаса. Вәкил дә, Нурияң дә үзеңә охшаганнар. Тач үзең инде, – диде ул.

Шуннан әни дә телгә килде.

– Каушап калдым, Галихан, көтмәгәндә, җир астыннан калкып чыккан кебек... – дип әйтеп куйды. Ул Галихан абыйның матурлыгын күрсәң син. Ул буй-сын, дулкынланып торган кап-кара чәчләр! «Кара, нинди пар килгән икән әни белән Галихан абый», дигән уй килде миңа шунда.

– Һәм бер оныкк әбисе дә. Еллар үткәч...

– Син елларны санама, Латыйфа! Синең әнә ике канатың – улың, кызың бар. Ә минем беркемем дә юк. Алай дисәң, җанда барыбер өмет бар икән әле...

– Ник өйләнмәдең соң, Галихан?

– Сине оныта алмадым, Латыйфа! Мин сине мәңге онытмаячакмын. Үлгәнче.

– Әй, булмаганны сөйләмәсәнә.

Мин алар янынннан китәргә дә, китмәскә дә белмичә, аптырап басып тордым. Күрәм, авыл хатыннары безнең якка карап-карап ала.

Әни ул карашларны шундук тоеп-сизеп алды.

– Галихан, бар, безнең яннан кит әле син, – диде ул, көтмәгәндә. – Адәм хурына калып, кеше теленә менәбез хәзер. Латыйфа акылыннан шашкан, Сабан туенда ирләр белән сөйләшеп тора иде, диярләр... Аннары син миңа Вәкил артыннан бүләк җибәрүеңне туктат, Галихан, ни хәл бу! Чит бер хатынга бүләк арты бүләк җибәреп торасың. Балалардан оят, валлаһи. Кире үзеңә җибәрермен, дигән идем, улым, алай яхшы булмый инде ул дигәч, мин синең бүләгеңнән күлмәк тегеп кидем...

– Шундый килешә үзеңә, Латыйфа, – дип елмаеп куйды Галихан абый. – Төшләремә зәңгәр күлмәгеңне киеп, ефәк яулыгыңны бөркәнгән килеш керерсең инде. Мин бит синсез килеш синең белән яшәдем, Латыйфа, аңлыйсыңмы? Төшләремә кереп йөдәтәсең ләбаса. Әрәмгә үткән гомер... Фатирым, машинам – бөтен нәрсәм бар, тик син генә юк. Ялгыз мин, Латыйфа җаным. Парын җуйган аккош кебек ялгыз яшим бит мин. Сине сагынып, синең белән сөйләшеп, урманнарда йөрим, нинидер могҗиза көтеп, сагышларымнан саргаеп яшәп яткан көнем минем. Беләсеңме, мин үземнең тормышым турында Вәкилең белән дә сөйләштем. Акыллы, тәртипле егет. Ул мине аңлады, Латыйфа!

– Галихан абый, әгәр әни каршы килмәсә, кушылыгыз сез. Рәхәт күргән әни түгел бит ул. Мин ышанам, сез бәхетле булачаксыз, сез бик бәхетле булачаксыз. Без сеңлем белән риза, – диде. «Минем өчен дә бәхетле булыгыз», – дип тә әйтте әле Вәкилең, Латыйфа. Чык миңа кияүгә, Латыйфа. Мин синең балаларыңа ата булырмын. Миңа Вәкилең бүген үк үз улым кебек инде. Нурия, син дә әйт әниеңә, кушылыгыз, диген.

– Кит булмаганны! Оныклар тугач, оялмыйча... Балалардан оят, валлаһи. Әйдә, кызым, киттек, – дип, әни кузгалып китте, аннан соң Галихан абыйга әйләнеп карады да: – Хуш, Галихан, зинһар, башка тузга язмаган сүзләр сөйләп йөрмә. Кешедән оят, – дип, авылга таба атлады.

Беләсеңме, Асия, мин бераз арткарак калдым да Галихан абыйга әйттем:

– Ә сез үз сүзегездән кире кайтмагыз, Галихан абый, мин сезнең яклы, – дидем. Өйгә кайткач, әни белән үзем сөйләшәм. Аның да бәхетле булырга хакы бар бит. Ул да кеше ләбаса!

Менә шундый хәлләр бездә, Асия дускаем. Көлсәң – көл, еласаң – ела.

Абыйларның тормышына килгәндә, шулай аерым-аерым яшәп яталар. Сөмбеләсе – әти-әнисендә, абый – Галия әбиләрдә. Тик күбесенчә Галихан абыйда куна кала икән. Урманда эшләре күп, ди. Яшь үсентеләр утырталар, корыган агачларны кистерәләр, урманны чистарталар. Җәнлекләргә тоз, нинидер ашамлыклар куялар икән. Абый шундый яратып эшли. Галихан абый аны үзенең ярдәмчесе итеп куйган.

Әлегә әнине күндерә алганыбыз юк. Ләкин күреп торам, ул шундый

үзгәрде. Очынып, очынып йөри. Минем аның шундый бәхетле чагын күргәнем юк иде әле. Абый әйтә:

– Нурия, әни белән сөйләшеп кара инде, – ди. – Миңа, ир кешегә, яхшы түгел. Хатын-кызларча аңлат үзенә, – ди. – Галихан абый әнинең кулын сорарга кайтырга җыена, – ди.

Авыл халкы гөр килә: «Рәхәт күргән Латыйфа түгел, чыксын, бәхетле булсыннар», – диләр. «Ояты булмаса, чыгар, оныгы тугач, әйе, кияүгә чыгар менә. Аннан соң кызы белән бергә рәттән бала табар, кызы да кияүгә чыгарлык булып җитешкән бит инде», – диючеләр дә бар. Менә шундый хәлләр бездә, дускаем, сау булып тор. Хатыңны көтеп калам.

Дустың Нурия».

* * *

Вәкил ул төнне Галихан абыйсында кунып калырга булды.

Күктән бертуктаусыз йолдызлар коелып торган август киче иде. Урманда шундый тынлык. Бары тик ниндидер кошның ухылдавы гына ишетелә, туктаусыз тукылдап утырган тукран да тынып калган.

Вәкил кайтырга җыенган иде инде. Галихан абыйсы:

– Вәкил, – синең бүген гаиләң янына кайтасың бармы? – дип сорады.

– Юк, Галихан абый, Галия әбиләргә кайтам да ятам. Бик арылды, – диде ул.

– Әгәр вакытың булса, әйдә, чүнниктә генә куныйк әле, нигәдер җаным алгысып тора.

– Ярар, Галихан абый.

Урман эчендәге умарталыкта нарат бүрәнәләрдән йорт салдырган иде Галихан.

– Әйдә, алайса, чәйләп алыйк та йокларга ятарбыз.

– Галихан абый, тик Галия әби көтәр бит инде. Урманда, чүнниктә кунасымны әйтмәгән идем.

– Акылсыз карчык түгел, эшең күп икәнен белә. Алай кайгырып тормас. Сөмбелә бик борчылмасмы?

– Әллә ни исе китә торган Сөмбелә түгел, Галихан абый. Аның өчен мин әллә бар, әллә юк. Ул, авылдан Казанга күчеп килгәч, үз дөньясына чумды. Баланы әби карый. Әби-бабай бик яшь бит әле. Бала алар өчен уенчык кебек тансык. Үзләре дә кырык яшьтән узгач, бала тәмен беләсең икән ул, дип, сөенә-сөенә карыйлар Кәримне. Ә Сөмбелә, – Вәкил туктап калды. Галихан эндәшмәде. Барып утны сүндерде дә, чишенеп, агачтан үзе ясаган ятагына ауды.

Чүнник йорты тәрәзәсеннән сузылып, ай карый. Вәкил яткан карават каршысындагы тәрәзәдән йолдызлар тулы күк йөзендә тулган ай йөзеп йөргәне күренә. Утны сүндергәч, күпмедер вакыт чүнник йорты караңгыланып торды да, күз ияләшә төшкәч, ай нурлары өйне зәңгәр нурга күмде.

Вәкилнең әнисе айлы төннәрне урамнан кергәч:

– Сөбханалла машалла, ай яктысы зәңгәрләнеп тора, утырып, мәрҗән тезәрлек. Күзем генә тия күрмәсен, – дип сөенер иде.

Кайсыдыр почмакта чикерткә чурлый. Алансудагы кебек. Кышкы

озын төннәрдә мич астында чикерткә сайравы да ничектер туган йортның сагышлы, рәхәт бер хатирәсе булып Вәкилнең күңелендә торды. Рәхәт иде егеткә Галихан абыйсы янында. Ул аңа өлкән абыйсы кебек якын иде. Никтер, абыйсы кебек кенә түгел, әтисеннән бернинди җанга ятышлы җылы сүз ишетмәгән Вәкилгә Галихан абыйсы үзенең киңәшләре, үгет-нәсихәтләре белән әтисен алыштыра кебек иде.

Вәкил сизеп ятты: Галихан абыйсы да йокламый. Ул тигез сулыш алып, тын гына ятса да, егет чамалады: аның Вәкилгә нидер әйтәсе бар иде. Ул бүген егетне шуның өчен өенә кайтармады. Тик сүз башларга кыенсынып ята булыр.

– Галихан абый, йокламыйсың бит, әйеме?

– Юк, Вәкил! Мондый айлы төнне йоклап буламыни? Күр әле, ай яктысы су кебек бит. Зәңгәрләнеп торган агымсулар кебек.

– Әйе, Галихан абый, үзем дә тулган айга карап сокланып ятам. Бигрәк матур, серле кич.

– Вәкил, синең инде улың үсеп килә. Аллага шөкер, исән-сау бала. Көннәр үткән саен, без утырткан яшь агачлар кебек, ул да исәя барыр, калкыныр. Тәпи атлап китәр, теле ачылып сиңа, әти, дип дәшәр. Үсә төшкәч икәүләшеп Мишәгә балыкка йөрерсез... – Галихан абыйсы сүзсез торды. –Тик гаилә тормышыңның рәтен-чиратын күрмим мин, Вәкил. Бала әти-әни белән үсәргә тиеш, ата-ана канаты астында үскән бала гына бәхетле була. Нинди тормыш инде бу синең? Хатының улың белән аерым яши. Үз өеңә кайтасың килмичә, урманнарда каңгырап йөрисең.

– Галихан абый, мин нишләргә тиеш соң?

– Фатирга күчегез. Галия әбиең янына алып кайт гаиләңне.

– Мин әйтеп карадым да бит. Сөмбеләне күндерә алмыйм. Миңа әти-әнием янында рәхәт, ди. Ул бит дуслары белән таң аткач та кайтып керми. Әгәр сиңа кияүгә чыкмаган булсам, миннән әллә нинди зур биюче чыгар иде. Сәхнә йолдызы булыр идем, сиңа, авыл мокытына, кияүгә чыгып кына харап булдым, дип җанымны талкый. Яратмыйм мин аны, Галихан абый. Ялгыштым мин. Һай, нинди зур хата ясадым. Гомерлек хата. Яратмаган хатын белән тору көн дә тозсыз аш ашау белән бер икән бит ул.

– Балаң бар бит, ул ятим үсә. Шуңа гына әйтүем.

– Галихан абый, мин үзем дә бит әтиле ятим булып үстем. Менә син миңа, улың белән Мишәгә балыкка йөрерсең, дисең. Минем дә әтигә ияреп балыкка төшәсем килгән вакытларым аз булган дисеңме? Юк, әти миңа беркайчан да, улым, дип дәшмәде. Ачуы килсә, тибеп очыра иде, күрше Газзәттәй эте Актүшнең көчеген тибеп очырган кебек. Ишетәсеңме, көчекне тибеп очырган сыман! Әни бездә әтигә карата ихтирам тәрбияләргә тырышты. Ата хакы – Тәңре хакы! Әтиегезгә бер кыек сүз әйтәсе булмагыз, имеш. Ә үзе ни күрде соң ул, Галихан абый? Гел кабахәт сүз. Тукмалу... Минем беренче елны институтка укырга китмәвемнең сәбәбе дә – әни ялгыз калмасын дигәннән генә иде. Их, киткән булсамчы шунда. Кабатлап әйтәм, яраткан кызым бар иде минем, Галихан абый. Шундый ярата идем үзен. Хәзер дә аны төшләремдә күреп уянам.

Әни җаным, әти белән яшәгәндә, ниләр генә күрмәде ул! Мин үсә

төшкәч, әнинең яклаучысы булдым. Әти үзе миннән куркып, ауга йә балыкка чыгып китә башлады. Әни дә азрак җиңел сулагандыр.

– Шулай, Вәкил, яратмаган кеше белән яшәү авырдыр. Мин бит әниеңнән башка беркемне дә ярата алмадым. Әтиең минем сөйгәнемне урлап алып кайткан көнне минем өчен кояш сүнде. Үлдем мин, Вәкил. Никах укылгач ук, иртән әниеңнең күз төбендә кара янган урынны күреп, сөйгәнемнең нинди адәм кулында бәргәләнүен уйлап, акылдан шашам дип торам, Вәкил! Хәлемнән килсә, буып атар идем мин ул шакалны. Әниеңә әйттем: «Әйдә, Латыйфа, үзем белән алып китәм. Курыкма, ирдән кайткан дигән сүз әйтеп, беркайчан да битәрләмәм», – дидем. «Юк, – диде әниең, – әти-әниемне утларга салыр хәлем юк».

– Әни нигә синең белән китмәгән инде шунда, әти бит аны болай да гомере буе, Галихан белән йөрисең, дип талады. Безгә дә, сез – Галихан көчекләре, диде.

– Минем бит Латыйфаны әтиең үлгәнче бер мәртәбә дә очратканым булмады. Үзем дә очрашудан куркып, авылга кайтканда, сезнең урамнан түгел, югары очтан йөри идем. Әнә очы кадәр дә гаебем юк әтиең каршында, Вәкил.

– Мин беләм, Галихан абый, минем әни беркайчан да андый эшкә бармаячак.

– Утыз яшьләр тулганда, өйләнергә кирәк дип, урманчылыкта хисапчы булып эшләүче бер кыз белән йөреп киттек. Бераз Латыйфага охшаганрак кыз иде. Хәйран гына күңелемә кереп, өйләнешергә сүз куештык. Гөлгенә – Казан кызы иде. Матур киенә. Эштә дә бик яраталар иде үзен. Чәчрәп чыкмый, тыныч кына, күндәм генә эшләп йөри. Инде авылга кайтып, әти-әни белән таныштырырга уйладым. Кыз ягы ду килеп, никахка әзерләнә. Ә безнекеләр сөенеп, булачак киленне көтте. – Әйдә, булачак әти-әни, әби-бабайларга бүләкләр алыйк әле дип, икәүләшеп кибетләрдә йөрдек. Төянеп, минем фатирга кайтып кереп, бүләкләребезне бүлә башладык. Әйдә, үзең кара инде, дим. Монысы – синең әти-әниеңә, монысы – минем әти-әниемә, дип, бүлә башлады бу: әтисе өлешенә электр бритвасы, әнисенекенә затлы эскәтер чыкты. Минем әтигә – арзанлы күлмәк эләкте. Ә инде әнигә, беләсеңме, нәрсә куйды ул. Мин үземә туйга дип костюм-чалбар тектергән идем. Шуннан аз гына тукыма артып калды. Әгәр әни шуннан итәк тектерә калса, ул аның тез өстеннән булыр иде. Әни, авыл хатыны, андый итәк кия аламы инде? «Син нәрсә, Гөлгенә, минем әниләргә шундый бүләк куясың? Бүләкләрнең барысын да мин сатып алдым бит! – дим. – Тигез итеп бүләргә кирәк!» Беләсеңме, Вәкил! Торып басты да чемоданга китереп типмәсенме минем гомерлеккә хәләл җефет итеп сайланган тыныч, әдәпле Гөлгенәм! Чемодан чажылдап, карават астына кереп китте. «Бөтен нәрсәңне анаңнарга ташы!» – ди бу. Күзем маңгаема менде. Өстемә салкын су сипкән кебек булды. Ипләп кенә янына килдем дә: «Киен, – дидем. – Бар, өеңә кайт, бернинди дә туй булмаячак».

Ярый әле, вакытында үзен күрсәтеп өлгерде. Миңа өстән уя, астан кисә торган хатын кирәкми. Булачак бабай белән икәүләшеп тә килеп карадылар. «Ялгыштым, гафу ит»! – дип ялына бу.

«Әйттем – бетте! Бернинди өйләнешү юк», – мин әйтәм.

Оятыннан ул эштән үк китеп барды. Менә шулай, дускай!

Күрәчәк күмер ашата, ди. Минем сине бүген кунарга урманда алып калуым юкка гына түгел иде, Вәкил. Җаным туктаусыз нидер көтеп, алгысып тора. Мин дә кеше бит. Минем дә бәхетле буласым килә. Әйдә, Вәкил, ял көне синең белән Алансуга кайтып килик әле. Үзем генә булдыра алмам, дип куркам. Кыскасы, мин әниеңнең кулын сорарга кайтмакчы булам. Ә син кем буласың, миңа кияү егете булып кайтасың инде, – дип көлеп җибәрде Галихан абыйсы.

– Мин бу хакта Нуриягә әйткән идем инде, – диде Вәкил. Әни, юк, оялмыйча , инде әби булгач... – дип каршы тора, ләкин сеңлем миңа Галихан абый кайтса, каршы килмәячәк, – дип язган.

– Чыннанмы, Вәкил?

– Әйе, Галихан абый, чыннан да шулай.

– Без шундый бәхетле булырбыз, Вәкил. Әниең, мин, син, Нурия һәм безнең оныгыбыз Кәрим. Безнең бәхетебез, әнә, тәрәзәдән карап торган тулган ай кебек түгәрәк булачак, Алла боерса!

Алсуланып, алланып таң атып килгәндә генә сөйләшүдән туктады Галихан белән Вәкил.

Галихан абыйсы тигез сулыш алып йоклап киткәч тә, Вәкил әле озак кына тәрәзәгә карап, үзенең бәхетсез язмышы, югалткан мәхәббәте турында уйланып ятты. «Улым бар бит, бар булган яратуымны улым Кәримгә бирермен, улым үсәр, Сөмбелә белән бергә яшәп бетерә алмасак та, үскәч аңлар ул мине дип, үзен тынычландырды Вәкил. Әнә, Галихан абыйсы, кырыкка җиткәндә, үзенең бәхетенә таба бара түгелме. Югалган бәхетенә, югалткан бәхетенә нинди озын, бормалы-бормалы юллар аша, югалтулар, табулар аша килә.

Әле гомер юллары озын. Алда Вәкилне нәрсә көтә? Ул белми, ләкин өмет йолдызы аны каядыр еракка, Урыстау болынында карт имән төбендә вәгъдәләр бирешкән чагына чакырып тора...

* * *

Латыйфа иртүк торып, гадәттәгечә, маллары янына чыгып китте. Нуриясе ду килеп өй җыештырып йөри. Әле ике көн элек кенә юган идәннәрне яңадан юып чыгарасы итте. Тиз-тиз генә болай да кершән кебек ак мичне акшарлап алды. Әнисе кергәндә, өйгә агач исе, чисталык исе таралган иде.

Ул әнисенә кичтән әйткән иде инде: «Әни, абый да кайтам, дип язган. Кичтән баш ясап куй әле. Иртәгә камыр ашлары, төче камыр басып, ит бәлеше пешерербез», – дигән иде.

Әнисе:

– Бәлеш пешергәч, бәлки, паштет, гөбәдия ишеләрен пешереп тормасак та ярар, – дисә дә, Нурия кистереп әйтте:

– Абый кайтса, үзе белән биреп җибәрербез, әни, – диде. – Әйдә, икәү бергә тиз-тиз генә пешерик. Абыйга Казанда андый тәмле ризыклар пешереп ашатучы юк. Аның биючесеннән он суы да, тоз суы да юк.

– Әй, кызым, гелән-гелән Сөмбеләне яманлап утырма инде. Үзеңнең дә кияүгә чыгасың бар. Каенанаң, каенсеңелләрең булыр. Каенсеңел, каен

шырпы, көн дә берсе кадала, дигәндәй, үзеңә дә каенсеңелләрең бәйләнеп торса, рәхәт булмас, бер дә рәхәт булмас, кызым.

– Әни, моның ише кеше булмас, авылга кайтып ишетелә бит. Кәримне имезми дә, ди, фигурасы бозыла, имеш, күкрәкләре салынып төшә. Шуңа күрә абыйның улына смесь ашата икән.

– Анысы нәрсә тагын?

– Сөт шикелле порошок инде. Җылы суга болгатасың да, шул ана сөтен алыштыра, янәсе.

– Әстәгъфирулла! Абыең кая карый? Бала әнкә сөтен имеп үсмәгәч, нәрсә була инде бу?

– Әни, абыйны тыңлыймы инде ул җилбәзәк нәрсә... Әйдә, тавык ите белән шулпа да куеп җибәрик. Хәзер йорт токмачы басып кисәм.

– Һай, кызым, нәрсәгә дип шуның кадәр ризык пешерәбез соң? Туйга әзерләнгән кебек кыланасың. Әллә миңа әйтмичә генә кияүгә чыгарга җыенасыңмы?

– Иртә әле миңа, әни. Укып бетергәч, күз күрер...

Өйлә вакытларына инде ашлары әзер булды, кояшта пешкән кебек кенә паштет, гөбәдияләре – сәкедә, ә яшь бәрән итеннән пешкән ит бәлеше кайнар мичтә кайтасы кунакларны көтә иде.

Латыйфа табагач белән бәлешен тартып чыгарды да, аш өстеннән шулпа алып, аңа борыч, дәфнә яфраклары салып, мич алдындагы утлы күмер өстенә куеп, аз гына күпертеп алды, зур агач кашык белән шулпаны бәлеш эченә салды. Өйдә шундый рәхәт иде. Тыныч, җылы иде.

– Кызым, абыең тизрәк кайтып җитсә ярар иде, юкса бәлеш төчеләнеп бетәр.

– Әни, озак тормас инде, сәгать 12ләр тирәсенә кайтып җитәбез, дип язган иде.

– Ник, Сөмбелә дә кайтамыни? Аллага шөкер, юкка авылда: «Вәкил аерылган икән, Сөмбелә эти-әнисендә тора икән, Вәкил урманда, чүнниктә яши икән, дигән гайбәт таралган. Әгәр Сөмбелә кайтып, кеше күзенә күренсә, авыл хатыннары безнең турыда сөйләүдән туктар иде, ичмасам...

Латыйфа тәһарәт алып, өйлә намазын укып, озак кына дога кылып утырды. Шул арада капка ачылганы ишетелде. Аннан икесе дә урманчылар киеме кигән Галихан белән Вәкил килеп керде.

Аптыраган хатын сәке читенә килеп утырды. Аның авыз ачып, бер сүз әйтер хәле юк иде.

– Кызым, бу ни хәл? Галихан абыең түгелме соң? Вәкил белән керүчене әйтәм. Адәм хурларына калдым, валлаһи! Кеше күзенә күренерлегемне, урамга чыгарлыгымны калдырмадыгыз. Раббым Аллам! Хараплар гына булдым.

– Әни, туктыйсыңмы син, юкмы?! Кешедә синең ни эшең бар, ә? Гомерең буе башта этидән, аннары кешедән куркып яшәдең. Үзең өчен кайчан яшәмәкче буласың? Әйт әле син миңа...

Нурия сүзен әйтеп бетерергә өлгерә алмады, ишекне каерып ачып, өйгә Вәкил белән Галихан килеп керде. Улы әнисен кочып алды. Галихан ак тигез тешләрен җемелдәтеп елмайды да ике кулын сузып:

– Исәнме-саумы, Латыйфа! Менә мин кайттым, сине алып китәргә

кайттым, – диде. – Юк, димә! Чык миңа кияүгә. Балалардан оят, димә. Анысы да хәл ителгән. Вәкил дә, Нурияң дә риза. Без бик бәхетле булырбыз, Латыйфа, син, мин, Вәкил, Нурия һәм безнең онычыбыз Кәрим. Чын әгәр. Без синең белән аерым-аерым, сагыну-сыктау белән узган егерме ел гомеребез өчен дә озак еллар бәхет-сәгадәтле тормышта яшәрбез... Ә кеше сөйләр-сөйләр дә туктар!

Латыйфа бер сүз дәшмичә, Галиханның күзләренә карап, аптырап басып торды. Соңыннан сискәнеп киткәндәй:

– Сез нәрсә, акылыгыздамы сез? Күр син боларны, икәүләшеп, әниләрен кияүгә биреп маташалар түгелме соң? Әйтәм аны, Нурия иртәдән бирле бии-бии, абый кайта, дип әзерләнеп йөрде. Абый гына түгел, бар икән монда хәлләр! Юк, уйламагыз да, кеше көлдереп..., – дип елап ук җибәрде.

Галихан Латыйфаны сәке читенә утыртты да иңнәренә кулын салып:

– Латыйфа, синең мине бәхетле итәсең киләме? – диде. – Мин бит кырык яшемә чаклы буйдак булып яшим. Синнән башка бер кешене дә ярата алмадым мин. Аяк астына салып таптама сүземне. Синнән башка яши алмыйм мин. Болай да синсез, әмма синең белән яшәдем. Синсез, ләкин синең белән!

Латыйфаны икенче яктан улы килеп, кочагына алды.

– Әни, яшь бит әле син. Нурия кияүгә чыгып китәр. Мин дә Казаннан еш кайтып йөри алмам. Улым да бар бит әле. Ялгыз башың яшәмә, әни! Каршы килмә. Без Нурия белән синең бәхетле булуыңны телибез, – диде ул.

Латыйфа бер сүз әйтмичә, урыныннан кузгалып китте дә:

– Әйдә, кызым, табын әзерлик. Бәлешне дә мичтән чыгар. Тавык турап куелган, – дип, җил-җил килеп, кече якка кереп китте.

Кичен хәзрәт чакырып, никах укыттылар. Мал-туарны урнаштыргач, Латыйфа ире янына Казанга күчеп китәргә тиеш иде.

Гомере буе кагылып-сугылып, кыйналып яшәгән Латыйфаның бәхетенә таба тәүге адымы иде бу...

**Унынчы бүлек**

Асияне бер көнне Ашханәләр трестына чакырып алдылар.

Инде КАИ ашханәләренә эшкә күчкән Асия, трест җитәкчесе ни өчен чакыра икән дип аптырап, хуҗа кабинетына китте. Товарищеская урамында студентлар өчен яңа ашханә ачарга җыеналар, тик мең квадрат метрлы мәйданны биләгән зур туклану комплексын ачарга ашханә мөдире таба алмыйлар икән.

Дөрес, Валентина Сергеевнага әйтеп караганнар, аның тәҗрибәсе дә зур, әмма ул: «Сез нәрсә, үземнең эшләп торган эшемне ташлап, шундый вазифага барырга мин әллә җүләрме? Әллә эшләп китә, әллә юк әле ул, – дип, каршы килгән. Тамара Лягинага да сүз катканнар, анысы да баш-аягы белән каршы булган: «Китегез, бер белмәгән җиргә бармыйм», – дип, кырт кискән.

Ә трест башлыгы ашханә директорына: «Сиңа бер атна вакыт бирәм. Шул вакыт эчендә мөдир тапмасаң, үзең эшсез калачаксың», – дип, бик катгый кисәтеп кайтарган.

Ләкин бу хәлләрдән Асия әлегә хәбәрдар түгел иде.

Трест каршында аны Шәриф Әкбәрович Харрасов каршы алды. Ак чәчле, мәһабәт гәүдәле, елмаеп кына сөйләшүче директор:

– Асия, син институтта укыйсың бит әле, әйеме? – дип сорап куйды.

– Әйе, Шәриф Әкбәрович, тик мин профессиям буенча укымыйм. Татар теле бүлегендә укыйм. Бу эштән китәргә җыенам мин. Мәктәпкә укытырга барам.

– Ник, ашчы хезмәте ошамыймыни?

– Ошый, тик мин шундый фаҗигагә тарыганнан соң кайнар плитә янында эшли алмыйм.

– Ярар, Асия! Без хәзер Хәлим Сәлимгәрәевич янына керербез.

– Ник, нигә чакыра ул мине, Шәриф Әкбәрович?

– Кергәч белерсең. Ул сиңа сораулар бирер. Ләкин син ашыгып җавап бирмә. Ул сорау биргәч, башта миңа кара. Мин башымны селкесәм:

– Юк, – диярсең. – Әгәр «әйе» дип ым каксам, «әйе», диген.

– Мин берни аңламыйм, яхшылап аңлатыгыз, зинһар.

– Соңыннан барысын да аңларсың.

Аптыравыннан гаҗиз булып, трест башлыгы янына керде Асия.

– Исәнме, сеңлем, бигрәк яшь икәнсең, шундый зур эшкә алынырга курыкмыйсыңмы соң? – дип сорады хуҗа.

Асия берни аңламыйча күзләрен тутырып, ашханә директорына карады. Тегесе, башын селкеп, юк, – диде.

– Юк, Хәлим Сәлимгәрәевич, курыкмыйм.

Трест башлыгының күзләрендә елмаю әсәре шәйләнде.

– Әтиеңнең сыеры бармы соң?

– Бар. Авыл җирендә сыерсыз буламыни?

– Институтта укыйсың икән...

– Әйе, ләкин җәмәгать туклануы өлкәсендә түгел, бөтенләй икенче өлкә буенча укыйм мин, Хәлим Сәлимгәрәевич.

– Синең яңа эшең турында мәгълүматың бармы соң? Бигрәк авыр эш бит.

Кыз аптырап, тагын ашханә директорына борылып карады.

– Әйе, миңа барысы да таныш, – дип җаваплады Асия.

Нинди эш турында сөйләшә соң болар? Никтер Шәриф Әкбәрович кирәкмәгән сораулар бирмәскә кушты. Аптыраш... Аннан соң Асиягә әллә нинди кәгазьләргә кул куйдырдылар.

– Хәерле юл сиңа, сеңлем, эшләрең уң булып, зур уңышларга ирешергә язсын!

– Рәхмәт сезгә, Хәлим Сәлимгәрәевич.

Шмидт урамындагы тресттан чыккач:

– Әйдә, Асия, җәяү генә Товарищеская урамына таба барыйк әле. Рәхмәт сиңа, мине подводить итмәдең, – дип, Асия янәшәсеннән атлады Шәриф Әкбәрович. Һәм алар бер катлы зур бина каршына килеп туктады. Директор портфеленнән бер бәйләм ачкыч чыгарып, кызның кулына тоттырды.

– Асия, менә бу синең эш урының. Бүгенге көннән син шушы ашханәнең мөдире. Котлыйм!

– Сез нәрсә, минем бернинди тәҗрибәм юк. Зинһар өчен, эшләмим мин бу эштә. Нәрсәгә дип мине мондый урынга куясыз? Тәҗрибәле Ольга

Сергеевналар, Лягиналар алынмаган эшкә мин ничек алыныйм? Мәгез ачкычларыгызны, – дип елап, ачкычларны директорга сузды кыз.

– Асия! Син бит бик уңган кыз. Мин бит синең ничек эшләгәнеңне карап йөрим. Рәшидә Гайнетдинова да үзеңә яхшы характеристика бирде. «Ул булдырачак», – диде.

– Кирәкми миңа бу эш. Мин, гомумән, профессиямне алыштырачакмын. Укытучылыкка китәргә җыенып йөрим.

– Китәрсең, Асия! Зинһар өчен, булыш миңа, ачып җибәр студентлар ашханәсен. Соңыннан китәрсең. Әлегә син миңа кирәк. Минем язмышым синең кулыңда. Трест башлыгына эшлим, дип әйттең бит.

Елый-елый, кулындагы бер бәйләм ачкычларны алып, яңа гына төзүчеләр эшләп бетереп тапшырган, әле төзелеш чүп-чары да җыелмаган мең квадрат метрлы бинаны ачып керде егерме яшьлек кыз. Ни өчен соң әле ул кеше сүзе белән йөрергә тиеш? Ник соң аның үз фикере юк. Мин, юк, дисәм, юк, диген, әйе, дисәм, әйе, диген, имеш. Үзе дә инде җебегән нәрсә, яңа туган сарык бәтие сыман, директор күзенә карап, попугай кебек, аның сүзен кабатлап, нинди авыр хәлгә юлыкты. Нинди капкынга эләккәнен сизмичә дә калды.

Ә тук чырайлы директор, трест хуҗасына биргән вәгъдәсен үтәп, сөенеченнән күкнең җиденче катына менеп җитеп, трест каршында калдырган машинасына таба атлады. «Ярар, эшләп карасын әле, – диде ул үзалдына. – Бер ай эчендә үк өстеннән чыгачак. Әтисенең сыеры бар, диде бит. Әлбәттә, кырык кешелек коллектив белән җитәкчелек итә алмаячак ул. Әлбәттә, бетәчәк бу бала. Ә мин ул арада аның урынына икенче кеше табачакмын. Бүре дә тук, сарык та исән калачак. Барысы да шәп булачак».

Ни эшләмәк кирәк, дөньясы эт оясы булгач, шундый даирәгә килеп эләккәч. Кеше үзенең энә очы чаклы гына җанын коткару өчен нәрсәләр генә эшләми бит, ә? Ник әле ул егерме яшьлек авыл баласының тормышын аяп торсын? Асиянең күз алдында җитен комбинаты ашханәсе директорының карашы белән шушы Әкбәровичның күз карашы бергә кушылды да, баласын эзләп, каршысына чыккан ана бүре күзләре белән бер булып, кызга текәлде. Ике директор да: «Асия, булыш миңа» – дип, үтәли тишәрдәй булып карап торалар иде.

Әйе, әйе, нәкъ шулай!

Ундүрт яшьлек кыз чагында Асия тау түбәсеннән түбән тәгәрәгәч, сөт тулы чиләкләрнең дөбердәп тәгәрәгән тавышыннан куркыпмы, ана бүре агачлар арасына кереп качкан иде. Әмма Асия соңыннан тау түбәсенә кабат күтәрелә алды. Ә болар, Асия упкынга төшеп киткәндә, коткарырга теләп, кулларын сузармы соң? Юк, әлбәттә. Киресенчә, кырыйдан сөенеп карап торачаклар. Бата башласа, күтәрелмәсен дип, башына басачаклар. Дөнья шулай корылган. Тормыш шулай дәвам итә. Тормыш аяусыз.

Әнә, илләр белән илләр сугыша. Патшаларның да бит кешеләр гомере, аналар, балалар язмышында бер эшләре дә юк. «Бу орышта фәлән хәтле дошман гаскәре юк ителде, шуның хәтлесе яраланды, гарипләнде» һәм вәссәлам. Ә бит һәрбер кеше – шәхес! Сугышасы киләме ул кешенең – аннан сорап тормыйлар. Асия дә яу кырында берүзе калган сугышчы кебек, япа-

ялгызы кыр чаклы ашханәдә, үкенә-үкенә, үзенең җебегәнлегенә, каршы әйтә алмаганына үртәлеп елап утыра менә.

Кинәт аның башына бер уй килеп төште. Ничек диелгән әле хәдистә: «Караңгылыкны сүгеп утырганчы, кечкенә генә бер чыра яндыр. Кешеләргә файдаң тияр».

Кыз яшьле күзләрен сөртте дә ишекләрен бикләде. Аның Роза апасы бар бит әле. Ул да КАИ ашханәсе мөдире булып эшли! Асиянең күңелендә ниндидер өмет чаткысы кабынып, ул җәяүләп, КАИның Н.Ершов урамындагы тулай торагына таба атлады.

Көзге тымызык көн. Талгын җилдә айкала-айкала яфраклар коела. Асиянең аяк астында – сагыш түсендәге сары келәм. Сары яфраклар, язын яфрак ярасы агач ботакларында яшь бөреләргә урын биреп, акрын гына җиргә түшәлә.

Асиянең күңеле күтәрелеп китте. Беренче мәртәбә Казан каласына аяк баскан унбиш яшьлек кызны каршы алган юан хатын «Чёртово чаплашка, деревенщина», – дип сүккәндә, Асия күңеленнән: «Мин сезгә үземнең чаплашка түгел, данлы, шанлы татарның уңган, булган кызы икәнлегемне дәлилләячәкмен», – дигән иде бит. Менә аңа нәкъ шундый очрак килеп чыкты. Дәлиллә! Җебеп, елап утырасы түгел монда! Ачып җибәр бу ашханәне. Син шунда үзеңнең кем икәнеңне күрсәтерсең. Бу синең өчен тормыш мәктәбе булыр...

Асия килеп кергәндә, Роза апасы өстәл янында ниндидер кәгазьләргә кул куеп утыра иде. Ул, әтисе Мәхмүт сугышка киткәндә, әнисенең йөрәк астында туарга җыенып калган. Абыйсы Айратка яшь тә өч ай булганда, дөньяга килгән. Колхоз рәисе булып эшләгән әтисе исә, сугышка чыгып киткән. Рәшидәсе ничек кенә җибәрәсе килмичә бәргәләнмәсен, ире:

– Юк, Рәшидә, минем бронем бар, – дип, тыл күсесе булып авылда калсам, мин балаларым, уллары һәлак булган аналарның күзенә ничекләр итеп карармын, – дип китеп барган. Һәм әйләнеп кайтмаган. Миллионлаган ир-егетләр кебек яу кырында ятып калган Айрат абый белән Роза апаның әтиләре. Рәшидә – Асиянең әтисенең бертуган апасы. Балалары белән Алансуда бертуганнар кебек бергә үстеләр, Аллага шөкер.

– Килдеңме, сеңлем, әйдә, кер, чәй эчеп алыйк! – дип каршы алды апасы Асияне, кызның елый-елый шешенеп беткән күзләренә текәлеп.

– Әллә еладың инде?

– Әйе, апа, син минем нинди эшкә тап булганымны беләсеңме соң?

– Беләм, әле генә Шәриф Әкбәрович чыгып китте.

– Белгәч, ник миңа әйтмәдең соң, апа? Мин менә бер бәйләм ачкыч күтәреп, басу кадәр ашханәдә тилебәрән орлыгы ашаган кеше кебек басып калдым. Нишләргә дә белмим.

– Аптырама, сеңлем! Бу эшкә бит берсе дә алынмады. Шәриф Әкбәровичның башка чарасы юк иде. Бу ашханә – безнең филиал ул. Валентина Сергеевна да, Лягина да каршы килгәч, куярга кеше таба алмыйча, аптырап беттеләр. Ә трест башлыгы Шәриф Әкбәровичка бер атна вакыт биргән. Син үзең ничек ризалык бирдең соң?

– Апа, мин бит үземнең кая барасымны белмәдем, – дип, Асия Хәлим Сәлимгәрәевич бүлмәсендә булган хәлләрне бәйнә-бәйнә апасына сөйләп бирде.

Апасы Асиягә текәлеп карап торды да:

– Булдырган, утлы күмерне ялангач кул белән синнән чүпләтә икән бу, – дип, кызга карап көлеп җибәрде. – Асия, бик шәп булган бу! Мин һәрчак синең янында булырмын. Тәҗрибәм зур. Ни дисәң дә, синнән сигез яшькә өлкәнрәк бит әле мин. Әйдә, үзебезнең кем икәнлегебезне Валентина Сергеевна, Тамара Лягина кебекләргә күрсәтик әле... Һәм Шәриф Әкбәровичка да. Мин сиңа булышырмын. Әйдә, хәзер чәй эчеп алыйк та киләчәктә башкарачак эшләр турында план төзербез. Без җиңә алмаган дошман тумаган әле, – дип, апасы кабинетына чәй, тәм-томнар китертте...

* * *

1975 елның язы иртә килде. Апрель башларында ук гөрләвекләр, шәһәр урамындагы кыш буе җыелган чүп-чарны үзләре белән ияртеп, агып бетте. Агач бөреләренә посып кышлаган күбәләкләр апрель кояшының җылы нурларында коенып уянды да, ефәк канатларын җилбәгәй җибәреп, куана-куана, язгы җилләр иркендә зәңгәр күккә күтәрелде.

Кичә генә яшенле яңгыр явып үтте. Ярата Асия күк күкрәп, яшенле яңгыр яуганын. Әйтерсең ләйсән яңгыр кыш буе йокымсырап яткан Җир-ананың битен юып, үзенең шифалы җилләрендә киптерә.

Дөнья сафланып калды. Агач бөреләре – бөре-борынчыклар гаҗәпләнеп, дөньяга карап шартлап ачылды.Чатнаган, ватылган асфальт араларыннан, үзара пышылдаша-пышылдаша сөйләшеп, исән-сау кышны чыгуларына сөенеп, нәфис үлән шытымнары баш төртте.

Хыялый Асия аларның пышылдап сөйләшүен дә ишетә иде кебек.

«Исәнме, саумы, күрше! Ничекләр итеп кышны үткәрдең? Иңнәреңдәге авыр ташны тишеп, ничек дөньяга чыга алдың?»

«Яшисе килә бит! Кояшны, шундый матур дөньяны күрәсе килә».

Әйе, үзенең шатлык-куанычлары, кайгы-хәсрәтләре белән иртәләп, Казанга да яз килде. «Бигрәк иртә килде быел яз. Соңыннан кырау төшеп, алмагач, чия чәчәкләрен харап итмәсә ярар иде», – дип хафаланды бакчачылар.

Инде менә биш ел дәвамында Товарищеская урамындагы зур ашханәне җитәкли Асия. Ул ашханәне ачып җибәргәнче аның күргәннәре! Документлар туплау, эшчеләр җыю, җиһазлар алу... – Тавык чүпләп бетерә алмаслык, кыз үз гомерендә күрмәгән, белмәгән, күз алдына да китерә алмаган мең төрле мәшәкатьләр.

Эшендә ул еш кына куна кала иде. Җитәкчеләр тормышы турында күпме китап укыды! Эшне ничек башлап җибәрергә, эшчеләр белән нинди мөгамәләдә булырга, санитария кагыйдәләре... Һәм өч ай дигәндә ул ашханәне ачып җибәрә алды. Роза апасы, бухгалтерлыкка укучы сеңлесе Рәмзия булмаса, бу эшне мәңге башкарып чыга алмас иде Асия. Мәңге!!!

И туганнарым! Сезнең йөрәгегездәге бетмәс-төкәнмәс ярату, бер-беребезгә булыша-булыша, тормышның аяусыз дулкыннары кочагында чарасыз калып, бата барганнарыбызга кул сузып ярдәм итү – ул безгә нәселдән бирелгән. «Күкрәгеңә ут керсә, тартып алыр кардәшең» диләрме әле?

Гөрләтеп эшләтеп җибәрде ашханәне Асия. Студентлар, аның үз яшендәге студентлар, рәхәтләнеп, иртәсен, кичен аның кулыннан тукланды. Укыдылар, белем алдылар. Ә кыз аларны туендырганнан соң, белем эстәп, Казан педагогия институтының татар теле бүлегенә чапты...

Әле эшкә урнашкан гына чагы иде, ничектер кызның башына килде: нигә әле ашханәдә комсомол-яшьләр бригадасы төземәскә? Шәп булачак бит. Әлегә Казан шәһәренең җәмәгать туклануы тармагында андый бригада юк. Ул кайчандыр үзе укыган 17 нче көллияткә китте. Мастеры Фәния Гариповнаны эзләп табып, киләчәккә планнары турында сөйләде.

– Фәния Гариповна, миңа штат тупларга булышыгыз әле. Минем комсомол-яшьләр бригадасы төзисем килә. Сезнең төркемдә аш-су өлкәсендә сәләтле шәкертләр бармы? – диде.

– И сеңлем, син шундый зур эшкә ничек алынасы иттең? – дип аптырап, Асиянең күзләренә текәлде мастер. – КАИда зур ашханә ачыла дип ишеткән идем ишетүен. Практикантларга заказ да килде... Ике ел уку дәверендә кызның таянычы булган, үзе дә авылда туып-үскән Фәния апасы, күрәсең, шәкертләреннән монысын ук көтмәгән иде.

– Мине бу эшкә, дөресен әйткәндә, мәҗбүри куйдылар, – диде Асия, уңайсызланып. Бер кеше дә алынмагач, минем каршы килә алмасымны чамалап, белеп, Шәриф Әкбәрович кодалады.

– Син соң, балакай, ник риза булдың? Өстеңнән чыгар, түли алмассың...

– Беләм, Фәния апа! Алда нәрсәләр буласын да беләм. Ләкин үзегез беләсез, мин бит юаш бер авыл баласы. Безне әти-әни, өлкәннәргә каршы сүз әйтмәгез, өлкәннәрне тыңлагыз, хөрмәт итегез, дип өйрәтте. Шуңа күрә төлке авызына ничек килеп кергәнемне сизми дә калдым. Җитен комбинатында чак үлемнән калгач, һөнәремне алыштырам, дип антлар иткән идем.

– Әле соң түгелдер, ашханәң ачылмаган, тауар алынмаган, өстеңдә зур суммалар юк, барма син бу эшкә, сеңлем. Бетәчәксең. Мин ишеттем, хәтта Валентина Сергеевналар, Тамара Лягиналар да алынмаган, ә син... Алар бит бу эштә, кем әйтмешли, елан аягы кискән... Әти-әниеңә бу турыда әйттеңме соң?

– Юк, әни хәсрәтеннән үләчәк, әлегә әйтми торырга булдым. Сәер, Хәлим Сәлимгәрәевич: «Әтиеңнең сыеры бармы соң?» – дип сорады.

– Соң, өстеңнән чыкса, әтиеңнең сыерын сатып түләрсең, дип әйтүе булган инде аның. Укыганда да сәер идең, хәзер дә үзгәрмәгәнсең икән.

– Әни дә гел, кызым, башка балаларым өчен кайгырмыйм, синең өчен борчылып, төннәр буе йоклый алмый ятам, дип әйтә иде.

Фәния апасы озак кына эндәшми торды да:

– Ярар, үзе теләгән елан ите ашаган, ди. Баскычтан менгәндә кыен, төшкәндә ансат. Шуны бел, Асия, – дип көлемсерәп әйтеп куйды.

– Беләм, Фәния апа. Мин кыска гына гомер юлымда баскычтан өскә дә мендем, инде, Аллага шөкер. Менеп җиттем дигәндә, тау башында, тешләрен ыржайтып, ана бүре көтеп торганны күреп, баскычтан түбән дә тәгәрәдем. Ләкин... соңыннан ул тау башына барыбер күтәрелә алдым мин, Фәния апа! Аллага тапшырдым... Әгәр мөмкин булса, Сез ул ашханәгә

килеп китегез әле, үзегезнең киңәшләрегезне бирерсез. Сәләтле комсомолъяшьләрне дә җибәрсәгез, мин Сезгә бик рәхмәтле булыр идем.

– Ярар, Асия, уңышлар телим сиңа һәм... – дип, бер мәл тын торды Фәния апасы... – Мин сиңа ышанам, сеңлем. Төркемдәге ун кыз да сиңа тора алмый, дип әйтә идем бит. Чыннан да шулай. Син булганлыгың, үҗәтлегең белән үз дигәнеңә ирешәчәксең, иманым камил, Асия.

Ул бүлмәсеннән чыгып, кызны озатып калды. Көллияттә укыганда, авырлыкларга түзә алмыйча, инешкә иелгән тал агачы кебек сыгылып елаганда, үзенең иңен куйган Фәния апасы яныннан чыккач, Асия бераз тынычлангандай булды.

Аннары кыз элек Роза апасы белән бергә Калинин урамында яшәгән Назимә апасы янына барды. Ул, медицина институтын тәмамлап, санэпидемстанциядә җәмәгать туклануы бүлегендә баш белгеч булып эшли иде.

– Хуш килдең, Асия, уз әйдә! – дип, аналарча җылы каршылады аны, инде шактый гына эш тәҗрибәсе туплаган Назимә Хәсәновна.

Асия, Роза апасы янына килеп йөргәндә, аның белән дуслашып өлгергән иде.

– Назимә апа, мин сезгә киңәш-табыш сорап килдем бит әле, – дип, үз хәлен аңлатып бирде кыз.

– Һай, балакаем, хараплар буласың, бетәсең бит, – диде Назимә Хәсәновна, тәмам аптырап. – Мин КАИ ашханәләрен тикшерергә баргач, Валентина Сергеевна әйткән иде: «Бер тәҗрибәсез егерме яше дә тулмаган авыл кызы шундый зур ашханәне ачмакчы була. Мескен, ачып карасын соң, бер айдан куып чыгарачаклар, төрмәгә үк утыртып куймасалар әле», – дигән иде.

«Төрмә» сүзен ишеткәч, Асиянең җаны өшеп, бөтен тәне куырылып килде.

– Мин аның син икәнен белмәдем бит, сеңлем. Роза апаң беләме соң?

– Әйтүен әйттем, ләкин эш узган иде инде. Миңа трест башлыгы кул куйдырды.

– Әле соң түгел, Асия! Гариза язып керт, эшли алмыйм, диген. Әти-әни рөхсәт итми, диген. Бер дә булмаса, эштән китәм, дип куркыт. Алар сине җибәрмәячәк, билгеле. Синең турыда «Повар от Бога» дип сөйләшкәннәрен үзем ишетеп тордым. Асия, мин сиңа сеңлем буларак әйтәм. Бертуган сеңлем кебек якын бит син миңа.

– Назимә Хәсәновна, хәзер нәрсәнедер булса үзгәртергә соң инде, – диде кыз. – Мин кирәкле җиһазларны, ашханә ачар өчен кирәкле савыт-сабаны алып бетердем. Миңа нинди журналлар ачарга, диварларга нинди мәгълүматлар яздырып эләргә, эшчеләргә нинди документларга кул куйдырырга – шуларны белергә кирәк. Әгәр мөмкинлегегез булса, иртәгә килеп китегез әле. Көллияттә үземне укыткан Фәния Гариповнаны да чакырган идем.

– Фәния дә киләмени? Бик акыллы хатын. Ашханәләргә практика узарга укучылар алып килә. Шунда таныштык. Сине дә укыттымыни ул?

– Әйе, Назимә апа, укыганда ул миңа бик булышты. Рәхмәт аңа. Ул булмаса, мин аш-су әзерләү серләрен болай яхшы үзләштерә алмас идем.

– Ярар, сеңлем, иртәгә сәгать уннар тирәсендә килермен. Фәнияне, Розаны да күреп киңәшербез. Ай-һай, йөрәк икән үзеңдә, курыкмыйча нинди эшкә алынгансың бит, Алланың рәхмәте, – дип озатып калды Асияне Назимә Хәсәновна.

Иртәгәсен авыр уйлар белән ашханәгә китте Асия.

Нинди тәҗрибәле кешеләр, хәтта апасы да, Асия, барма шундый авыр, куркыныч эшкә, дип куркытып тора. Ә аңа нишләргә соң ?

Әй син, яшьлек, җүләр яшьлек! Кайларга ашкынып, юләрләнеп, башыңны кара кайгыларга саласың соң син?! Күреп торасың лабаса, барысы да синең өчен курка. Эшли алмасаң, өстеңнән чыкса, кем түләр? Әти-әниеңне хәсрәт утларына салачаксың бит. Соңыннан утырып еласаң да соң булыр.

«Юк, – дип, сәер Асия акыллы, төптән уйлый белә торган Асиягә җавап бирә. – Соң өч ай дәвамында төннәр буе пычак, тимер щёткалар белән кыра-кыра, сеңлең Рәмзия белән төзелештән калып каткан цемент, бетонны юдыгыз. Кулларыңа кара әле, чатнап, канап, чебиләп беткән ләбаса. Инде ашханәңне ачар вакыт җиткәндә, кемгәдер калдырып китеп барасыңмы? Юк, китмим. Эшлим», – дип, катгый итеп җавап бирә акыллы Асиягә үзсүзле, сәер Асия.

Менә шулай ике Асия, бер-берсе белән сөйләшә-сөйләшә, ашханәгә барып җитте. Башта Фәния апасы икенче елын укучы яшь кызларны җыеп килеп керде.

– Кызлар, менә бу кыз Асия Сәлимовна, сез эшләячәк ашханә мөдире була. Быел укып бетерәсез, тугызыгызга да әлеге ашханәгә юллама биреләчәк. Комсомол-яшьләр коллективы төзеп, эшегезне шушында башлап җибәрәчәксез.

Нәрсә сөйли бу Фәния Гариповна? Егерме яше тулмаган кызга Асия Сәлимовна дип тора. Булмаганны.

– Асия Сәлимовна аш-су осталыгына безнең көллияттә өйрәнде. Гаҗәеп уңган, тырыш кыз. Әле дә хәтеремдә, «Зәңгәр күл» пионер лагеренда әллә ничә шәһәр кызын алыштырып эшләде. Сез дә тырышсагыз, егерме яшегез тулганда, шундый ук дәрәҗәгә ирешеп, сезнең дә исемегез янына әтиегезнең исемен кушып мөрәҗәгать итә башларлар. Шуның өстенә Асия кичләрен институтта белем ала.

Кызлар шау-гөр килеп, ашханәнең төрле почмакларына таралып, өр-яңа җиһазларны, савыт-сабаны, өсләренә киеп эшлисе ап-ак формаларын карап йөрде. Барысы да ялт иткән: тузаннар сөртелгән, идәннәр кырып юылган иде.

Назимә апасы килеп кергәч:

– Асия, сеңлем, син әллә эшчеләр җыйдың дамы инде? Ашханәң бүген үк ачып җибәрерлек, – дип гаҗәпләнгән иде.

– Юк, Назимә апа, без өч ай буе сеңлем Рәмзия белән төннәрен монда кунып эшләдек, себердек, юдык, бар нәрсәне тәртипкә китердек, – диде Асия.

– Икегез генәме?

– Әйе...

«Шаккатырасың, валлаһи. Кулларыгыздан куаныгыз. Мин сиңа хәзер

тагын ниләр эшләргә кирәген аңлатам. Күзләр генә тимәсен, эшли аласың икән бит. Валентина Сергеевна ашханәсендә мондый тәртип юк», – дип, Назимә Хәсәновна да Асиянең күңелен күтәреп китте.

Иңнәренә канатлар үсеп, очына-очына, тулай торагына кайтып китте Асия. Аның инде тугыз ашчысы бар, калганнарын соңыннан җыяр. Һәм эшләр! Көнне төнгә ялгап, үзенең максатына ирешкәнче эшләр. Әти-әнисенә булышыр, үзе дә кеше кебек яши башлар. «Ефәк кебек яшьлегеңне кирәкмәскә сарыф итмә!» дигән бит әүвәлгеләр.

Асияме инде гомерен бушка сарыф итүче! Ул бит һәрбер көннең кадерен белеп яши. Әнисе әйтә иде: «Кызым, бүген эшлисе эшне иртәгәгә калдырма, калган эшкә кар ява», – ди торган иде.

* * *

– Ашханәгә ремонт кирәк булыр, бик таушалган! – диде бер килүендә Хәлим Сәлимгәрәевич. Асиянең улы туарга ун көнләп вакыт калган, әмма декрет ялына китә алмыйча һаман эшли иде.

Бер көнне Назимә апасы килде дә:

– Асия, шундый яхшы эшлисең. Соклангыч, – диде. – Әмма син декрет ялына киткәч, Валентина Сергеевна белән Лягина синең урында икесе сменалап эшләргә җыена икән. Тик Хәлим Сәлимгәрәевич: «Ничек оялмыйсыз, ашханәне ача алмыйча интеккәндә, икегезне дә чакырттым. Курыктыгыз. Япь-яшь кыз баланы, авыл кызын, елата-елата куйдык. Афәрин! Шундый яхшы эшләп китте. Аннан соң Казан каласында беренче булып комсомол-яшьләр бригадасы оештырды», – дип, тегеләрне куып чыгарган.

Әйдә, болай эшлибез. Хәзер мин синең ашханәңне санэпидемстанция нормалары буенча ремонтка ябам. Ә син, исән-сау балаңны табып, аңа ярты яшьләр булмыйча ачтырмыйм. Чөнки шундый зур ремонтны алар тиз генә башкарып чыга алмаячак.

Балаңны карарга няня табарсың. Якын гына торасың бит. Әле кооператив квартираңа да ай саен түләп барырга кирәк. Шулай килештек.

Улы Муратны табар өчен биш ел эшләгән ашханәсен ябып китте Асия. Кире әйләнеп кайтырмын да коллегаларым белән инде яратып өлгергән эшемне дәвам итәрмен, дип ниятләп китте.

Ләкин...

«Сукыр тавык юлга чыкса, буран кубар», дигән мәкаль дөрес икән. Асиянең улы туып, ике ай дигәндә, трестлар юкка чыгып, һәрбер районның үз җәмәгать туклану комбинаты ачылды. Асиянең җанын-тәнен биреп эшләгән ашханәсе Бауман районы карамагында калган иде. Хәлим Сәлимгәрәевич Вахитов районына күчкән. Назимә Хәсәновна юатты юатуын:

– Сеңлем, бер дә кайгырма, декрет ялыннан соң, алар сине үз урыныңа куярга тиеш. Оятларына көч килер. Интегә-интегә эшләгән эшеңнән алып атмаслар, – диде.

– Һай, белмим шул, Назимә апа, алырсың, бар, эт авызыннан сөяк, – дип үрсәләнде Асия.

– Әйдә, балаңны карарга тизрәк кеше тап. Май ахырларында ачтырам ашханәңне...

Май аеның матур бер иртәсендә Асия, улын күтәреп, агач трамвайга утырып, Бауман районы җәмәгать туклану идарәсенә китте. Ул килеп кергәндә, кадрлар бүлеге мөдире Тәслимә Абдулловна кабинетында ак чәчле бер юан хатын белән чәй эчеп утыра иде.

Тәслимә ханымны белә Асия. Роза апасы яшендәге, кара тут йөзле хатын. Ул да белә Асияне. Чөнки апасы янына килгәндә, күп тапкырлар күрешкәннәре бар. Ләкин бу юлы аның исәнләшүгә җавап бирәсе килмәде. Коры гына:

– Күрмисеңмени, безнең деловая встреча, – дип, коридорда көтәргә боерды.

Әле төшке ашка кадәр бер сәгать вакыт бар иде.

Көтте Асия. Памперс заманы түгел бит. Улы асты юешләнеп көйсезләнде, елады.

Юан хатын чыкмады да чыкмады. «Деловая встреча»лары төш вакытына чаклы сузылды.

Ниһаять, ишектән кара янып, Тәслимә Абдулловна, аның артыннан ишелеп, теге хатын чыкты да, кадрлар бүлеге мөдире таныш булмаган кешегә караган кебек Асиягә текәлде.

– Мин хәзер төшке ашка китәм. Сине кабул итә алмыйм, – диде ул төксе генә.

– Тәслимә Абдулловна, мин бит бала белән, инде сәгать буе сезне көтәм. Биш кенә минут вакыт табыгыз инде, – дип ялварды Асия.

– Нәрсә монда бала сөйрәп йөрисең? Бала тавышы йөрәгемә ярамый. Икенче юлы имгәкләрегезне өстерәп киләсе булмагыз.

– Сезне монда барыбер көтәчәкмен, – дип өзгәләнде Асия. – Төшке аш вакытыгыз бер сәгатьтән артмас бит.

Тәслимә Абдулловна артыннан шартлап ябылган ишек тавышына йоклап яткан бала куркып уянды да өзгәләнә-өзгәләнә елый башлады.

– Ашыйсың киләмени, балакаем, җаным минем! Күрәсеңме, нинди бәндәләр яши Җир йөзендә. Мөселман бәндәсе югыйсә... Бер сәгать буе танышы белән чәйләп утырды. Безне күрәсе килми инде аның, улым. Шула-а-а-й... Берәүләр түрә булса, чабатасын түргә элә, диләрме әле? Бу да авыл баласы бит. Ул да апасы белән Калинин урамындагы ике катлы тулай торакның беренче катында яшәде.

Имгәкләрегезне сөйрәп йөрмәгез, диме, улым? Әйе, шулай ди. Үзе дә күп балалы гаиләдә үскән ләбаса. Гомере буе никтер сөмсере коелып, кара көеп йөри ул. Аның да туганнары имгәк булдымы икәнни? Үзенең дә ике баласы бар лабаса. Үзе имгәк ул, әйеме, улым? Булырмын мин сиңа имгәк, диген, менә үсеп кенә җитим, күрсәтермен мин сиңа имгәкне, диген.

Ике сәгатьтән соң, арып-талып, зур сеткаларына «күчтәнәчләр» төяп, кайтып керде Тәслимә Абдулловна.

– Әле син һаман утырасыңмыни? – диде ул, тавышын бөердән чыгарып. – Мин синең монда икәнеңне онытканмын да инде. Юкка көткәнсең, синең мәсьәләне мин хәл итә алмыйм. Нәчәлник хәл итә. Тик бүген ул юк, иртәгә була.

– Ник аны өч сәгать алдан әйтеп булмадымыни? Мине бала белән көттереп торырга кирәк идеме?

Кадрлар бүлеге башлыгы эчкә баткан кара зәһәр күзләрен Асиягә төбәп:

– Синнән сорап торганнар, ди, анда кем белән ничек сөйләшергә икәнен, – дип, саубуллашмыйча да кабинетына кереп китте.

* * *

Асия атна буе идарә башлыгы янына керә алмады.

Барган саен: «Юк, бүген булмый», – дип җавап бирә иде сәркатип.

– Кайчан булачак соң?

– Ул безгә әйтеп йөрми.

– Телефон аша белешергә ярыймы?

– Шылтыратып торыгыз.

Шулай атна үтте. Идарә башлыгы – сәүдә министры урынбасарының хатыны. Галәмәт чибәр, зифа буйлы хатын. Ә киеме! Бу сиңа авылга ефәк күлмәк, үкчәле ак туфли киеп кайткан Сөмбелә име генә түгел инде. Ире сәүдә министры урынбасары булсын да, хатыны гади Казан хатыннары кебек киенеп йөрсенме? Булмаганны! Тузга язмаганны.

Инде Асия дә акны карадан, чынны ялганнан аера башлады.

Сөмбеләнең ефәк күлмәге дә чын ефәк булмаган лабаса. Туфлиләренең өстенә ябыштырылган зәңгәрсу ташлар да ясалма, ялтыравык пластмасс булган. Сөмбеләнең үзе кебек! Аның Вәкилгә булган «мәхәббәте» кебек. Ә Ирина Ивановнаның киеме чын ефәктән, чын күннән, тик үзе генә чын ук түгел бугай. Аның алдында барысы да бөтерелеп кенә йөри.

Күрегез сез, Шәриф Әкбәровичны гына, Ирина Ивановнаның аяк астында туфрак булыр иде, валлаһи. Җыелыш-мазар беткәч, шофёры хуҗасының затлы пәлтәсен хатынның иңнәренә сала. Япон зонтигы тоткычының төймәсенә генә баса да, шырт иткән тавыш чыгарып, аллы-гөлле зонтик ачылып, Ирина Ивановнаның өстенә ябыла. Аллам сакласын, хуҗа хатынның акка буялган, әле иртән генә чәчтарашханәдә ясатып чыккан прическасына яңгыр тамчысы тама күрмәсен!

Менә шулай, дускай, «фырт» киенеп йөрү өчен ким дигәндә, совет сәүдә министры урынбасары хатыны булырга кирәк.

Асия инде үзе дә кышларын Франциядә тегелгән затлы пәлтә киеп йөри. Мәскәүгә баргач, ГУМ чатында чират саклап, төн кунып, сатып алды. Учларына зур итеп чират номеры да сугылган иде әле.

Менә шундый кәттә хатын иде Бауман районы җәмәгать туклануы идарәсе башлыгы. Асия кебек авыл баласы якын килерлек түгел иде.

Ишекне шакып, ул кабинетка үтте.

– Мөмкинме?

– Проходите. Какой вопрос?

– Мин Товарищеская урамында урнашкан КАИ студентлар тулай торагындагы ашханә мөдире булам. Декрет ялыннан чыктым. Эшкә чыгарга кирәк иде.

– Ә кем әле сине кире урыныңа куям, ди? Син анда бик начар эшләгәнсең. Мин ул урынга үземә кирәк кешеләрне куям. Сиңа эштән китәргә туры киләчәк.

– Ничек инде?.. – диде Асия, агарынып. – Ул ашханәне мин ачтым. Беләсезме, миңа ничек авыр булды? Аннары минем декрет ялыннан соң үз урыныма чыгарга хакым бар.

– Әйе, син үз урыныңа чыга аласың. Ләкин шуны бел, бер ай да эшли алмаячаксың, бер ай да, мин сине беркайда да эшли алмаслык итеп, «бүре билеты» тоттырып куып чыгарачакмын.

– Ничек инде, тик торганда, бер гаепсез кешене эштән азат итеп буламыни?

– Була, эзләсәң, бөтен нәрсәдән гаеп табып була. Бигрәк тә безнең эштә... Утыр, үз теләгем белән эштән китәм, дип, гариза яз.

Асия чарасызлыктан елап җибәрде. Калтыранган куллары белән гариза язды да Ирина Ивановнага таба этеп куйды. Аннан соң өмет тулы яшьле күзләрен башлыкка төбәде. Аңа ана бүре күзләре кебек рәхимсез, яшькелт соры күзләр карап тора иде. Асия җаны өшеп, сискәнеп китте.

– Вы свободны, – диде тимергә тимер ышкылганда тешкә тия торган тавыш.

Асия, сулкылдап елап, ишеккә таба атлады. Тик ишек тоткасына тотынырга өлгерә алмады, ишек үзеннән-үзе ачылып китте дә, аннан киң итеп елмаеп, Шәриф Әкбәрович килеп керде. Асия белән чак кына маңгайга маңгай бәрелешмәделәр.

Ә Шәриф Әкбәрович артында Валентина Сергеевна белән Тамара Лягина басып тора иде...

* * *

Асия трамвайга утырып тормыйча, җәяү генә үзләренә таба атлады. Биш-алты тукталыш узасы бар. Улының ашыйсы киләдер. Күкрәкләре сөт белән тулышып авырта иде. Ә күзеннән бертуктаусыз яшь акты. Әрнүле, рәнҗеш тулы күз яшьләре.

Йа Раббым, ничек үләр икән бу адәмнәр? Шушындый эшне эшләп буламыни?!

Асияне яшь баласы белән эштән куып чыгардылар. Ә ул эшләмичә берничек тә тора алмый, чөнки аларның кооператив фатирга түлиселәре бар. Иренең хезмәт хакы гына җитмәячәк. Димәк, якын-тирәдә генә кая да булса эшкә урнашырга кирәк. Кирәк тирәкне еккан, ди. Әнисе быел лаеклы ялга чыгачак. Биш бала табып үстергәч, ул илле яшьтән ялга чыга ала. Әгәр ул улын әнисенә кайтарып куйса, улы ана назы күрмичә, әнкә сөтеннән мәхрүм булып, сыер яки кәҗә сөте эчеп, ятим бала булып үсәрме? Асия улыннан башка саргаеплар үләр бит.

Йа Раббым, бер Аллам! Кеше түгелдер лә сез, хатын-кыз исемен, ана исемен күтәреп йөрүче бәндәләр! Үзегезнең дә балаларыгыз бар лабаса! Үзегез дә аналар бит сез! Сезнең аркада биш айлык баласын әнкә сөтеннән мәхрүм итеп, авылга озатачак Асия. Ә сөт рәнҗешен кая куярсыз? Асиянең күз яшьләренә коенып үткәргән йокысыз төннәре рәнҗешен, ана рәнҗешен кая куярсыз?

Әнисенә Муратын кайтарып куйган Асия төшендә һәрвакыт улын югалтып, елап уяныр. Сикереп торыр да куркынып: «Улым кайда?» – дип, сабыен эзләр.

Шулай айлар узар. Асия дә, баласын югалткан ана бүре кебек өзгәләнеп, баласын сагынып яшәр.

Бу халәтне балалары янында үсмәгән аналар гына аңлый ала.

Күкрәкләрен сызлатып, шаулап төшкән, баласы имәсе сөтне савып, алмагач төбенә түккән аналар. Төннәрен яңа туган нарасыйдан гына килә торган яшәү исен тоймаган аналар.

Еллар үтәр, ана сөтеннән мәхрүм үскән улы да озын буйлы, чибәр ирегет булып җитешер...

Ләкин сөт рәнҗеше китмәс. Бигрәк тә ана сөте рәнҗеше.

Һәм Асиянең баласын сагынып түккән кайнар күз яшьләре сезне бу дөньядамы, ахирәттәме барыбер эзләп табар...

Асия ире белән атна саен авылга улы янына кайтып йөрер. Нарасые башта әти-әнисен танымыйча, ятсынып торса да, әнисе китәргә җыенганны сабый күңеле белән тоеп, нәни куллары белән:

– Әннә, әннә! – дип, Асиянең муенына сарылыр. Дәү әнисе баланы әнисеннән көчкә аерып алыр.

Яшь ананың күзеннән яшь, йөрәгеннән кан тамар.

Әнисе машина әрҗәсендә сөт бидоннары арасында елый-елый китеп барганда, улының, тагын үзен ташлап киткәннәрен тоеп: «Китмә, әнием, калдырма мине», – дигәндәй, үксеп елап калуы Асиянең төшләренә кереп йөдәтер. Аннан соң сәгатьләрне, минутларны санап, тагын атна ахырын көтәр. Шулай айлар, еллар узар.

Улының тәүге адымнарын атлап, тәпи киткәнен дә күрми калыр Асия.

Сабый беренче адымнарын әти-әнисенең кулына тотынып түгел, әбибабасының ярдәме белән ясар. Егылып, берәр җирен авырттырса, зарланып, сарылып еларга янында әнисе булмас. Үзен өзелеп яраткан әби-бабасы янында да рәхәт булыр сабыйга.

Тик ана назына ни җитә!

Ана белән баланы тоташтырып торган кендек бавы өзелгәннән соң йөрәк-бәгыреннән сирпелеп чыккан әнкә сөте, хәләл сөт, баланың киләчәк тормышына бәрәкәтле сихәт бирергә тиешле сөт ишегалдында үсеп утырган алмагач төбенә түгелер. Сабый әнкә сөтеннән мәхрүм калыр. Алай гына түгел, ана назыннан да мәхрүм калыр сабый.

Муратка ике яшьләр чамасы булганда, шәһәрдән кайткан әтисенә ул «кияү», әнисенә «алма апа» дип эндәште.

Чөнки әби-бабасы баланың әтисенә «кияү» дип, туган-тумача әнисенә «алма апа» дип эндәшә иде.

– Ярар, үзегез янына күчкәч, дөресләп әйтер әле, – дип юатыр Асияне әти-әнисе.

**Унберенче бүлек**

Асия үзенең көллияттә укыганда ач торган чакларын исенә төшерде. Бер телем икмәккә тилмереп яшәгән уналты яшьлек чакларын...

Кыз ул көнне кичке мәктәпкә укырга бармады. Моннан соң, көллияттә укуы беткәч, ашыга-ашыга, белем эстәргә Восстание урамына чабасы юк. Туйганчы йоклар, ичмасам. Тик никтер күңеле көн саен укырга йөргән мәктәбен сагына. Әллә дүрт ай буена, әрәмгә үткән гомерен жәллиме?.. Ярар, алган белемнең зыяны тимәс әле дип, гәрчә үзен-үзе юатса да.

Аның инде икенче тәүлек авызына бер тәгам ризык капканы юк. Үсә торган яшь организм ашарга сорый. Әти-әнисе, кызлары ашау-эчү җирендә эшләгәч, Асиянең тамагы тук, дип беләдер инде. Әгәр авылга хат язып салса, 3 сум булса да акча җибәрерләр иде дә... Тик Асия үз-үзенә биргән вәгъдәсендә нык тора. Әти-әнигә болай да авыр! Алардан бер тиен дә акча алмаска! Беркайчан да зарланмаска!

Ярый әле, Казан каласында яшәүче кечкенә апасы, әнисенең сеңлесе Сания бар. Исеме кечкенә булса да, аның, бар туганнарының кайгы-хәсрәтен, шатлык-куанычларын үзенә сыйдыра алырлык зур йөрәге бар. Кызның әле тагын Яңа бистәдә яшәүче Әхмәт бабасы һәм Роза апасы да бар.

Ул көнне җәяүләп кенә Әхмәт бабасына китте Асия. Аның хатыны Сәлимә шундый тәмле итеп аш пешерә. Бабасының колхоз базарында ит чабучы Исмәгыйль атлы әшнәсе кичен калган сөяк-санакларын әзерләп куя да Әхмәт бабасына биреп җибәрә, шулардан Сәлимә апасы аш әзерли. Лебердәтеп кенә өчәр сәгать кайнатып пешергән аш шулкадәр тәмле, телеңне йотарлык була.

Асия килеп, өченче катка менеп, озак кына кыңгырауга басып торса да, ишек ачучы булмады. Икенче катта исә әнисенең энесе яши. Тик аның хатыны ирнең туганнарын сөйми. Тамак гүргә кертә, диләрме әле? Асия курка-курка гына, кыңгырау төймәсенә басты.

– Кем бар анда?

– Мин идем, Мәгъшия апа, Асия...

Теге яктан ачкыч борган тавыш ишетелде. Асия эчкә узды. Ә анда, залдагы түгәрәк өстәл уртасында зур тәлинкәдә булары чыгып торган ярмалы бәрәңге шәйләнде: өстенә атланмайда кыздырып кишер, суган сипкәннәр. Һәм ап-ак йомшак күмәч. Асия, авызына төкерек җыелып, күзен хуш ис аңкытып торган бәрәңгегә текәп, катып калды.

– Ни йомыш? – дип сорады җиңгәсе.

– Менә Әхмәт абыйларга килгән идем, алар өйдә юк икән.

– Белмим шул, без алар белән йөрешмибез. Күргәнем юк, – дип, ишек тоткасына ябышты Мәгъшия. – Ярар, хуш, безнең әле төшке аш вакыты... – Һәм ул Асиягә чыгып китәргә ишарә итеп, ишекне ачты.

Йа Аллам, сиңа шунда ireңнең апасының кызына, уналтынчы яшенә яңа чыккан ач балага бер кисәк күмәчең, ике бәрәңгең жәл идемени соң?! Бер чынаяк сөтле чәй эчереп, озатып калсаң, никадәр савап алыр идең!

Абыйсы хатынына бер сүз дә әйтә алмады.

Асия җәяү генә Калинин урамындагы тулай торакта яшәүче Роза апасына китте. Ә анда бер төркем кызлар, киенеп-ясанып, кинотеатрга барырга җыена иде. Шунда Юлия исемлесе:

– Менә бит, бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына! Асия, балакаем, бар әле, «Победа» кинотеатрында һинд фильмы бара, билет ала тор әле, үзеңә дә ал! – дип, кызны озатып та җибәрде.

Су буе чиратта торып, Асия алты билет алды. Йә, нәрсәгә инде аңа бу билет? Фильм кайгысымыни Асиядә? Шул илле тиен акчаны үзенә бирсәләр, кызга өч ипи алырга җитәчәк бит. Әле тагын бер тиен өстәсә,

өч тиен була да, бер мәртәбә трамвайга утырып бара ала яки бер стакан сироплы газлы суга да җитәчәк.

Бераздан шаулаша-шаулаша, киенеп-ясанып, бүлмәдәшләре белән Роза апасы төшеп килгәне күренде.

Һәм ул көлемсерәп:

– Әйдәгез, кызлар, туңдырма белән сыйланабыз, – дип әйтеп куйды.

Асиянең күңелендә шундук: «Алсалар ярар иде», дигән өмет уты кабынды. Инде пломбир туңдырмасы да, аның тышындагы вафля да кетер-кетер килеп, энҗе тешләре арасына кереп барадыр кебек иде.

– Әй, кирәкмисана! – диде шунда чуваш кызы Римма, татарчалатып.

Алмадылар. Җыелышып, фильм карарга залга кереп утырдылар. Башта Советлар Союзында космосны үзләштерүгә багышланган киножурнал күрсәттеләр. Ә аннан соң ятим кыз бала турында ике серияле һинд фильмы башланды.

Бер ананың ничек итеп ятим баланы рәнҗетүе, ашарга утыргач та кызның тәлинкәсенә иң кечкенә, көйгән-янган ризыклар салуы, һәм арка сөяге сыек булган ир затының, кызның әтисенең, баласын яклап, бер сүз дә әйтә алмавы турында иде ул фильм. Нәкъ Мәгъшия апасының ире – Асиянең абыйсы кебек инде менә! Шуның өстенә, һаман шул ашау, эчү турында сүз бара. Һәм өстәл өсте тулы ризык! И халык елады инде!

Асия дә бертуктаусыз үзен кызганып елап утырды.

Ачның күзе икмәктә, тукның күзе хикмәттә, дип, юкка гына әйтмәгәннәр шул.

Бик соң гына бетте ике серияле фильм. Соңыннан, тулай торакларына кайтканда да, үги ананы сүгеп, тамагы туйганчы ашамаган яшь кыз баланы кызганып, елый-елый кайттылар.

Өйләренә кайткач, күмәч турап, чәй булса да эчәрләр әле дигән өмет бар иде Асиянең күңелендә. Ач килеш йокларга ятмаслар бит инде!

Ләкин... Күбесенең иртән биштә торып, эшкә барасылары бар икән.

– Әйдәгез, чәй эчеп алыйк! – диде Роза апасы.

– Завтра рано утром на работу, спать надо, – диде Юлия.

– Ятар корсак ятар, озакламый таң атар! – диде татар егете белән йөрүче, тел өйрәнүче чуваш кызы Римма.

Юынып, Роза апасы белән бер кешелек тимер караватка, башын як-якка куеп, ач килеш тагын йокларга ятты.

Әй, бу юашлык! Роза апасының һич югы күмәче булгандыр бит инде. «Апа, минем ашыйсым килә!» – дип әйтсә, апасы ашатмас идемени?

Асиянең төн буе күзенә йокы кермәде. Күз алдыннан булары чыгып торган, өстенә кыздырылган суган белән кишер сибелгән ярмалы ап-ак бәрәңге китмәде. Әле ул майда кыздырылган суган белән кишернең исе ни тора!

Тәрәзәләргә акрын гына таң алсулыгы сарылганда, Асия әле керфек тә какмаган иде.

Әнә, апасы торып киенде дә, Асиягә ачкычны ишек төбендәге кечкенә палас астында калдырырга кушып, эшкә чыгып китте. Башка кызлар берәм-берәм чыгып шылды. Караватында бер Римма гына ятып калды. Төн буе күзенә йокы кермәгән Асия торып утырды да Риммага төбәлеп, озак итеп тыңлап торды. Тигез сулыш алып йоклый иде чуваш кызы.

Асия яланаяк килеш салкын идәнгә басып, апасы караватының баш очындагы буяулары кубып беткән иске тумбочка янына килеп басты һәм сак кына, аның ишеген ачты. Шыгырдамыйча гына ачылды, рәхмәт төшкере. Аллага шөкер, дип сөенеп, калтыранган куллары белән тумбочканың өстәге катыннан ипи кисәге эзләргә кереште ул. Тик анда кашык, пычак, стакан-чәшкеләрдән башка берни дә юк иде. Өстәвенә кулы ялгыш стаканнарга тиеп китеп, алар ипи катысы эзләп изаланган кызның котын алып, чыңлап куйды. Асия куркуыннан тагын Римма ягына карап, тынып калды. Әллә бик арыган иде, әллә яшьлеге белән йокысы каты булды – кыз пыф-пыф итеп йоклавын дәвам итте.

Әй, сөенүләре шунда Асиянең! Һәм ул тынычлап, тумбочканың аскы катында кармалана башлады. Ниһаять, кулы таш кебек каты, ярты кирпеч икмәккә орынды.

– Ипи!

Башы күккә тиярдәй булып, Асия тиз генә юрган астына чумды да, төкереге белән җебетә-җебетә, ипи ашарга кереште. Аның әле гомерендә дә мондый тәмле ипи ашаганы юк иде!

Озын-озак гомер дәвамында нинди генә ризыклардан авыз итмәде ул, ләкин иң яраткан тәгаме ипи булды. Кулына икмәк алган саен юрган астына качып ашаган каткан ипи исенә төшәр аның. Һәм кайнар булары чыгып торган, өстенә атланмайда кыздырылган кишер белән суган сибелгән ярмалы ап-ак бәрәңге! Мәңге онытмас аны Асия! Һәм эшенә кем генә килеп кермәсен – таныш кешеме ул, түгелме, баймы, хәерчеме, дәрәҗәле кешеме, юкмы – аңа барыбер булыр. Сүзен һәрчак шуннан башлар:

– Әйдәгез, башта ашап-эчеп алыгыз! – дияр.

Әгәр килгән кеше уңайсызланып: «Юк, мин әле генә ашап килгән идем», – дисә:

– Чәй эчермичә җибәрмим. Кирпеч заводына килмәдегез бит, ашау-эчү җиренә килдегез, – дип, килгән кешене туендырып җибәрер.

«Икмәк авазы бар», диләр. Моның шулай икәненә дә инаныр Асия. Бервакыт Себергә сәяхәткә баргач, «Йорторы авылы имамы Навил хәзрәт, аны танып: «Мин сезне беләм. Конгресска килгәч, сезгә кергән идем. Көн эссе, чәй эчәсем килгән иде, – диде. – Сез шәхсән үзегез миңа чәй, чәкчәк һәм өстенә казылык куелган бер телем икмәк чыгардыгыз! Минем кайдан икәнемне белгәч: «Хәзрәт, мин сездән акча алып тормыйм. Сез бит мосафир кеше, савап булсын!» – дип, озатып калдыгыз».

Менә моны икмәк авазы дими, ни дисең! Ничә еллар үткәч, ничә мең чакрымнарга барып ишетелгән бит Асиянең бер чынаяк чәе белән бер телем икмәгенең авазы! Рәхмәт сезгә, Навил хәзрәт! Безнең татар халкының гореф-гадәтләрен Себердә саклаганыгыз өчен рәхмәт!

Әйе, нәкъ шулай, берәүнең кулыннан тәгам ашаган иманлы инсан беркайчан да үзенә авыр чакта ярдәм кулы сузган кешене онытмас. Исенә төшкән саен, үзе, йә булмаса ашаган икмәге, ул изге адәмгә дога кылып торыр.

Бу икмәк авазы булыр!

Бабасы әйтмешли, изге адәмне Аллаһ үзенең бәрәкәте белән сөендерер!

Әйе, икмәкнең дә хәтере бар!

* * *

Әллә ничә ашханә ачтырдылар Асиягә. Инде эшләтеп җибәргәч, түрәләр (алар биектә утыра – барысын да күрә), аның урынына туганнарын, дусларын, әшнәләрен куялар да, Асия тагын эшсез кала.

Ашханә ачып, эшләтеп җибәрү өчен күпме көч, күпме йокысыз төннәр кирәк икәнен бу эшне үзе башкарган белгеч кенә белә. Читтән карап торган кешегә ул, бәлки, җиңел генә кебек тә тоеладыр. Илдә бөтен нәрсә талонга калган заманнар. Аш-су тирәсендә эшләгән кешегә кызыгып та карыйлардыр. Боларның тамагы тук, өсте бөтен, янәсе.

Әмма халык телендә «Ач тамагым, тыныч колагым» дигән гыйбарә дә бар бит әле. Асия боларның барысын да үз йөрәге аша үткәрде. Ул бетмәс-төкәнмәс тикшерүләр, Госторгинспекция, халык контроле, ОБХСС, санэпидемстанция, җәмәгать туклану өлкәсеннән килгән тикшерүчеләр һ. б.

Асия эшкә килгәндә, бүген тагын ничә тикшерү килер икән дә, кемнәр нәрсә язып китәр икән, дип үрсәләнә. Эшләргә һич мөмкинлек бирмиләр. Урам себерүчеләргә кызыгып карый иде Асия. Болар хәзер эшләрен бетерә дә, өйләренә кайтып, тынычлап, кайнар бәрәңге ашап булса да, ял итәчәк бит.

Тикшерүчеләрне матур итеп озатырга да кирәк бит әле. Әгәр күңелләрен күрмәсәң, лабораторияләр әллә ниткән куркыныч, алтын койрыклы стафилокакклар, эчәк таякчыклары табып газаплаячаклар. Алар «тикшерергә ярамаган» ашханәләргә кагылмый, ә Асия кебекләргә. «Килгәндә үк, менә бу белгечне юк итәргә, эшеннән алырга дигән боерык белән килә. Һәм сәгатьләр буе синең җаныңны талкый. Башта алар аш өстендә йөзеп йөргән, тирес астыннан чыккан симез ак кортлар кебек дуңгыз майларын тастымал белән сөртеп корыта, аннан үлчи. Әгәр биш грамм җитмәсә, акт язып, икенче көнне тиешле органнарга чакыртып, утлы табага бастыралар. Син инде кеше икәнеңне онытасың. Җир йөзендә үзеңнең нинди түбән дәрәҗәдә булуыңны шунда гына беләсең.

«Син карак, урлыйсың, кеше хакын ашыйсың», янәсе.

«Соң сезне ничек матур итеп озатып була соң? – дип, эченнән генә үзен сүккән «нәчәлник»кә шаккатып карап тора иде Асия. – Әле теге атнада гына өерегез белән килеп...»

Тик ул дәшми, чөнки аның сүз әйтергә хакы юк. Әгәр каршы әйтсәң, беттем диген инде. Сине шунда ук кара исемлеккә кертеп, төрмәгә үк утыртып куюлары бар. Аннары балаң тилмереп, әнисез үссенме? Әнә ич беренче комсомол-яшьләр бригадасы төзеп, Асия эшләтеп җибәргән ашханәдә трест башлыгы җитәкчелегендә Валентина Сергеевна, Тамара Лягиналар һәм аны упкын читенә бастырып, эш урынын саклап калган Шәриф Әкбәровичлар рәхәтләнеп эшләп ята.

Менә шулай гомер үтәр. Без җиңдек, дип куаныр бу адәмнәр. Киләчәктә үзләрен ана сөте рәнҗеше куып тотачагы турында уйламаслар да. Үзеңә түгел, газизеңә төшә ул рәнҗеш. Алда Асия боларның барысын да күрер. Ул адәмнәрнең кайсылары үлә алмыйча, дистә еллар кеше күзенә карап ятар. Кайсыларын бала хәсрәте аяктан егар. Шуңа күрә тыелганнардан тыелып, кеше рәнҗетмичә яшәргә тырышырга кирәк. Әле үзебез белмичә кылган гөнаһларыбыз да бихисаптыр.

Корымлы казан янында йөреп, каралмыйча калып булмый, диләрме әле?

Шуннан дуңгызга «җизни» дип әйтергә дә өйрәнәсең. Әйе, СССР вакытында җәмәгать туклануы өлкәсендә эшләүченең хәлләрен шунда хезмәт куеп караган кеше генә белә. Әле бит план дигән нәрсә дә бар. Әгәр үзеңә төшерелгән планыңны үтәмисең икән, икенче көнне үк гариза язып, комбинат директоры янына барырга әзер булып тор. Ашханәгә бирелгән планыңны үтәгән очракта да, әгәр районда план үтәлмәсә, ай ахырында төннәр буе кәгазьдә план ясыйсың.

«Менә тагын шуның чаклы кирәк, яз».

«Ничек языйм, минем калдык тауарым да юк бит инде».

«Кәгазь белән генә ялган документ яздырып ал. Тауарны соңыннан алырсың».

«Ә тикшерү килсә»?

«Булышырбыз».

«Әнә, «Блинная» кафесы мөдире Әминә апаны кулга алганнар, Кошеловны, Таһир Нәбиевичне. Берсе дә яклап бармады. Әле Киров районындагы ашханәдә эшләүче Венера апа да тоткарланган. План үтәр өчен, өстәмә бәя куеп, завод эшчеләренә бәрәңге сатканда тотканнар. Инде өченче аен утыра».

«Асия! Кирәк. Тыңла мине, кирәк», – дип ялына ашханә директоры.

План үтәр өчен дефицит тауар табып, аны өстәмә бәя белән, тормышыңны, дәрәҗәңне куркыныч астына куеп сатасың – план үтисең. Шәхсән сиңа аннан берниндә табыш керми, ләкин планың үтәлә. Әле тагын бер ай тынычлап эшли аласың.

Анысы бер хәл. Әле ашамлык калдыклары планы бар. Анысы инде Залесный дуңгызлары, Асия әйтмешли, «җизниләр» өчен. Гаҗәбенә ни диярсең, валлаһи! Ашамлык калдыклары булсын өчен ризыкны сыйфатсыз итеп әзерләргә кирәк ләбаса. Кайлардан гына аласың ул ашамлык калдыкларын?! Кешеләрне ашатырга кирәк бит! Акча түли бит алар.

Анысына да өйрәнәсең икән. Зур-зур кисмәкләр тезелгән машина шофёрына күпмедер акча төртәсең дә, ашамлык калдыклары җыючы акчасын кесәсенә салып куя да кисмәкләргә берничә чиләк су өсти. Әйдә, ярар, су эчеп кенә дуңгыз симерә алмый, хет бераз майлары кимер.

Менә шулай, шагыйрь җанлы, нечкә күңелле, яз көне үләннәрнең пышылдаша-пышылдаша шытып чыгуларын, үзара сөйләшүләрен колагы белән түгел, йөрәге белән ишетә алучы сәер Асия Залесный дуңгызлары планын да үтәп барыр.

Өстәвенә, сиңа черек, бозылган тауарны бүлеп бирәләр дә, син аны чыгарып ташларга тиеш, ә җитмәүчелек булса, казна йортына илтеп ябасыларын көт тә тор. Монда инде этиеңнең сыерын сатып кына котыла алмыйсың.

* * *

Туксанынчы еллар! СССР халыкларының хыяллары, киләчәккә булган өметләре чәлпәрәмә килеп җимерелгән, каһәрләнгән еллар! Кешеләргә хезмәт хакы түләмиләр, түләгән очракта да кемгә ат дугасы, кемгә бүтән кирәкмәгән тауар бирәләр. Ә менә укытучыларга... аракылата түләделәр.

Шаккаткыч хәл! Эчәсең киләме синең, юкмы – рәхәтләнде балаларга тәрбия бирүче укытучы-мөгаллимнәр аракыга! Тәрәзәдән укучы балалар исләре китеп карап торды: үзләрен әдәп-әхлакка өндәүче укытучылар тартма-тартма аракы ташыды.

Асиянең әтисе сугышка кергәндә: «Әгәр һәлак булсам, мине коммунист, дип санагыз», – дип гариза язган булган. Аллага шөкер, сугыштан исән-имин, орден-медальләр тагып кайтып, гаилә корып, биш бала тәрбияләп үстерде ул. Әтисе чын күңеленнән Коммунистлар партиясенә ышанып яшәде. Сиксән бишенче елларда мәңгелек йортына күчте.

Әти, җаным! Ярый әле вакытында бу дөньяны ташлап киткәнсең! Әгәр үлеп котылмаган булсаң, әрәм гомереңне кызганудан, син инанган Коммунистлар партиясенең бер көн эчендә юкка чыгуын күрүдән яралы йөрәгең ярылыр иде. Ә бит ышандың, әти. «Алда безне якты көннәр көтә», «Коммунистлар партиясе Советлар Союзы халыкларын сиксәненче елда инде коммунизмга алып керәчәк», – дия идең. Черәшә-черәшә «уфалла» арбасы сөйрәп, колхозның печән, салам эскертләре төбеннән малга курмы йолкыган балаларыңа да шуны аңлатырга тырыштың. Балаларың да ышанды ул әкияткә! Мәктәп директоры пионер, октябрят балаларыңны: «Сез карак! Сезнең кызыл галстук, октябрят значогы тагып йөрергә хакыгыз юк!» – дип сүккәндә дә, түздең син, әти!

Инде менә синең һәм әниненең ата-аналарын «кулак!» дип, Себергә сөргән, атып үтергән, җирләрен, мал-мөлкәтен тартып алып, нәселләрен юк иткән адәмнәрнең оныклары ил-җиргә баш булып, әби-баба җирендә үзләренә мал җыя.

Күпме кеше эшсез калды ул елларда! Асия бу вакытта ашханә мөдире булып эшли иде. Көннәрнең беренче Фирая апасы үксеп елап килеп керде. Гомере буе Яңа бистәдәге заводта эшләгән, әллә нинди зур дәрәҗәләргә ирешкән апасын трамвайдан куып төшереп калдырганнар.

– Асия, беләсеңме, кондуктор мине «Бессовестная, уже пожилая женщина, а без билета катаешься», дип сүгеп, этә-төртә трамвайдан төшереп җибәрде. И, оялдым да соң, и, хурландым да соң! Мин бит әле пенсиягә дә чыкмаган. Картлык көнемә дип җыйган акчаларым янып, чүпкә әйләнде. Заводны да яптылар.

– Тукта әле, апа, җаным! Нигә елыйсың? Баш ярылып, күз чыкмаган лабаса! Әйдә, миңа эшкә кил. Кассир булып эшләрсең. Заводыгыз ачылгач, кире үзегезгә кайтырсың.

– Рәхмәт инде сиңа, Асия! Син училищега укырга кергәч, мин: «Торгаш буласыңмыни?» – дип, синнән көлгән идем. Әти шунда әйтте: «Фирая! Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа Саләллаһу Галәйһи вәссәлам дә хатыны Хәдичә белән бергәләп сәүдә иткән. Сәүдә безнең халык өчен сөннәт ул», – дигән иде. Ә син бөтен нәселгә эш табып, аларның авыр хәлләрен җиңеләйтеп торасың. Рәхмәт сиңа! – дип чыгып киткән иде апасы.

Ул ел буе Асиядә эшләде. Заводлары ачылгач чакыртып алдылар үзен. Менә шундый авыр еллар! Хәер, Асиянең дә эше бик җиңел түгел. Табышы да юк. Эшеннән куып чыгарылган дус хатыны әйтте беркөн:

– Әйдә, Асия, чит илгә тауар сатарга чыгабыз, – диде.

– Кит булмаганны, Вәсилә, шундый эш буламы?

– Була икән шул. Әнә, минем дусларым, Польшадан мебель ташып, баеп бетте инде.

– Юк, юк, Вәсилә! Эшемнән дә китә алмыйм, ирем дә каршы килер.

– Асия! Беләсеңме... – дип тукталып калды Вәсилә, аннан соң кеше ишетмиме дип, як-ягына карап алды да сүзен дәвам итте: – Беләсеңме, банкта эшли торган дусларым әйтте: «Акча алышына, булган акчалар буш кәгазьгә әйләнәчәк», – диләр. Син бит акчаңны кассага салмыйсың, доллар җыясың. Ә Румыниягә чыгып, акчаңны долларга алыштыра аласың. Шундый мөмкинлек бар.

– Вәсилә, мин нәрсә әйтергә дә белмим инде. Чираттагы ялымны алсам гына.

– Чит илгә чыга торган паспортың бармы? Булмаса, чарасына кереш. Ун көндә әзер булыр.

* * *

Поезд белән чыгып китте алар Румыния иленә. Инде күпме еллар буе бу эш белән шөгыльләнгән юлдашлары акчаны кая яшерәсен, таможняга күпме түлисен белә иде. Таможня үтәргә чиратка баскан хатын-кызлар чүлдә барган кәрванны хәтерләтә. Өркәчле дөяләрмени. Җилкәләрендә – зур-зур биштәрләр, кулларында – арбалар. Арбалар өстендә барысының да бертөсле чапталары. Шакмаклы, зәңгәр-кызыл сумкалар.Чикне чыкканда, бар җирләрен тентеп үткәрәләр. Әнә, өстәл янында утыручы таможня хезмәткәре әйтә:

– Кемдә ике литрдан артык аракы (Россия аракысын Румыниядә, Польшада бик яраталар, ди Вәсилә) булса, өстәлгә чыгарып салыгыз, – ди.

Асиядә егерме шешә аракы һәм шашлык кыздыра торган бер аппарат бар. «Ничек булса да, бу хурлыктан котылырга кирәк», – диде ул. Үзалдына. Шашлык аппаратын да, дүрт шешә аракыны да өстәлгә илтеп куйды һәм, коты очып, калтыранып, калган шешәләрне дә илтеп тапшырыйм дип, кире арбасына таба атлады. Аның кул арбасы туп-тулы, кызының кечерәйгән киемнәре астында ничә еллар буе җыелган акчалары яшерелгән.

– Женщина, туктагыз! – дигән тавышка ул кире борылып килде. «Беттем!» дип уйлады Асия. Хәзер аны контрабандада гаепләп, ябып куячаклар... Күз аллары караңгыланып китте.

Таможня хезмәткәре тишәрдәй булып, хатынга бераз карап торды да:

– Проходите, вам зелёный коридор! – дип, бер арба акчасы, уналты шешә аракысы белән Асияне генә ишектән чыгарып җибәрде.

Поездга да иң беренчеләрдән булып кереп утырды ул. Бөтен гәүдәсе туңып, калтырана башлады. Соңыннан вагонга юлдашлары да кереп тулды. Барысы берьюлы кемнедер сүгә, елый-елый таможняны каргый.

– Безнең чүлдәге өркәчле дөяләр кебек интеккәнебезне күрә бит инде болар.

– Әйтмә дә инде, малай, җаным, ярты әйберебезне талап алып калдылар бит. Бу калдык-постыкны төяп баруның ни фәтүәсе бар! Минем кредит түлисем, балаларымны ашатасым, укытасым бар.

– Ә мине, – дип дәвам итте Вәсилә, – эшемнән куып чыгарып, үз туганнарын минем урынга куйдылар. Мин өч балам белән ни кылырга

тиеш, әйтегез әле. Шулкадәрле йөк ташый-ташый, бөтен эчем төшеп бетте бит инде. Ирем эшсез калды да эчүгә сабышты. Тәмам кешелектән чыкты. Аек вакытта әйтеп тә карыйм: «Самат, синме соң бу?! Нинди кеше идең, хайван дәрәҗәсенә төштең бит инде!» – дим. «Ә мин ни эшләргә тиеш? Кеше таларга чыгыйммы? Әллә югары белем, шундый зур тәҗрибәм белән урам себерергә кушасыңмы? – дип, авызымны каплый. – Сындым мин, Вәсилә.Тормышның бу якка тәгәрәве күпме ирләрне харап итте. Һәм мине дә... – Саматымның күзләрендә яшь иде. – Сез хатын-кызлар безгә караганда көчлерәк булып чыктыгыз бит әле. Бездән бушаган аракы шешәләрен җыеп булса да, көннекен-көнгә ялгап барасыз. Инде менә чит илдән мебель ташыйсың. Польшага урын-җир кирәк-яраклары, электр җиһазлары илтеп сатып, акча эшлисең. Ә мин беттем», – ди.

Хатын-кызлар, арбалы хатыннар – өсләренә адәм күтәрә алмаслык йөк төягән нәфис затлар, елаша-елаша, кайгы-хәсрәтләрен бүлеште. Әле яңа гына бу төркемгә килеп кушылган мишәр кызы Сәрия телгә килде:

– Әй, кызлар! Сезгә бер кызык хәл турында сөйлим әле, – диде. – Бүген мәзәк инде ул, ну, малай, җаным, күрмәгәнемне күрсәтте миңа ир дигәнем. Үткән юлы Румыниягә барганда, миңа юлдашларым әйтте: «Сәрия, әгәр барасы булсаң, үзең белән балага узудан саклана торган «изделие» ал». Исемен оныттым, кабартсаң, шар кебек әйбер, аңладыгыз инде, шуны алырга куштылар. Күрәм, һәрберсенең сумкасында икешәр пачка ята! Мин кешедән кимме әллә? Ике пачка алып, сумка төбенә салып куйдым. Мин Румыниядә бу «изделие»нең бер пачкасын сатып бетердем. Икенче пачкасының яртысы сатылып бетте. Әбиләр килеп-килеп сорый: «Бу нәрсә бу, сагызмы?» «Юк, – дим, – бу сагыз түгел, «анти-бэби» мин әйтәм. Оныкларына сагыз алырга чиратка баскан әбиең «Тфү-тфү» дип төкеренеп китеп барды.

Озын сүзнең кыскасы шул, кызлар, шактый гына акча эшләдем мин бу «анти-бэби»дән. Икенче пачкасын сатып бетерә алмадым, чөнки утызлап кеше шул әйберне сатабыз. Бөтен Румыния хатыннарына «анти-бэби» кирәк түгел бит инде. Юкса бу илдә бөтенләй бәбиләр тумас. Ярар, – дип сузды Сәрия. – Калдырып китеп булмый бит, Казанга кире алып кайттым мин моны һәм, кеше күзе төшмәсен дип, шкаф башына җыеп куйдым. Алла сакласын, балалар күрмәсен!

Беркөнне эштән кайтып керсәм, ирем гүпчи кара янып, ишек төбендә басып тора!

– Нәрсә булды, бәгырь кисәгем, – минәйтәм, – нәрсәгә дип янып бетмәгән пужар кисәве кебек каралдың?

– Салып торып җибәрермен, – ди бу. – Син, анда загранда пуездда ниләр майтарып ятасың?

Һични аңламый басып торам, кызлар. Соңгы көннәрдә ирнең ачуын китерердәй бер генә дә кыек эш эшләгәнем юк иде бит. Ашатам, эчертәм, оланнарын карыйм, җыям, юам, үтүклим. Ә бу гөнаһ шомлыгы миңа:

– Салып торып җибәрермен! – дип тора.

Өйгә кердем. Ә анда теге «анти-бэби»ләр караватта тезелешеп-тезелешеп ята, малай, җаным. Нәрсә эзләп, шкафның өске катына менгән диген син аны.

– Боларның калганнары кайда?– дип сорый бу. – Кем белән булдың? Әйт!

– Тукта әле, бәгырь кисәгем, мин аларны саттым бит! Сатып бетерә алмаганнарын кире алып кайттым. Румыниядә учырт торып алдылар, – дим. Ышанмый гына бит. Ярый әле, минем белән бергә Румыниягә йөргән хатынның телефоны бар иде:

– Мә, – мин әйтәм, – Гөлсинәгә шалтырат, ышанмасаң, аннан сора.

Номерын җыеп, трубканы кулына тоттырдым.

– Әлү, Гөлсинә! Минем Сәрия Румыниядә нәрсәләр сатты ул? – дип төпченә башлады бу.

– Күп әйбер сатты инде: урын-җир, электр тауарлары, аракы, тәмәке, калганын белмим дә инде.

– Тагын нәрсә-ә-ә? – дип сузды минеке, тавышы да усаллана төште.

Трубкада тынлык! Эчтән генә көтәм инде. Әйт инде, Гөлсинә, җаным, әйт инде! Син үзең дә шуны саттың бит. Тучны мине аерып җибәрә бу, дим.

Шулчак трубкада Гөлсинәнең мин тилмереп көткән сүзләре ишетелде:

– Ә, онытып торам икән, барыбыз да «анти-бэби» саттык, – диде ул. Сәрия сатып бетерә алмады, монысы иремә булыр, – дип, кире алып кайтып китте. Ярамадымы әллә?

Минеке йомшый төште:

– Моннан соң бу эшеңне күрмим! – дип тотынган иде, мин бар булган «анти-бэби»не йөзенә бәрдем.

– Оятсыз, – мин әйтәм, – ничек оялмыйча бөтен тормышыңны сөйрәгән хатыныңа шундый сүзләр әйтәсең? Аерылам мин синнән! – дип, котын алдым.

Әле генә тормышларыннан, таможнядан зарланган хатыннар вагонны җимерердәй итеп көлешә башлады.

Беренче тапкыр шундый авыр, аңлаешсыз юлга чыккан Асия, бер сүзгә дә катнашмыйча, плацкарт вагонның ятагында уйланып ятты.

Юлдашлары кемнең нинди ризыгы бар – шуның белән кичке ашны ашарга утырды. Вәсилә Асия янына килеп:

– Әйдә, тамак ялгап алыйк! – дигәч:

– Юк, дускаем, ашамыйм. Нигәдер калтырата, – дип, өстенә одеялын тартыбрак ябып куйды.

– Асия, синең жарың бик көчле бит! Бу нервыдан инде. Син әле безнең кебек каешланмагансың. Кызлар, берәрегездә нервыны тынычландыра торган дару юкмы?

Юлчы хатыннар шунда тыныч кына ятып торган Асиягә күз салды.

– Бәхетең бар икән, Асия! Зелёный коридордан чыгып китә алдың.

– Әйе, Асиянең бәхете бар, – диешә-диешә, кемдер дару, кемдер пластик стакан белән су китерде.

Бу – Асиянең киләп-сарып йөрүчеләр тормышына беренче адымы иде. Матурлыгының чиге-чамасы булмаган, түбәләре ак болытларга тиеп торган чал башлы Карпат таулары башында татар кызлары румын чегәннәренә Казаннан төяп килгән тауарларын сата.

«Ак калфагым төшердем кулдан!» – дип уйлап куйды Асия.

Әнә үрәмән хәтле бер румын чегәне Вәсиләнең бер төргәк сигаретын урлаган. Кемдер күреп, Вәсиләгә бу турыда әйткәч, ул юлбарыс кебек теге

аюга ябышты. Якасыннан тотып селкепме-селки. Урлаган сигаретлар шап-шоп җиргә коела.

– Әй, Вәсилә! Андый ямьсез сүзләр әйтмә инде. Яхшы түгел бит.

– Урламасын! Мин бит аны татарча сүгәм. Татарча белми ул, Асия!

«Ак калфакның каралган чагы»! – дип, янә күңеленнән кабатлады Асия.

Әй, дөнья, нинди хәлләргә төшердең син сөяргә-сөелергә дип кенә туган гүзәл татар кызларын? Кайда сезнең ап-ак беләкләрегезгә кигән көмеш беләзекләрегез? Кайда сезнең хыялларыгызга ай нурларын кушып җеп эрләгән чакларыгыз?

Әнә, Сәрия исемле мишәр хатыны мактый-мактый, «анти-бэби» сата... Әнә, татар хатыны, дусты Вәсилә сугыша-талаша сигарет сата...

Үз авылларының һәрбер гөл-чәчкәсенә, Урыстау өстеннән алсуланып кояш чыкканына, Ялантау түбәсенә ямансулап, урак ай килеп кунганына сокланып яшәгән Асия менә аракы сата...

«Ак калфагым төшердем кулдан...»

* * *

Адәм баласы бөтен нәрсәгә күнегә икән. Акчаларын румынныкына алыштырган Асия, ул лейларын долларга әйләндереп, сумкасы төбенә саллы гына төргәк Америка акчасын салып куйды. Аллага шөкер, бу хурлыклы, авыр, газаплы сәфәрдән котылам, ахрысы, дип сөенә-сөенә, Карпат таулары түбәсендәге иске генә кунакханәнең дүрт кешелек бүлмәсендәге иске ятагына кайтып ауды.

Йа Раббым! Инде ничә көн буе базарда сату итә ул. Уналты шешә аракысын талаша-талаша алып бетерделәр. Ә аның башка сатар тауары юк. Әнә, кызының кечерәйгән кием-салымын да сатып җибәрде. Эше беткәч, үзе белән килгән якташларына булышты.

Мондагы хәерчелеккә хәйраннар калырлык, билләһи. Поезд тәрәзәсеннән кешеләрнең кар өстеннән бата-чума көнбагышка охшаган, нindидер үсемлекне урак белән урып йөргәннәрен күреп, исе-акылы киткән иде Асиянең. Ник бу Хода бәндәләре уңышны көз көне җыймый икән? Кар ерып, урак урган кешеләрне аның гомерендә дә күргәне юк иде әле.

Гаҗәбенә ни диярсең, валлаһи. Юл буйлап поезд тәрәзәсеннән шаклар катып карап барды Асия. Хәерчелек. Кыйшаеп беткән йортлар, каралты-кура. Авылындагы кебек төзек, җыйнак, аклы-каралы төсләргә буялган капкалар да юк. Әллә ниткән котсыз җимерек авыллар!

Шулай инде, урак өстен кышкы салкыннарга калдырган халыктан нәрсә көтмәк кирәк? Боларда «язның бер көне ел туйдыра» дигән мәкаль юкмы икәнни соң? Яисә Карпат таулары башындагы базарга Советлар Союзының Татарстан мәмләкәтеннән килгән, уңган-булган, инде сату эшендә үзләре дә тегермән ташыдай чарланып, чатнап торган татар хатыннарыннан тауар алырга килгән румын хатыннарының кием-салымына кара син! Әстәгъфирулла! Хет кеше янына чыкканда, адәм рәтлерәк киенеп булмыймы икәнни соң? Ни дисәң дә, безнең кызлар чибәр. Алар кап-кара йөзле, әллә ниткән зур борынлы румын хатыннарыннан кара каргалар арасындагы ак күгәрченнәр кебек аерылып тора! Ә халкыбызның сөйләм теле җаннарга сары май булып ята. Бигрәк тә чит илләргә чыксаң!

Румыннарның телләре дә ничектер тупас төсле, шартлап тора, сыгылмалы түгел. Әйе, нәкъ шулай, чит илләргә баргач кына үз илеңнең, үз халкыңның кадерен беләсең икән. Әгәр читтә татар телендә сөйләшүчеләрне очратсаң, ул сиңа якын туганың кебек була икән! Ә инде берәрсе татарча җырлап та җибәрсә, җаннарың тәмам айкала инде. Моң канатлары сине әллә кайларга, үзең дә күрмәгән, белмәгән, аңламаган кыйтгаларга алып китә. Юк, ул үз иленнән беркая да китмәячәк. Аланнарын, инде туган җиренә әйләнгән Казанны ничекләр ташлап китеп булсын! Асия күп күрде инде чит илләрдә җәннәттә яшәүчеләрне.

Моннан унике еллар элек аңа Германиядә бер оныгы белән хастаханәдә ятарга туры килде. Ун көнгә дип килгәннәр иде. Өч көн эчендә диагноз куеп чыгарып та җибәрделәр. Нинди зур акчалар түләп килгәннәр иде, югыйсә. Ашау-эчү такыр. Авылда әниләр мич төбенә салып пешерә торган түгәрәк күмәчне кара слайсер белән буеннан-буена кисәләр дә, өстенә кәгазьдән аз гына калынрак дуңгыз колбасасы, аз гына сыр куеп, тәмәке кебек төрелгән шикәр комы (биш грамм чамасы булыр инде ул) һәм бер пешерерлек чәй бирәләр – шуның белән вәссәлам. Дөрес, оныкка йогырт та куйганнар иде. Дәү әнисенә йогырт та ашатмаска булганнар.

Асия, намаз иясе, алманнарның телен белми. Сугыш турында фильмнар караганда, фашистларның «Швайн» дип акырганнарын ишетеп, бу сүзнең дуңгызларга кагылышлы икәне исендә калган иде калуын. Бик кыйммәтле ризык керткән кебек, зур поднос күтәреп кергән, кап-кара тәнле, зур кара күзле, күзенең агы нигәдер кызарыбрак торган, ап-ак тешләре нигәдер берсе өстенә берсе өелебрәк үскән хатынга ул:

– Бу швайнмы, мин мөселман, швайн ашамыйм, – дип әйтәсе итте.

– Йа, йа, ферштейн, – дип, кара хатын Асиянең ипиен алып чыгып китте. Озакламый шул ук зур подноска колбасасыз гына, алманнарча әйтсәң, коры ипи салып, аның алдындагы җыелмалы өстәлгә китереп куйды. Әле зур эш эшләгән кебек елмайды да Казан каласында гел тәмле ризыклар гына ашап үскән оных та:

– Дәү әни, Германиядә гел шулай ашап торалармы икән? Минем инде эчем авырта башлады, – диде.

– Улым, аз гына сабыр ит, – дип юатырга кереште Асия оныгын. – Бу сиңа Казан каласы түгел. Якын-тирәдә генә кибете дә юк, булса да, мин аларның телләрен белмим. Үзем дә инде кәгазь калынлыгы колбасаны кире биреп чыгардым. Әгәр ашарыңа берни булмаса, ач үлем куркынычы янаса, дуңгыз ашарга да ярый, ди бит.

Ул үзе ничек тә түзәр иде, ә бала? Ләкин Асиягә бүтән колбаса кертеп тормадылар.

Ярый әле, икенче көнне хастаханәдән чыгарырга булдылар. Баланың куркыныч бер чире дә юк иде. Казан каласында да хәл итәлә торган мәсьәлә дип, бер миллион акчаны кесәләренә салып куйдылар да елмаеп озатып калдылар.

Кайтып китәргә аларның әле тагын җиде көне бар иде. Шуңа күрә, форсаттан файдаланып, Швейцариягә сәяхәт кылырга булдылар. Бу илдәге гүзәллеккә, яшеллеккә, шарлавыкларга исең китмәле. Дүрт көн буе Швейцария шәһәрләрен, музейларын карап, хозурланып, бу гаҗәеп ил

турында сөйләгәннәренә таң калып, хушланып, алар кабат Герман иленә кайтырга җыенды. Барысы да яхшы, күңелләре күтәренке иде. Тик... Әлеге дә баягы ашау мәсьәләсе генә бимазалап тора. Һаман шул сыр, колбаса, ипи, чәй...

Бервакыт Асия түзмәде, рус телле экскурсоводтан:

– Әйтегез әле, сездә гел дуңгыз колбасасы белән ипи генә ашап торалармы әллә? – дип сорады.

– Германиядә шул инде: ризыклар бутербродларга, колбасага көйләнгән, – диде бу. – Шуңа бездә халыкның күбесе ашказанында гөмбә авыруы белән изалана.

– Алай икән, – диде Асия, – болай тукланып торсагыз, ашказаннарыгызда гөмбә генә түгел, имән агачы үсәр әле.

Швейцария Германия белән чиктәш. Асиянең бераз булкасы һәм бер шешә төбендә суы бар иде. Алла боерса, тиздән кайтып җитсәк, сөтләп, кайнар чәй эчәрбез, дип өметләнде ул.

– Улым, аз гына түз, хәзер Даниэлла апаңнарга кайткач, калган аш булса да ашарбыз, – дип, оныгын да юатты.

Даниэлла – биш еллар элек Казаннан Германиягә күчеп киткән, алманга кияүгә чыккан татар хатыны, Асиянең дусты. Шулай хыялланып кайтып килгәндә, телефон шалтырады:

– Асенька, кайткач, сез чәй эчеп торасызмы, әллә тамагыгыз тукмы?– димәсенме бу! Асия нишләсен:

– Даниэлла! Юк, юк, чәй эчмибез. Без Швейцариядә ашап-эчтек. Рәхмәт, – дияргә мәҗбүр булды инде.

Әй, гөнаһ шомлыгыннан яралган нәрсә. Немецка кияүгә чыккач, татарлыгын оныткан, күрәсең. Ире белән Казанга кайткач, Асия аларга нәрсә генә пешереп ашатмый бит. Бер алларына, биш артларына төшә. Ә ул чит илдән кайткан дустына: «Чәй эчәсеңме»?– дип тора. Аның янында оныгы бар бит әле! Үзе түзәр Асия, ул ачлыгын да, туклыгын да күргән кеше.

– Улым, менә бу ипине ашап куй да, Даниэлла апаңнарга кайткач, ашарга сорап торма! Сабыр булырга кирәк!

– Дәү әни, минем эчем авырта, ипиләрен ашап тормыйм. Су гына эчәм, – диде бала.

Иртәгәсен Даниэлланың кызы Карина, дөбер-дөбер килеп, алар йоклаган өченче катка менеп ашарга чакырды. Әмма өйдә бернинди ризык исе килми иде. Әллә ниткән зур, бай, ләкин җансыз йорт иде бу. Дания, үз исемен Даниэллага әйләндергән сыман, татар халкының гореф-гадәтләрен, кунакчыллыгын, аш-суга осталыгын да оныткан иде, ахрысы. Залларында ындыр табагы чаклы өстәл өстендә зур-зур тәлинкәләрдә слайсер белән киселгән ипи, дуңгыз колбасасы, сыр һәм каһвә аппараты тора.

– Сезгә кофены нинди чынаякка ясыйм? – дип сорады Даниэлла.

Асия уңайсызланып кына йөз граммлыга, диде. Аның күз алдына әнисенең җырлап утырган ак самавыры, түбәтәе өстендә хуш ис таратып, мәтрүшкәле такта чәй пешергән чәйнеге килеп басты.

Раббым бер Аллам! Нинди хәлләргә төштең син, Дания? Бәхет эзләп, шушы җирән немецның байлыгына кызыгып, үзебезнең гөл-чәчәкле

ил-җиребезне ташлап чыгып киттеңме? Без, татарлар, чәй эчмичә тора алмыйбыз. Ә монда, юлдан килгәч, душка кереп, юынып алыйм әле, дигәч, Даниэлла:

– Тукта, бу немец эшкә китсен инде, алайса кайнар су килгәнче, салкын суны җыеп, агач төбенә сибәсе була, – дигән иде.

– Ярар, алайса, юынып тормам, чәй эчеп алыйк, булмаса, – диде Асия.

Чәйләп алдылар, әмма ул табын яныннан торып китәргә дә өлгермәде, немец ире ипи сындырып алганнан калган кисәкне шакмаклап турап, тастымал өстенә җәеп куйды. Асия аптырап, кайчан илемә кайтып китәрмен, бу тормыштан, ясалма елмаюлардан кайчан башымны алып качармын дип, сәгатьләрен санап көтте.

«Туктале, Асия, Германиягә килгән-килгән, үзеңнең татар икәнлегеңне күрсәтеп, шул немецларны туйганчы ашатып кит әле», – дигән уй килде аның башына.

– Дания, – диде ул, – сезнең өегездә ит, он, суган, йомырка кебек әйберләр бармы?

– Бар, ләкин алар барысы да каткан!

– Ничек?

– Бездә шулай, кибеткә атнага бер тапкыр гына чыгабыз да бар ризыкны катырып куябыз.

– Ничек инде?

– Шулай, кирәк чакта эретеп ашыйбыз.

– Ипине дәме?

– Әйе, бөтен әйберне.

– Кызык! Син бит татар кызы. Ник токмачлы аш, өчпочмак, пәрәмәч, гөбәдия пешермисең?

– Юк. Без рестораннан китертәбез, барып ашыйбыз.

– Дания, менә сиңа биш евро акча. Син миңа кибеттән тавык, катырмаган суган, ит, кишер, йомырка һәм башка төрле ризыклар алып кайт әле.

– Нәрсәгә ул сиңа?

– Соңыннан белерсең. Йорт токмачы гына салып, аш пешермәкче булам.

– Азапланма, Асия, минем ирем дә, кызым Карина да аш ашамый. Бик зур компания башлыгы ул минем ирем.

– Ашамаса ашамас, мин пешерим әле. Оныгымның да үзебезнең ризыкларны ашыйсы килә.

Бер сәгатьтән Дания төянеп кайтып та җитте.

И кинәнде Асия. Көне буе пешеренде. Даниянең ире, кызы кайтканчы, тавык шулпасына йомырканың сарысыннан гына басып, җеп кебек итеп киселгән токмач салып, ул шулпа өстенә күтәрелеп менгән, бәрәңге белән тавык ите өстенә атланмайда кыздырылган суган белән кишер сибелгән, өчпочмак хуш исләр таратып, мичтә пешеп утыра, өйгә бәрәкәтле хуш ис таралган иде.

Башта укудан Карина кайтып керде. Ишектән узуга әнисенә:

– Зеер, зеер, гуд, – диде бу.

Аңлады Асия, тәмле исне бала да сизә.

– Нәрсә дип әйтә ул Карина?

«Өйдә әллә нинди сәер ис килә», –ди.

Ире дә кайткач, аптырап:

«Даниэлла, нишләптер бездә бик уютно стало», – дигән икән.

Табын янына утырышкач, Асия үзе затлы тәлинкәләргә аш бүлеп, башта Майк алдына куйды. Аннары – калганнарга. Даниянең аш яратмый торган ире, бер кашык ашны кабып куюга, күз карашын Асиягә төбәде. Җирән кашлары әллә ничек кенә сәер итеп сикереп куйды.

– Гуд, гуд... – Һәм аның көмеш кашыгы авызы белән тәлинкә арасында шундый тиз йөри башлады. Бушаган тәлинкәсен кабат Асиягә сузып, нидер әйтте.

– Нәрсә ди ул, Дания?

– Кабатларга куша.

– Алай икән...

Ул арада оныкның тәлинкәсе төбендәге зәңгәр кыңгыраулар да күренә башлаган иде инде.

– Улым, анда аш бетә инде, башка сорама. Өчпочмак ашарсың.

Онык, кашыгын тәлинкә кырыена куеп, тыныч кына мичтән өчпочмак чыкканны көтеп тынып калды.

Менә Асия хуш ис таратып торган кайнар өчпочмакларны, зур тәлинкәләргә тезеп, өстәл уртасына утыртып куйды. Майк башта бер өчпочмакны уртлап куйды, аннан соң икенчесенә, өченчесенә үрелде. Шаккатты Асия. Адәм баласы гомере буена ризык күрмәгән, диярсең.

Ә икенче көнне ул ун йомыркага токмач басты. Котлет кыздырды. Гөбәдиясе мичтә кызарып пеште. Пәрәмәче, кыстыбые тагын... Кыскасы, рәхәтләнде немецлар татар халык ашларын ашап.

Икенче көнне Асия белән оныгы туган илгә кайтып китәргә җыенды. Иртәнге ашны ашарга утыргач, Майк хатынына нидер әйтте.

– Асия, беләсеңме, Майк сиңа Германиядә эш тәкъдим итә, – диде Дания.

– Нинди эш икән ул, дустым?

– Ул сиңа безнең өйдә ашчы булырга тәкъдим итә, эш хакын күп түлим. Мин нинди генә ресторанда ашамадым, нинди генә илдә булмадым, ләкин беркая да мондый тәмле ризыклар ашаганым юк иде, ди.

– Нинди хезмәт хакы түләмәкче була соң? – дип сорады Асия, шаярып.

– Мең ярым евро.

– Юк, мин үземнең хезмәтемне бик югары бәялим, Дания.

– Ә син Казанда күпме алып эшлисең соң?

– Күп, Дания. Мин Казанда бик күп алып эшлим. Акчаны аны бәрәкәтләп тотсаң, азы да җитә, бәрәкәтләп тотмасаң, күбе дә бетә. Чит илләрдә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул, дигән борынгылар. Миңа үзем хәтле алтын бирсәләр дә, беркая да чыгып китмим мин. Казанымны яратам, татарларны яратам, гаиләмне, туганнарымны шундый сагындым мин, Дания. Син ничекләр итеп түзәсеңдер, белмим.

Майк, эшкә чыгып китешли, Асиягә карап елмаеп хушлашты. Ә Дания моңсуланып, тәрәзәгә карап, тын гына елый иде. Күз яшьләре яңагы буйлап ага да ага.

Асия акрын гына килеп, дустының иңнәреннән кочып алды. Рәхәтләнеп елаштылар.

– Асия! – диде Дания, күз яшьләрен сөртеп. – Син беләсеңме минем

ничек интегеп яшәгәнемне? Син мине бик бәхетле, дип уйлыйсыңдыр инде. Чөнки мин гел елмаям, көләм, шаярам. Ә минем күңелемдә күпме сагыш, сагыну. Җаным елый минем, Асия! Синең белән Казан урамнарында бергә йөргән чакларны сагынам. Урман-кырларны, Иделебезне, төбендә су аналары яшәгән Кабан күлебезне, туганнарны сагынам.

Асиянең күңелендә тагын җыр сүзләре кабатланды: «Туганнарның сагынган чагы...»

– Беләсеңме, дустым, мин Германиягә күчеп килгәч, ирем әйтте: «Даниэлла, син килгәч, мин утка, суга күбрәк түли башладым, – диде. Шаккаттым, юкка череп баеган бит бу немец. Акчасын кая куярга белми, ә утны, суны чутлап тора. Түзеп булмый аның саранлыгына. Бер көнне бәдрәфкә кереп китте бу. Мин бәдрәф ишеген шакыйм.

– Нәрсә булды? – ди.

– Тукта, тукта, Майк, эшеңне тәмамлагач, юдыртмый тор, мин дә кереп чыгыйм, икебезнекен дә бергә юдырырбыз! – дим.

– Син нәрсә, – ди, – акылдан яздыңмы әллә, бу бит не гигиенично.

– Мин әйтәм, зато экономично.

Шуннан уйга калды. Бик бәйләнми башлады. Безнең бит озак кына балабыз булмый торды. Каринаны бик соң таптым. Синең оныгың яшендә минем кызым. Бүген үк йөгерә-йөгерә, Казаныма кайтып китәр идем. Ләкин ул миңа кызымны бирмәячәк. Үзе дә шулай ди. Менә шулай, алтын читлек эчендә бер тиенгә моң-зар булып яшәп яткан көнем. Кызыма унсигез яшь тулгач, бәлки, кайтып китәрмен әле, Асия. Мин көнләшәм синнән, дускаем. Ак көнләшү белән көнләшәм. Син үз илебездә рәхәтләнеп, ана телеңдә сөйләшәсең, ни теләсәң, шуны ашыйсың, эшлисең, ә мин өч катлы зиннәтле йортта алтын читлектәге кош сыман кагынам, очып китәргә зар-интизар булып ятам.

Асиянең дустын кызганудан йөрәге парә-парә килде. Ул, хушлашып Казанга, туган ягына очты.

Йа Раббым! Адәм баласынаниләр генә җитми икән соң? Илең сине укыткан, эшле иткән, заманында бушлай фатирын биргән, ә син үз илеңне ташлап, чит илләргә чыгып киткәнсең. Нәрсә җитми адәм балаларына? Океаннарда лайнер артыннан очкан, берәр юлчы үзенә ипи кисәге булса да ташламасмы дип очкан акчарлаклар кебек бит алар. Куба утравында «рәхәттә» яшәгән халыкны да күрде Асия. Андагы хәерчелекне күреп, исе китте. Ә бит бала чагында биредә яшәүчеләр шундый бәхетле, дип уйлый иде.

Куба – любовь моя,
Ветров зари багровый...

Кирәкми океаннары да, зәңгәр төннәре дә үзләренә булсын. Асиягә үзенең Казаны, татарлары, туганнары кирәк. Кипарислар түгел, Тереклек елгасына су эчәргә иелгән елак таллар кирәк аңа! Нәфисә Васыйлова җырлый иде:

Үз илемдә ямьле миңа
Бәрәңге бакчасы да...

Инде күрде Асия дөньяның төрле кыйтгаларына таралып, дуслары, таныш-белешләре зар-интизар булып, илләрен төшләрендә күреп, туганнарын, әти-әниләрен сагынып яшәп ята икән...

Менә шундый уйлар белән кайтты Асия Казанына, Татарстан дигән җәннәтенә.

Инде үзенең «челнок» хезмәтенә килгәндә, моннан соң беркайчан да бу хатыннарга, өркәчле дөя хезмәтен үтәүче асыл затларга иярмәм, дип, үз-үзенә антлар иткән иде Асия. Юк, алай булмый икән шул! Син үзең теләгәнчә генә яши алмыйсың икән. Аннан соң яшь чагында ачлы-туклы яшәгән тормышың да аякларың йөреп торганда, башың эшләгәндә тырыш син, мал тап, дип кытыклап тора иде.

Әйе, тырышты Асия, йорт җиһазларын Польшадан ташыса, Польшага электр тауарлары, киҗе-мамык тукымадан тегелгән урын-җир, тагын әллә ниләр алып барды. Үзен спекулянтлыкта гаепләүчеләргә дә аның җавабы әзер иде:

– Сез ник үзегез бу хезмәтне башкармыйсыз соң, ә кешедән гаеп эзлисез. Барыгыз, һәркемгә юл ачык бит. Сез дә «челнок»чылар хәленә төшеп, өстегезгә кеше күтәрә алмаслык йөк төяп, таможня хезмәткәрләреннән таланып, кимсетелеп, чит илләргә чыгып китеп карагыз. Без, «челнок»чылар, карлы-бозлы көннәрдә, йә адәм түзә алмаслык эсселәрдә сату иткәндә, сез ирләрегез кочагында изрәп йоклап ятасыз, рәхәт чигәсез. Шуңа күрә безне, тырыш хатыннарны тикшермәгез инде сез, озын тырнаклы, нечкә билле матур киенгән сылу ханымнар, нәзакәтле туташлар.

Асия кат-кат йөрде бу катмарлы юлда. Җыелган Америка долларларын өч литрлы банкага дыңгычлый-дыңгычлый тутырды да әти-әнисе нигезендәге кечкенә генә алмагач төбенә күмде. Шул вакыт алмагач сыек, яшь тавыш белән Асиягә дәште:

– Асия, ник күмәсең син акчаларыңны минем тамырларым янына? – диде.

– Алмагачкай, син минем хәзинәмне саклаучым бул, ярыймы, – дип җаваплады Асия. – Бу өч литрлы пыяла банка – минем банк. Ә син – аның саклаучысы. Син исән-имин булып, җил-давылларга каршы торырлык булып үс кенә. Мин дә синең кебек үз хыялларыма таба сынмый-сыгылмый, дәһшәтле дулкыннарга каршы йөзгән кораб кебек йөзим.

Алмагач иртәнге җилдә яшь яфракларын лепердәтеп алды да тынып калды. Асия дә, агач төбен тигезләп, коедан алып, мичкәгә җылынырга салынган суын алмагач төбенә сипте.

– Сау бул, алмагачкаем, мин Казаныма кайтып китәм, ә син нигеземне, мөлкәтемне саклап, бәрәкәтле, уңдырышлы туфракта кояшның якты, җылы нурларында коенып, күккә күтәрел, минем канатлы хыялларым кебек, – дип пышылдады ул.

Еллар узды. Инде алмагач та үсте. Сорты яхшы булды, күрәсең, язларын шау чәчәккә күмелеп, кияү куенына керергә әзерләнгән кәләш кебек, Асияләр бакчасына хуш ис таратып, соңыннан ап-ак таҗларын тирә-юньгә сипте. Ә артыннан нәни генә, кечкенә генә алма бөреләренә урын калдырып коелды ул ап-ак чәчкә таҗлары...

Ул елны яз яңгырлы килде. Асия туганнары белән әнисенең өен юарга

кайтты. Өйдә кеше яшәмәсә дә, майның кояшлы бер көнендә өй юу аларның гадәтенә кергән иде.

Шундый да якты яз иртәсе иде. Әле кояш Урыстау өстеннән күтәрелеп кенә килә. Томанлы, димәк, көн матур булырга охшаган. Әнисенең йорттагы ястык-түшәкләрен, дивардагы келәмнәрен, идәндәге паласларын кагып, тузаннан арындырырга мөмкин булачак. Яңгыр гына яумасын да, көне генә ару торсын.

Асия, алмагач янына килеп, инде кәүсәләре калынаеп, яргаланып торган алмагачка сүз катты:

– Исәнме, саумы, алмагачкаем! Инде син дә зур булып үстең. Минем шәхси банкымны сакладыңмы? Миңа әйбәт хезмәт иттеңме? – дип сорады.

Алмагач бу юлы нәни яфракларын лепердәтеп кенә түгел, иртән искән җилдә шаулап җавап бирде:

– Асия, мин үз вазифамны син кушканча яхшы башкардым, – диде ул. – Мин дә картаеп барам бит инде, ә син үзеңнең хәзинәңне барлап, тикшереп торырга тиеш идең ләбаса! Их, сине, ваемсызны!

Асия банканы агачның кайсы ягына күмгәнен дә оныткан иде инде. Чамалап казый торгач, тапты тагын. Хәзинәне тартып чыгаргач, йөрәге күкрәк читлегеннән сикереп чыгардай булып тибә башлады. Өч литрлы банка эчендәге долларлар су эчендә ята иде. Асиянең ничә еллар буена черәшә-черәшә балаларын, ирен ташлап, чүлдә йөк ташыган өркәчле дөя кебек интегүләре инде ничә еллар буе су эчендә череп яткан лабаса.

Асия, күзләренә яшь төялеп, алмагач төбенә килеп утырды. Алмагач кабат телгә килде:

– Син үзеңнең нинди ялгышлык эшләгәнеңне аңладыңмы инде? – диде. – Минем сиңа шалтыратып әйтергә телефоным юк лабаса. Ә син, ваемсызланып, хәзинәңне миңа тапшырдың да, дистә еллар буена ачып та карамадың.

Әйе шул, бу турыда уйланылмаган, дөнья куган да, дөнья куган Асия.

Ул банкага җыелган суны шыбырдатып, алмагач төбенә агызды. Ничә ел су эчендә ятты икән бу долларлар? Америка акчалары? Америкада бу долларларны бер шәхси компания бастыра, дип ишеткәне бар аның. Күпме кирәк, шуның кадәр сугып ята, ди. Ә бит Асиянең акчасы күпме тир, күпме күз яше түгеп, күпме хәсрәт чигеп табылган иде. Һәм үзенең ваемсызлыгы аркасында чүпкә әйләнеп, череп харап булган.

– Менә шулай, ваемсызлык яхшылыкка илтми, Асия, аң бул, – дип озатып калды аны алмагач.

Асиянең әнисе аерым-аерым гәҗит битенә йомырка төргәндә әйтә иде:

– Кызым, тартмага гына салма, бер-бер хәл була калса, йомыркаларның барысы да ватылып бетәр. Бүлеп-бүлеп тутыр йомыркаларыңны.

Асия соңга калып аңлады: йомыркаларны, чыннан да, бер тартмага тутырырга ярамаган икән.

* * *

Асия сеңелләре белән бик тырышып өйләрен юып чыгарды. Юан нарат бүрәнәләрдән салынган йорт, буялмаган идән, түшәм... Инде мичләрен дә акшарлап алганнан соң, мичтән хуш исләр аңкытып пешеп утырган ит бәлешен чыгарып, түгәрәк өстәл уртасына куйдылар.

Өйдә шундый да рәхәт иде. Сафлык, чисталык, агач исе – балачак исе, туган нигез исе. Өстәл түрендә ак яулыклы әниләре балкып утыра.

– Балалар, ник азапланып, ел саен юасыз сез өйне? Кыш буе тормыйбыз, мичкә якмыйбыз. Болай да чиста бит инде, – дип, кызларын йомшак кына битәрләп алган кебек итте ул. – Шулай да яз көне өй югач, рәхәт инде. Сулышлар иркенәеп китә. Рәхмәт сезгә, балалар, нигезне карап торганыгыз өчен рәхмәт. Мине шулай олылап, тәрбияләп торганыгыз өчен рәхмәт. Үзегезне дә олыгайган көнегездә балаларыгыз шулай хөрмәт итеп яшәсен.

– Әй, әни, безнең бурычыбыз шул бит инде – ата-ананы тәрбияләү. Безнең гамәлләребезне үз балаларыбыз күзәтеп тора лабаса. Без, әни, гомеребез буена ни генә эшләсәк тә, күпме генә тырышсак та, сиңа бурычыбызны түләп бетерә алмаячакбыз! – диде урамнан келәм күтәреп кергән абыйлары.

Өй тулы бала-чага, уллары, кызлары, кияү, киленнәре! Бәхетле ана балаларының өй җыештырганын күзәтә. Күзләре генә түгел, йөзендәге еллар салган вак-вак җыерчыклары да елмая сыман. Матур итеп, ак әбиләрчә картайды әниләре.

Асия эш белән матавыкланып, банка эчендә харап булган хәзинәсе турында бераз онытыбрак торган иде. Әйдә, ярар, баш ярылып, күз чыкмаган ич бабасы әйтмешли.

«Таптым, дип сөенмә, югалттым, дип көенмә, кызым, – дияр иде ул. Сабырлык кирәк. Аллаһ сабырларны һәм юмартларны ярата. Җәннәткә иң элек юмартлар керер икән».

Асиянең бала чагында булган хәлләр әле бүгенгедәй хәтерендә. Бервакыт Фәүзия апаларының ике сарыгын урлап алып чыгып киткәннәр иде. Фәүзия – Габделхәй картның кызы. Ул елап әтисе янына килеп кергән. Әтисе сораган:

– Нәрсә булды, кызым?

– Әти, бүген төнлә ике сарыгыбызны урлаганнар.

– Ярар! – дигән Габделхәй карт. – Берегез дә авырмыйсыз, барыгыз да исән-саудыр бит. Бар, шуңа күрә урлаганнар, булмаса, урламаслар иде.

– Әти, ничек инде син шулай җиңел генә карыйсың моңа?

– Кызым, ник алай бәргәләнәсең? Син кайгырып, саулыгыңны бетергәннән ни файда бар? Абзарыгызда сарыкларыгыз калгандыр лабаса.

– Әйе, әти, әле ун баш сарык малыбыз бар.

– Шулай булгач, урланган ике сарык өчен кирәкмәгәнгә кайгырып, елап утырма. Калган ун сарык бәтиләсә, егеремедән артык була бит ул.

Фәүзия апа әтисе яныннан тәмам тынычланып чыгып киткән.

Шундый авыр вакытларда үзенең акыллы киңәшләрен бирүче Габделхәй бабасы бар иде Асиянең. Бүген дә менә бала чагындагы шул хәлләр исенә төшеп, күңеле тынычланып калды. Ашап-эчеп алгач, барысы да үз машиналарына төялешеп китеп барды. Йорт азрак җилләгәч, тәрәзә пәрдәләрен, чаршау-кашагаларны, элენгеләрне элешергә, сеңлесе Раушания белән куна калды Асия.

Ул әлеге дә баягы хәзинәсен өстәлгә китереп утыртты да, су эчендә торып бүрткән Америка акчаларын банкадан бушата башлады. Әнисе намаз укып утыра иде. Намазын укып бетергәч, өстәл өстен тутырып яткан яшел акчаларны тотып карыйсы итте.

– Кызым, бу нәрсәләр акча дисәң акча түгел, әллә ниткән акай күзле ямьсез кеше башы төшкән кәгазьләр. Заём дисәң, аңа да охшамаган, – диде ул.

– Доллар бу, әни, Америка акчасы.

– Нишләп юеш соң алар, кызым? Аннары бигрәк күп, куркыныч.

– Әни, мин аны күп еллар элек Антоновка төбенә күмеп куйган идем. Полиэтилен капкачтан саркып кереп су тулган.

– Әстәгъфирулла тәүбә. Кайчан күмдең соң син аларны?

– Ун еллар элек, әни, күмдем дә казып карамадым, – дип, әнисен тынычландырырга ашыкты Асия. – Курыкма, әни, урлап алган акча түгел. Минем күп еллык хезмәтем нәтиҗәсе бу. Мин бит банкка акча салмадым, әни. Сезнең җыйган барлык акчаларыгыз янып, көлгә әйләнгәч, үз банкымны ачып, нигезебезгә, алмагач төбенә күмеп куйдым. Ул вакытта әле алмагач чыбык кына иде. Әти мәрхүм утырткан Антоновка. Алмагач та үсте, минем долларларым да үсте. Биш-алты меңгә сатып алган доллар бәясе үсеп, алтмыш меңгә җитте һәм череп юкка чыкты. Менә шундый хәлләр, әни. Бик азапланып тапкан, күпме тир түгеп җыйган мал бу. Минем ваемсызлыгым аркасында юкка чыккан мал.

– Ярар, кызым, кайгырма. Әнә, мичкә як, кибә-кибә янар шунда, – дип, Нурания карчык, кәлүшләрен элеп урамга чыгып китте. Исе дә китмәде кызының юкка чыккан хәзинәсенә.

Асия бер йөз долларны кулына алып, ертып карады. Юк, ертылмады. Америка президенты акаеп, Асиягә карап тора иде. Хатын идәнгә, караватларга җәймәләр җәеп, долларларны киптерергә таратты. Идән-сәке, өстәл-урындыклар ямь-яшел булып, әнисе әйтмешли, акай күзле, зур башлы ямьсез Америка президентлары белән тулды.

Шөкер, тиз кипте долларлар. Инде кеше-кара күргәнче, үтүкләп, санап банкаларга тутырып, тимер капкач белән ябып, төрле урыннарга күмеп куясы гына калды.

Йомыркаларны бер тартмага тутырмавың хәерле!..

*(Ахыры киләсе санда.)*



Оксана
Ильюп

# ҖАН ЯЛГАНЫР ТӨНГӘ...

## Илһам корабы

Ахшам үткән күптән. Уникедән
Төн янтайган яңа таңга таба.
Тулган айга багам, каләм алам.
Бу көнгә дә, димәк, салам тамга.

Төн – авышкан кораб. Таңга карап
Хозурлана. Мин – өлеше, имеш.
Аның белән бергә җан терелтәм,
Күккә ашам, тәнем җирдә килеш.

Йолдызларны күзлим, сүзләр эзлим.
Алар – илһамият чыганагым:
Җәеп тамырларын яфрак ярыр,
Куак-куак уйлар шытар тагын;

Үрчер ботаклары, уйга сарып.
Төн җегәре ярсыр минем канда.
Җанда сүзләр җәйрәр. Ә мин шигъри
Явым булып түгелермен таңга.

Шәфәкъ бездән тиздән әҗер сорар –
Бу бит аның чиксез биләмәсе.
Фәсәхәтле төндә минем көн дә
Шул ук юлдан килә әйләнәсе.

Таң әҗере әзер – яңа шигырь.
Җимеш биргән илһам үсентесе.
Яңа туган көнгә кереп барыш.
Шәфәкъ яна, алсу дөньям төсле.

Җан ялганыр төнгә. Иртәгә дә
Корабыма кайтам әле кабат.
Янә каләм алам, илһам табам
Йолдыз тулы айлы күккә карап.

---

Оксана ИЛЬЮП (1984) – *шагыйрә, җырчы, музыкант. «Оча алам», «Үзгәрдең» шигырь җыентыкларының авторы. Чиләбедә яши.*

## Әнкәй мирасы

*Җырлый-җырлый әнкәй оек бәйли...*
Рәниф Шәрипов

**I**

Күзгә уелып калган бер хатирә:
Каңгылдашып оча торналар,
Җырлый-җырлый әнкәй йон эшкәртә.
Орчыгына җыры чорнала.
Моңын отам каеп йөрәгемә,
Булмасын дип мәңге җуясы.
Бу әнкәйнең миңа диеп биргән
Иң кадерле, иң зур мирасы.

**II**

Салкын кышның озын кичләрендә,
Күзлек киеп, әнкәй шәл бәйли.
Орчык кебек, мин – кеченә бәбкә,
Бөтереләм әнкәй тирәли.
Чәчен тарыйм, алкаларын карыйм
Һушым китеп якут ташына.
Әкият сорыйм: «Әнкәй, «Таңбатыр»ны
Укы әле миңа, башыннан».
Төш аралаш тоташ әкияткә
Чумып калган ул чак-сәгадәт.
Әкияттән сеңгән татар теле –
Әнкәемнән изге әманәт.

**III**

Чытыр-чытыр янган утын көе
Колагыма сала ишарә:
Иртә таңнан әнкәй мич өстендә
Тәмле «көләсә»ләр пешерә.
Тиздән «әпәй» салыр. Ә мин исә
Тормый ятам көтеп пешкәнен.
Самавыры әзер булгач назлап,
«Тор, кызым!» дип, үзе дәшкәнен.
Әпәй исе сеңгән йомшак куллар
Чәчләремнән сыйпый иркәләп.
Зур телемгә куе каймак ягып,
Чәй эчәбез аннан икәүләп.

**IV**

Мич өстендә әзерләнгән ашлар
Әнкәемнән изге хәзинә.
Еллар узган. Күзем ачмый ятам.
Уйлар куба, гүя зилзилә.
Хатирәләр – энҗе төймәләре,
Күңел түрләремә эленгән.
Туган телем тәме, аның яме –
Икмәк исе аша беленгән.

**V**

Өй түрендә әнкәй оек бәйли.
Йомгагыннан җырлар сүтелә.
Еллар аша җырлар ага. Моңы
Кайтавазлар булып ишетелә.
Татлы хатирәләр назлый җанны.
Күзем ачмый уйда чуалам.
Мин – кечкенә бәбкә, зур тормышка
Әнкәй җырларыннан юл алам.

## Балачагым

Мин нарасый.
Тузган чәчләремне назлап,
җылы ләйсән яңгыр ялый.
Печән өсте.
Зәвәл вакыт.
Әнкәй учак көйли.
Әткәй – чалгы яный.

Чыңын урлый кайтавазлар көче.
Кушылып кошлар сайрый,
җырлый урман.
Әй зәвыклы аһәң!
Чүмәләдән
ышыктарак әткәй куыш корган.

Ни рәхәте анда черем итү
йокыларны хыялларга төреп!
Янда гына нидер майтаручы
әткәй-әнкәй бар икәнен белеп.

Печән исе. Яланнарда – чәчкә.
Чәчләремә шушы исләр сеңгән.
Әнкәй өчен әткәй бүген янә
чәчкәләрнең иң матурын өзгән!

Кич кырында әткәй атны җигә.
Арбабызда – яңа чапкан үлән.
Басу кала артта. Басу түгел,
балачагым артта калган икән...

## Җирсү

Менә-менә кайтырмын күк иде
Туган якларыма чит җирдән.
Бар да мине көтә сыман һаман:
Әткәй, әнкәй, таллар һәм чирәм.

Сагындырды. Кайчак сыгылдырды
Тормышымның шыксыз давылы.
Һәрчак булды күңел түрләремдә
Туып-үскән газиз авылым.

Менә-менә кайтам кебек иде
(Шулай уйлау куәт биргәндер).
Туган яклар – узган гомер икән,
Тәңгәллеген Аллаһ белгәндер.

Кайтмадым шул. Кайтыр юлларыма
Күз яшьләрем сыгылып тамарлар.
Чит җирләрдә җирсим. Тарта җанны
Туган нигез, тарта тамырлар.

***

Кайсыдыр бер дәвер чорыннан сакланган
Рәссамның таушалган пумала буявы.
Ул бакый әсәре эченә яшергән
хыяллар яктысын, өметле уйларны.
Иң мөһим сорауга иң төгәл аңлатма
буларак ул сызган бик серле сырларны:
вакытның нилеген, кешенең кемлеген
күрсәтеп, төсләргә күчергән инсанны.
Ул рәссам, күрәсең, даһилар сафыннан.
Ул – алдан күралган сынаулар тоҗымын:
Кешеләр язмышын, үсешен, үлешен,
Киләсе буынга калдырган үз ымын;

Аңлаган гүяки мәхлуклар телләрен,
Кошларның җырларын, җилләрнең көйләрен;
Бәхетнең барлыгын, дөньяның асылын,
Яшәеш күчәрен, хыялның кәүсәрен...

Кайсыдыр бер дәвер очында яшәгән
Бер гали рәссамның без – даһи әсәре.

## Төньяк балкышы

Төнге күккә алсу тамган, тәвәккәлләп.
Тәрәзәдә тузган көнем кайтавазы
күңелемә хатирәләр куя язып.
Сузыла-сузыла узып бара озын шәүлә.
Көн шундый зу-ур! Дөнья төсле. Мин – кечкенә.
Һаман сабый сыман әле. Һаман бала.
Учларымны ал син җылы учларыңа –
мин ышанам мәхәббәтнең саф көченә.
Пакьлә мине. Сакла мине. Якла мине.
Күрсәт миңа барлык ямен бу Җиһанның.
Янар төнге асманнарда төсе таңның,
алсу капкан йолдызларга буяп Җирне.
Төшенерлек булса әгәр Күк серенә,
Бүгенем дә кичәгедә калмас иде.
Алып китә көнне сихри балкыш җиле,
Хатирәләр каеп күңел дәфтәремә.

## Кыш аша

Итәгемә җил чорнала.
Мин юыртам карлар ерып.
Әйди синең тарафларга
якты хатирәләр җыры.
Кыш ырымы кар бизәген
отып, чәчләремә үрә.
Белә өзелеп сагынуларың,
мине бизи шуңа күрә.
Синең ярда тоташ кояш,
синең ярда – диңгез шаулый.

Йөрәк көтә очрашуны,
күңел сусап, сине даулый.
Тасма-тасма юллар чигәм.
Синле җилләр сиңа җилә.
Кар чигендә көтәсең син –
шуны белү миңа җитә.
Алларымда таныш чалым.
Карлы буран калыр артта.
Сөю җыры, назым җыры
язым көтә синле якта.

## Югалту

*Бер үк көнне бакыйлыкка күчкән ике*
*даһи – Ирек абый Сабиров һәм*
*Разил абый Вәлиевнең рухына.*[*]

Гүя аңлап дөньяларның зарын
күз күрсенде – ул да иза чиккән:
Ерткаланган җилләр ярсуында
үзе теккән кызгылт-сары чикмән.
Җил тамаша кылды: бии-бии,
көйгә салды шыксыз каһкаһәсен.

Кыш әзерләр тиздән ап-ак кәфен,
укый-укый җиргә таныш әфсен.
Төксе калды шәһәр – ямен каһәр
фасыл гаме гүя гаип итте.
Күзнең тугры адымдашы булып
осталарның осталары китте.

[*] Ирек Сабиров – 20.11.2020, Разил Вәлиев – 20.11.2023.

Бәгырь итен телде калучылар.
Ни итәсең – Әҗәл эше тәҗел.
Көз – көз генә, ул кабатлар юлын,
ә киткәннәр – бакыйлыкта хәзер.
Тәмамланды дәвер.
Көнкүрештә, әйтерсең
көз – саундтрек,
йә декорация бу сәхнәдә.
Тик төшенеп булырмы соң икән
төп мәгънәгә фәкать бер мәртәбә?
Җир үзе дә бер тетрәнеп куя
мәңгелеккә алып даһиларын.
Ул да сыкрый, күреп кешелеккә
биниһая төшкән язмыш зарын.
Кучкән кайтмас. Тик аларсыз калган
көзләр кайтыр, тырнап үксез жанны.
Мәңгелекнең серен белеп, балкыр
күктә остазларның йолдызлары.

## Тәкъдир

I

Бу тормыш – иң күркәм режиссёр.
Бу язмыш – иң яхшы драматург.
Иң кызык әсәрләр – аныкы.
Сәхнәләр – зәвыклы вә матур.
Һәм аның кимәле – камиллек:
Ул уйлап чыгара киртәләр,
гашыйклар – сынаулар аркылы
бәхетнең үренә җитәләр.
Хыяллар хөрлеге – канатлы
Мәхәббәт турында искәртә.
Хыяллар булганда, сөюгә
юк ара, юк чикләр, юк киртә.

II

Ул безнең тарихка да күптән
сюжетның иплесен яздырган.
Без – рухи игезләр, имеш. Тик
Син башка йолдызлык ярыннан.
Аралар бик ерак. Кавышу
Чарасы да гаять чамалы.
Очрашкан сәгатьләр – минутлап,
Мизгелләп санала ни бары.
Ә безнең иңнәрдә канатлар,
Йөрәктә – мәхәббәт куәсе.
Без оча беләбез. Төшләрдә.
Һәм бик нык килгәндә күрәсе
Син җигәсең җилләр юргасын
Һәм очасың биек-биеккә!
Син җыясың миңа күкләрдән
Йолдызлар бәйләмен бүләккә.

III

Ә күзгә күзләрең бакканда
Һәм җаннар кушылган чагында,
мәхәббәт ярчыгы Галәмдә
Яралта бер хәят тагын да.
Өр-яңа илһамлы бер сюжет.
Өр-яңа бик матур бер әсәр.
Бу тормыш – иң яхшы драматург.
Бу язмыш – иң күркәм режиссёр.

## Тәүге баскыч

Иң серле чагымның бу – тәүге баскычы.
Киртәле, катмарлы күп юллар үтелгән.
Күп юллар. Сынаулар. Күп өмет юк булган.
Күптәннән бәгырем кителгән, үртәлгән.
Бу баскыч тәүгесе. Ә артта – киң дала.
Артымда еракта тузанда бер бала
исемә төшәлми – хәтерем җуелган.
Буынга сызыклар каелып куелган.
Һәм бүген мин явым – яңгырдан да елак.
Ә Синдә канатлар – керт мине астына,
башка беркайчан да җил-мазар тимәсен.
(Үз көбәм юкарган ахрысы чак кына).
Чүәгем ашалган, киемнәр таушалган.
Чәчләргә чал көмеш бизәкләр ясалган.
Ә Синең кулыңда калебем ачкычы.
Иң серле чагымның бу – тәүге баскычы.



Гөлүсә
Батталова

# ЧЫРА*

ХИКӘЯ

*Айнур*

Бүген безгә яңа укытучы керде. Алия исемле. Күрүгә үк яратмадым. Чыра! Нәкъ үзе инде. Ябык. Нәзектер билләре. Йөзе дә каен чырасы төсле ап-ак. Әллә авыру инде? Коңгырт чәчләре дә туп-туры булып иңнәренә салынып төшкән. Кыяфәте ошамадымы, юк инде ул. Дәрес башлануга миңа күзләрен тутырып, озак итеп карап торды. Беләм мин аның нәрсәгә караганын. Җаббаров фәлән, Җаббаров төгән дип, минем хакта башка укытучылар сөйләп тә өлгергән инде аңа, иманым камил. Бу башкисәрдән ничек котылырга дип уйлап карап торды ул. Шулай, бөтенесенең дә миннән котыласы килә... Артык кашык бит мин.

Яңа укытучыга эчемнән генә Чыра дип кушамат тактым. Дәресләрдә бер хәреф тә язмадым, җавап бирмәдем. Әнә, ботаниклар җавап бирсен, алар почётта. Миңа укымасам да ярый. Барыбер миннән кеше чыкмаячак. Өченчекөн завуч шулай диде. Бер-ике сорау биреп карады да Чыра башка кагыкмады. Кул пычратып ятмыйм, дигәндер инде. Бигайбә. Мин бит түбән сортлы. Күралмыйм барысын да.

*Алия апа*

Класс бусагасыннан атлауга күрдем мин аларны. Кап-кара шомырт күзләр. Алардагы әрнү... Юк, мин күрәзәче дә, рентген аппараты да түгел. Бер карауда кешенең тормыш юлын сөйләп бирә алмыйм. Әмма бу баланың

* *«Сез иң гүзәл кеше икәнсез!» конкурсында икенче урын алган хикәя.*

Гөлүсә БАТТАЛОВА (1982) – *шагыйрә; «Бер йотым бәхет», «Кесә тулы – давыл!» исемле китаплар авторы. Әтнәдә яши.*

күзләренә карауга тәнем чымырдап китте. Сабыйларның ваемсыз карашы түгел бу. Яраларыннан кан саркыган караш. Минем әле олыларда да мондый төпсез күзләрне очратканым юк иде. Дәрес барышында берни язмады, сорауларыма җавап бирмәде. Мин дә артык басым ясамадым. Бу баланы аңларга, аның бу хәлгә төшү сәбәпләрен ачыкларга кирәк башта. Юкса, ул тагын да йомылачак, үз эченә кереп, җиде кат йозак артына бикләнсә, башка тартып чыгарып булмаячак...

Тәнәфестә укыту эшләре буенча директор урынбасары Сәярә Мөстәкыймовна янына ашыктым.

– Гафу итегез, бер укучым турында сорамакчы идем...

– Рәхим итегез...

– Айнур Җаббаров... Аның турында...

– Аның турында нәрсә әйтәсең? Анасы ташлап китте. Кече улын үзе белән алды. Монысын атасына калдырды. Ир-ат ялгызы бала үстереп ята торган заманмы? Читкә китте дә өйләнде. Малай карт әби өстендә хәзер. Денгә кертә торган бала түгел, явызның явызы. Документларын әзерли башларга кирәк, күптән махсус мәктәпкә күчерергә вакыт.

– Ничек?.. Сез нәрсә? Сәярә Мөстәкыймовна, ул баланың йөрәге болай да яралы, без аны шул бер әбисеннән дә аерып, интернатка җибәрикме?

– Безнең мәктәптә калып, сугышсын, кыйнашсын, урлашсынмы? Кем тәрәзә ваткан – Җаббаров, кем канга батканчы сугышкан – ул, кем укытучыны кешегә дә санамый – тагын шул! Тора-бара ул юньсез бала зуррак җинаятькә дә бармас дип вәгъдә бирә аласызмы? Бөтен дөньяга шуның аркасында фаш булыйкмы? Башыбыз суд юлыннан чыкмасынмы?

– Мин вәгъдә бирәм.

– Ни дисез?

– Айнур Җаббаровның тәртибе һәм укуы чирек ахырына тел-теш тидермәслек булачак. Мин вәгъдә бирәм.

– Хе... Андый вәгъдәләр белән җайлы гына селтәнмәгез. Без ул малайны туганнан бирле беләбез, сез бүген күрдегез.

– Аңа шанс бирергә кирәк.

– Шанс... Аңа язмыш тарафыннан шанс бирелмәгән. Карагыз аны, Җаббаров сезнең җаваплылыкта булачак. Алай-болай була икән, үз өстегезгә алачаксыз!

*Айнур*

Тәк. Булды бу. Чырадан Чыра ясадым. Кызык! Эч катып көләрлек. Мәктәптән кайтуга көн дә бер эш – бозау белән тавыклар өчен бәрәңгегә кушып, арпа пешерәм. Буржуй мичендә. Кем уйлап тапкандыр ул исемне. Мин үзем ул мичне паровозга охшатам. Ә нәрсә, морҗасыннан төтен чыга, үкереп яна, җитмәсә, дүрт көпчәге дә бар. Әнә шул мичкә утын пүләннәреннән чыра телеп, ут үрләтәм. Утынны түмәре белән тыгып куеп яндырырга тырышып караган да булды, барып чыкмады. Әби, эш

рәтен белмисең дип, арт сабакны укытты. Шуңа мин хәзер башта чыра теләм, аннан, әби күрмәгәндә, шулардан әллә нинди сыннар ясап уйныйм, соңыннан шуларны мичкә тутырам да ягып җибәрәм. Нервы чыкканда, агачны да ярсыбрак юнам, кул киселгәне дә бар. Ачу килә инде, нишләп килмәсен. Минем классташлар сәпиттә чаба, телефонда уйный. Минем берсе дә юк. Әбидән сорап караган булды, кайдан җиткерим, улым, дип кочаклап елады да, башка сорамаска үз-үземә сүз бирдем. Юкса, тагын елар. Еласа, чирләр. Чирләсә, үләр. Ул үлсә, мине интернатка илтеп ябарлар. Ә минем анда барасым килми...

Агачны да Чырага охшатып булыр икән! Куллары, аяклары, салам чәчләре – тач шул!.. Ә?.. Кәкрегә бөкре! Капкадан Чыра үзе килеп кереп ята түгелме? Ахырзаман алдыннан кемне искә алсаң, шул килеп чыга дип сөйли әби. Бүген ахырзаманмы әллә? Мыскыл итеп көләргә килгәндер инде. Урамда туп тибәсе урынга, мичкә ягып, тавыкларга бәрәңге пешерәм бит...

*Алия апа*

Мин килеп кергәндә, ишегалдындагы кечкенә тимер мич янына чүгәләп, нидер эшли иде ул. Капка келәсе тавышына күтәрелеп карады да каушап китте – тиз-тиз генә өс-башларын каккалады. Кашларын җыерды, карашын аяк очларына төшерде. Сак булырга, артык тиз якынаерга тырышып, болай да дөньядан яшеренгән йөрәкнең капкаларына бәрелмәскә тырышырга кирәк.

– Сәлам, Айнур.

– Исәнмесез.

– Яңа укытучыгыз буларак, һәрберегезнең өйләренә йөреп чыгарга булдым, менә сезгә дә кердем.

Ул дәшмәде. Аяк очы белән җирдә яткан агач кисәкләрен күчергәләде. Ныклабрак карасам, ниндидер сыннар. Төгәл уелган йөз сызыклары, рәссам каләме сызып үткән кебек нәфис кул-аяклар...

– Боларны син ясадыңмы, Айнур? Алып карарга мөмкинме?

– Карагыз.

– Гаҗәеп. Син боларны шушы бер пычак белән уйдыңмы? Оста сынчы ясаган диярсең.

Ул янә дәшмәде. Курткасының туза башлаган җиң очларын яшерергә теләгәндәй, йодрыкларын төйнәде.

– Исәнмесез, кеше бар икән... – Лапас ягыннан олы гына яшьтәге бер апа чыкты. Аның әбисе иде ул.

– Исәнмесез. Мин – Айнурның укытучысы. Алия исемле булам. Яңа килдем.

– Әйе, әйткәннәр иде шул яңа укытучы киләчәк дип. Менә без шулай Айнур улым белән икәү генә яшәп ятабыз инде. Мин Фәүзия әби булам. Әйдәгез, ишегалдында гына тормыйк, өйгә керик.

Өйгә үк үтәргә ниятләмәгән булсам да, каршы килмәдем. Миңа Айнурдан башка гына әбисе белән сөйләшергә кирәк иде. Нәкъ мин уйлаганча, ул миче янында кайнашып калды, без өйгә кердек. Үтә тыйнак, әмма бик

пөхтә җыештырылган авыл йорты. Түр якта тәрәзә буенда өстәл. Китап-дәфтәрләр тезеп куелган – Айнурныкылар.

– Укытучылар диюгә, йөрәк жу итеп китә инде минем. Тагын ниләр майтарган икән дип. Орышып та карыйм, кыйнап та. Юк, игә китереп булмый. Эшкә карусыз ул үзе. Бөтен хуҗалык икебез өстендә. Тик менә уку юк инде. Җеннәре котыра. Иптәшләре белән бик аралашмас булып килә. Кимсенәдер дә. Бик тырышсам да, аталы-аналы балалар киенгән кебек киендерә дә, кыландыра да алмыйм. Моның да ата-анасы бар да... кирәге генә юк...

Бер тында күңеленә җыелганны бушатты да елап җибәрде әби кеше. Үземнең дә өстәлдә өелеп торган аның китап-дәфтәрләрен кочаклап, тәгәри-тәгәри үксисем килде. Көчкә тыелдым.

– Айнур белән өстәмә шөгыльләнергә уйлыйм, сез каршы килмәсәгез.

– Нинди каршы килү ди, булмаганны! Акылга сай балалар интернатына гына җибәрмәсәләр ярар иде дип куркып йөрим. Моңа кадәрге укытучылары гел шуны әйтә иде...

Тизрәк саубуллашып чыгып китү ягын карадым. Бәгырем сулык-сулык килде, җаным өзгәләнде. Мин чыкканда, ул һаман да әле мич тирәсендә нидер юнып утыра иде. Акрын гына атлап килеп, аның янәшәсенә чүгәләдем. Кулыма ул ясаган сыннарның берсен алдым.

– Айнур, бигрәк матур монысы. Миңа бүләк ит әле.

– Алыгыз. Барыбер мичкә ягам.

– Рәхмәт! Мин аны саклармын. Сау булып тор, иртәгә мәктәптә күрешербез.

– Сау булыгыз.

*Айнур*

Чыра, кичә мин ясаган сынны мәктәпкә алып килеп, өстәленә утыртып куйды. Үзенең сыны икәнен белә микән ул? Дәресләрдә миңа бер сорау да бирмәде. Бераз языштырган булып утырдым. Аның сынын ясаганга оялдыммы шунда, шайтаным белсен. Әмма Чыраны барыбер күрәлмим! Алар барысы да бертөрле! Элеккесе миннән ничек котылырга белмәде. Бусы да шул булачак. Кыңгырау! Өйгә!

– Сау булыгыз, укучылар! Айнур, азга гына тоткарлана алмассыңмы? Миңа синең ярдәмең кирәк иде.

Минем? Ярдәмем? Чырагамы? Завуч фикере буенча дөньяның соңгы адәм актыгының кемгәдер ярдәме тияргә мөмкинме? Класс бушады. Икәү калдык – Чыра да мин.

– Класс бүлмәсенә гөлләр алып килгән идем. Гөл чүлмәкләре сыярдай кыршауларым да бар. Шуларны китап киштәсенең ян-ягына беркетергә кирәк. Синең кулың эш рәте белә, булыша алмассыңмы, Айнур?

– Яхшы.

Өйдә бөтен ир-ат эшен башкарып өйрәнгәнгәме, Чыраның йомышын унбиш минутта хәл иттем. Класс почмагының бер ягы кәкрәйгән икән, бер очтан аны да турайтып кактым. Ямьсез булып тормасын.

– Бик зур рәхмәт, Айнур. Син миңа шундый булыштың. Минем термоста үлән чәем бар. Әйдә, кайтып киткәнче, чәй эчеп алыйк.

Алгы парталарның берсенә укытучы термос чокыры белән хуш исле пар бөркелгән чәй китереп куйды. Үзенә башка чокырга салды. Контейнерыннан таба печеньесы чыгарды. Мондый печеньены минем гомеремдә бер генә – класстагы туган көн кичәсендә генә ашаганым бар иде. Классташ Гүзәлнең әнисе пешереп җибәргән иде аны. Чәйдән баш тартам дип торганда, тәме әле дә тел очында йөргән печеньелар уемны үзгәртте дә куйды. Мин аларны тагын кайчан авыз итә алам әле? Әби аш пешереп ашата алса да, рәхмәт. Сөйләшми генә икәү чәй эчтек. Печеньелары шундый, шундый тәмле иде! Чәе шундый хуш исле! Андый чәйне беркайчан эчкәнем юк иде!

– Рәхмәт, Алия апа...

*Алия апа*

– «Без бергә» фестиваленең гамәли-декоратив сәнгать номинациясендә катнашырдай укучыларыгыз бармы? – Сәярә Мөстәкыймовнаның соравы хөкем карары укыгандай дәһшәтле яңгырады, завуч булуына карамастан, әнә шулай тәрбия эшләренә кагылышлы мәсьәләләрне дә һәрчак контрольдә тотарга ярата иде ул.

– Бар. Айнур бик оста итеп агач эшләнмәләр ясый.

– Җаббаров! Тагын Җаббаров. Сезнең класста башка укучы беткәнме әллә? Сәйләннән беләзек, йөзекләр ясый хәзер бөтен кыз бала. Шуларны тәкъдим итегез.

– Бөтен кеше дә эшли белгән эш белән бәйгедә уңышка ирешеп булмас дип уйлыйм. Агачны кисеп ясау – сирәк шөгыль, аннан соң хәзер экологик материаллардан ясалган эшләнмәләр трендта.

– Трендта. Яхшы. Бөтен мәктәпне хурлыкка калдыра күрмәгез Җаббаровың белән.

– Калдырмабыз. Мин аңа ышанам.

Сыйныф бүлмәсенә килеп кергәндә, шау-шудан тәрәзәләр зыңлап тора иде. Айнур үз партасы артында дәреслеккә иелеп, нидер укый. Гөлләр әләргә ярдәм иткән көннән соң ул үзе белгән-аңлаганча дәресләрен хәзерләп килә башлады. Әлбәттә, язуы – хаталы, мәсьәләләренең чишелеше күп очракта дөрес түгел, әмма боз кузгалган иде инде. Минем өчен иң кадерлесе шул иде.

– Укучылар, тынычландык! Биш минутлык тәнәфестә дә калдырып китәрлек түгел сезне! Тагын нинди шау-шу куптаргансыз! Мин сезгә бер яңалык алып кердем.

– Апа, нинди яңалык?

– Әйтегез инде тизрәк!

– «Без бергә» дип аталган балалар фестивалендә катнашу мөмкинлеге бар. Агачны кисеп ясаган эшләнмәсе белән классташыгыз Айнурга үз көчен сынап карарга тәкъдим итәм. Сез ризамы?

– Айнур?

– Җаббаровмы?

– Ул нәрсә ясый белә соң?

– Менә минем кулымда – ул ясаган сын. Әйтегез әле, кемгә охшаган?

– Апа, бу бит сез!

– Сезгә охшаган бу, апа!

– Әйе, дөрес. Айнур агачтан минем сынымны ясап бүләк итте.

– Моны ул ясадымы?

– Чынмы?

Үзенең исеме яңгырауга аның күзләре әсәрләнде. Ниләр бар иде соң аларда: ышанып җитмәүме, ышанырга куркумы? Мин сынны укучыларга күрсәткәч, классташлары аңа борылды. Ул оялып, башын иде.

– Айнур, фестивальдә катнашырга ризамы син? Каршы булмассыңмы?

– Юк... Каршы түгел...

...Дәресләрдән соң ул үзе минем яныма килде.

– Алия апа, нинди агачтан, нәрсә ясарга соң?

– Нәрсә ясарга икәнен син үзең уйла. Күңелең ни тели. Минем тормыш иптәшем – Илсур абыең – балта остасы. Ул кисеп ясар өчен юкә, усак яисә зирек агачы әйбәт, ди. Бүген дәресләрдән соң эшләрең беткәч, безгә кил, ул сиңа агач материалын да, кирәк булса, махсус коралларын да бирер. Безнең өйне беләсеңме?

– Беләм. Рәхмәт. Килермен...

Илсур Айнур турында минем сөйләүдән белә иде инде. Аларның өендә булган көнне өйгә кайтып җитүгә түгелдем мин. Ике баласының берсен үз иткән, икенчесен язмыш кочагына ташлап киткән анага да, ярты ятимне дөм ятим иткән атага да, әйләнә-тирәдәге таш бәгырьле адәмнәргә дә үпкә-рәнҗешем әнә шулай күз яшьләре булып чыкты. Мине – олы кешене шушы хәлгә җиткергән вакыйгалар сабыйны нишләтергә тиеш? Беркемгә, бернигә ышанычы калмаган түгелме аның? Дөньяга өмете өзелмәгәнме? Коткарып калып булырмы аны? Үзебезнең явызлыктан йолып алып булырмы? Бер елап бушангач, иремә Айнур ясаган сынны күрсәттем. Бәрәңге турый торган пычак белән утын агачыннан юнып ясалган сынны күреп, ул шаккатты. «Миндәге кораллар аның кулына керсә, ниләр коеп куяр иде икән бу малай? – диде ул. – Җай табып, дәш әле безгә. Миндә агач эшкәртер өчен бөтен кирәк-ярак бар. Ясасын рәхәтләнеп. Мондый сәләт меңгә бер кешегә генә бирелә ул!»

Килмәс дигән шигем бар иде. Әмма ул килде. Илсур аны үз дусты кебек каршы алды. Остаханәсенә алып керде. Төрле агачта коралларның төрлечә эшләвен аңлатты. Айнур да җанланып китте. Сораулар биреп, эш коралларын сынап карады. Мин аларның үзара уртак тел табуына инанып, берәр тәмле ризык белән сыйларга вәгъдә биреп, өйгә кереп киттем... Алар шактый озак юандылар остаханәдә. Ул арада мин бер-ике таба өчпочмак пешереп өлгердем, чәй кайнаттым. Күптәнге дуслар кебек көлешә-көлешә сөйләшеп кергәннәрен күрүгә, эчемә җылы йөгерде.

– Вәт егет бу! Кулында эш коралы уйнап кына тора. Болай булса, әллә нинди шедевр туачак әле фестивалегезгә!

– Әле ясый да башламаган бит... Алия апа, Илсур абый миңа эшләнмәне үзенең остаханәсендә ясарга рөхсәт бирде! Сезгә килеп йөрсәм ярармы икән?

– Әлбәттә, Айнур, әмма бер шарт белән. Остаханәдән соң чәй эчәргә кергәч, дәресләреңне дә карарбыз. Ризамы?

Ул шундый самими итеп елмаеп җибәрде.

– Яхшы, риза...

*Айнур*

Агачтан ясалган эшем мәктәп күләмендә беренче урын алды. Директор грамота бирде. Моңа кадәр линейкага мине начар укуым һәм тәртибем өчен чыгаралар иде. Макталырга чыкканда – икенче икән. Фестивальнең район турында җиңгәч, мәдәният йорты сәхнәсендә бүләкләделәр. Диплом белән конверт бирделәр. Каушадым. Кулларым, тезләрем калтырады. Сәхнәдән төшүгә Алия апа кочагына атылдым. Үксеп елап җибәрдем. Башкалар ни әйтер дип тә уйламадым. Әни киткәннән бирле беренче елавым иде бу... Өйгә кайтып, әби белән конвертны ачып карсак, өч мең акча! Әби: «Урлап кайттың мәллә, малай актыгы!» – дип ярмакчы иде дә, конвертның тышына «1 урын – Айнур Җаббаров» дигән язуны күргәч, «Бу көннәрне дә күрермен икән...» – дип еларга тотынды. Үз акчаң, үзеңчә тот дигәч, җыеп куйдым, сәпит алырмын. Җитмәсә, алдагы уңышларыма мая булыр. Әби шулай диде.

Республика турына безне Казанга алып бардылар. Әйтсәң, кеше көләр, шәһәргә беренче баруым! Әллә ниткән зур бинага алып керделәр. Татарстанның төрле районнарыннан килгән балаларның эшләрен тезеп куйдылар. Минеке дә шулар арасында! Әллә ничек шунда. Горурлык та. Оялта да. Менә берзаман зур-зур абый-апалардан торган жюри безнең эшләрне карап, бәяли башладылар. Минем тагын куллар калтырый. Алия апа шыпырт кына колагыма пышылдады: «Борчылма, Айнур. Мин янәшәңдә». Шундый рәхәт булып китте...

Жюри минем эшем янына килүгә, сәер хәлләр башланды. Аһ-ваһ киләләр, фотога төшерәләр, үзләре фотога төшәләр. Ни булганын аңлап бетермим.

– Кем ясады бу шедеврны?

– Мин. Айнур Җаббаров.

– Ничәнче класста укыйсың?

– Өченчедә.

– Бала болай ясый алмас. Әтиең булышкандыр.

– Минем әти юк. (Мине бар дип белмәгән әтине бар дия алмыйм бит инде!) Әни дә юк. (Ул минем өчен чыннан да юк инде...)

Ярый әле Алия апа ярдәмгә килде.

– Айнур әлеге эшен үз куллары белән ясады. Идеясе дә аныкы...

Көтелмәгән авыр тынлыкны үзем бозарга батырчылык иттем. Югыйсә жюри бу эшем белән ни әйтергә теләгәнемне аңламыйча борылып китәр кебек тоелды. Шуннан курыктым.

– ...Бу эшем Ышаныч дип атала. Мин аны укытучым Алия апага

багышладым. Алда торган малай – мин үзем. Алга атларга микән, юк микән дип куркып торам. Ә артымда – укытучым. Ул миңа ышана. Куллары белән мине киләчәккә этәрә. Салкын, усал җилләр аның да, минем дә чәчләрне тузгыткан, әмма безнең күзләр балкый – без алдагы бәхетле көннәргә карап торабыз...

Бер тында сөйләп бетердем дә (белмим, сүзләрен кайдан таптым?), Алия апага күтәрелеп карадым. Аның күзләреннән нәфис битләре буйлап күз яшьләре тәгәри иде...

**P.S.**

*Айнур*

Ул көнне дә җиңдем мин. Медальләре, дипломнары, бүләкләре күп булды ул җиңүнең. Шатлыгы да. Горурлыгы да. Әмма алары – тансык кәнфитнең тышкы ялтыравык кәгазе кебек кенә... Минем җиңүем бүтән иде. Аны без Алия апа белән икәү генә белдек. Икәү генә аңладык. Казаннан мин башка малай булып кайттым инде. Чирек ахырында унбер фәннең икесеннән генә өчле чыкты. Калганнары – дүрт! Алдагы чиректә бөтенесе яхшы билге булырга тиеш – максат шундый. Уку болай кызык әйбер икән ул. Башта ник белмәгәнмен шуны? Мине сүккән завучы, директоры да мактаган булалар. Җебеп төшмим. Алия апаның ышанычын акларга кирәк – иң мөһиме шул. Теге чакта безнең класска килеп кермәгән булса, мин нишләп беткән булыр идем икән? Мине интернатка озаткан булырлар идеме? Болай да бар дөньясын күрәлмәгән кешегә ул интернат учакка май сипкән төсле булыр иде. Минем күзләремдәге әрнүне ничек күреп алган икән ул? Беркемгә ачылмас булып бикләнгән яралы йөрәгемә ничек ачкыч тапкан? Үз анам белән үз атамнан күрмәгән җылылыкны ничек биргән? Мин бит аңа Чыра дип кушамат таккан идем. Оят инде хәзер. Хәер, бер уйласаң, нәкъ чыра төсле инде ул. Калын-калын утын түмәрләре үрләтеп җибәрә алмаган учакны кабызучы, иң кирәк җылыны бирүче чыра – укытучым Алия апа бит инде!



*Гөлара Шәрипова исеме күпләргә таныштыр да: әлеге дә баягы интернеттан – социаль челтәрләрдән. Анда ул шигырьләрен дә куя, табигать күренешләрен дә, тормышын яктырткан кадерле мизгелләрне дә, иҗатындагы төрле яңалыклар – конкурсларда җиңү яулаган җырларын, сәхнәләрдә Раил Садриев кебек билгеле затлар укып, зур яңгыраш алган шигырьләрен һ.б. күрсәтеп бара. Интернеттан ерак кеше булганга, мин бу шагыйрәбезнең үзен күргәч, шигырьләрен үзем укыгач кына танышып, беренче тәэсирләр моңарчы мине алдамады, дип ышанганга Гөлара ханымның шигырьләрен журналыбызда тәкъдим итәргә булдым. Чын табигать баласы, садә, ихлас хисләр, кичерешләр иясе дип таптым мин аны. Тәэсир итү көче – гадилектә, бернинди дә йогынтылар, иярүләр булмыйча, табигый, тансык, нәфис җан иясе тавышы булуында!*

*Гөлара ханым – дүрт баһадирдай ул үстергән, инде оныкларын да сөйгән бәхетле ханым, чын татар гаиләсе учагын механизатор ире белән горур балкытучы чын милләт әнкәсе! Яшәве – Казанбаш авылында, әйе, әйе, нәкъ менә кайчандыр Гариф Ахунов укыган, яшьлегендә Мөхәммәт Мәһдиев укытучы булып эшләгән, соңыннан «Фронтовиклар» романында тасвирланган атаклы Арча төбәгеннән ул. Тукай исеме белән горурланган бу яклардан соңгы арада шагыйрьләр сирәк күренә иде. Бәлки, Гөлараның «Кул арты» җиңел булып, зур әдипләр янәшәсендә шагыйрьләр авазы да телләргә кереп яңгырар? Ә бу – без көткән тансык сөенеч хәбәре булыр шикелле.*

**Рәдиф ГАТАШ,**
*Татарстанның халык шагыйре,*
*«Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы.*

Гөлара
Шәрипова

# МОГҖИЗАЛАР БАРГА ЫШАНАМ...

## Кемгә нәрсә җитми?!

Авыруга – саулык, ярлыларга – байлык,
Вәсвәсәле җанга тынгы җитми.
Эшле кеше вакыт җиткерә алмый,
Ә эшсезнең өйдә көне үтми.

Кемнәргәдер җанын бушатырга
Кеше җитми үзен аңлый торган.
Берәүләрнең күңелендә бушлык,
Икенчеләр мөлдерәпләр тулган...

Сикәлтәле юллар үткәннәр бар,
Бар эзләүче тигез җирдән түмгәк.
Кул, аяксыз көчле рухлылар бар,
Бар шундыйлар – сау-сәламәт имгәк.

Кеше төрле, уй-фикерләр төрле,
Аерыла холык, эш-гамәлләр.
«Безнең хәлләр – шөкер!» дияр идем,
Сездә, дуслар, сездә ничек хәлләр?

Шөкер итәр өчен сәбәп бармы?
Сәбәпләр күп, уйлый китсәң төптән...
Имин тормыш, ак бәхетләр юрап,
Яңа елның кары ява күктән!

## Могҗизалар көтәм

Тылсым барга һаман ышанам мин,
Могҗизалар барга ышанам.
Айга карап, серләремне сөйлим,
Ай да уйчан, миңа охшаган...

Төнге күктән энҗеләрне күзлим,
Теләк телим йолдыз атылса.
Бәхетемнән күккә күтәреләм,
Чәчләремне назлап, таң туса...

Ак карлардан аклык алам җанга,
Төшкән чакта кайнар учыма...
Керфегемә кунган энҗеләрне
Тиңлимен мин бәхет кошына.

Хыялый мин, хыял канатында
Очам күктә, төшәм җиремә.
«Могҗизалар чынга ашар» дигән
Өмет яши күңел түремдә!

## Кояшлы буран

Үзем дә сизмәстән кинәттән
Юлыктым кояшлы буранга.
Җилбәзәк бер шаян болыттан
Уйнаклап кар ява урамда.

Кояшның нурлары үчекләп,
Җил-кызның шәл чугын аралый.
Шаярып йөгерә ак буран,
Беркемгә, бернигә карамый.

Кояшлы буранның тәэсире
Күңелгә моң булып уралды.
Хисләргә бирелеп, ун үттем
Мамыктай кар яткан урамны.

Битләрем алмадай кызарды,
Кочканда шук буран билемнән.
Гаҗәеп гүзәллек, әйтерсең
Табигать ак нурдан чигелгән!

* * *

Мин елга да түгел, карурман да,
Күкләрне дә кочмый канатым.
Җир кызы мин, әллә инде шуңа,
Тезләремне бик еш канаттым.

Күз яшемне йотып елмайдым да,
Шатлыгымнан үксеп еладым.
Таптым да мин, кайчак югалттым да,
Җан ачысын булды тойганым.

Елга булып минем күңел ташый,
Урман булып шаулый уйларым.
Хыялларым зәңгәр күкне коча,
Ирек даулый йөрәк җырларым.

Елга, урман, иксез-чиксез күкне
Сыйдыра ала олы йөрәгем.
Беркайчан да, хәтта эчемнән дә:
Нигә тудым җиргә, димәдем.

Сынатмыймын, нигә сиздерергә,
Кемгә кирәк минем яшьләрем?!
Гомеремнең һәрбер яңа көнен
Мин яшисем килеп яшәдем.

Шулай яшим, чөнки язмыш миңа
Гомерләрнең биргән ярсуын.
Бу халәтем, күңелемне айкап
Ярларымнан чыгып ташуым...

## Соңгы хат

Югалтмыйча һаман саклыйм сиңа язган соңгы хатны.
Уртасында чәчкә ята, хәтерләтеп үсмер чакны.
Ак юлдагы хисләрнең дә кайнарлыгы сулган кебек.
Күңел кылын тибрәтсә дә, бәгырьләрне үтми телеп.

Чын күңелдән язган хатым, ни сәбәптер китми калган...
Соңгы хат бу – соңгы өмет, татлы сагыш җаннан тамган.
Кипкән нәфис чәчкә кебек сулган инде сөю гөле.
Вакыт-вакыт айкый бары күңелләрне хәтер җиле.
Кайчакларда шушы хатны үткәннәргә юллар булам.
Уйлыйм аннан, хыялый җан, яшьлек гөлең күптән сулган.
Терелтергә тырышма да, үз чәчкәңә сип син сулар.
Хат эчендә калсын бары яшьлек белән бәйле уйлар.
Ядкарь итеп саклыйм хатны, сагынганда укыйм ачып.
Ә эчендә саф, самими яшьлек гөлем калган качып.

## Яшьлек

Яшьлектә яшьнәдек, ә хәзер шул чорны балалар кичерә.
Яшьлек тә, иң тәүге хисләр дә бер генә бирелә кешегә.
Күңелдә саклана мәңгегә, бер якты хис булып, җуелмый.
Нигә соң яшьлегең үзеңә шулай тиз үтәр күк тоелмый?
Артыңа борылып карасаң, күзләрең яшьләнә сагыштан.
Кем генә, әйтегез, кем генә шул тәүге яр белән кавышкан?
Сагыну-сагышлы, ялгышлы, хыялга уралган мәхәббәт.
Күңелдә калган тик хатирә, калмаган әрнүләр, җәрәхәт...
Яшьлегем, хыялый яшьлегем! Сагынып исемә төшәсең.
Сизми дә калганмын, ни ара баламның йөзенә күчкәнсең...

## Яраттым! Яратам!

Елмаеп уяндым, син язган җылы хат
Җаныма елышкан сагышны тараткан.
Ачылган күңелдә тулышкан бөреләр,
Иреннәр пышылдый: «Яраттым! Яратам!»

Яшәрдем сизелеп, әйтерсең иңемдә
Җип-җиңел, мамыктай фәрештә канаты.
Йөрәкнең үз эше, буйсынмый акылга,
Кабатлый ашкынып: «Ярата! Яратты!»

Хат юлы – тиң икән киек каз юлына,
Күңелем күгендә сызылып эз калган.
Сүзләрең иң назлы, иң матур көй булып
Кылларын мең чиртеп җаныма уралган.

Йөрәккә туктаусыз тамчыдай сүз тама:
«Яратты! Ярата!», «Яраттым! Яратам!»
Елмаеп уяндым, син язган җылы хат
Җаныма елышкан сагышны тараткан...

## Минем өчен һаман баласың...

Үсеп җиттең, улым, тик шулай да,
Минем өчен һаман бала син.
Кайчагында һич тә уйламастан
Сагыш утларына саласың...

Сабый чактагыдай гел яклыйсым,
Аралыйсым килә бәлаләрдән.
Юк шул инде, улың буйга җиткәч,
Көтү кала карап тәрәзәдән.

Гаепләмә, балам, гел борчылып
Синең өчен янып-көйгәнемә.
Ачуланган чакларым да була,
Якын алма, зинһар, йөрәгеңә.

Егет булып җитешсәң дә күптән,
Минем өчен һаман баласың.
Кайчагыңда һич тә уйламастан,
Сагыш утларына саласың...

## Кар җылысы

Наратларга сарган мамык карлар
Әнкәй шәле сыман тоелды.
Назланыйм дип сыенуым булды,
Ак энҗеләр өскә коелды.

Чәчләремә кунды, керфегемә,
Күз сирпергә тордым кыймыйча.
Хис ташкыны ургып тышка чыкты,
Күңел киңлегемә сыймыйча.

Ылыслардан килгән татлы искә
Кар җылысы килеп кушылды.
Энҗе ява, ә мин ләззәтләнеп,
Җыя алмый торам һушымны!..

«Әнкәй шәле» диеп сарылдым да
Бер илаһи назга тарыдым.
Моңа кадәр ничек белмәгәнмен
Кайнарлыгын җиһан карының.

## Киез итек

Ап-ак карга басып атлап киләм,
Аягымда кара киез итек.
Бала чакта балтырының читен
Әни җаным куя иде китеп.

Тамга сала, буталмасын диеп,
Бер калыптан чөнки барысы.
Каралары затлы, йомшак та бит,
Каты була иде сарысы.

Көне буе чана-чаңгы шуып
Юкарадыр иде асты да.
Сумалалы җептән энә саплап
Әткәй салыр иде астына.

Киез итек киеп үстек лә без,
Иң мөһиме – аяк туңмады.
Кич җиттеме – итек, бияләйләр
Сырып ала иде торбаны.

Итек балтырымның читләренә
Салынмаган бүген бер тамга.
Балачагым хатирәсе булып,
Эзем кала бары ак карда...

## Балачагым кышы

Ак кар яуды җиргә. Энҗе карлар
Аклыгыннан күзләр чагыла!
Ак кышларым, алып кайтыгызчы,
Бер кайтыйкчы балачагыма!

Киез итек киеп, шәлем бәйләп,
Бияләйләр киеп кулларга,
Бик телимен туган авылымның
Урамнарын кат-кат урарга.

Җыелсыннар иде дус-ишләрем,
Таулар шуар идек бергәләп.
Кар бабаен өеп куяр идек,
Тәгәрәтеп зуп-зур түгәрәк.

Кар атышып бер уйныйсым килә,
Күшеккәнче, куллар туңганчы.
Өйгә кайткач әни шаян кызын
Бер орышыр иде туйганчы!

Орышса да, тәмле чәен ясар,
Ашын бүләр иде әнкәем.
«Мич каршына барып җылын!» диеп,
Утын өстәр мичкә әткәем...

Ак кышларым, алып кайтыгызчы,
Бер кайтыйкчы балачагыма!
Энҗе карлар җиргә яуган чакта
Гамьсез чорны күңел сагына.



*Азалия Сабитова 2007 елның 3 сентябрендә Арча районының Ашытбаш авылында туган. Г.Тукай исемендәге Ашытбаш урта мәктәбенең X сыйныфында укый. Республика күләмендә татар әдәбияты олимпиадаларында катнашып, җиңүләр яулый. Район үзәгендә эшләүче «Нур» балалар телерадиостудиясенә йөри. Мәкаләләре «Мәдәни Җомга», «Шәһри Казан» газеталарында, хикәяләре «Ялкын» журналында басыла. «Көмеш Кыңгырау» газетасы белән даими хезмәттәшлек итә. Бөтенроссия «Илһам» бәйгесенең «Проза» номинациясендә җиңүче; Ш.Галиев исемендәге премия лауреаты. 2023 елда «Глаголица» Халыкара әдәби бәйгесенең «Проза» номинациясендә Гран-при иясе.*

Азалия
Сабитова

# 1:1

хикәя

2004 ел.

Кояш җылысына мәдхия укучы юкәләр җил юнәлешенә тартыла. Әйтерсең сыгылмалыкларын тикшереп карыйсылары килә. Ничек кенә тырышмасыннар, ахыр чиктә, барысы да ерактагы урман полосасы белән бәйлелек тапмый изалана да якындагы авыл зиратына сарыла. Җил искән якта эшчән халык иртәнге өмәгә җыелган. Ахирәт дөньяда яшәүче әрвахларның ризалыгына ирешмәктән, зур хезмәт куя. Араларында хатын-кызлар күренми, бары ирләр, табигатьләре таләп иткәнчә, бөтен авыр эшне башкара.

Игътибарымны зират кырындагы яшел чардуган янында арлы-бирле йөрүче нәни кызчык белән Хәнәфи карт җәлеп итте. Оныкның моннан ике ел элек гүр иясе булган әбисе янына тәүге тапкыр килүе. Яше кечерәк булганлыктан, әти-әнисе дә, бабасы да алып барырга кыймыйлар иде үзен. Кешенең башка тормышы барлыгы турында сүз кузгатыр өчен, җитлеккән яшьтә түгел Миләүшә. Калын тимер белән уратып алган «рәшәткә» дә аңа берни хакында сөйләми. Кыз баланың әле сабый чагы. Ул бары ирен читләре колакларына җитәрлек итеп елмайсын, тәгәрәр хәлгә килеп көлсен, сулмасын, сүнмәсен, гомеренең тәмен белеп калсын. Һәм бары шатлана-шатлана матур миләүшә чәчәкләрен җыеп йөрсен.

– Кызым, бу чәчкәләр сиңа бик ошады, ахрысы!

– Әйе, мин аларны синнән күбрәк тә җыйдым, бабай! Бергә-ноль була, – дип сөйләнде шат сабый, яңа «ярыш уены»н башлап.

– Ярый, сиңа җиңелсәм була, кызым! Бергә-ноль булсын! – диде Хәнәфи карт. – Чәчәкләр синең исемеңә дә, үзеңә дә нык килешеп тора әле. Миләүшәләр гомер агышы, тирә-яктагы, кешеләр күңелендәге чисталык, сафлык хакында сөйли. Без дә менә әлеге җирлекне матурладык, әрвахларыбыз яткан җиргә яңа сулыш өрдек. Алар иркенләп, шатланып ятар хәзер.

Нәни кыз бабасының җылы карашын тоеп, үзенең уңышына, уңганлыгына, чәчәкләр белән уртак тел табуына янә сөенде.

Миләүшәләрнең җәһәт кенә кибүен, сәбәпсез гомерләре өзелүен теләмәде ул. Аның бит әле бу матурлыкны әнкәсенә күрсәтәсе бар. Баланың уенда ана белән кыз чәчәкләрне җылымса су салынган кечкенә банкага утыртып куя, киләсе көн тугач та, алар әле һаман назлап, күзләрне иркәли… Бу матур фикер кызны шунда ук канатландырды.

2016 ел.

Август киче. Салкынча. Шаян җил фатир тәрәзләрен шакый. Кешеләр алдында рәхимсез булып кыланырга телидер инде...

Сөйкемле Миләүшә бу кичтә җилне тиргәде. Иртәгә бик мөһим көн. Хәлиткеч иртә алдыннан һава торышының болай кырыслануы шомландыра иде.

Унберенчене бетерде бит инде кыз. Чыгарылыш сыйныф укучысы булып, мәктәп сәхнәсендә елмаеп басып торганда, тормышның беренче этабы тәмамлануын аңлады. Алда бары зур тормыш көтә. Нинди булыр ул? Миләүшә күз алдына китергән кебек авыр, әмма матур хатирәләргә бай булырмы? Әллә, Рәдиф абыйсы сөйләгәнчә, яшьлек михнәтен мулдан өеп, «яхшысы»на саранланырмы?

Вакыт, әйтерсең, чапкын экспресс. Ул әлеге вазифасына шундый җайлашкан, сәгать телләрен дә уздыра хәтта. Уку йортына керер өчен документлар белән йөрер чак җитте. Бу җәйдә кыз урта гомуми белем алуны раслаучы диплом алды. Аның хыялы – Казан федераль университетының химия факультетына укырга керү. Аннан яхшы укытучы чыгар иде, мөгаен…

Килеп туган яңа проблеманың сәбәбе федераль университетка керә алмауга бәйле түгел иде. Икенче көнне кыз, кирәкле документларын барлап, калага юл тотты. Барып җиткәч хәбәр салырмын дип, шәһәргә якын торган бистәгә тыныч күңел белән такси чакыртты.

Көн, кичәге кебек, борынын салындырмаган иде. Сары майдай кояш чыгып, иртәдән бар җиһанны нурга төрде. Әмма аның болай шатлана төшүе «яхшыга өметлән, Миләүшә!» дип кайтаваз салуы булмаган икән.

Калага җитәрәк бер борылышта кыз утырган автомобиль, каршы полосага чыгып, юл һәлакәтенә очрады. Икенче бер машина белән бәрелешеп, ике як та каты зыян күрде…

***

Хастаханә идәннәрен Гөлзифа апага бүген икенче тапкыр таптарга туры килде. Бу ике көн эчендә ул барлык санитарка, шәфкать туташлары белән якынаеп бетте. Үз кешесе кебек иркен аралаша, дөнья хәлләре белән бүлешә, алардан да ниндидер яңалык алырга җитешә. Моңарчы бер белмәгән кешеләр белән кинәт кенә якынаеп китеп сөйләшүләре сәбәпсез түгел иде. Кызы коточкыч юл һәлакәтенә очраганнан соң, ашаган ашы да аш түгел, йокысы да качты.

...Кичә Миләүшәне ашыгыч ярдәм машинасы белән иң якындагы 13 нче хастаханәгә алып киттеләр. Юл һәлакәтендә кызның бер аягы көчле җәрәхәт алган. Периферия тамырларының тез асты артериясенә зур зыян килү сәбәпле, ярты аягын ампутацияләделәр. Әлеге катгый фикергә килү өчен, пациентның үзеннән дә рөхсәт алынырга, яисә ул да бу мәгълүматтан хәбәрдар булырга тиеш иде. Үз аңына килә алмаган кешедән, билгеле, сорап булмый, моңа өстәп табиб әле оператив эш итәргә тиеш.

Вакытның кысанлыгы, Миләүшәнең хәле начар булуы ампутацияләү турындагы карарны Гөлзифага кабул итәргә мәҗбүр итте. Ул исә, кызын алда нинди сынаулар көтәсен күз алдына китереп, кыяр-кыймас кына эшне белгечкә тапшырды. Бу очрак авыр булганга күрә, аякның бары тик мөмкин булган өлешен калдырып, калганын кисәргә туры килде.

...Кыз хәзер «уяну палатасы»нда ята. Шуңа әнкәсе дә бәргәләнеп, үзен кая куярга белми өзгәләнеп йөри. Табибның: «Барысы да яхшы узды, уянуын гына көтәсе калды…» диюе җанга җылылык өргән иде. Наркоздан чыга алырмы, дип тә аның кадәр курыкмый ана. Үзенең сул аягындагы үзгәрешләрне күргәч, нишләр кыз? Еласа, юатыр өчен нинди сүзләр таба алыр әнисе? Алда көткән зур сынаулардан куркып калмасмы? «Бирешмә, кызым, бирешмә!» дип күпме кабатларга туры килер аңа?

Кыз уянды. Кул бармакларының бер фалангасы ап-ак юрган өстендә җиңелчә селкенеп, куе керфекләр салмак кына тибрәлеп куйдылар. Әйтерсең Миләүшә наркоздан айныган, ләкин яңа тормышка күз ачарга куркып ята иде. Бу аксиома, мөмкин дөреслеккә бик туры килеп бетми.

Булган үзгәрешләрне бәян итү максатыннан, табиб шул ук мизгелдә авыру кыз янына юнәлде. Пациентның уянуы да аны канәгатьләндерә алыр иде, әмма Миләүшәнең сулышы тигез, йөрәк тибеше яхшы булуына үз күзләре белән инанасы килде.

Ыгы-зыгы тынганнан соң, Гөлзифа апа белән улы Рәдифкә дә керергә рөхсәт иттеләр. Аларның җилкәләренә дә мөһим вазифа йөкләнгән иде: кызга күз-колак булып, ике сәгать йокларга ирек бирмәү. Ашау да катгый тыела. Аягы турындагы хәбәрне тагын да соңрак, йоклап хәл алганнан соң гына әйтергә куштылар. Юл һәлакәтенә очрап, аягына операция ясауларын әйтә алсалар – әлегә шул җиткән.

28 август

Олы вакыйгадан соң бер атна вакыт үтте. Хастаханәдә озак тотмыйча, кызны өенә озаттылар. «Ак бина» ишекләрен ябып чыгып китсәләр дә, бирегә алар табиб күрсәтмәләрен үтәп, еш килеп торалар. Протезга ия булып, реабилитолог белән эшли башлаганчы, күп кенә пунктларны үтисе барын онытмаска кирәк. Сул аякның «тимер дәвам»ына тәңгәл килүе, ялгана алуы мөһим. Шуңа күрә физиотерапевт күрсәткән компрессияле лимфалар системасын яхшырак эшләтү өчен, массаж, шәхси гигиенага җаваплы карарга кирәк. Өч-дүрт атнадан соң, барысы да яхшы гына барса, вакытлы протез ясатып булачак. Димәк, 14 сентябрь көнне хастаханәгә аеруча дулкынлану, сынганнан соң тәүге шатлану хисе белән килеп керәчәк Миләүшә.

– Кызым? Табиб шалтыратмагандыр бит? Эндәшеп караган идем, җавап бирмәдең…

Тынлыкны бозып, сүз башлады Гөлзифа әнисе.

– Юк, Рузия белән сөйләшкән идем. Ул үзе килмәгәч, күрешкән дә юк. Шалтыратып, хәлләремне сораган булды. Питерга архитектура университетына кергән икән. Уку вакыты башлангач, бик сирәк кайтырга туры килә, ди. Хәер, нишләсен инде ул монда, әтисе болай да башка шәһәрдә яшәде, чыгарылыш сыйныфта укыганда, мондагы әбисе вафат булды, әнисе исә Санкт-Петербургта көтә. Шундый мөмкинлек булганда... Дөрес эшләгән.

Классташы өчен ихлас шат кыз. Үзенең мондый хәлдә калуы гына гаделсезлек булып тоела. Уку йортына керер өчен чираттагы елны көтәргә кирәк. Миләүшә

авыр хәлдә ятканда, аның карьерасы түгел, хәзерге тормышы күпкә мөһим иде. КФУга укырга керү турындагы хыял сүнмәсен бары. Соң булса да, чыңга ашсын!

14 сентябрь.

Пәнҗешәмбе киче шатлыклы хәбәр китерде. Хастаханәдән шалтыратып, вакытлы протезның әзер булуын хәбәр иттеләр. Әлеге вакыйга җомга иртәсенең кызу үтүенә сәбәпче булды. Бәхетле булырга рөхсәт иттеләр түгелме? Һәрхәлдә, телефон трубкасыннан яңгыраган тавыш аңа тимер аякның әзер булуын гына җиткермәде бит!

Мизгел эчендә аяз күк йөзен кара өем-өем болытлар каплады. «Булдыра алырмынмы? Тырышып карап та, килеп чыкмаса?» дигән сорау ватык магнитофон кебек шактый битәрләде кызны.

– Мәскәүне дә бер көндә генә төземәгәннәр. Беләсеңме шуны? Син бит унсигез ел элек тә йөри алмый идең. Сабыйлар ничек тәүге тапкыр тәпи йөри башлый соң? Хак, аларда әле үзаң формалашып бетмәгән була. Өлкән кеше кебек фикерләсә, ун сабыйның бишесе, куркып калып, мүкәләп кенә йөрү юлын сайлар иде. Бәлки, чынлап та килеп чыкмас... – Бу сүзләрне әйтү Гөлзифа апага бигрәк тә кыен иде. – Тик анысын белү өчен дә беренче адым ясап карарга кирәк бит! Ярты юлга килеп җиткәч, барысын да ташлыйкмыни? Йөрәгең чыдармы?

Әйе. Ялгышырга хакы юк Миләүшәнең. Хакы юк! Ишетәсезме? Ул – кемнеңдер яшәү мәгънәсе... Яшәү мәгънәсе!

19 сентябрь.

Миләүшә шул ук көнне реабилитация үзәгенә язылды. Атнасына дүрт тапкыр табиб-реабилитолог белән махсус курслар үтә. Калган көннәрне җайлырак физик күнекмәләрне үзе башкара. Дәвалануга кереп китәр алдыннан, аякны сак кына кыймылдату да авырлык тудыра иде. Бер-ике көннән соң бераз ияләнде. Әмма протез аякка басу әле дә кыенрак. Гәүдәне төз тотуы – аеруча. Тез өсте дөрес формасын сакларга тиеш. Югыйсә бу вакытлы тимер аяк бит. «Тулаем рәткә керү чоры унбер, унике айдан соң гына башланачак», – ди табиб.

Кыз шөгыльләнгән залда аның кебек тырышып, тир түгүчеләр күп. Араларында тугач ук «гарип» статусын алучылар да, тормыш шартлары нәтиҗәсендә авыр хәлгә юлыкканнар да бар.

Җәрәхәт дәрәҗәсенә карап, һәрбер группаны берничә табиб җитәкли. Аерым авыр очракка эләккән пациентлар белән индивидуаль эшләү дә каралган. Миләүшә үзе дә күмәк залга кичә генә йөри башлады. Бергә дәвалануның файдасы юк түгел. «Үзеңнекеләр» белән танышып аралашу өчен яхшы мөмкинлек. Башкаларның авыр тарихын тыңлап тетрәнәсең, аларның ихтыяр көченә карап сокланасың, ясаган һәр адымнарына сөенәсең. Чыннан да, нинди хыялый, сабыр, көчле рухлы кешеләр җәмгыятенә килеп эләкте кыз. Алар мохитендә тәрбияләнеп, үз алдына зур максатлар куярга өйрәнде. Иң зур теләкләренең берсе – бию түгәрәгенә язылу!

Бу хыялга бүген иртән булган хәл сәбәпче. Реабилитация үзәгенә иртәрәк килеп җитте Миләүшә. Яшьләрнең сәгате башланганчы графикта кече яшьтәге балалар сеансы тора. Сәгать тугыз тулып, нәкъ унике минут иде. Каршы як залдан калын үкчәле, олпат гәүдәле булып күренгән бер апа чыгып бара. Аксаклап кына авыр атлаган нәни кызны җитәкләгән үзе. Ара-

тирә еш-еш сулап, бер сүз такылдый: «Хореография турында оныт! Ничек кире кайтмакчы буласың? Без дәваланып йөргәндә күпме ай бушка үтте! Элеккеге көчне кайтарыр өчен дә шактый вакыт кирәк булачак! Исеңдә калдыр: монда эләккәннәр элеккеге тормышларына кире кайта алмый!»

Авыр сүзләр унсигез яшьлек кызның күңелен яралады. Ә нәни балага нишләмәк кирәк? Кызганыч, бу каты бәгырьле апа сабыеның күңелен күрә алмас шул. «Монда эләккәннәр» дип әйтүе генә дә ни тора… Ә булдыра алса, ә бәлкем тимер аягы белән биергә өйрәнсә?

2018 ел, 26 июнь.

Физика фәненнән булган соңгы имтиханын уңышлы тапшырып, кыз авылга юл тотты. Кала белән вакытлыча саубуллашып торачак ул, чөнки җәйге яллар башланды. Соңгы имтихан алдыннан да шәһәрдә калды бит. Туган нигезенә тыныч күңел белән кайтып керәсе килде кызның. Химия факультетына кергәч, физика белән аралар ерагаер дигән фикер ялгыш булган икән. Бу фән белән Миләүшә арасындагы низаг әле дә калды кебек. Юк, бүген бераз сүрелде ул. Беренче курс әйбәт тәмамланды да соң!

Шәһәргә Рәдиф үзе килде. Пәнҗешәмбе көннең җитүен Гөлзифа апа да бик зарыгып көтте. Дулкынландыргыч мөһим көн булса да, кызының булдырып чыгачагына өметләнде ул. Бу имтиханнар аңа, баштан узганнар белән чагыштырганда, әллә ни олы сынау кебек күренмәде. Узасы узган инде дип, тынычланып йөрергә рөхсәт бирде үзенә. Кышкы сессияләр чоры җиткәч, ана бераз борчылып алган иде. Улының «йөрәгеңә барысын да якын алудан тукта» дигән киңәш, кисәтүләреннән соң тынды. Кайгыртасы әйберләр болай да җиткән. Миләүшә, икенче яртыеллык башлангач, бию залына да язылып куйды. Гәрчә бик рөхсәт ителмәсә дә.

Киләчәкне дә кайгыртырга кирәк, бүгенге көн белән генә дә яшисе килә. Тормыш гаделме? Гадел! Тик моны аңлар яшькә җитә алырмы кыз? Ә менә монысы – иллегә-илле…

***

Иртәгесе көнне, төшке ашка кадәр өлгерим дип, онык зиратка юнәлде. Җил искән якка тайпылучы юкәләр, урман полосасы белән әле дә бәйлелек тапмый, изалана. Әби белән бабасының хәлен белергә килде кыз. Яшерми: миләүшә чәчәкләренә тап булмамынмы икән, дигән уй да өстенлек итә. Алар гына никтер күренми быел. Былтыр булганын-булмаганын да белми кыз. Абыйларыннан да сорарга җөрьәт итмәде. Бу якта үсмәгәннәр. Бәлки, каршы як чыгу юлында бардыр. Шуннан килде бит, күзенә шәмәхә берни чалынмады. Кайда соң сез, «миләүшәләр»? Кем яшерде сезне?

Җавап озак көттермәде. Чәчәкләрне бабасы үз янына яшергән икән. Яшел рәшәткә белән киртләп куелган кабер өстендә күзләрне камаштырырлык миләүшәләр үсеп утыра иде. Гаҗәп хәл! Оныгының киләсен белеп, мәрхүм Хәнәфи карт үзе җыеп чыккан, диярсең!

Нык авыр. Яшь капчыклары тулып ташыр хәлгә җитте. Тик шулай да Миләүшә шат! Бабасы өчен шат…

– Бергә-бер, бабай, – дип эндәште сагынуын яшерә алмаган ягымлы тавыш. Уникe елга сузылган уен шулай тәмамланды…

# «КЫЗЫЛ КАУРЫЙЛАР» КЫЗЫГЫРЛЫК ЯШИ

*1955 елда фронтовик шагыйрь Әдип Маликов хатыны Саҗидә Сөләйманова белән «Татарстан яшьләре» газетасының үз хәбәрчесе булып, Әлмәт шәһәренә кайтып урнаша. Шул елның сентябрь аенда шәһәр газетасында «1955 елның 15 сентябрендә Горький исемендәге мәдәният йортында татар әдәбият-иҗат түгәрәгенең беренче утырышы була» дигән белдерү эленә. Әдип Маликов әнә шулай яшь язучыларның әдәби түгәрәген оештырып җибәрә. Шушы көннән түгәрәккә эшче яшьләр тартыла башлый. Нефтьче-оператор Җәмит Рәхимов, токарь Ильдар Әхсәнов, драматург Сәет Кальметов, журналист Фазыл Мостафин, төзүче Шамил Бикчурин, соңрак укытучылар Энҗе Мөэминова, Саҗидә Сөләйманова, төзүче Клара Булатовалар түгәрәкнең беренче әгъзалары булалар. Алар һәммәсе дә күренекле шагыйрьләр, язучылар булып, нефть төбәге, анда яшәүче хезмәт ияләре турында матур-матур әсәрләр иҗат итәләр. Бу түгәрәккә йөрүчеләр исемлеге зурая, 1963 елның 23 мартыннан ул Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт оешмасы булып эшләп китә. Әнә шуннан соң  берләшмәгә тәңгәл рәвештә Саҗидә Сөләйманова үзе дә әдәби түгәрәк оештыра. 1980 елдан, шагыйрә вафатыннан соң аның истәлегенә «Кызыл каурыйлар» дип исемләнгән әдәби-иҗат берләшмәсен төрле елларда Әхтәм Фәтхетдинов, Ләйсән Кәшфи, 2009 елдан алып Минзифа Әхмәтшина җитәкли.*

*Бүген берләшмәгә егермедән артык кеше йөри. Алар арасында төрле яшьтәге нефтьче-ветераннарыбыз, укытучылар, тәрбиячеләр, мәдәният һәм башка хезмәт ияләре бар. Төрле елларда «Татнефть» җәмгыятенең «Рухият» хәйрия фонды тарафыннан каурыйчыларның унбишләп китабы нәшер ителде. Бу изге хәйрия эше дә «Кызыл каурыйлар» әгъзаларының төбәктәге иҗади хәрәкәттә үз урыннары барлыгын күрсәтә. Моннан тыш, иҗатчыларның үз көчләре белән төрле нәшриятларда чыккан кырыклап китабы бар.*

**Минзифа ӘХМӘТШИНА**

***

Ялган белән бозның арасыннан
Мин сайладым салкын бозларны.
Кояш яктыртса да эретә алмый,
Яраларга салган тозларны.

Тынычрак карыйм тормышыма,
Чыкмыйм мин дөньяга ялтырап.
Яраларны бозмы каплаганга,
Йөремимен хәзер аптырап.

Вакыт – табиб, диләр. Ялган ла ул,
Көмеш төсе биргән әремгә,
Тик ачысы шулай кала бирә,
Күпме бал өстәмә – әрәмгә.

Акыл бирә, йөрәкне җылытмый,
Тәҗрибәсе бар да, юк көчең.
Һәр адымым гомер белән түлим,
Кыйммәт ала мәлгунь эш өчен.

**Рәмзис ИСМӘГЫЙЛЕВ**

* * *

Хак Тәгалә күптән сугар иде
(Андый көчне каян аласың?),
Закон белән җиңеп буламыни
Бу заманда адәм баласын?

Иске йолаларны йолкып аткач,
Күпләр иш итмәде яңасын.
Чал чәченнән урап тотып кыйный
Исерек кызы исерек анасын.

Ата улны, ана кызны белми,
Ни белән соң моны үлчәргә?
Ничек безне Җир күтәрә икән,
Ничек ычкынмый ул күчәрдән?

Тапсыз килеш саклый алмадык шул
Кеше дигән бөек исемне.
Кешелеген күпләр ничек аклар,
Нишләттең син, дөнья, кешене?

**Әзһәр ЗӘЙНИ**

## Татар булуыма горурмын

Татар булуыма горурланам,
Олуг милләт безнең татарлар.
Дөньяның һәр почмагында безне
Бөек халык диеп атыйлар.
Гореф-гадәтебез саклый безне,
Күп милләтләр җирдә торса да.
Яшәү дәрте белән яна татар,
Нинди генә эшләр кылса да.
Сөю көче бетмәс татарларда,
Хөрмәтли ул ата-анасын.

Бабасының васыятен тотып,
Тәрбияли сабый баласын.
Туган итеп саклый бердәмлекне,
Яхшы эшне татар булдыра.
Сокланырлык моңын саклаган ул,
Бүген яңа җырлар тудыра.
Татар булуыма шатланамын –
Данлы милләт булып яшибез.
Әләм итеп бөек татар исемен
Җирдә яшен булып яшьнибез.

**Нур СИБАГАТУЛЛИН**

## Мин төш күрдем...

Күкләр микән шулай шаяралар,
Әллә инде үзгә бер сәбәп –
Куркыныч төш күрдем: анда сиңа
Бүтән белән иттем хыянәт...

Төшем куркытты, дип әйтмим аны –
Күңелемне бары айкады.
Әйтче, зинһар, нинди шаяру бу,
Әллә инде күңелем чүп-чары?!.

Син уйлама – тәнем катышмады –
Китеп бардым бары калдырып.
Олы юлга минсез кузгалдың син,
Карамадың хәтта борылып...

...Һәрчак очам бары синең янга,
Түзә алмыйм синсез җирсүгә.
Хыялыңдагыча булалмасам,
Кичер, зинһар, барысы өчен дә!..

**Айзат СОЛТАНОВ**

## Сагыш җиле

Кичтән искән җилләр ямь калдырып,
Авылымны үтеп киткәндер.
Кайтам әле, кайтам авылыма,
Әти инде атын җиккәндер...

Келтер-келтер тәгәрмәчләр барыр,
Күңелләрне моңнар уятыр,
«Керим әле урманнарга», – диеп,
Йөрәк, түзми, җыру кузгатыр.

Мизгел кебек үткән шушы чорлар:
Җигүле ат көтми капкада.
Сагыш кына хәтер җиле белән
Ятып елый койма-тактада.

**Зәлидә ЗАРИПОВА**

## Ятим булмас халкым, җыр булса

Китә ирләр, олпат ирләр китә,
Төз наратлар шартлап аугандай.
Йөрәк тетрәп куя шул чагында:
Бар дөньясы ятим калгандай.

Иртә киткән олпат шагыйрьләрнең
Иҗатларын барлап узганда,
Бер охшашлык табам кебек үзем
Кошкайларны озатып калганда.

Бүген дә бит һаваларда әнә
Кыр казлары очты тезелеп.
Синең кебек, якташ, бу мизгелдә
Озатып калдым җаным илереп.

**Зөлфия СИРАЕВА**

## Әтиемнең моңлы гармуны

Моң агыла төнге тынлык ярып,
Өздереп лә уйный гармуны.
Кем соң, кем соң күңел кылларыннан
Учак якты телеп, яндырып?

Моң агыла, кайтам балачакка,
Җыр-биюле шаян яшьлеккә.
Шул моңнарда үстек гармун тыңлап,
Сәхнәләрдә җырлап үстек лә.

Әти уйный, ә без балалары
Җыела идек аның янына.
Күрше-тирә кич утыра иде,
Яшьләр килә иде моңына.

Гармуннары калды истәлеккә,
Истәлеккә калды җырлары.
Юртактай үтеп киткән еллар,
Юатырга юк шул моңнары...

**Сирина ҖИҺАНШИНА**

## Авыл мунчасының сихәте

Сауналарга алыштыраммы соң
Үзебезнең авыл мунчасын?!
Кергән кеше һич оныта алмый
Җанга-тәнгә биргән шифасын.

Мәтрүшкәле каен себеркесе
Хуш исләрен бөркеп чакыра.
Тирләп-пешеп, бар дөньяңны онытып
Чабынулары соң ни тора!

Үлән суларының төнәтмәсе
Дәвалый бит җитмеш чиреңнән.
Озак булмый түзеп, сагындырып
Кайтара ул киткән җиреңнән.

Чистарта ул тәнне, җаныбызны,
Дәваларны бирә нихәтле!
Гел яшәртеп торсын әле безне
Авыл мунчасының сихәте!

**Гүзәлия ГАЛЛӘМОВА**

## Шагыйрьгә

Биек тауларга менәсең,
Һаваларда йөзәсең.
Елга, күлләргә төшәсең,
Ромашкалар өзәсең.

Ромашкалар, ак каеннар
Юлларыңа тезелгән.
Ак бәхетләр өләшәсең
Бүлеп алып үзеңнән.

Шигырең күчә кәгазьгә,
Тезмә, сихри юл булып.
Илһамың сүнмәсен, шагыйрь,
Яңгырасын җыр булып.

**Рафаил ӘХМӘДИЕВ**

## Әнкәй төсе – яран гөл

Әнкәйнең төсе булсын дип,
Яран гөлләр утырттым.
Тәрәзә төпләрен ямьләп,
Чәчкә атып утырсын.

Тәрәзәм саен яран гөл,
Карамый китмәсеннәр.
Иркәләп, назлап су сибәм,
Саргаеп кипмәсеннәр.

Күңелләремне юатам,
Гөлләр янына килеп.
Гөлләрем миңа елмая,
Әнкәй елмайган кебек.

**Гөлсинә САВГАНОВА**

## Изге ягым...

Туган якта йөреп килдем әле,
Чулман буйларыннан урадым.
Яр башына басып, суда йөзгән
Корабларга кулым болгадым...

Их, шушында кайтсам, хисләр ташый,
Күңел ярларына уралып...
Сагышларым гүя юкка чыга,
Кайгыларым китә таралып.

Чал Камадан искән назлы җилләр
Нигә шулай якын күңелгә?
Үзәкләрне өзеп, йөрәкләрдән
Бөтерелеп хисләр түгелә.

**Гүзәлия ШӘРИПОВА**

## Төнге уйлану

Төннәрен торып утырам,
Чумам тирән уйларга
Әллә вакыт җитмәдеме
Туган илне буйларга?

Төннәрен торып утырам,
Биреләмен хисләргә.
Минем гомер матур узды –
Тез чүкми ят-ишләргә.

Төннәрен торып утырам,
Уйлыймын туган илне.
Урыс абзыйның уенда
Бетерү безнең телне.

Төннәрен торып утырам,
Уй-хисләргә биреләм:
Гомер үтте, без яшәдек,
Онык өчен илерәм.

**Роберт САФИН**

## Күңел бакчасы

Сусап яткан күңел бакчамда
Әлмәт урамнары чагыла.
Зәңгәр күлнең тыныч дулкынын
Ялгыз узган кичләр сагына.

Сагынам ишекнең йозагын,
Киттем шул мин туган йортымнан.
Әти-әниемнең күзләре
Яшьләнеп озатты  артымнан.

Тиз генә кайталмам шикелле,
Күңелгә шик тула, билгеле.
Күрешкәч кулларын кысармын –
Күптәннән кайтмавым сизелер.

Авылым тургае, исәнме,
Сузасыңмы син үз көйләрең?
Әби-бабам кабере өстеннән
Уз син сайрап, яктырт гүрләрен.

**Рамазан РӘХИМҖАНОВ**

## Язмаларым

Язмаларым булып бер истәлек,
Гомерлеккә калсын иде дә,
Тормышымның барлык бусагасы
Күренеп торсын дәфтәр битендә.

Үтәр гомер, үзгәрерләр чорлар,
Тик үзгәрмәс язган шигырьләр.
Укырлар да бәлки минем хакта
Искә алып сөйләп йөрерләр.

Кеше гомере мәңгелек түгел,
Һәр кешегә санап бирелгән.
Тормыш юлын һәркем үзе сайлый,
Язмыш шулай тигез бүленгән.

Җырларымда килә  аңлатасым:
Шигырьләрем калсын гомергә.
Мин булмасам әгәр, алар калыр
Тарих итеп сезгә сөйләргә.

**Рөстәм КӘРИМОВ**

# «МИН – ҮЗ УРЫНЫМДА...»

Рәис Равил улының интервьюсын йомгаклаган бу сүзләре тормышта зур уңышларга ирешкәннәрнең, асылда, үз язмышларын «эзләп тапкан», үзләренә насыйп илаһи юлны лаеклы узган шәхесләр булуын тагын бер кат раслыйдыр. Чыннан да, бүген Рәис Муратов – «Железногорск» Космос элемтәсе үзәгенең директоры, тормышыбызны алардан башка күз алдына да китерми торган күп кенә технологияләрнең көн саен, мизгел саен яныбызда булуын тәэмин итә торган интеллектуалларның берсе бит! Кайсыбыз гына телефон, теле-радиотапшырулар, һәртөрле элемтә каналлары: кәрәзле телефоннар һәм спутник тапшырулары, Интернет яки һава торышын алдан белү һәм башка шундый заман алгарышының билгеләреннән башка яши ала?!



Хәер, язмышының шушы икәненә ул үзе кайчан төшенде икән? Гел «бишле» билгеләренә укып, мәшһүр уку йортына – Томскидагы Политехника институтына укырга керергә карар кылгачмы, яки аны тәмамлап, 1981 елны иң югары технологияләр үстерелә торган «ябык» шәһәргә килеп, космик аппаратлар белән идарә итү өлкәсендә эшли башлагачмы, әллә өр-яңа Космос элемтәсе үзәген төзегәндәме – кем белсен...

Рәис Равил улының нәсел-гаилә тамырлары Татарстанның Балтач районыннан. Әтисе Равил ачлык елларында Янгулдан читкә чыгып киткән Гариф һәм Сара гаиләсендә, Казакъстан чигендәге зур сәүдә-аралашу юллары кисешкән, СССРның Себер белән дә, Ерак Көнчыгыш, төрки республикалар белән дә бәйләнешләрен тәэмин иткән Атбасар шәһәрендә туа. Монда тимер юлга эшкә урнашып, туган җирдә калган якыннарына терәк булып яши башлаган бертуган егетләр ел саен Балтачка кайтып йөриләр. Туган җиргә бер кайтуында Равил урамга су алырга гына чыккан күрше кызы – 16 яшьлек чибәр Әлфинурны күрә, гашыйк була һәм кызны, Заһидулла агай гаиләсенең ай-ваена карамыйча, үзе белән алып та китә. Менә шушы гаиләдә туып-үскән Рәйсә, Рәис һәм Марина, үзләренә әтиләрендәге тырышлыкны, әниләрендәге сабырлыкны туплап, Балтач яктысын һәм җылысын дөньяның төрле төбәкләрендә, гыйлем итеп тә, мәрхәмәт итеп тә таратып яшиләр. Рәйсә Равил кызы – Атбасарда, гомере буе мәктәптә эшләгән кадерле укытучы булып, Марина Равил кызы исә – инглиз теле белгече – Астанадагы Назарбаев-университетта чит телләр укытып, аннары үз эшен ачып җибәреп гомер итәләр.

Апа һәм сеңел янәшәсендә, татар гаиләсе җылысында, әнисенең моңлы татар җырларын тыңлап, тәмле милли ризыклар тулы мул табыннар күреп үскән Рәис кечкенәдән гыйлемгә тартыла, логик-математик зиһене, инженерлык акылы белән

аерылып тора. Биш яшендә ул үзлегеннән укырга өйрәнә, мәктәптә төрле олимпиада-ярышларга бик теләп йөри, район һәм өлкә бәйгеләрендә беренче урыннарны яулый. Саннар дөньясында кайнаган яшүсмер 9 сыйныфта укыганда вузлар өчен математика дәреслекләреннән мәсьәләләрне чишә! 1976 елны Атбасарда 2 нче урта мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, Рәиснең төбәктә иң көчле техник вузга – Томск дәүләт политехника институтына укырга китәргә карар кылуы табигый була. Ул Автоматика һәм хисаплау техникасы факультетына, Мәгълүматый-үлчәү техникасы белгечлеге буенча укырга керә. Фән-техника алгарышы, мәгълүматый-элемтә технологияләренең көнләп түгел, сәгатьләп үскән вакыты бу!

Ул заманда югары мәктәпне тәмамлау «распределение» дигән гамәлгә килеп бәйләнә: Томск политехына ел саен илнең барлык төбәкләреннән, техник белгечләргә ихтыяҗ булган оешмалардан дипломлы белгечләрне үзләренә эшкә чакырырга киләләр. Рәис шикелле «5»легә генә укыган студентка исә сайлау мөмкинлеге беренче итеп бирелә. Ул Красноярск-26 дип аталган, атом-төш сәнәгате һәм спутниклар ясау буенча специальләшкән көчле фән үзәгенә, халык телендә «тугызлы» дип йөртелгән ябык шәһәргә китәргә карар кыла. Юрий Гагарин галәмгә очкан заман егетләрен өр-яңа космик технологияләр эшләү мөмкинлеге кызыктыра, билгеле.

Красноярск янында, 1954 елны шәһәр читендәге шәһәр булып тайга уртасында, Енисей елгасы буенда төзелгән бу урын беренче тапкыр килүчеләрне гаҗәеп табигате, яшеллеге белән шаккатыра. Байкал инеше һәм Саян тауларының бер кисәге – Атаман тавы, кеше кулы белән ясалган Кантат күле шундый бер тәэсир тудыра ки, әйтерсең саф һава, зәңгәр сулыклар, йөзъяшәр наратлар монда алып барылган атомны буйсындыру эшенең чынбарлык булуын да шик астына алалар. Әмма биредә, чыннан да, СССР дип аталган зур илнең космосны үзләштерү үзәкләренең берсе урнашкан; космик аппаратлар төзү, аларның уңышлы эшләвен тәэмин итү бурычы тормышка ашырыла. Рәис Равил улы хезмәт юлын шушында – Россия космос фәнен тудыручыларның берсе академик Михаил Фёдорович Решетнёв Генераль конструктор һәм Генераль директор булган Гамәли механика фәнни-сәнәгать берләшмәсендә башлап җибәрә. Илкүләм күренекле мәгълүмати спутник системаларын әзерләүче үзәккә эшкә килү – космик гыйлемнең иң алдынгы сафларына кушылу, иртәгәге көн технологияләрен уйлап табуга һәм гамәлгә ашыруга өлеш кертү мөмкинлеге бирә. Бу берләшмәдә 1200дән артык очу аппараты – барлык спутникларның 70 проценты – ясалу гына да күп нәрсә хакында сөйли. Академик М.Ф.Решетнёв җитәкчелегендә илдәге космик аппаратларның очышын тәэмин иткән автомат магнитлы-гравитацион ориентлашу системасы эшләнә.

Рәис Равил улы оешмада инженер белгечлеге буенча – космик аппаратлар белән идарә итү хезмәтенә керешә, бераздан – инженер-конструктор һәм әйдәп баручы инженер-конструктор вазифаларына күчерелә. Бу эш геостационар спутниклар – геостационар орбитада оча торган аппаратлар – аша алып барыла. Алар Җир шары әйләнү тизлегендә хәрәкәтләнәләр һәм җир өслегенә нисбәттә бер урында «эленеп» торган булып чыгалар. Спутник аша элемтә каналларын һәм телетапшыруларны эшләтү шулай башкарыла. Әмма спутник орбитасы «тере» – ул дулкынланып тора, «шуып» китә: шуңа да инженерларга һәр алты сәгать саен аны карарга, урынына-оясына кайтарырга, яңадан көйләргә, спутникка язылган мәгълүматларны яңартырга кирәк!

Әлбәттә, бу – галәмдәге аппарат белән идарә итүнең бер өлеше генә. Рәис Равил улы һәм аның хезмәттәшләре космик аппаратларның нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итүдән алып – спутниклардан җирдәге үзгәрешләр хакындагы мәгълүматлар алуны тизләтүгә, космонавтлар белән элемтәне көйләүгә кадәр бик күп бурычларны хәл итү юлларын табалар, гамәлгә куялар, камилләштерәләр. Илебезнең галәмне үзләштерү өлкәсендәге уңышларында аларның да өлеше зур.

1990 елларда башлыча хәрби максатларда кулланылган спутниклар тормыш-



*Муратовлар гаиләсе киләчәк буыннарны тәрбияләү өчен җан ата.*

көнкүрешкә дә зур дулкын булып үтеп керә башлый. Очу аппаратлары өч юнәлештә: геодезиядә, навигациядә һәм элемтә технологияләрендә нык үсеп китә. Хөкүмәт халык хуҗалыгында элемтә һәм телетапшырулар өчен файдаланыла торган спутниклар белән идарә итү тармагын төзү турында карар кабул итә. 1992 елның сентябрендә шушы эшне оештыру максатыннан «Персей» фән-техника фирмасы төзелә, аңа «Галс» һәм «Экспресс» дип аталган спутниклар белән идарә итү бурычы йөкләнә, моның өчен 1996 елны мөстәкыйль платформа булдырыла. Әлеге эшнең үзәгендә кайнаган Рәис Равил улы, Гамәли механика фәнни-сәнәгать берләшмәсенең йөкләмәсен үтәп, 2000 елдан «Персей»га эшкә күчә.

Әлбәттә, бу тармакны үстерү өчен «Железногорск»ның сайлап алынуы очраклы түгел: Россиянең үзәгендәге бу урынның элемтә һәм телетапшырулар өчен җаваплы спутниклар төркемен тулысынча «күзәтү» мөмкинлеге бирүе, моннан тыш, спутниклар ясау оешмасының да шушында урнашуы аны уникаль мәйданга әйләндерә.

2002 елда «Персей» очышлар белән идарә итү җайланмаларын һәм ике станцияне күчерү өчен «Железногорск»та Космос элемтәсе үзәге төзергә керешә, 2004 елны заманча җиһазландырылган бина әзер була, Космос элемтәсе үзәге оешып, «Персей» генераль директорының урынбасары – баш инженер Р.Р.Муратов шунда эшкә күчә.

«Железногорск» Космос элемтәсе үзәге – Россия спутник элемтәсе операторы булган «Космос элемтәсе» (ГП КС) Федераль дәүләт унитар предприятиесенең 5 филиалыннан берсе. Үзәктәге оешма Россия Федерациясендә һәм 58 чит илдә (БДБ дәүләтләре, Европа, Якын Көнчыгыш, Азия-Тын океан регионы, Төньяк һәм Көньяк Америка, Африка, Австралия) кулланучылар өчен теле-радиотапшыруларны, элемтәне тулысынча тәэмин итүче 12 спутник белән идарә итә. Ул хәл итә торган стратегик бурычлар арасында теле-радиотапшырулар, спутник тапшырулары, Россия Федерациясе Президенты һәм Хөкүмәтен, Интернет челтәрен, диңгез судноларын һәм башка хәрәкәт итүче объектларны элемтә белән тәэмин итү кебек гамәлләр бар.

«Железногорск» Космос элемтәсе үзәге – шушы олы эшчәнлекнең мөһим бер тармагы. Галәмдәге аппаратлар белән идарә итү, инновацион технологияләр үстерү белән беррәттән, Үзәк Себердә космос гыйлемен һәм сәнәгатен үстерүгә юнәлтелгән өр-яңа региональ технологик платформа булдыруда катнаша. Биредә иң куәтле

технологияләр сынау уза, илебезнең галәмне үзләштерү һәм космик киңлекне файдалану эшенең киләчәк юллары сызыла. Рәис Равил улы Муратовның күпсанлы дәүләт бүләкләре арасында «Маршал Василий Чуйков» медале һәм 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» орден медале булу да – аның казанышларын, уңышларын тануның бер чагылышы бит.

«Космос элемтәсе» (ГП КС) оешмасы бүген зур үсеш-сикереш чорын кичерә: ул 2034 елга кадәр эшләп орбитага чыгарылачак 12 яңа геостационар спутник белән идарә итү бурычын үз өстенә алачак. Үзәктәге оешма белән бергә, «Железногорск» Космос элемтәсе үзәге дә ике тапкыр зураерга тиеш: бүгенге урыныннан 7 чакрым ераклыкта яңа мәйдан билгеләнеп, зур төзелеш башланган. Димәк, яуланасы үрләр билгеләнгән – яңа гыйльми ачышлар алда әле. Бүген шәһәрнең визит карточкасына әйләнгән 35 җир өсте станциясе янына тагын шуның кадәр үк «тәлинкәләр» урнашыр, илебездә галәмне үзләштерү эшенең алдынгы булуын алкышлап, яңа төсләр белән балкырлар!

Гомумән алганда, «Железногорск» үзәге ябык шәһәрдә генә түгел, Красноярск краенда, бигрәк тә аның мәдәни тормышында аерым урын тота. Төбәктәге бер генә мәдәни чара, спорт ярышы да Космос элемтәсе үзәге хезмәткәрләре катнашыннан башка узмый дисәк, ялгыш булмас. Яшь рәссамнарга, музыкантларга яки спортчыларга ярдәм һәрчак өстенлекле, мөһим бер гамәл дип карала. Мондый чараларның да үзәгендә – Рәис Равил улы һәм аның матур гаиләсе.

Муратовлар гаиләсе, Рәис Равил улы һәм аның хатыны Татьяна Владимировна әле 2008 елда гаиләдәге табышның 10 процентын хәйриягә тоту хакында карар кабул иткән булалар. Артканга түгел – бу вакытта әле өч бала тәрбияләүче гаиләнең алар өчен ипотекалар түләгән чагы. Күңел кушканга! Башта гаиләнең хәйрия суммалары ушу-каратэ белән шөгыльләнүче яшь спортчыларга һәм спорт ветераннарына ярдәмгә юнәлтелә. Аннары болар янына башка спорт төрләре кушыла: хоккей, футбол, чаңгыда йөрү, баскетбол, нәфис гимнастика, көрәш, йөгерү, шахмат, киез итекле хоккей, йөзү һ.б. Төбәктән балаларның өлкәдәге яки илкүләм ярышларга баруын матди тәэмин итү белән бергә, Муратовлар еш кына үзләре дә, җанатарлар булып, алар белән бергә юлга чыгалар. Мондый җиңүләр алар өчен үзләренең шәхси казанышыннан да кадерлерәк.

Балалар һәм яшүсмерләр спорты Үзәк җитәкчесен һәм коллективын Балалар йортына алып килә. Шефлыкка алып, матди ярдәм күрсәтү генә түгел, җитәкче хезмәттәшләре алдына чын мәгънәсендә аралашу-тәрбия эшенә катнашу бурычын куя. Олылар һәм балалар бергәләп Спартиан уеннары хәрәкәтенә кушылып китәләр. Ягъни бер гаилә – Балалар йортыннан бер бала белән бергә ярышта катнаша, бергәләп җиңүгә юл уза. Моннан тыш, балалар өчен Рәсем конкурслары, КВНнар уздыру, күпләгән чаралар – барысы да галәмне үзләштерүчеләрнең – Җирдәге рухи-мәдәни атмосфера өчен дә, киләчәк буыннарны тәрбияләү, аларның күңелләрендә кешелеклелек һәм мәрхәмәт орлыкларын үстерү өчен җан атуы хакында сөйлиләр.

Гадәттә, дөньяга киң карашлы кешеләр күп нәрсәләр белән кызыксына торган була. Рәис Равил улы өчен бу – күрәсең, чит шәһәрләр, чит җирләр белән танышу, аралашу, даими хәрәкәттә булу. Дөньяның барлык кыйтгаларын күргән Муратовлар Россия буйлап сәяхәтләрне дә ярата, ата-баба җире – Казанны да үзләренеке саный. Рәис Равил улы Казандагы авиация университеты белән уртак проектларга бик теләп катнаша, Татарстанның уңышларына, шәһәребезнең көннән-көн матураюына игътибар итеп яши.

Хәер, сәяхәткә китеп, спутникларыннан аерылып та озак тора алмый ул: чөнки – үз урынында, яраткан хезмәте, фән белән шөгыльләнә, галәмдә дә, җирдә дә үзенең якты эзен-сукмагын салып яши.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*филология фәннәре докторы.*

# КҮПКЫРЛЫ БАЙ ИҖАТ ИЯСЕ

## ХӨСӘЕН УРАЗИКОВНЫҢ ТУУЫНА – 130 ЕЛ



Актёр, режиссёр, драматург, педагог, ТАССРның халык (1945), РСФСРның атказанган (1950) артисты, Ленин ордены кавалеры (1957) Хөсәен Ибраһим улы Уразиков 1894 елда Саратов губернасы Дергачёв өязе Сәфәр авылында күп балалы гаиләдә дөньяга килә. 1920 елда Самара драма студиясен тәмамлый. Оренбургта, Фрунзеда татар труппаларында эшли. 1923 елдан Кызыл Октябрь исемендәге татар театры актёры (хәзер Г.Камал исемендәге театр). Баштарак ул милли драматургия буенча куелган спектакльләрдә күбесенчә эпизодларда гади көнкүреш рольләрен башкара. Соңга таба төп рольләрдә чыгыш ясый. Алар арасында Юныс Хаҗи (Ш.Камал, «Хаҗи әфәнде өйләнә»), Мулла (М.Әблиев, «Шәмсекамәр»), Биктимер (Т.Гыйззәт, «Ташкыннар»), Мортаза бай (Ә.Фәйзи, «Тукай»), Бикәмәт (Н.Исәнбәт «Зифа») һ.б. кебекләре драма артисты буларак аның йөзен ачыклый, коллективта урынын билгели торганнарына керә. Озак еллар режиссёр булып эшли. 1944–1948 елларда Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының художество җитәкчесе була. Куйган спектакльләре арасыннан «Мактаулы заман» (Т.Гыйззәт, 1937), «Хуҗа Насретдин» (Н.Исәнбәт; К.Тумашева белән бергә, 1940), «Миңлекамал» (М.Әмир, 1944), «Мулланур Вахитов» (Н.Исәнбәт, 1948), «Диңгездәгеләр өчен» (Б.Лавренев, 1948), «Зифа» (Н.Исәнбәт, 1954) кебекләре данлы театрның үсеш этапларын билгели. «Каюм Насыйри» пьесасының автордашы (М.Гали белән бергә) һ.б. 1933–1965 елларда Татар театр училищесында укыта.

Х.Уразиков – театр тарихында ныклы урын алган, бу төр сәнгатьнең төрле өлкәләрендә бай иҗат мирасы калдырган олы шәхесләребезнең берсе. Аның исеме Г.Кариев, С.Гыйззәтуллина-Волжская, К.Тинчурин, Г.Болгарская, Ф.Ильская, З.Солтанов, Х.Әбҗәлилов, Г.Шамуков, Ф.Халитов кебек күренекле сәхнә осталарыбызның исемнәре белән янәшә тора.

Х.Уразиков үзенең иҗат эшчәнлеген 1920 елда Самара драма студиясендә К.Тинчурин белән З.Солтанов җитәкчелегендә башлап җибәрә. Алар Уразиковка Г.Кариев реалистик мәктәбе традицияләрендә актёр, режиссёр эше буенча тәүге күнекмәләр бирәләр, сәхнәдә тормыш дөреслегенә мәхәббәт, һәртөрле ялганга, штампка килешмәүчән караш тәрбиялиләр. Болардан тыш, Х.Уразиков һәр ике укытучысының, актёр һәм режиссёр буларак, иң көчле якларын – К.Тинчуринның театральлеген, образны психологик яктан ачарга омтылышын, З.Солтановның сәхнәдән яңгыраган сүзгә аеруча игътибарын кабул итә. Соңрак алар Х.Уразиковның үз иҗат йөзен билгеләүче төп сыйфатлар булып әвереләләр.

«Г.Кариевка хатирә», Дүртенче татар бригадасы, Г.Тукай исемендәге Алма-Ата шәһәре труппаларында, Кызыл Октябрь исемендәге һәм Әстерхан татар дәүләт театрларында эшләгән еллар артистның үз амплуасын, мөмкинлекләрен ачыклау, иҗат йөзен, башкару үзенчәлекләрен эзләү чоры булып саналырга хаклы. Бу вакытларда уйналган Хәмзә бай (Г.Камал, «Беренче театр»), Бәдри (М.Фәйзи, «Галиябану»), Хәзрәт

(С.Рәмиев, «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!») һәм башка рольләр – беренче авырлыклар, зур иҗат юлының тәүге баскычлары.

Егерменче еллардагы газета-журнал мәкаләләре аша артист Уразиковның үсеш юлын шактый ачык төсмерләргә була. Аларда баштарак Бояр (Д.Юлтый, «Карагол»), Мәрди (К.Тинчурин, «Сүнгән йолдызлар»), Чалбарчы (К.Нәҗми, «Печән базары») кебек эпизодик рольләр, соңрак – әсәрләрнең төп геройлары белән янәшә куярлык Хәсән (Г.Кутуй, «Балдызкай»), Җиһанша (К.Тинчурин, «Зәңгәр шәл»), Гыйсмәт (Ә.Таҗетдин-Рахманкулов, «Боз астында упкын») кебек персонажлар турында сүз бара. Бу рольләрне башкарып, Х.Уразиков үзен ышандыру сәләтенә ия булган, кызыклы характерлар тудыра алучы шактый оста артист буларак таныта.

Х.Уразиков үсешендә К.Тинчурин әсәрләре аерым урын алып тора. «Зәңгәр шәл»дәге Җиһанша образы, мәсәлән, Уразиковның принципиаль уңышы булуы белән бергә, шул әсәрдәге икенче бер образга (Ишанга) үзенчәлекле хәзерлек тә булып тоела. Нәтиҗәдә, беренче тапкыр Әстерхан татар дәүләт театрында 1929 елда уйналган һәм соңыннан да берничә тапкыр яңартылган Ишан образы артист Уразиковның биографиясенә лаеклы бер бизәк буларак кабул ителә. Х.Уразиков иҗатында фикер киңлеге, сурәтләү чараларының байлыгы ягыннан Ишан белән беррәттән Мисбах хаҗи («Җилкәнсезләр»), Шакирҗан («Сакла, шартламасын») Туктамыш («Ил»), Үтәш («Кандыр буе»), Кыям («Беренче чәчәкләр») кебек образлар шактый зур урын алып торалар. К.Тинчурин әсәрләрендәге әлеге образлар Х.Уразиковка осталыгын чарларга, диапазонын киңәйтергә, үзен төрле жанрларда сынап карарга зур мөмкинлекләр тудыра, иҗади йөзен формалаштырырга ярдәм итә.

Шул ук вакытта Уразиков рус һәм чит ил классиклары әсәрләрендә дә дәвамлы рәвештә зур һәм җаваплы рольләр башкарып килә. Шулар арасыннан дөньяның күп күренекле сәнгать осталары уйнаган һәм Х.Уразиков тарафыннан тыенкы манерада, ләкин эчке бер кайнарлык белән башкарылган Варум (Ф.Шиллер, «Мәкер һәм мәхәббәт»), Левшин (М.Горький, «Дошманнар») рольләре аның өчен өлгергәнлеккә үзенчәлекле имтихан булып тора.

50 еллык сәхнә эшчәнлеге дәверендә Х.Уразиков тарафыннан барлыгы 160 ка якын роль уйналган. Шуларның Ишан, Мисбах хаҗи (К.Тинчурин, «Зәңгәр шәл», «Җилкәнсезләр»), Колый Тархан, Бикәмәт (Н.Исәнбәт, «Хуҗа Насретдин», «Зифа»), Сәмигулла (Ш.Хөсәенов, «Зөбәйдә – адәм баласы»), Левшин, Печенегов, Иван Коломийцев (М.Горький, «Дошманнар», «Соңгылар») кебек татар артистлары тудырган иң гүзәл образлар галереясында сакланырга хаклы. Әлеге образлардан чыгып, артист Уразиков иҗатының үзенчәлекле якларын билгеләп китү зарур. Сәхнәгә революциядән соң килгән икенче буын татар артистлары вәкиле буларак, Х.Уразиковка Г.Кариев мәктәбенең реалистик традицияләрен «татар театры атасы»ның иң якын хезмәттәшләреннән кабул итү насыйп була. Шуңа күрә аның иҗатына, беренче буын татар артистларындагыча, сәхнәдә тормыш дөреслегенә тугрылык, халыкның тормыш-көнкүреш, мәдәниятен аңлап эш итү, милли характер үзенчәлекләренә, кеше күңеле нечкәлекләренә тирән үтеп керә белү хас. Аның осталык диапазоны гаҗәп киң. Ул – драматик яки юморга бай булган рольләрне бердәй осталык белән башкара алучы бик сирәк очрый торган артистларның бер вәкиле. Х.Уразиков иҗат иткән геройлар матур тембрлы тирән баритон тавышка, уртачадан чак кына калку нык гәүдәгә, тыенкы, ләкин гаҗәеп ышандыра алу сәләтенә, пластикага, төгәл жестка ияләр. Бу сыйфатлар тормышчанлык, гадилек, бөтенлек белән берлектә Х.Уразиков иҗат иткән сәхнә образларының коллектив портретын тудыралар.

Х.Уразиковның артистлык хезмәте бай һәм тирән. Ләкин аның мәдәниятебезгә керткән өлеше моның белән генә чикләнми. Х.Уразиков – халкыбыз сәнгатенә үзенчәлекле, тирән эчтәлекле спектакльләр биргән сәләтле режиссёр да. Тирәннән тикшергәндә, ул куйган спектакльләрнең үз вакытында халык тормышында, ил язмышында шактый әһәмиятле урын тотканлыгы күренә.

1930 нчы елларда Татар дәүләт академия театрында Станиславский системасы белән кызыксыну аеруча көчәя. Бу театрга С.Булатов, Р.Ишморат, Г.Исмәгыйлов, соңрак Ш.Сарымсаков, К.Тумашева кебек режиссёрлар килү белән бәйләнгән. Г.Исмәгыйлов театрда «системаны» өйрәнү буенча махсус дәресләр оештыра, үз эшен шул нигездә алып барырга тырыша. Х.Уразиков бу дәресләргә бик теләп йөри, үзлегеннән күп укый, эзләнә. Шуның нәтиҗәсе буларак ТДАТ сәхнәсендә куелган беренче спектакльләре белән үк ул үзен К.С.Станиславский системасының төп нигезләрен нык үзләштергән режиссёр буларак таныта.

Х.Уразиков тарафыннан куелган спектакльләр күбесе заман темасына багышланган. Аның «Мактаулы заман» (Т.Гыйззәт), «Миңлекамал» (М.Әмир), «Диңгездәгеләр өчен» (Б.Лавренев), «Ялгыз каен» (М.Кәрим), «Зифа» (Н.Исәнбәт), «Таң атканда» (Ш.Шаһгали), «Зөбәйдә – адәм баласы» (Ш.Хөсәенов) кебек әсәрләре турыдан-туры заман проблемалары белән бәйләнгән. Аларда заман кешесе төп каһарман, заманга хас конфликт, зур фикерләр, җәмгыятьнең төп үсеш тенденцияләре чагыла.

Һәр пьесаны сәхнәгә куйганда, режиссёр алдына иң элек драматургның иҗади йөзен билгеләү, аның үзенә генә хас стилен өйрәнү проблемасы килеп баса. «Авторның стилен саклау – театрда иң мөһим мәсьәләләрнең берсе, – ди Вл.И.Немирович-Данченко. – Авторны өйрәнү, яки дөресрәге, аның иҗади йөзен билгеләү, спектакльнең стилен дөрес табарга ярдәм итә». Режиссёр авторның стилен белү генә түгел, аның үзенчәлеген артистларның уен манерасында чагылдыра белергә тиеш. Мәскәү Художество театрында Метерлинкның әкияти-фантастик, Л.Андреевның абстракт-фәлсәфи, М.Горькийның революцион-романтик, А.Чеховның ярымтоннарга бай, вакыт атмосферасы белән тулы әсәрләре бер үк вакытта диярлек бара. Һәм аларның һәркайсы өчен режиссёрлар тарафыннан аерым стиль, аерым сурәтләү чаралары, уен манерасы табылган була. Татар театры тарихына күз салсак та, Г.Камал, Г.Коләхмәтов, М.Фәйзи, К.Тинчурин, Ф.Бурнаш һ.б. кебек драматургларның әсәрләре төрлечә уйналганын күрербез.

Драматургның эчке дөньясын өйрәнү проблемасы классик әсәрләрне куйганда гына түгел, бәлки режиссёр белән бер чорда яшәгән авторлар әсәрләрен куйганда да калка. Чөнки режиссёр пьеса сәнгатьчә эшләнеше ягыннан бик үк югары тормаган очракта да анда киләчәктә үстерерлек кыйммәтле орлыкны тотып ала белергә тиеш. Х.Уразиков режиссёр буларак әнә шул сыйфатка ия була. Ул пьесаны бер тапкыр укып чыгу белән, аның сәхнәдә ничек барачагын, тамашачылар тарафыннан ничек каршы алыначагын әйтеп бирә алган. Бу факт бер яктан аның драматургия кануннарын яхшы белүе турында сөйләсә, икенче яктан, авторларның иҗади йөзен бик тиз күрә алуы турында сөйли. Ләкин драматургның стилен тою өчен режиссёрга аның бер генә әсәрен белү җитми. Шуңа күрә Х.Уразиков иң элек Т.Гыйззәтнең бөтен иҗаты белән танышып чыга, аны тулысынча аңлавына ышангач кына, әсәрне куярга алына. «Башка әсәрне укып чыккач та, драматург белән җитди сөйләшергә, аның белән килешеп, әсәрдән күп кенә урыннарны, сүзләрне кыскартырга, үзгәртергә туры килде. Авторга күп кенә тәкъдимнәр ясалды. Иҗади дуслык шартларында барган бу аңлашу уңай нәтиҗә бирде, ул әсәрен өр-яңадан төзәтеп китерде һәм бу хәл спектакльнең уңышын тәэмин итте. Мондый сөйләшүләр, аңлашулар эш процессында драматурглардан Мирсәй Әмир, Нәкый Исәнбәт иптәшләр белән дә булды», – дип искә ала Х.Уразиков.

Күренгәнчә, Х.Уразиков бервакытта да бер яктан килгән әзер әсәрләр көтеп тормый. Әгәр әсәр темасы, идеясе, проблемалары белән кызыклы икән, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан тиешле дәрәҗәдә үк булмаса да, ул драматургның иҗат лабораториясе белән таныша һәм пьесаны сәхнәгә куйганда гына түгел, бәлки язылу процессында да актив эш алып бара. Авторлар белән эшләү режиссёрдан аерым талант сорый. Чөнки һәр иҗат кешесенеке кебек үк, һәм драматургның үз эчке дөньясы, характеры, яраткан һәм яратмаган нәрсәләре була. Алар арасындагы контакт төп ике төрле нәтиҗә бирергә мөмкин. Беренче очракта автор белән режиссёр арасында зур иҗади дуслык

туа. Бу дуслык һәр ике художникны да баета, зур эшләргә рухландыра. Режиссёр драматургны театр трибунасыннан халыкка җиткерерлек зур проблемалар белән баета, театр арсеналындагы техник мөмкинлекләр белән таныштыра. Үз чиратында драматург белән аралашу режиссёрга авторның иҗат методын, дөньяга карашын, стилен, үзенчәлекле якларын тоярга ярдәм итә. Бу исә әсәрне сәхнәгә куйганда, икенче төрле әйтсәк, автор фикерен артистлар уены аша тормышка ашырганда зарури. Икенче очракта режиссёр белән автор арасында бернинди дә уртаклык табылмый. Шуның нәтиҗәсе буларак, һәр ике художникның хезмәте бушка китә. Мондый үзара «ярдәм», бары тик җансыз характерлар, схематик геройлардан торган спектакль генә тудыра ала.

Режиссёр Х.Уразиковка авторлар белән эшләгәндә зур такт, эчке культура ярдәм итә. Ул бервакытта да үзенең фикерен өстен куймый, киңәш төсендә генә әйтә. Шуңа күрә аның белән эшләве һәрвакыт җиңел, иҗади атмосферада үтә.

«Хөсәен Уразиков, реалист артист буларак, режиссёрлык эшен дә реалистик формада корып җибәрә. Ул өстәл артында сүз сөйләүдән бигрәк, артистларның үзләре белән күбрәк шөгыльләнеп, образлар өстендә, һәр образның әсәрдә тоткан роле турында практик рәвештә, сүз, фикерне тамашачыга җиткерү турында эш алып бара». Т.Гыйззәтнең «Мин ничек артист һәм драматург булдым» дигән мәкаләсеннән алынган бу өзек Х.Уразиковның спектакльне эшләү методын ачык күзалларга мөмкинлек бирә.

«Хуҗа Насретдин» (Н.Исәнбәт әсәре, режиссёр К.Тумашев белән бергә куелган), «Каюм Насыйри» (М.Гали һәм Х.Уразиков әсәре), «Мулланур Вахитов» (Н.Исәнбәт), «Банкрот» (Г.Камал), «Хөррият» (М.Әмир) кебек беренче карашка агымдагы чор белән турыдан-туры бәйләнмәгән әсәрләрне дә Х.Уразиков чын мәгънәсендә заманча итеп куярга тырыша. Әсәрнең актуальлеген, билгеле булганча, сурәтләнгән вакыйгаларның спектакль барган көннәрдә булуы гына билгеләми. Иң мөһиме – сәхнәдә бүгенге тамашачыны дулкынландырырлык проблемалар чагылуы, заман кешесенең уй-хисләрен кузгатырлык геройлар гәүдәләнүе кирәк. Режиссёр Уразиков әлеге әсәрләрне сәхнәгә куйганда, әнә шундый принциплар нигезендә эш итә.

Х.Уразиков – татар театры өчен бик тә традицион булган реалистик режиссура вәкиле. Аның мондый программасы газета-журнал мәкаләләрендә, радио, телевидение чыгышларында атап әйтелмәгән. Ләкин ул – реализмны көндәлек тормышта, турыдан-туры спектакльләр кую процессында пропагандалаучы. Шуңа күрә аның әсәрләре тышкы яктан караганда да – «нәкъ тормыштагы кебек». Тамашачы алдында, һәрвакыт диярлек – дүртенче стенасы алынган гадәти йорт яки иксез-чиксез ерakларга китеп югалучы, йөрәккә якын табигать күренеше. Аларда – тормыштагы кебек көн һәм төн, яз һәм җәй, көз һәм кыш алышынышы. Бу шартларда «яшәүче» кешеләр дә табигый сөйләшәләр, тормыштагыча хәрәкәтләнәләр. Күренә ки, режиссёрның һәр сурәтләү чарасы – декорация, яктылык, музыка, реквизит, бутафория, театраль шау-шулар – барысы да сәхнәдә кешене, аның эчке дөньясын, уй-кичерешләрен, хисләрен мөмкин кадәр калкуырак гәүдәләндерүгә юнәлдерелгән. Әлеге принцип бүгенге көн режиссурасында яңадан алгы планга чыкты. Димәк, Х.Уразиков режиссурасы да актуальлеген югалтмаган.

Х.Уразиковның драматургия, театраль педагогика өлкәсендәге хезмәтләре дә җитди игътибарга лаек. Ул тәрҗемә иткән «Икмәк», «Гаҗәеп эретмә» (В.Киршон әсәрләре, русчадан) «Йөрәк серләре» (Б.Рахманов, үзбәкчәдән), үзе генә һәм Ш.Сарымсаков белән бергә инсценировкалаган «Тау чәчәге» (М.Ибраһимбеков), «Сәүбәновлар» (К.Нәҗми, «Язгы җилләр»), М.Гали белән берлектә язган «Каюм Насыйри» әсәрләре үз вакытында сәхнәдә шактый уңыш белән барганнар. Ул тәрбияләгән артистлар әле бүген дә республика театрларында уңышлы эшләп киләләр.

**Гали АРСЛАНОВ,**
*сәнгать фәннәре докторы, ТФАнең мөхбир әгъзасы,*
*Татарстанның атказанган фән эшлеклесе*

# БЕЗНЕҢ ОСТАЗ УЛ!

Факил Сафин татар әдәбиятын укып барган укучы өчен, беренче чиратта, үзенең «Гөлҗиһан» повесте, «Биек тауның башларында», «Саташып аткан таң», «Шәүлә» романнары, тирән мәгънәле лирик, шулай ук балалар өчен язылган шигырьләре белән таныш.

Мөслим районының Әмәкәй авылында туып үскән Факил Сафин, хезмәт юлын бик иртә башлап, төрле елларда колхозда механизатор, авыл мәдәният йорты директоры, авыл мәктәбе укытучысы, директоры, «КамАЗ» заводы эшчесе, газета-журналлар хезмәткәре, баш мөхәррир вазифаларын башкара. Бүген исә ул – ТР Язучылар берлегенең Яр Чаллы бүлеге җитәкчесе. Һәр яңа эш урыны, һәрбер яңа яшәү урыны – ул тормыш тәҗрибәсен үстерүгә, күзаллауларың үзгәрү, киңәю яисә яңалары формалашуга туры юл. Бай тормыш һәм хезмәт биографиясенә ия язучының әдәби әсәрләре дә дәүләт тарафыннан да (Факил Сафин Г.Исхакый, Г.Тукай премияләре лауреаты), киң җәмәгатьчелек тарафыннан да югары бәяләнә.

Факил абый җитәкчелегендә Яр Чаллы делегациясе 2023 елның август аенда Апаста узган Әдәби Сабантуйга кунакка барды. Әлеге Сабантуйда онлайн форматта узган *#әдәбимарафонга* йомгак ясалды. Мәйданга аяк басу белән, җөмһүриятебезнең төрле районнарыннан килгән китапның тугры дуслары – әдәбиятны яратып укучылар – Факил абыйны шунда ук танып алып, фотосурәткә төшәргә үгетли дә башладылар. «Без сезне укыйбыз, сезнең китапларыгызны яратабыз», – дигән җылы сүзләр әледән-әле яңгырап торды. Менә бу язучылыкның матур җимешләре, теләсә кайсы язучы өчен мәхәббәт сүзләредәй колагын иркәли торган назлы сүзләр бу дип уйлап куйдым мин ул вакытта. Китапларың китапханә киштәләрендә өр-яңа килеш тузанга батып ятмый, кулдан кулга йөреп укыла, таушалып тузып бетә икән, укучы тәмле тел белән язылган әсәрләрдән рухи ләззәт ала.

«Саташып аткан таң» трилогиясе һәм аның логик дәвамы булган «Шәүлә» китабын мин үзем мәктәптә югары сыйныфларда белем алган чагымда ук укыган идем. Еллар узган, ә романның төп геройлары – Әхмәтсафа Дәүләтьяров, аның яраткан хатыны Рабига, Рабиганың энесе, режиссёр Ширияздан Сарымсаков, аларның ачы язмышлары күз алдыннан китми. Реаль тарихи геройлар һәм чор тарихын чагылдырган бу ике китап, минемчә, татар әдәбиятында үз урынын тапты.

Әхмәтсафа Дәүләтьяров көчле кеше архетибын гәүдәләндергән герой буларак хәтеремдә калган. Үзе яшәгән системаны төзүдә катнашкан, аннан соң шуңа хезмәт иткән кеше шушы ук системаның корбанына әверелә. Хатыны Рабиганың ачы хәсрәте, әтисен дә, әнисен дә югалткан ике ятим баланың башларына төшкән гомерлек кайгысы укучының йөрәге аша уза. Бу бит безнең татар тарихы, безнең әби-бабаларыбызның башыннан узган хәлләр дигән уй әйдәкләп бара романны укыганда. Рабиганы ире канаты астында, яклауга-саклауга, яратуга төреп, балалары янәшәсендә күрәсе килә дә бит. Заман җилләре аны да, иң сөекле якын кешеләреннән аерып алып, нахакка башын төрмәдә черетә. Трилогиянең дәвамы булган «Шәүлә» тулаем Рабига язмышына багышлана, аның хатларыннан гыйбарәт. Китапны укып чыгар өчен дә көчле йөрәк

кирәк! Гаделсезлек, нахак сүз меңләгән җанны кыйган бит ул чорда. Дәһшәтле узган гасырның 30 нчы еллары азагы турында сүз бара. Бу әсәрен иҗат иткәндә, Факил Сафин әдәби сүз остасы буларак та, документаль фактларны өйрәнеп, шәхес язмышы аша чорга бәя бирүче тарихчы буларак та ачыла.

Факил абый – шәхсән минем өчен остаз-мөгаллим дә әле ул. Әлеге дә баягы Яр Чаллының 52 нче татар мәктәбендә белем алып, журналист, шагыйрь булам дип хыялланып, төрледән-төрле бәйге, олимпиадалар, шәһәрдә уздырылган чараларда актив катнашып яшәгән чорда аның әдәби остаханәсенә килеп эләктем. Бер шәлкем шигырьләрем – шагыйрь абый кулында. Мин каушау, куркып калудан урындыгымда тик кенә утыра алмыйм: ни әйтер? Нинди үзем күрмәгән җитешсезлекләргә төртеп күрсәтер икән? Шул вакытта шагыйрьнең кулына килеп эләккән шигырьләремнән ике юл гына хәтеремдә калган:

*Чулман тигез чайкала.*
*Баржалар алга таба...*

Факил абый шушы юлларны укый да уйланып тора. «Чулманның чайкалуында поэтикалык бар кебек. Нәрсәдер җитешми монда. Инверсия кулланырга мөмкин. Тирәнрәк образлар кирәк...» Аннан соң тагын бер-ике юл, тагын... Һәр юлны шулай сүтеп җыя. Бик күп урынлы тәнкыйть белән бергә шактый гына уңышлы чыккан юл бу дигән сүзләрне дә ишетәм ул вакытта. Алардан күңелемә җылы йөгерә. Бу дәресләр мине шигырь язу осталыгында шактый гына чарлый: шигырь төзелеше, рифма-ритм бөтенлеге, цезура, образлылык кебек төшенчәләрне бик гади итеп ачып сала остазым. Имәндә икән чикләвек, нигә миңа моны элегрәк татар теле дәресләрендә әйтеп бирмәделәр икән, мин бөтенләй башкача яза алыр идем бит дигән нәтиҗәләр ясыйм үзем өчен. Журналист булам дип хыялланып йөргән җирдән мәктәпне тәмамлагач, ул вакытта КДУның татар филологиясе һәм тарихы факультетына юл тотам. Тарихны чамалы гына беләм – тарих төркемен сайлыйм. Факил абый салган шигърият сукмагына чүп үләне үсми бирәдә дә: «Иделем акчарлагы», «Шигъри Сабантуй»ларда җиңүче даны – минеке. «Әллүки» әдәби иҗат берләшмәсе утырышлары – бүген сагынып сөйли торган матур хатирә инде.

Әйләнмәле-борылмалы тормыш юлларыннан янәдән шигърият, әдәби иҗат юлына аяк басуымда да Факил абыйның роле әйтеп бетергесез. Һәр сирәк-мирәк очрашуыбызда ул шуны искәртеп килде: «Иҗатың бар. Китабыңны чыгарырга кирәк». Мин һәрвакыт шигырьләр җыентыгымны чыгарасым килә дип яшәсәм дә, кулъязманы туплап, нәшриятка илтеп тапшыруны сузып килдем. Ниһаять, узган җәйнең июнь аенда Факил абый җитәкләп диярлек мине Казанга нәшриятка алып китте. «Безнең арттан дәвам үсеп килмәсә, эшләгән эшебезнең бер мәгънәсе дә юк. Ныклы адымнар белән яшь иҗатчылар килергә тиеш бүгенге әдәбиятка. Айзирә Имамованың җыентыгын күрдек. Хәзер синекен күрергә насыйп булсын. Түбән Камада яшәп иҗат итүче өметле шагыйрә Алия Зартдинова да әзерләр әле китабын, – дип сөйли ул. – Лилия Гыйбадуллина, Йолдыз Миңнуллина, Рифат Сәлах, Резеда Гобәева, Рүзәл Мөхәммәтшиннар бер шаукым булып килеп керделәр бит әдәбиятка. Менә хәзер безнең төбәктән син, Айзирә Имамова, Алия Зартдинова, Искәндәр Ишалин үсеп, үз сүзегезне әйтә алачаксыз дип ышанам мин». Факил абый шундый зур ышаныч белдерә икән, артка чигенергә, үз-үзеңә түбән бәя биреп, һаман «язсам ярый, язмасам да, бик хуш» дип кенә селкенеп йөрергә хакыбыз юк инде!

Факил Сафин – Кама аръягы шәһәрләре һәм районнары язучы-шагыйрьләре өчен оста оештыручы да әле. 1991 елда ул Чаллыда «Аргамак» журналын оештырып җибәрә, 2001 елда чыга башлаган «Мәйдан» журналының башында да ул тора. Шул ук вакытта әдәби иҗат белән рәсем, музыка сәнгате арасында күпер салучы да ул.

Иҗатчылар өчен уздырылган чараларда һәрчак рәссам, җырчы, композиторларны да күрергә мөмкин. Татарстанның халык рәссамы Мәдияр Хаҗиев болай ди: «Факил дустым мине бу чараларга чакырып тартып китермәсә, милли рухым сүрелүгә таба бара иде. Әйтик, Балык Бистәсенә сәяхәттән соң, миндә милли рух яңа көч белән күтәрелде, илһамланып иҗатка тотындым. Татар яши, яшәячәк дигән зур ышану белән кайттым мин ул сәяхәттән».

Әйе, ел да Факил Сафин кырыкка якын төбәк иҗатчылары өчен Татарстанның төрле районнарына сәяхәт оештыра. 2023 елның июлендә Балык Бистәсе районына оештырылган шундый сәяхәттә мин дә катнаштым. Моңа кадәр Чаллы – Казан юлы өстендә кала торган ниндидер бер район итеп кенә күргән Балык Бистәсе бөтенләй башка яктан ачылды минем өчен дә, башка иҗатчылар өчен дә.

Яңа Сала авылындагы Нурулла Гарифның шәхси татар тарихы музее, Юлсубино (Балтач) авылында халык шагыйре Равил Фәйзуллинның туып үскән нигезендә булу, аның исемен йөрткән мәктәптә ачылган музеен күрү, шагыйрьнең үзе белән күрешү, Үзәк китапханәдә укучылар белән очрашу – сәяхәтнең онытылмас матур мизгелләре.

Шунысын да әйтеп китмичә булмый: Факил абый – балалар өчен дә оста, үз итеп яза торган шагыйрь. Аның әти-әни, туган тел, туган нигез – йорт темаларын матур итеп ача белүе, гади көндәлек вазгыятьне көлкеле дә, гыйбрәтле дә хәл итеп сурәтләп бирә алуы таң калдыра. Сабыйларның күңелен күрә белә шул шагыйрь абыйлары, гади сорауларга тирән җаваплар эзли ул. Аның «Камиләгә кем кирәк?» шигырендә («Кошлар яратучы малай», Казан, 2013) балалар өчен булган иҗатында яктыртылу алган бөтен темалары кереп сыйган кебек:

*Үссен өчен тизрәк,*
*Камиләгә бик кирәк:*
*Әнисе дә, әтисе дә,*
*Әбисе дә, бабасы да*
*Көн дә аңа бик кирәк.*
*Тагын – туган Татар иле,*
*Туган-үскән җир кирәк,*
*Татлы туган тел кирәк!*

Чын татар шагыйре һәрчак бәхетле балачак, туган ил, туган тел турында уйлана!

Бүгенге көндә Яр Чаллыда Факил Сафин әдәби остаханәсе эшләп килә. Ул Чаллыда һәм якын-тирә шәһәр-районнарда яшәп иҗат итүче каләм әһелләрен бергә туплау, очрашулар оештыру, иҗатларын бәяләү, үсеш өчен юллар күрсәтү максатын алга куя. Аерым башлап иҗат итүче шагыйрь яисә язучының әсәрләре дә тикшерелә бу остаханә утырышларында, автор үз шигырен укып, аңа бәя бирү форматы да бар. Шунысы куанычлы: әдәби иҗатка тартылган мәктәп укучылары да, югары уку йортлары студентлары да якын килә бу җылы учакка. «Чаллы төбәге иҗатчылары көчле бит ул! Сезне күзәтеп барам, сезгә сокланам», дигән фикерләрне олпат язучы-шагыйрьләребездән ишетергә туры килгәндә, һәрчак: «Әйе шул, безнең Факил абый бар. Ул барыбызны да барлап, җыеп, үсендереп тора», – дип җавап кайтарам.


**Гөлназ НУРИЕВА**



*Күренекле кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматов татар язучылары һәм журналистлары белән. 1972 ел.*




*Әлмәт язучылары киңәшмәсендә. 1972 ел, 19 декабрь. Рафаил Төхфәтуллинның (фотода уртадагы рәттә сулдан икенче) 2024 елның 1 гыйнварында туууына 100 ел тула.*



*Әдипләрнең очрашкан чагы. Әхәт Гаффар (сулда) белән Равил Фәйзуллин. 2024 елның 1 гыйнварында Ә.Гаффарның туууына 75 ел тулды.*



*«Казан утлары» журналы редакциясе мөхәррире Лилия Гатауллина.*




*«Атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре» исемен алган көнне. 2013 ел.*



*«Казан утлары» журналы редакциясе коллективы. Утырганнар (сулдан уңга): Гөлзадә Бәйрәмова, Флёра Сабирова, Рәдиф Гаташ, Лилия Гатауллина. Басып торалар: Наис Гамбәр, Мансур Вәли-Барҗылы, Марсель Галиев, Гөлназ Хөснетдинова, Рашат Низами. 1994 ел.*



*Юбилей көннәрендә дуслары һәм хезмәттәшләре янәшәсендә. Лилия Гатауллина беренче рәттә сулдан алтынчы. 2023 ел.*

## Иштван Даби хаты

*13.08.1978*
*Венгрия*

Газиз Марсель!

Мин хатыгызны, татарча-русча сүзлекне һәм шигырьләрегезне күптән алдым. Зур рәхмәт!

Сезгә җавапны бүген генә бирә алам, чөнки хәзергә кадәр эшем күп булды.

Сез миңа татар әдәбияты белән танышырга ярдәм итә аласызмы? Җавабыгызны көтәм.

*Сәлам белән, Иштван Даби.*

## Разил Вәлиев хаты

*18.08.1983*
*Пицунда*

Марсель туган!

Менә, ниһаять, күңел утырып җиткәч, сиңа хат юлларга булдым.

Соңгы арада җаннар соң дәрәҗәгә җитеп талкынган – күңелгә тынгы таба алмыйча, монда килгәч тә, шактый иза чиктем. Аннары мондагы һәр агач, һәр атлаган җир нәрсәнедер искә төшерә, хәтерне яңарта. Шул чакларда йөрәкләр өзелеп төшәрдәй була.

Илдар абый, гадәттәгечә, Муса Гали бар. Алар белән көн саен дөньяны сүтеп җыябыз. Давыт Көгелтинов зур башын югары чөеп, яңа чабыштан килгән шәп айгыр шикелле йөри.

Бер инде монда хәлләр.

Теге көнне сездән аерылгач, машинаны подъезд төбенә куеп, өйгә кереп йоклаган идем, иртән торсам, дүрт тәгәрмәчнең дүртесен дә салдырып алып киткәннәр. Чаллыдан тәгәрмәч китертеп, көне буе шуның артыннан йөрдем. Кемдер каныга бугай миңа. Ярый, хәерлегә булсын, без күрәсен бүтәннәр күрмәс.

Мин 29ында кайтам, самолёт белән. Син киткән булырсың шул. Күрешә алмыйбыз, жәл!

Ярый, хуш, хәерле юл сиңа!

Мәскәүне яулап кайт!

*Сәлам белән, Разил.*

## Клара Булатова хаты

*18.11.1988*
*Әлмәт*

Шулай дөнья. «Ятимнең авызы ашка тисә, борыны каный». Конференция эшендә Марсель Галиевлар, Нәбирәләр катнаша дип, Әхәт Гаффар куанып кайтып әйткәч, иң элек дүртаяклап үрмәләп, бөтен бүлмәләрне юып чыктым. Үземчә бик оста итеп дерелдек кайнаттым, пилмән ясап куйдым.

Гафифә, Сәрия, Зәлидә исемле кызларымның кулдан язган шигырь төргәкләрен укып чыктым да, Марсель дә танырлык булсын инде дип, күңелгә хуш килер сыман тоелганнарын Нәфистән күчертеп яздырттым. Мактама «чебураш»ларын чакырып торуны кирәк санамасалар да, Ленарның «Мәктәп», Лененың (апалы-энеле

Маннангуловлар болар, өметле бала икесе дә) «Сез дә язылыгыз!» дигән шигырьләрен дә шул өемгә өстәдем. «Рус мәктәбендә укучылар да татарча шигырь язалар бит әле бездә!» – дип шаккатырмакчы идем теге халыкны.

Шул. Нәтиҗәдә кан басымы зерә матур котырып күтәрелгән дә күзгә бәргән. Үземне сөйкемле генә бер ашыгыч ярдәм машинасына утыртып, соңгы ун елның кимендә ел ярымында «пропискада» булган шушы изге йортка китереп аударганнар. 2 февраль булган бу. 4-5 февральләрдә минем көткән кешеләрем Әлмәттә бит инде! Бер күземнең яртысы ачылды, торып йөри башладым. Бүлектә сестраларга әйтә куйдым бит. «Шулай, шулай, минәйтәм, язучылар Әлмәткә җыелды. Алар, мин әйтәм, бик игелекле халык. Әлмәт тикле Әлмәткә килеп җиткәч, мин бичараны ничек тә күреп, хәл белеп китәләр инде алар, мин әйтәм. Аның Марсель Галиев дигәне ил алдында кычкырып ук әйтмәсә дә, шушы як егете булгангадыр, мин әйтәм, мине бигрәк тә үз күрә, килми калмас, дидем. Нәбирә дә – килүчеләр арасында бер хатын-кыз, илтифатсыз калмас, дидем. Минем сәеррәк якларымны да беләләр, мөгаен, «больницага алып килү тыела» дигән белешмәдән карап, тозлы балык, колбаса, кара уылдык, торт кебек әйберләрне дә төяп килерләр, алары өчен дә сүз әйтмәссез дип, алдан кисәтеп куйдым. Чәчәкләрне кибеттән булмаса, базардан алып килә инде алар, акчадан тормыйлар, мин әйтәм.

Ышанды бит беркатлы халык. Тотындылар мин сиңа әйтим, палаталарны, коридорларны, стеналарны, идәннәрне порошоклап юарга. Авырып ятучы шагыйрәләренең хәлен белергә тере язучылар килә бит!

Безнекеләрдән күреп, бүтән отделениеләр тотынды. Өмә. Медсанчастьтан да бер иптәш Управлениеләрнең берсендә эшләүче җиңгәсен китереп яткыру турында эш йөртергә дип кереп чыккан арада бу хәлне күреп, мөгаен, астыртын гына берәр комиссия килә торгандыр дип кайтып, үзенекеләрне дә күтәргән, диделәр. Мондагыдан да ялт иттергәннәр, диделәр, анысын.

Ярар, үзебезгә кайтыйк. Минем постельне көн саен алыштыралар. Умывальник почмагына әллә өч, әллә дүрт тапкыр инде теге «Майский» дигән сафландыргыч препаратны сиптереп чыктылар. Каян тапканнардыр, Әлмәттә күренгән әйбер түгел. Аны сорап керсәң, хуҗалык кибетләрендә: «Айдан төштегезме әллә? Аларны бит инде әллә кайчан алкашлар эчеп бетерде», – дип торалар. Тәрәзәгә яңа пәрдә элделәр. Палатага электр самовары кереп утырды. Сестра-хозяйка иңе-җиңе таман яңа халат та табып бирде үземә. Бөтен сәдәфләре исән, кесәсе дә ертылмаган, поясы да бар. Миңа гына инде, берүземә. Ну, авырулар сүз әйтми. Хәтта дару таратканда, «Нигә теге хатынга өчәрне бирәсез, миңа берне генә?» – дип тавыш чыгаручылары да каршы түгел. «Бездә аерым палаталар дәгъвалаучы начальниклар да контор саен, председательләр дә колхоз саен, ә менә шагыйрәбез берәү генә бит безнең!» – дип кенә җибәрәләр.

Ирләр башындагы пенсионер Бәхти абыйга кадәр чәчен, чәчен генә түгел, алагаем тырпайган кашларына хәтле май сөртеп тарады, пижамасын алыштырды. «Кайчан киләләр инде Марсель Галиевлар, Клара Булатова апаем?» – дип, пылт итеп палатага килә дә керә, килә дә керә.

Шул. Әле кичә пенсия акчасынамы, тугыз катлы өйдә коридор юып алган өстәмә акчасынамы сатып алган чәчәкләрен күтәреп, элекке укытучы Сәлимә апа килеп китте (юләр Сәлимә дип йөртәләр инде мескенкәйне, авырый шул. Ә нинди белемле, тырыш укытучы иде!..). Язучылар килгәч үткәрелгән әдәби кичәгә барган булган. Шунда кемнәндер сорап, минем монда ятуымны белгән дә килгән менә.

Бүген Рафиуллин базар йөреп кайтты. Каләмдәшләрем исеменнән алып кайткан күчтәнәчләрне рәхәтләнеп таратып чыктым әле авыруларга. Әле беренче каттагы Сөләйманга да ике лимон, бер әфлисун төшердек. Азәрбайҗан ул. Татар язучыларын да, җиләк-җимеш, чикләвек ишеләрне үлеп ярата.

Аннан соң әле менә теге көннәрдә Колшәрип, Кәләй тирәсендә йөргәндә, иптәшләрнең берсе: «Менә шушы тирә бит инде ул безнең Булатованың яшьлегенә

кушылып җырлаган Дөмәй буйлары», – ди, үзәкләре өзелеп бөгелеп төшә дә, ди, Марсель Галиев белән Рөстәм Мингалим тамакларына килеп тыгылган төерләрен йота алмый интегә, Нәбирә Гыйматдинова яшьле күзләрен кая куярга белми, өчәүләп: «И, бичара Клара апа! Исән чакларыңда нишләп кадерләреңне белмибез икән соң?!» – дип, бик гаҗизләнәләр икән, ди.

Менә әле хәзер генә мин яткан терапия бүлеге коллективына заманча тизлек һәм инициатива белән планнан тыш олы җыештыру үткәргән һәм үзләре үрнәгендә шул мөһим эшкә бөтен үзәк больницаны күтәргәннәре өчен администрациянең рәхмәт белдерүе турында хәбәр иттеләр.

Язучыларның ярдәме тиде алай да...

## Флёра Сафиуллина хаты

*28.03.1998*
*Казан*

Үзгәртеп кору әдәбиятка да фикер хөрлеге алып килде. Берәүләр бу хөрлекне теләсә нәрсә язу, теләсә ничек язу, чиксез бер тәртипсезлек итеп кабул итсәләр, икенчеләр өчен «хөрлек» сүзенең эчке бер мәгънәсен, аның артында яткан тарихи катламнарны гына түгел, сүзнең аһәңен, ямен-тәмен белеп, тел дәрьясының төпкелләренә төшеп, мәрҗәннәр эзләп табуны өстенрәк күрделәр.

Марсель Галиев үзенең элеккеге иҗаты белән моңа әзер иде. Аның әсәрләрендәге фикер хөрлеге, андагы чиксез ассоциатив бәйләнешләрне туган телебезнең аһәңле яңгырашы аша бирү осталыгы, телебезнең сәнгати бөеклеге зәвыклы укучыны үзеннән ычкындырмый, түбән тормыш ләззәтләреннән азат югарылыкка күтәрә, әдәби телебез өчен күңелләрдә горурлык хисе уята.

«Догалы еллар» шундый гүзәл бер тәэсир калдыра. Бу җыентыкка эссе-сурәтнамәләр, заман-чор, әдәбият хакында фәлсәфи-лирик уйланулар туплап бирелгән. Монда әдипнең 60-90 еллар әдәби-мәдәни тормышына караган гаҗәеп язмалары урын алган. Әдип өчен иң изгесе – туган җир, туган туфрак, Чатыр-тау... Әдипне дөньяга шулар тудырган бит. Ә әсәрендәге шәхесләре нинди!.. Болар – композитор Рөстәм Яхин, язучы Мөхәммәт Мәһдиев, шагыйрь, әдип Нәби Дәүли, әдәбият тәнкыйтьчесе, Җәлил иҗатының мирасчысы Гази Кашшаф, тел остасы Хәсән Сарьян, шагыйрь һәм галим Мостафа Ногман, соңгы чор иҗаты белән яшьнәп алган Мәхмүт Хәсәнов, нәфис сүз остасы Фәйзи Йосыпов, «оча торган татар» Рудольф Нуриев, әдәбиятыбызның аксакалы Әмирхан Еники, шигърияткә аргамактай ярсып кергән Равил Фәйзуллин, әдип, драматург Аяз Гыйләҗев, моң иясе Илһам Шакиров...

Шуларның берсе турында гына язу да нинди авыр һәм җаваплы эш. М.Галиев дистәләрчә еллар буе үзе белгән татар мәдәни һәм әдәби мохитен яза. Бу затлы шәхесләр аша Марсель Галиев сак кына, нәфис кенә тормыш фәлсәфәсен бирә, күпмедер бәя бирә, мөнәсәбәтен белдереп куя.

Татар әдибенең бу дәрәҗәдә дөнья кешесе булып күренгәне юк иде әле. Гомеренең күп өлешен төрле диңгезләрдә, океаннарда йөзеп үткәргән һәм татар тормышына «читләргә китеп карап» язган Миргазиян Юныс бу юнәлештә беренче булгандыр. М.Мәһдиевнең язмаларын да без бер дөнья эчендә яшибез дигән мәгънәдә укыган идек. Р.Фәйзуллинның Испан корридасы турында язганнары хәтердә... Татар әдибе – мескен түгел, аның илаһи күңеле, шанлы ата-бабалардан калган эчке бер горурлыгы аны бу дөньяның бөекләре рәтенә этәрә кебек...

Татар авылының гап-гади гаиләдә туган гап-гади баласы галәм шагыйре дәрәҗәсендә фикер йөртә, бу бөек, серле-тылсымлы фикерләр гүзәл бер хикәяләү барлыкка китерәләр.

Бу әсәрдә – хөр фикернең иркекле агышы; бу әсәрдә – халкыбызның ачы язмышы,

аның данлы үткәне белән горурлану; бу әсәргә «татар феномены»ның асылын аңларга һәм укучыларга аңлатырга тырышу; бу әсәрдә күңелне ярып кергән һәм инде һәрвакыт синең белән калачак кыйссалар, риваятьләр, вакыйгалар...

Бу язмаларның укучы буларак миңа тәэсире турында сүзләр белән язып бирү мөмкин түгел. Минем тел байлыгым моңа көчсез. Ләкин аларны укыганда, мин дулкынланып, шатланып, горурланып, күземә яшь килеп, тамагыма төер тыгылып укыдым. Сөендем... Шундый әдәби тел булыр икән!.. Һәр язган сүзе энҗе кебек. Аның һәр җөмләсен мәктәп дәреслегенә мисаллар итеп кертергә мөмкин.

Һәр сүз урынында, бер җирдә дә төртелмичә укыйсың. Сүз могҗизасы таң калдыра. Соңгы еллар татар прозасында бу дәрәҗәдә затлы, нәзакәтле, аһәңле яңгыраган татар теле юк иде кебек. Аның язмаларына (һәм җырларына да!), әдип үзе язганча, «борынгы бабайлар авазын алып килгән җил пышылдагандыр» һәм Марсель бу күренешне ихтыярсыздан кәгазьгә төшергәндер кебек тоела.

Әдәби портретларда шәхесне бизи торган, күтәрә торган хәлләр, вакыйгалар лирик-күтәренке рухта тасвирлана. Халык күңелендә алар шундый биеклектә саклансын өчен эшли торгандыр моны Марсель. Дөрес эшли... Болай язарга Марсель Галиевне мәгърур Чатыр тау «өйрәткән икән». Чатыр тау үстергән икән әдипне: «Уй-хыялларыңа канат куяр өчен шушындый лаек биеклек кирәк икән. Бу кодрәт каршында үзеңнең бик кечкенә зат икәнеңне беләсең, әмма Тау үз биеклеге белән исертеп, сиздермичә генә олылау хисе – юаныч бирә, күңел дөньяның офык сызыгына тоташа да... йөрәгең Тау йөрәге белән бер аһәңдә тибә башлый...» Марсель Галиев сурәтләве дә шушы борынгы, юмарт җилле, бөек хисле Чатыр тау кебек...

Марсель Галиев әдәби портретлар остасы икәнен бу язмаларында тулысынча күрсәтә алган. Андагы шәхесләрне бер ымнан, бер сүз-гыйбарәдән, бер гамәлдән танып була. Татар халкының күренекле затлары күңелгә Марсель күрсәткәнчә, йә матурлык, йә җорлык, йә милләтпәрвәрлек, йә үзәк өзгеч моң, йә юмарт күңеллелек, йә Ходай биргән затлы сәләт белән кереп калалар. Һәр шәхес үзенчәлекле сурәтләүләр белән ачыла. Бу язмаларда татар әдәбияты һәм теле мөгаллимнәренә никадәр байлык тупланган!

М.Галиев шигырьдән прозага килеп керде. Шигырьдә камиллекнең чиге юк. Шулай да, шагыйрь М.Галиев үзен прозада күбрәк ачкандыр дип уйлыйм. Шигъри теле белән прозада да шагыйрь булу дәрәҗәсенә күтәрелде ул...

Марсель Галиев – прозада шагыйрь, рәссам. Аның буш сүзе юк. Һәр сүз мәгънәви, интонацион җегәргә ия. «Мәҗүси җил», «Тауның текә маңгае», «балыклары сикереп чыгып, арба тәгәрмәченә урала торган күлләр», «билгә каеш итеп урарлык йөгерек юллар», «саллы имәннәр янәшәсендә чытлыкланып бөтерелгән көяз каеннар», «сөтле чәй кебек нурлы йөзле әбиләр», «Түбән оч парламенты»; «Анда – бала чагында моңлы азан тыңлап үскән иманлы буынның моңсу картлыгы чал күбекләрдә чагыла»; «җил ашаган тау ташы сыман күпне күргән чырай» һ.б.

М.Галиев – фәлсәфи гомумиләштерүләр остасы. Бу сентенцияләр – кысылган код кебек. Мондый саллы гыйбарәләр бер минутта гына тумый торгандыр, аларның сүз җегәрен, мәгънәви катлауларын нечкә тоемлау нәтиҗәсе.

Менә Туфан:

«Туфан – бөек Тукайның имгәтелгән дәвамы иде.

Туфан – канаты киселгән җәяүле кош иде.

Туфан – эчке әрнүен җиңгән, ак уйлы, үтәли күренгән өрфия җанлы шәхес иде». Бу җөмләләрдә Туфан үзе. Рөстәм Яхин турындагы бер җөмлә хәтергә уелып кала: «Татарның ул – бәхетле сагышы»... Яисә Испаниянең Севилья шәһәре турындагы нәфис гыйбарәләр гаҗәеп яңгырый:

«Севилья – тәмле авазларның төсле яңгырашы.

Севилья – зәйтүн агачына кунган яшь испан сандугачының таң нурында коенуы».

Ә Лорканы автор болай ди: «Лорка – гаҗизанә язмышлы испан халкының йөрәге ярылган гитарасы». Илһам Шакировка багышланган юлларны горурланып укыйсың: «Син – кара урман Иясе, моң Иясе...», «гасыр улы», «туган халкыңның күңел күгенә күтәрелгән тургай, солтанатлы талант иясе».

Диварларга язып куярдай канатлы сүзләр итеп татар җырына багышланган ун гыйбарә тетрәндерә, йөрәкне еш-еш типтерә, сулыш ешая, сүзләрнең көтелмәгән, ләкин акланган бәйләнешләреннән бугазга төер тыгыла. Болай итеп Марсель Галиев кына әйтә ала:

«Татар җырында – Биек Кытай дивары артындагы борынгы чин халыкларына күчкән ефәктәй нәфис көй бормалары бар... Татар җырында Алтын Урданың җилгә изүен ачкан балбаллы япан далаларында Идегәйдән илсез калган мосафир-кыпчаклар яккан учакларның әрнүле күмер пышылдаулары бар»...

М.Галиев гаять иркен итеп, табигый гына, рәхәт, җай гына дөнья буйлап, замана буйлап гизү osталыгына ия: аның хикәяләвендә көтелмәгән тарихи бәйләнешләр, янәшә куюлар дөнья тарихының бербөтен икәнлеген күрсәтәләр, бу дөньяда төркиләрнең, татар халкының үз цивилизациясе һич тә ким булмавын тулысынча дәлилле аңларга мөмкинлек бирәләр: туган якның йөзек кашы булган Чатыр таудагы байбаклар һәм кар түбәле Һималай кыяларында яшәүче байбаклар; Балтач авылы һәм Идегәйнең әтисе бәкләр бәге Балтачы; рус академигы С.Паллас, Екатерина II һәм Чатыр Тау; Испания һәм Шәрык дөньясы...

Марсель Галиев кадәр нечкә-назлы юморлы язучыны белмим. Н.С. Хрущёвның Азнакай якларына килү вакыйгасы ни тора! М.Галиев «горурланып»: «Миңа да тарих җиле кагылып узды», – дип елмая. Ә әдәби портретлардагы нәзакәтле, сак, нәфис ихтирамлы юмор авторның әдәби шәхесләргә никадәр ихтирамлы, хәерхаһлы булуы турында сөйли. М.Галиев олпат фәлсәфәче, үзенчәлекле тарихчы әдип буларак, елдан-ел үсеп килә. Аның һәр кыйссасы, затлы шигъри юлларны эпиграф итеп алып, халкыбыз тарихының теге яки бу чорын гаять бай, мул сурәтләр белән тасвирлый. Бу тарих – канлы, фаҗигале, кимсетүле... һәм горур. Шәрык горурлыгы бу! Хикәяләүнең кайчак моңсу да, авыр сагышлы интонациясе көчле рухлы, үткәндәге һәм киләчәктәге оптимистик интонация белән алмашынып бара.

Әдипнең бу язмаларын гадәти үлчәм белән бәйләп булмый. Ул язган телне шәрехләү мөмкин түгел. Затлы сәнгать үрнәкләрен карап туя алмаган, сүз белән аңлатып бетереп булмаган кебек, Марсель язганнарны да үзеңә укырга кирәк.

Бу китап укучыларда югары әдәби зәвык тәрбияләүдә гаҗәеп бер илаһи көч булуына шигем юк. Марсель Галиев әсәре шушы тотрыксыз, керләнгән, куркыныч, ямьсез заманда нур чәчеп, «менә безнең нинди гүзәл телебез бар!» дигән горурлык хисе уята. «Әдип» сүзенең нинди зур көчкә ия булуын тагын бер дәлилли.

*Профессор Флёра Сафиуллина.*

*Фәрит Яруллинның тууына – 110 ел*

# КҮПМЕ ҖЫРЛАР ҖЫРЛАНМЫЙЧА КАЛГАН



Бу юлы без журнал укучылар игътибарына композитор Фәрит Яруллин әсәрләрен тәкъдим итәбез. Шушы аһәңсазның иҗатына мөрәҗәгать итүебез һич тә очраклы түгел: күренекле композитор, беренче татар балетының авторы, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Фәрит Яруллинның тууына 110 ел тулды.

gabdullatukay.ru сайтында урын алган мәгълүматларга караганда, татар халкының сөекле композиторы Фәрит Яруллин 1914 елның 1 гыйнварында Казан шәһәрендә, танылган музыкант Заһидулла Яруллин гаиләсендә дөньяга килә.

1923–1930 елларда Яруллиннар Уфада яши, аннан янә Казанга әйләнеп кайта. Фәрит кечкенәдән музыка сәнгатенә гашыйк булып үсә. 1930 елда ул музыка техникумына укырга керә, виолончельдә һәм фортепианода уйнарга өйрәнә.

1933 елда талантлы яшь музыкант Мәскәү консерваториясе каршындагы рабфакка композиция классына укырга җибәрелә, аннан соң ул Татар опера студиясендә композиция буенча дәресләр ала. Биредә атаклы педагог Генрих Литинский Фәрит Яруллинның өлкән остазына һәм дустына әверелә. Аның хәер-фатихасы белән балет жанрына беренче адымнарын ясый. Студент елларында Фәрит Яруллин фортепиано, скрипка һәм виолончель өчен күп кенә сонаталар да иҗат итә.

1939 елда Фәрит Яруллин Габдулла Тукай әкияте буенча «Шүрәле» балетын иҗат итә. Әсәргә либреттоны Әхмәт Фәйзи яза. Спектакльне сәхнәгә чыгарырга әзерлек барган бер вакытта Бөек Ватан сугышы башланып китә. Фәрит Яруллин 1941 елның июлендә армия сафларына алына һәм хәрби пехота мәктәбенә җибәрелә. Аңа Бөек Җиңү көнен күрү насыйп булмый. 1943 елның 17 октябрендә Австрия башкаласы Вена шәһәрен фашистлардан азат иткәндә, батырларча һәлак була. Ул күңелендә йөрткән яңа әсәрләр әнә шул мизгелдә үзе белән бергә мәңгелеккә китеп бара.


«Шүрәле» балеты беренче тапкыр Казанда 1945 елның мартында Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында куела һәм чын-чынлап халык күңелен яулый. Тагын биш елдан балет Ленинградта Киров исемендәге опера һәм балет театрында сәхнәләштерелә. Казанда Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында «Шүрәле» балеты тагын 1952, 1957, 1970, 1986 һәм 2000 елларда куела.

Шунысын әйтергә кирәк, музыка сәнгате тарихына Фәрит Яруллин исеме беренче татар балеты авторы буларак кереп калды һәм 1958 елда, ягъни вафатыннан соң күп еллар узгач, шушы әсәре өчен аңа Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә.

Хәзер инде, әйдәгез QR-код ярдәмендә журналның сайтына кереп, Фәрит Яруллин әсәрләреннән төзелгән концерт тыңлыйк. Төрле елларда башкарылган әлеге язмалар Татарстан радиосы фондында саклана.

*Әхәт Гаффарның тууына – 75 ел*

# УЛ ҮЗ ЧОРЫН ТӨПТӘН АҢЛАП ЯЗДЫ



Язучы-прозаик, драматург, журналист, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, М.Горький исемендәге әдәби конкурс лауреаты Әхәт (Габделәхәт) Габдрахман улы Гаффарның (Гаффаров) (1949–2021) тууына 75 ел.

Татарстан радиосы архивында Әхәт Гаффар иҗатына бәйле язмалар шактый. Әйтик, һәр елны яз айларында Минзәлә татар дәүләт драма театрында куелган «Язлар моңы» спектакленең радиоварианты эфирга бирелә, Сабан туе көннәрендә «Сөлгем уртасында – Җир шары» дигән радиокомпозиция яңгырый. Артистлар укуындагы хикәяләре дә әледән-әле тыңлаучылар игътибарына тәкъдим ителә. Шулай ук Ә.Гаффарның үз тавышы сакланган язмалар да байтак. Болар – үзе укыган әсәрләр, публицистик чыгышлар, әңгәмәләр. Шулар арасында 2017 елның июлендә яздырылган тапшыру, безгә калса, аерым урын алып тора. Чөнки биредә әдипнең тормыш юлы да, дөньяга карашы да, әдәбиятка, халыкның киләчәгенә кагылышлы фикерләре дә тулы чагылыш тапкан. Журнал укучылар игътибарына без нәкъ менә шушы тапшыруны тәкъдим итәргә булдык.

Укучыны кызыксындыру өчен әңгәмәдә яңгыраган берничә фикерне кәгазъгә күчерик. Әйтик, тапшыруны алып баручы Әхәт Гаффарга болай дип дәшә:

– Зур иҗат юлы узган бер әдип каршында утырам. Син безне яшүсмер вакытта шактый елаткан кеше. Гадәттә бит шигырь укып елыйлар. Ә Синең «Әҗәт» дигән китабыңны укыганда бүтәннәргә күрсәтмәскә тырышып елаганнар бүгенгедәй истә. Үзең гомер буе проза яздың, тик менә елата алгансың икән, димәк, Син шагыйрь дигән сүз бит.

– Шагыйрьлек бардыр, әлбәттә, чөнки мәктәптә өченче-дүртенче классларда укыганда ук инде үзебезнең Балык Бистәсе районындагы «Октябрь юлы» дигән район газетасында минем шигырьләрем басыла иде. Шигырь язудан башланадыр инде ул әдәбиятка килеп керү.  Ә проза ул соңрак килә.

– Каләм уйнату бармы әле ул һаман да?

– Эш дәвам итә, иҗат дәвам итә. Ләкин минем бер сүзне әйтәсем килә, үземнең каләмдәшләремә дә җиткерәсем килә. Язучы – бер чорның улы ул. Шул чорны чагылдыра, шул чор кешеләренең язмышларын тасвирлый. Үзе яшәгән чорның елъязмасын калдыра. Әйтик, егерменче гасырда формалашкан язучылар бүгенге яшьләр тормышын аңлый аламы? Аңласалар да, кабул итеп җиткерә алмый алар аны, бигрәк тә яза алмыйлар. Вакытында туктый да белергә кирәк. Ә менә үз чорыңны никадәр тулырак итеп биреп калдыра алсаң, шул кадәр язучы дигән исемгә лаек булып саналасың...

...Әхәт Гаффар үз чорын язды, шул чорның елъязмачысы иде. Әсәрләренең озын гомерле булуы, әле бүген дә яшьләр күңелен дулкынландыра алуы менә шуннан килә.

Әйдәгез, тыңлыйк: 2017 ел, 30 июль. «Кызыклы очрашулар кунакханәсе» сәхифәсендә Әхәт Гаффар белән әңгәмә. Тапшыруда күренекле язучыларның һәм әдәбият галимнәренең аның иҗатына кагылышлы фикерләре дә урын алган.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

## Ахун премиясе

35 ел буе «Казан утлары» журналында эшләү дәверендә ничә мең (бәлки миллион!) әсәр укыганмын икән? Кызганыч ки, санап бармаганмын... Ә күпме язучы белән аралашырга насыйп булды миңа! Һәрберсенең үз холкы, үз гадәте, кем әйтмешли, үз «тараканы»... Әсәрләре бездә басылганда, алар редакциягә еш сугыла, кайберләре хәтта корректураны да карап чыга иде. Билгеле инде, сүз иярә сүз чыга, чәй куела, өстәлдә кәнфит-прәннек пәйда була... Язучыларга безнең белән әңгәмә кору зерә файдалы, чөнки без аларның өр-яңа әсәрләрен иң беренче укыйбыз, алар үз әсәрләрен бездә «сынап карыйлар»... Халык авазы, ягъни мәсәлән. Фикеребезгә колак салып, роман-хикәяләренең кайбер җирләрен төзәткән кешеләр дә булмады түгел. Җыеп кына әйткәндә, бәлки без шул рәвешчә татар әдәбиятын үстерүгә шактый саллы өлеш керткәнбездер дә әле. Әмма күзгә күренми һәм матди яктан һич сизелми торган гамәл инде бу.

Шулай да, бар иде язучылар арасында шәп кешеләр. Менә Гариф абый Ахуновның әсәрләре басылганны аеруча көтеп ала идек. Ник дигәндә, ул язучылар арасында иң юмарт, иң ихлас кешеләрнең берсе. Бүлмәбезгә килеп керә дә: «Кызлар, ничек анда минем роман?» – дип көлә-шаярта башлый. Үзе белән бәйрәм ияртеп кергән шикелле була: тирә-юньдә бар нәрсә хәрәкәткә килә, күңелле ыгы-зыгы башлана... Эх! Эш белән бәйле мәсьәләләрне хәл итеп бетергәч, чәй табыны җәюләр, күңелләребезне ачып, рәхәтләнеп сөйләшеп утырулар...

Берзаман әсәре басылып чыга да, Гариф абый гонорарга килә. Бухгалтериягә кереп акчасын ала да, кояштай балкып, безнең бүлмә ишеген ача. Без бүлмәдә өч кыз эшли идек. Яшьлектәге якын хезмәттәшләрем: Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Бәйрәмова һәм мин.

Гариф абый, хәйләкәр елмаеп, сүз куша:

– Лилия, әйт әле син миңа шуны, җәйге күлмәкләрнең иң матуры күпме тора ул хәзер?

– Унбиш сумнар тирәсе бардыр, Гариф абый, – дим. – Ник сорыйсыз?

– Тә-ә-ә-әк, – дип суза ул. – Кызлар, бәгырькәйләрем, сез минем роман чыкканда бик тырышып эшләдегез. Хезмәтегез бик авыр, тавык та чүпләп бетермәслек вак эш. Сезгә хөрмәтем дә, рәхмәтем дә зур. Шуңа күрә сезнең өчегезгә дә Ахун премиясе бирергә карар иттем. Хәзер һәрберегез ялт кына кибеткә барасыз да иң матур күлмәкне алып киясез.

Һәм ул, торып баса да, кулларыбызны кысып, өчебезгә дә унбишәр сум акча тоттыра. Үзе шундый канәгать елмая! Безнең шатланганны күреп рәхәтләнә иде ул...

И-и-и-и сөенә идек шуңа! Яшь чаклар бит... Көн саен яңа күлмәк киясе килгән вакытларыбыз.

Бераздан Гариф абый янә яңа роман бастырырга килә. Килгән саен тәмле әйберләр кыстырып керә. Дүртәүләп чәй эчәбез, сөйләшәбез, көлешәбез... Гариф абый үз

тормышыннан кызык хәлләр сөйли. Һәм, гадәттәгечә, әсәр басылып чыккач, Гариф абый янә бухгалтериягә юнәлә... Ә без, ишектән күз алмыйча, аны көтеп торабыз. Ниһаять, ишек киерелеп ачыла да, авызы колакка җиткән Гариф абый күренә.

– Лили-и-я-я-я, – дип суза ул керә керешкә. – Сез аякка кия торган теге танкетка дигән нәрсәгез күпмерәк тора икән ул хәзер?

– Ун сумнар торадыр, Гариф абый, – дим.

– Язучылар союзында әллә кемнәр әллә нинди премияләр алып ята. Алсыннар әйдә! Ә менә Ахун премиясе бары тик сезгә генә бирелә, бәгырькәйләрем! Аңа бары сез генә лаек! Теге танкетка дигән әйберегезне алырсыз инде, яме? – ди. Һәм, ифрат мәмнүн булып, һәрберебезгә унар сум акча тапшыра...

Әйе, язучыларга премияләрне мулдан бирәләр, әллә ниндиләре бар. Әмма бездән башка берәүнең дә Ахун премиясен алганы юк һәм булмаячак та. Өч тапкыр Ахун премиясе лауреаты булуым белән горурланып, сөенеп, Гариф абыйны сагынып искә алам.

## Пенсия арттыру яки яңа роман кыйссасы

Рафис Корбан «Казан утлары» журналына эшкә килгәч, редакциядә инде утыз биш ел эшләүче Лилия Гатауллина белән бер бүлмәдә утыра башлый.

– Минем белән утырган егетләрнең берсе дә югалып калмады. Рөстәм бер ел узар-узмастан «Идел» журналына баш мөхәррир булып китте, Ләбибкә «Безнең мирас» журналына баш мөхәррир булу өчен минем белән тугыз ай утыру да җитте. Сине алда ниләр көтә икән, Рафис абый? – ди аңа бүлмәдәше.

Язучылар берлеге рәисе булып та эшләгән, Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире дә булып торган, гомумән, нинди генә җаваплы вазифалар башкармаган Рафис Корбан аның бу сүзләренә кул гына селти:

– Кирәкми бер вазифасы да. Күпме эшләп, әнә, күпме генә пенсиям чыкты, – ди.

Шулай да бу хикмәтле бүлмәдә утыру Рафис Корбанга да тәэсир итә: эшли башлавына озак та үтмәстән, ул яңа роман язып өлгертә. Анысы дөнья күргән арада яңасына тотына. Анысын да тәмамлагач, бер ай отпускка китеп, ял иткән арада тагын бер романга нокта куя. Иҗаты гөрләп торган Рафис Корбанга пенсиянең азлыгы гына һич тынгы бирми.

Үзенең дә пенсиясен арттыру турында уйланып йөргән тәҗрибәле бүлмәдәше аңа бер айга эштән китеп торырга киңәш итә. Каян белешкәндер, кемнән сорагандыр: имеш, бер ай эшләмичә торсаң, пенсия артачак икән. Рафис Корбан уйлаганын сузып йөрергә яратучылардан түгел: шул ук көнне гаризасын баш мөхәрриргә тотып керә. Бер айдан кабат күрешергә килешеп, җылы гына саубуллашалар. Тик Рафис Корбан, акчам артып килмәде дип, «пенсия ялын» тагын ярты айга суза. Аннары, кулын селтәп, эшкә чыга.

– Ну, уңышлы булдымы ялың? – дип сорый баш мөхәррир.

– Артмас микән дип көттем, артмады шул. Аның каравы бер роман яздым, – ди Корбан.

– Ай ярымдамы? – дип гаҗәпләнә редактор. – Яңа гына өч санда биреп бетердек бит әле романыңны. Тиз генә бастыра алмабыз инде монысын.

Эшкә чыгып, бер атна үтүгә Корбанның саклык банкы картасына пенсия акчасы килеп төшә. Унбер меңгә арткан! Бүлмәдәше өчен ихластан куанган Лилия Гатауллина баш мөхәррир бүлмәсенә очып керә:

– Мин дә бер айга ялга китәм, менә гаризам!

– Бер шарт белән генә, – ди баш мөхәррир, гаризага кул куя-куя, – пенсия арттыру ялында роман язмасаң гына җибәрәм!

**Лилия ГАТАУЛЛИНА**

## Уфа кучтәнәче

Рөстәм Галиуллин нәүбәттәге мәртәбә Башкортстанга сәфәргә кузгала. Бу юлы Уфаның үзенә. Аэропортта чакта аңа редакция кызлары шалтырата:

– Син барып җиттеңме әле?

– Юк, – ди баш мөхәррир. – Менә хәзер самолётка утырта башлыйлар.

– Монда сиңа курьер посылка китерде. Уфадан. Бер хатын-кыздан. Нишләтик?

– Берәр повесть-мазардыр инде ул...

– Юк, бик зур күренә. Ким дигәндә кучтәнәч-мазар яисә... Ачмыйча, бүлмәңә кертеп куйыйкмы?

Баш мөхәррир уйга кала. Нәрсә икән соң бу, чыннан да? Әгәр хәзер үк ачмасалар, үзе Казанга әйләнеп кайтканчы, бу «серле» посылканың әллә ниләргә әверелүе бар.

– Ачыгыз сез аны, – ди ул, ниһаять, тәвәккәлләп.

Телефон аша кызларның нәрсәдер кыштырдатканнары, кискәннәре, ертканнары ишетелеп тора.

– Ну, нәрсә? Траптан менеп барам, тизрәк әйтегез?

– Һәй... – Кызларның күңелсезләнеп әйткән сүзеннән шомланып, баш мөхәррир баскычтан менгәндә сөртенә. – Роман гына булып чыкты бит әле бу...

Кызларның кәефен кырганын аңласа да, ул, җиңел сулап, Уфага оча торган самолётка кереп китә.

## Өметле депутат

Ркаил Зәйдулланың депутатлыкка сайланып йөргән чаклары. Читтән караганда гына, дөньядагы иң рәхәт эш сыман күренә ул, болай... аның да үз мәшәкатьләре юк түгел. Шагыйрь исемлек буенча Түбән Кама районына беркетелгән, ул чорда аңа ике шәһәр арасын шактый узарга туры килә. Бу юлы аны Кама Аланы үзәк мәйданында халык алдында чыгыш ясарга чакыралар. Ләкин аңа кадәр бистәнең алты ишегалдында халык белән очрашып, «Безнең ишегалды» дигән программаны тәкъдим итүдә катнашырга кирәк икән. Кандидат беренче ишегалдына килә. Халык җыелган, зур схема эленгән, анда хисапсыз саннар, катлаулы сызымнар биешә... Төзелеш оешмасы җитәкчесе, аның урынбасарлары, прораблар схемага күрсәтә-күрсәтә сөйлиләр, парковка, тротуар, балалар мәйданчыкларының киләчәктә нинди булачагын аңлаталар. Беренче ишегалдында Ркаил Зәйдулла халык белән янәшә басып, дәшми генә тыңлый. Икенчесендә бер-ике җөмлә кыстырып куя. Өченчесендә теге төзүчеләр янына басып, чиратлашып сөйлиләр. Калган өч ишегалдында күрсәткеч таяк Ркаил Зәйдулла кулында гына була, схема белән ул таныштыра, халык сорауларына да ул гына җавап бирә. Алтынчы – соңгы ишегалдында сүз беткәч, таралышыр алдыннан бер рус агае алга чыгып баса да Ркаил Зәйдулланың җилкәсеннән кага-кага сөйли:

– Безнең районнан гомер-гомергә йә артистны, йә язучыны депутат итеп интектерделәр. Рәхмәт Хөкүмәткә, бу юлы, ниһаять, иң кирәкле кешене – төзүчене депутат итәргә булганнар! Сайлыйбыз сине, дускай!

**НАЛАСАЛЫ**

## Ничә юләр?

«Казан утлары» журналы редакциясе иң яхшы повестька конкурс ачып җибәрә. Конкурсның темасы – бүгенге заман кешесе.

– Әсәрләр килә башладымы? – дип сорый Вакыйф Нуриев проза бүлеге мөхәррире Камил Кәримовтан.

– Килә. Менә Зөлфәт Хәкимнән килде.

– Повесте ничек атала?
– «Юләр» дип атала. Тагын Батулладан килде.
– Аныкы ничек атала?
– Аныкы «Ике юләр».
Бераздан телефон шалтырый. Берәү Башкортстаннан шалтырата:
– Конкурска повесть яздым, – ди. – Юләрләр турында.
– Бездә бер юләрле, ике юләрле әсәрләр бар инде. Сезнекендә юләрләр саны өчтән дә ким булмасын! – диләр  егетләр.

## Зыялы егетләр

Марсель Гали белән Газинур Морат очраклы гына «Казан утлары» редакциясендә очрашкач, бу вакыйганы билгеләп үтәргә уйлыйлар. Чәркәләргә бүлгәч кенә, көтмәгәндә, бүлмәгә Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла белән журналның баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин килеп керә. Шактый ук каушый төшкән Газинур шунда чәркәсен китаплар артына яшереп:
– Ишекне шакып керергә кирәк иде, –  ди. –  Сез бит – зыялы егетләр.

**Вакыйф НУРИЕВ**

## Бүген безнең «өчесе»

Ярты гомере юлда үткән, СССРны аркылыга-буйга үткән Рәдиф Сәгъдине, еш кына газета-журнал җитәкчелеге: «Әйдә, бергәләп әйләнеп кайтыйк инде», – дип, иптәшкә чакыралар. Ярдәмчел егет, хәер, күптән егет түгел инде ул, каршы килми, чыга. Бер елны «Безнең мирас» журналының мөхәррире Ленар Гобәйдуллин белән сәфәргә чыгып китәләр. Пермь краеның Барда районына. Күрәсен күреп, эшлисе эшләрне эшләп бетергәч, тизрәк Казанга кайтып җитәр өчен иртәнге сәгать икедә үк олы юлга чыгалар. Ижау трассасына чыгар өчен 40 чакрым. Шунысын искәртергә кирәк, Ленар энекәш барган саен Бардада туганнарын таба тора, әле тагын булырга тиеш, ди.

...Иртә таңнан, әле җирле халык тирән йокыда вакытта ук кузгалып китәләр. Ленар хөрмәт йөзеннән: «Рәдиф абый, өч көн буена ялыккансыздыр инде, рульдә үзем кайтам, сез рәхәтләнеп ял итегез, йоклагыз!» – ди. Әлбәттә, өлкән яшьтәге юлдашы каршы килми, башын кресло күтәртмәсенә салып, йокыга да тала. Кемдер кинәт төртеп диярлек уята язучыны. Башын күтәреп күз салса, Ленар рульгә сыгылып төшеп йоклап киткән, машина аларга таба килгән, «КамАЗ»га каршы чаба. Рәдиф яшен тизлегендә рульне борып алып, икесен дә коткарып кала. Йөк машинасы йөртүчесенең өне киткән чырае гына чагылып кала. Ике-өч минут сүзсез утыргач, язучы телгә килә: «Утыр, салага, минем урынга!» – дип, Ленарны сүгә дә үзе тагын рульгә утыра.

Өч көннән соң Рәдиф Сәгъди редакциягә килеп керсә, Ленар бүлмәсендә берүзе.

«Рәдиф абый, бүген безнең җан тәслим кылуыбызның өченче көнен үткәргән булырлар иде», – ди Ленар, күрешергә кулын сузып. Тегесе кулын селтәп, кабинеттан чыгып китә.

**Рәдиф СӘГЪДИ**

# СКАНВОРД



Борынгы татар халык җыры

Язучы ... Сабирова

Казакъларда шагыйрь-импровизатор, җырчы

Укымышлы (иск.)

Рафаил Төхфәтуллин повесте

Язучы Атилла ...

Мәдинә Маликова романы

Актёр Камил ...

Җырлы-биюле балалар уены

Мәшһүр итальян композиторы

Татар яшьләре журналы

«Рәдде бичара кыз» драмасы авторы

Язучы Факил ...

Шекспир короле

... Коржавин (рус шагыйре)

Хәсән Туфан поэмасы

Борынгы Рим императоры

... Бәшири

Бәйлек

...-Сибиряк

... Шабаев

Башкортстанның халык шагыйре

Түбән Новгород өлкәсендәге шәһәр

Язучы ... Камалов

Санкт-Петербургта чыгучы әдәби журнал

Рәсүл Гамзатовның милләте

Эмиль Золя романы

Шәрык әдәбиятында шигырьләр җыентыгы

Татар телендәге беренче шәхси газета

Беренче совет автомобиле

Нәкый Исәнбәт туган авыл

кыса

Телеканал

Монгол игенчесе

... Гаетбаев

Томас ... Рид

Максим Горький романы

Немец физигы

Зәңгәр, шәмәхә



**Рәис ГАБДУЛЛА** *төзеде*

*Сканвордның җаваплары киләсе санда.*

## ӘЛМӘТТӘ ТАНТАНА

Әлмәт шәһәренең Яшьләр үзәгендә Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге оешуга 60 ел тулу уңаеннан «Әдәби Әлмәт» дип исемләнгән тантана булды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла шушы төбәктә яшәп иҗат итүчеләргә, шул исәптән Лилия һәм Резеда Фәхретдиноваларга – ТР Мәдәният министрлыгының «Мәдәнияттәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе, Фоат Садриев, Клара Булатова, Рәмзия Габделхаковага – Татарстан Язучылар берлегенең «Әдәбияттагы казанышлары өчен» медале, Дамир Гарифуллин, Мөҗәһит Әхмәтҗанов, Зинаида Захарова, Нәфисә Сабирҗанова, Резеда Шәриповага Рәхмәт хатлары тапшырды.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

Чаллыга татар әдәбияты көннәренә 15ләп язучы килде. Алар татар телен һәм әдәбиятын укытуга йөз тоткан гимназияләрдә, мәктәпләрдә укучылар белән очраштылар, түгәрәк өстәлләрдә катнаштылар. Чаллы татар дәүләт драма театрында Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Айгөл Әхмәтгалиеваның юбилей кичәсе узды. Әүвәл кунаклар һәм тамашачылар театр залында А.Әхмәтгалиеваның «Капка» хикәясе буенча куелган спектакльне карады. Аннары Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла юбилярны котлап, ТР Рәисе фәрманы белән Айгөл Әхмәтгалиевага «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» исеме бирелү шатлыгын уртаклашты. Ул аңа Татарстан Язучылар берлегенең «Әдәбияттагы казанышлары өчен» медален дә тапшырды. Бәйрәмдарны шулай ук Чаллы шәһәре башлыгының социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Рамил Хәлимов, Чаллы язучылар оешмасы җитәкчесе Факил Сафин, «Чаллы икмәге» җәмгыятенең генераль директоры Рафаэль Юнысов, Казаннан килгән язучылар, Камал, Тинчурин, Әлмәт, Оренбург театрлары вәкилләре, юбилярның якташлары – актанышлылар котлады. А.Карачурина, «Казан егетләре» чыгышы кичәгә ямь өстәде.

* * *

Зәй районында да татар әдәбияты көннәре булып узды. Бер көн Татарстанның халык шагыйре Мөдәррис Әгъләмов иҗатына багышланды. Чараларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, язучылар Равил Фәйзуллин, Марсель Галиев, Ләбиб Лерон, Факил Сафин, Әлфия Ситдыйкова, Лилия Гыйбадуллина, әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов, әдипнең хатыны, шагыйрә Нәҗибә Сафина катнашты. Кунаклар Мөдәррис Әгъләмов укыган Түбән Биш мәктәбендә, Ринат Фәрдиев исемендәге татар гимназиясендә укучылар белән очраштылар. Төп чара Сөббух Рәфыйков исемендәге Үзәк китапханәдә булды.

## РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВКА – 75 ЯШЬ

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында күренекле язучы, җәмәгать эшлеклесе, Мәскәүдә чыга торган «Татарский мир – Татар дөньясы» газетасының баш мөхәррире, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт, Төркия, Көньяк Америка һ.б. илләрнең әдәби премияләре лауреаты Ринат Мөхәммәдиевка 75 яшь тулуга багышланган «Сират күперләрен кичкәндә» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булды. Юбилярны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла котлады һәм аңа берлекнең «Әдәбияттагы казанышлары өчен» медален тапшырды. Якташларының котлавын Мамадыш районы мәдәният идарәсе җитәкчесе Степан Спиридонов ирештерде. Кичәдә Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының Россиядәге тулы вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшинның котлау телеграммасын укыдылар. Кичәне әдәбият галиме Әлфәт Закирҗановның әдипнең иҗаты турында этрафлы чыгышы дәвам итте. Театр сәхнәсендә Р.Мөхәммәдиевның «Сират күпере», «Кенәри – читлек кошы», «Тәмле прәнник» һ.б. әсәрләреннән аерым эпизодлар күрсәттеләр, өзекләр укыдылар. Аларны К.Тинчурин театры артистлары башкарды. Георгий Ибушев, Рәсим Низамов, Рөстәм Насыйбуллин, Вәис Бәйрәмов, Хәбир Ибраһимов юбилярны җырлары белән котладылар. Кичәне Гүзәл Зыятдинова белән Артём Пискунов алып барды.

## ИСКӘ АЛУЛАР

КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында язучылар Аяз Гыйләҗев белән Арпад Галгоцига багышланган кичә булды. Анда Венгриянең Казандагы баш консулы Сергей Сюч, институт директоры Рәдиф Җамалетдинов, ТР Мәдәният министрлыгының бүлек мөдире Айрат Фәйзрахманов,

А.Галгоциның хатыны Каталин Галгоци, галимнәр Хатыйп Миңнегулов, Фоат Галимуллин, Әлфәт Закирҗанов, Флёра Сәйфуллина, Искәндәр Гыйләҗев (А.Гыйләҗевның улы) һ.б. чыгыш ясады. Кичәне КФУ доценты, әдәбият галиме Миләүшә Хәбетдинова алып барды.

* * *

Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиевның тууына 95 ел тулуны туган ягы Апас районында зурлап билгеләп үттеләр. Бирегә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла җитәкчелегендә зур делегация килде. Кунаклар арасында шагыйрьнең улы Җәмил белән кызы Алсу да бар иде. Чара Олы Бакырчы авылындагы Ш.Галиевның музей-йортында башланды, мәдәният йортында дәвам итте. Район башлыгы Айрат Җиһаншин тәкъдиме белән Апасның яңа урамына Шәүкәт Галиев исеме бирелде.

* * *

Уфада Зәки Вәлиди исемендәге Милли китапханәдә Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллинны искә алдылар. Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Айгиз Баймөхәммәтов үз чыгышында Р.Миңнуллинның иҗаты ике тугандаш республиканың дуслык күпере булып торуын әйтте. Чарада Казаннан кунаклар – Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин, язучылар Рафис Корбан, Галимҗан Гыйльманов катнашты.

## КОТЛЫЙБЫЗ СЕЗНЕ, ҖИҢҮЧЕЛӘР!

«ТАТМЕДИА»ның конференцияләр залында 2023 – Россиядә укытучылар һәм остазлар елы уңаеннан «Казан утлары» журналында барган, ТР Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән каләм ияләре һәм мәктәп укучылары арасында оештырылган «Сез иң гүзәл кеше икәнсез!» дип аталган ачык әдәби конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы булып узды. Аны Тинчурин театры артисты Резеда Сәлахова алып барды. Тантанада «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков соңгы елларда үзләренең коллективы тарафыннан Телләр комиссиясе ярдәме белән гамәлгә ашырылган проектлар турында сөйләде. ТР каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды башкарма директоры Нурия Һашимова «Казан утлары» журналы редакциясе мөхәррире Лилия Гатауллинаны – 60, байтак еллар шушында эшләгән язучы, юмор остасы, автор-башкаручы Алмаз Хәмзинны 75 яшьлек юбилейлары белән котлады. ТР массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен «Казан утлары»ның бүлек мөхәррире Гөлия Сәлаховага – Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының Рәхмәт хаты, 100 еллык тарихы булган журналны цифрлаштыруга, сайтын үстерүгә зур өлеш кертүләре өчен редакция хезмәткәрләре Алинә Хәбибуллинага, Ләйсән Зариповага «Татмедиа» АҖнең Мактау кәгазьләре тапшырылды. ТР Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар комитеты рәисе урынбасары Камил Нугаев бүгенге тантанага нисбәтле сөенечле уй-фикерләре белән уртаклашты. Аннары конкурска йомгак ясалды. «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин бәйгенең максатлары, бурычлары, нәтиҗәләре, географиясе (быел да Төркиядән, Сүриядән әсәрләр килгән) турында чыгыш ясады. Җиңүчеләргә дипломнарны ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов тапшырды. Менә алар – җиңүчеләр:

**Повесть номинациясе**

I урын – **Әлфирә Галиева** ( «Сары атым алтын нукталы»); II урын – **Асия Юнысова** («Сылукай»); III урын – **Гөлинә Гыймадова** («Усал»). Кызыксындыру бүләге – **Нурания Гыйльметдинова** («Мөнбәрле мөгаллим»), **Гөлназ Нуриева** («Бәзәкә тавы»), **Сания Әхмәтҗанова** («Чын кешеләр»).

**Хикәя номинациясе**

I урын – **Ркаил Зәйдулла** («Кани калды Нишапур»); II урын – **Гөлүсә Батталова** («Чыра»); III урын – **Әнисә Зәйнуллина** («Очрашу»). Кызыксындыру бүләге – **Алия Мөбарәкшина** («Таң сызылганда»), **Айзилә Сабирова** («Минем яраткан усал укытучым»), **Наил Шәрифуллин** («Шагалиев шәүләсе»).

**Шигърият номинациясе**
**(мәктәп укучылары өчен)**

I урын – **Назлыгөл Гайнетдинова**, Теләче, Баландыш; II урын – **Рәдиф Миңнеханов,** Мамадыш, Усали; III урын – **Әмир Фәрхуллин**, Мамадыш, Җәнлек совхозы. Кызыксындыру бүләге – **Аяз Батталов** (Әтнә, Күәм), **Камилә Демидова** (Чаллы, 37 нче мәктәп), **Раил Мәрданов** (Балтач, Норма).

## «ИДЕЛЕМ АКЧАРЛАГЫ»

«Иделем акчарлагы» яшь язучылар бәйгесенең җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы булып узды. Быел бәйгедә 68 кеше катнашты. Гран-прига Балтач районыннан Гөлзилә Фәхретдинова лаек булды.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Р.ШАЙДУЛЛИНОЙ-МУРАТ «На вершине горы обитает волк», рассказ Г.БАТТАЛ «Лучина», мемуары А.ХАЛИМА «Папа, мама, сколько мне лет?»; стихи Ф.САФИНА, М.МИРЗЫ, О.ИЛЬЮП.*
*«Новые имена»: стихи Г.ШАРИПОВОЙ с предисловием Р.ГАТАША;*
*рассказ А.САБИТОВОЙ «1:1».*
*«Литературные объединения» стихи: Р.ИСМАГИЛОВА, А.ЗАЙНИ, Н.СИБАГАТУЛЛИНА, А.СУЛТАНОВА, З.ЗАРИПОВОЙ, З.СИРАЕВОЙ, С.ЗИГАНШИНОЙ, Г.ГАЛЛЯМОВОЙ, Р.АХМАДИЕВА, Г.САВГАНОВОЙ, Г.ШАРИПОВОЙ, Р.САФИНА, Р.РАХИМЗЯНОВА, Р.КАРИМОВА с предисловием М.АХМЕТШИНОЙ.*
*«Наука»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.*
*«Искусство»: статья Г.АРСЛАНОВА, посвящённая 130-летию Х.Уразикова.*
*«Юбилеи»: статья Г.НУРИЕВОЙ.*
*Из фотоархива журнала «Казан утлары».*
*«Памятные письма»: письма И.Даби, Р.Валиева, К.Булатовой, Ф.Сафиуллиной М.Галееву.*
*«Бесценные голоса»: статьи к 110-летию Ф. Яруллина и 75-летию А. Гаффара.*
*Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*«Страница сатиры и юмора»: миниатюры.*
*Сканворд. Составил Раис ГАБДУЛЛА.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На нашей обложке: зима на ул. Федосеевской г.Казани. Фото И.АБРАМОВОЙ.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by R.SHAYDULLINA-MURAT «A wolf abides on the top of the mountain», story by G.BATTAL «Wicker lamp», memoirs by A.KHALIM «Dad, Mom, How Old Am I?»; poems by F.SAFINA, M.MIRZA, O.ILYUP.*
*«New names»: poems by G. SHARIPOVA with a foreword by R.GATASH;*
*story by A.SABITOVA «1:1».*
*«Literary associations» poems by: R.ISMAGILOV, A.ZAINI, N.SIBAGATULLIN, A.SULTANOV, Z.ZARIPOVA, Z.SIRAEVA, S.ZIGANSHINA, G.GALLYAMOVA, R.AKHMADIEV, G.SAVGANOVA, G.SHARIPOVA, R.SAFIN, R.RAKHIMZYANOV, R.KARIMOV with a foreword by M.AKHMETSHINA.*
*«Science»: article by D.ZAGIDULLINA.*
*«Art»: article by G.ARSLANOV dedicated to the 130th anniversary of Kh.Urazikov.*
*«Anniversaries»: article by G.NURIEVA.*
*From the photo archive of the magazine «Kazan Utlary».*
*«Memorable letters»: letters from I.Dabi, R.Valiev, K.Bulatova, F.Safiullina to M.Galeev.*
*«Priceless voices»: articles for the 110th anniversary of F.Yarullin and the 75th anniversary of A.Gaffar. The column is led by N.AKMAL.*
*«Page of satire and humor»: miniatures.*
*Crossword puzzle. Built by Rais GABDULLA.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our cover: winter on the st.Fedoseevskaya, Kazan. Photo by I.ABRAMOVA.*

---

*Тышлыкның беренче битендә:* Казанның Федосеев урамы.
*И.АБРАМОВА фотосы.*